Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан

Казан • Казань
2024

**Духовное наследие**
Поиски и открытия
*Выпуск 22*

**Габдрахман Сагди**

# ИЗБРАННЫЕ СОЧИНЕНИЯ

Том 1

**Рухи мирас**

Эзләнүләр һәм табышлар

*22 нче чыгарылыш*

**Габдрахман Сәгъди**

# САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

1 нче том

УДК 94 (093)
ББК 63.2
С 93

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

Проект «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау»
ТР Дәүләт программасы кысаларында ТР Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Язма мирас үзәге тарафыннан гамәлгә ашырыла

**Редколлегия:**
***И.Г. Гомәров** (проект җитәкчесе),*
***Д.Ф. Заһидуллина, А.М. Ахунов***

**Фәнни редактор**
*филология фәннәре кандидаты **И.Г. Гомәров***

**Рецензентлар:**
*филология фәннәре докторы **Ф.Ф. Гыйлемшин,***
*филология фәннәре кандидаты **Э.М. Галимҗанова***

**С 93** **Сәгъди Г. Сайланма әсәрләр.** Т. 1 / Г. Сәгъди; төз., текст. иск. һәм аңл. әзерл.: Л.Ш. Гарипова, И.Г. Гомәров, Л.Р. Надыршина, Г.М. Ханнанова, А.Н. Хәсәнова; кереш сүз авт. Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2024. – 256 б. («Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар = Духовное наследие: поиски и открытия» сериясе. 22 нче чыгарылыш).
ISBN 978-5-93091-494-8

Җыентык халкыбыз рухи мирасының нигезен тәшкил иткән әсәрләрне, татар текстларын өйрәнү, аз билгеле язма чыганакларны бастырып чыгару өлкәсендәге яңа табышлар белән укучыларны таныштыру традициясен дәвам итә.

Чираттагы чыгарылыш тел һәм әдәбият галиме, мәгариф эшлеклесе, педагог Габдрахман Сәгъдинең (1889–1956) гыйльми эшчәнлегенә багышлана. Китапта аның 1912–1932 елларда матбугат битләрендә, аерым җыентыкларда дөнья күргән фәнни мәкаләләре, язмалары урын ала. Әлеге текстларның күпчелеге гамәлдәге хәрефләр белән беренче тапкыр басыла. Басма белгечләр, татар тарихы һәм мәдәнияте белән кызыксынучы киң катлау укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-93091-494-8 (1 т.)
SBN 978-5-93091-495-5

© ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2024

# ГАБДРАХМАН СӘГЪДИ ҺӘМ АНЫҢ ХЕЗМӘТЛӘРЕ

Татар тарихында, мәдәниятендә XX гасыр башы феномены «алтын чор», «тизләнеп үсү дәвере», «яңарыш вакыты» буларак бәяләнеп, игътибарны үзенә җәлеп итеп, сокландырып тора. Бу күренешнең күпсанлы сәбәпләре арасында иң мөһиме мәйданга көчле-куәтле бер ташкын кебек килеп кергән яшьләр – шәхесләр белән бәйле. XX гасыр башы татар җәмгыяте үз милләтен яңа үрләргә күтәрергә омтылган, белемле, еш кына университетларда укуын дәвам иттерүче, рус һәм чит телләрне белгән, дөньякүләм социомәдәни яңалыкларга сизгер яшьләр үстереп җиткерә. Сәясәтчеләрне, галимнәрне, журналистларны, язучыларны берләштергән әлеге буын дисбесендә Габдрахман Сәгъди дигән асылташ та бар. «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең 22, 23, 24 нче чыгарылышлары Г. Сәгъдинең «Татар әдәбияты тарихы» (1926), «Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре» (1926), «Символизм турында» (1932) хезмәтләрен, аерым мәкаләләрен туплап нәшер ителә. Алар галим мирасының бер өлешен күзалларга мөмкинлек бирер дип исәплибез.

Габдрахман Гайнан улы Сәгъдиев 1889 елның 27 (14) мартында элеккеге Уфа губернасы Златоуст өязе Морзалар волосте (хәзерге Башкортстан Республикасы Салават районы) Таймый авылында (элеккеге атамасы – Атау, ягъни утрау, башкорт авыллары арасында утрау рәвешендә урнашкан татар авылы) рухани гаиләсендә туа. Уфада яшәүче туганнары Роберт Гайсә улы төзегән шәҗәрәдән күренгәнчә, Сәгъдиләр нәселе бик борынгы, Габдрахманның бабалары, агалары – указлы муллалар, хаҗилар укымышлылар (Алкай (169?–?) бине Мәкъсүт (1735–1815) бине Сәгъди (1769–1842) бине Ульдан (1806–?) бине Гайнан (1850–1902) бине Габдрахман (1889–1956)). Г. Сәгъдинең әтисе – шулай ук указлы мулла, хаҗи, мәдрәсә, китапханә тоткан мөдәррис-мөгаллим була. Габдрахманның Гафур (1880–?), Һади (1883–1933), Шәех (1885–1944) исемле бертуган абыйлары да – үз заманының зыялылары[1].

[1] Кара: *Гыйлаҗева Ч.* Тормыш һәм иҗат баскычлары // Габдрахман Сәгъди: фәнни-биографик җыентык / төз. Д. Заһидуллина, Ч. Гыйлаҗева. Казан: Җыен, 2008. Б. 19–51.

Гайнан хаҗи төпчек улы Габдрахманны төп йортта калдырырга исәпли, шуңа да укудан тыя. Бу каршылык сәбәбеннән, 12 яшеннән малай үз тормышын үзе корырга мәҗбүр була. 1902 елда ул Троицк шәһәрендәге «Рәсүлия» мәдрәсәсенә килеп урнаша, гарәп, төрек, фарсы телләрен, мәдәниятен өйрәнә. Мондагы укытуның канәгатьләнерлек түгеллеген аңлап, дөньяви белем алырга омтыла, Европа әдәбиятына якыная, аңарда рус теле һәм әдәбиятын өйрәнү теләге уяна: үзлегеннән һәм укытучы яллап, шушы дәрьяга чума. Рус уку йортларына керү юлы ябык булганга, белемен дәвам итү өчен, Төркиягә юл тота, 1908–1911 елларда Истанбулдагы Дәүләт университетының филология факультетында «төрки әдәбиятлар тарихы» белгечлеге буенча югары филологик белем ала.

Илгә кайтуга, Габдрахман үзенең белемен һәм акылын милли мәйданда барган үзгәрешләргә хезмәткә куя. 1911–1913 елларда ул Актүбәдә, 1913–1914 елларда Казакъстанның элеккеге Верный (Алматы) мәктәпләрендә эшли, мөдирлек вазифасын башкара. Аннан бер ел Екатеринбургта, бер ел Ыргыз шәһәрендә мөгаллимлек итеп (күченеп йөрүе җәдиди карашлары сәбәпле җирле муллалар белән каршылыкка кереп, полиция күзәтүенә эләгүдән була), моннан туган ягына кайта, 1916–1917 елларда шушында балалар укыта. Февраль революциясе чорында Златоуст өязе Морзалар волостенда Ревком рәисе вазифасын башкара, 3 айлык татар-башкорт педагогия курсларында татар теле һәм әдәбиятыннан дәресләр алып бару өчен Бөгелмәгә чакырыла.

Үзе дә укытучы булган Г. Сәгъди XX гасыр башы вакытлы матбугатында милли яңарыш, бигрәк тә мәктәп-мәдрәсәләрне үзгәртү мәсьәләләрен күтәрә. Бу чорда ул шагыйрь дә булып таныла: «Шура» журналында шигырьләрен бастыра.

«Әдәбиятыбызны мәдрәсәләрдә укыту» (1910) дигән мәкаләсендә татар телен һәм әдәбиятын кичекмәстән милли уку йортларына кертү, моның әһәмияте хакында сүз алып барып, мөгаллим Г. Сәгъди тел һәм әдәбиятны бәйләнештә, бер агым итеп укыту, имла, сарыф, нәхү, әдәбият кануннары һәм тарихы кебек предметларны расписаниегә урнаштыру мөмкинлекләрен барлый. Язманың 1911 елны дөнья күргән дәвамында Г. Сәгъди гарәп фәннәренең үрнәк була алмавын, татар тел белеме, әдәбият тарихы һәм теориясен

үзебез өчен, үзебезнең җирлеккә, тел һәм әдәбиятка нигезләнеп язу кирәклеген искәртеп үтә.

Беренче китапка кергән «Тел вә әдәбият мәсьәләсендә файдалы агым» (1912) мәкаләсе шушы фикерләргә каршы төшүчеләргә, аеруча Хәлил Әбелханов «Шура» журналындагы (1912, № 11–12) язмасына җавап итеп бирелгән. Х. Әбелханов болай дип язган була: «...сарыф вә нәхү, әдәбият кагыйдәләренең чын әдәбиятка мөнәсәбәте юк, алар әдәбиятка карашны агулый, боза гына», «кагыйдәләр әдәбият белән арадашсыз танышудан килә торган ләззәттән укучыны мәхрүм итәләр». Аңа кайнарланып каршы төшкән Г. Сәгъди фикеренчә, татар телен тирәнтен өйрәнү әдәбиятны аңлауга комачауламый, бәлки ярдәм итә. Бу яктан Г. Сәгъди Ф. Әмирханнар, Г. Тукайлар, Г. Ибраһимовлар белән бер юнәлештә, фикердәш буларак чыгыш ясый. Шушы чордагы күп кенә әдәбиятчы яшьләр кебек үк, хәтта телнең аерым бүлекләре (морфология, синтаксис) буенча мәктәп-мәдрәсә дәреслекләре дә яза.

Җәдит мәктәп-мәдрәсәләр ачылу милли тел-әдәбиятка, әдәбият кануннары һәм кагыйдәләренә игътибарны үстерә. Яңа укыту программалары, Г. Сәгъди әйткәнчә, тел-әдәбият фәннәренә төзек система, бердәм агым итеп карый һәм әдәбият кануннарын шул тәртипнең бер мөһим баскычы рәвешендә күзаллый. Нәкъ менә яңа агым әдәбият теориясеннән китаплар язылуга сәбәп була: бу эшне Г. Сәгъди башлап җибәрә. Беренче дәреслекләр нәзари фикергә караган мәгълүматларны тәртипкә сала, кагыйдәләр эшли, шуларның дөреслеген әдәби материалларда исбат итә. Бер сүз белән әйткәндә, яшь Сәгъди әдәбият теориясенең тулы канлы фән юнәлеше булып формалашуының башында тора. Бу юнәлештә ул Г. Баттал, Н. Хәлфин, Җ. Вәлиди, Г. Ибраһимов, Х. Кәримов, Гата Исхакый, Җәгъфәр һ. б. әдәбиятчылар белән иңгә-иң торып, бәхәсләшеп эшли. Шул ук вакытта беренче нәзария дәреслекләрендә татар әдәбияты тарихчысы һәм тәнкыйтьче буларак та чыгыш ясый.

Октябрь инкыйлабыннан соң да Г. Сәгъди мәгариф мәсьәләләреннән читләшми[1]. Авторның «Икенче баскыч совет мәктәпләрендә

[1] *Заһидуллина Д.* Мөгаллим һәм методист-галим // Габдрахман Сәгъди: фәнни-биографик җыентык / төз.: Д. Заһидуллина, Ч. Гыйлаҗева. Казан: Җыен, 2008. Б. 342–348.

әдәбият һәм аны укыту методлары» (1927) мәкаләсе аның әлеге предметка гаять зур әһәмият бирүе турында сөйли.

Хәер, бу мәкалә язылганчы, Г. Сәгъди тормышында зур үзгәрешләр була. Ул каты авырып китә, үпкә туберкулёзы диагнозы белән Кавказның «Тимерхан шура» шифа үзәгендә дәвалана. Кайту юлында Бакуда туктап, кыска вакытлы педагогик курсларда лекцияләр укый. Көзен Төркестан республикасының Мәгариф халык комиссариаты аны Ташкентка укытучылык эшенә чакырып ала. Шулай итеп, авыруы аның бу тәкъдимне кабул итүенә, Урта Азиягә китүенә сәбәп була. 1921–1925 елларда Г. Сәгъди үзбәк ирләр һәм хатын-кызлар мәгариф институтларында, рабфакларда, Ленин исемендәге хәрби мәктәптә үзбәк классик әдәбиятыннан, Төрки-татар мәгариф институтында татар әдәбияты, педагогика, тел һәм әдәбият укыту методикаларыннан лекцияләр укый. 1922 елда Ташкентның Көнчыгыш институтындагы төрки филология (тюркология) кафедрасына үзбәк әдәбиятыннан укытучы итеп сайлана. Г. Сәгъди бу елларда Урта Азия югары уку йортлары өчен күпсанлы дәреслекләр яза, үзбәк, казакъ, төрекмән телләрендә чыга торган газета-журналларда языша. Татар әдәбияты буенча эзләнүләрен туктатмый.

1925 елның көзендә Татарстан халык мәгариф комиссариаты, Г. Ибраһимов тәкъдиме белән, Г. Сәгъдине Казанга чакырта. Биредә ул 1930 елга кадәр Татар Коммунистлар университетында, педагогия техникумында татар әдәбияты тарихын укыта, 1926 елны Казан Көнчыгыш педагогия институтына доцент булып сайлана. Анда татар теле һәм әдәбияты кафедрасын, шулай ук әдәбият кабинеты эшен оештырып җибәрә.

Казанда Г. Сәгъди утызлап гыйльми хезмәт яза. Алар арасында иң күләмлеләре – «Татар әдәбияты тарихы» (1926), «Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре» (1926), «Татар театр әдәбияты һәм аның үсү тарихы» (1926). «Символизм турында» (1932) китабы да 1929 елда төгәлләнә. Болар барысы да «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең 22, 23, 24 нче чыгарылышларында урын алды.

Бер үк вакытта Г. Сәгъди аерым язучы-шагыйрьләрнең иҗатын монографик өйрәнү белән дә шөгыльләнә. «Татар шагыйрьләре арасында Тукай» (1923) язмасында ул Г. Тукай иҗатын халык тормышында биләгән гаять мөһим урыныннан чыгып бәяләү

омтылышы ясый, аның әсәрләрендә күренгән идея-эстетик үзенчәлекләрне барлый. 1926 елның мартында вафат булган Ф. Әмирханга багышлап язган «Фатих Әмирхан» (1926), «Татар пролетариатының беренче әдибе Гафур Коләхмәтов» (1927), «Кандалый турында» (1927) язмалары тирән эчтәлекле һәм нечкә зәвыклы, эстетик якка игътибарлы булулары белән аерылып торалар.

Г. Сәгъди борынгы татар әдәбияты тарихын өйрәнүгә дә өлеш кертә: XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый әсәрләрен беренчеләрдән булып укучыга тәкъдим итә. Галимнең әлеге тикшеренүләре «Беренче дәвер татар әдәбиятыннан яңа материаллар» исемендә 1927 елда басылып чыга.

Г. Сәгъдинең бу чорда язылган хезмәтләренең 1917 елга кадәр башланган тикшеренүләрнең дәвамы булуы күзгә ташлана. Әмма 1920–1930 еллар гыйльми мирасы хакында сүз алып барганда, Г. Сәгъдине иң беренче чиратта татар әдәбияты тарихын язучы, аны фән буларак мәйданга чыгаручы дип бәяләргә кирәк. Галимнең 1926 елда дөнья күргән «Татар әдәбияты тарихы» китабы милли әдәби барышка тәртипле, системалы бәя бирә һәм XX гасыр дәвамында татар әдәбиятының өйрәнелешенә юл күрсәтә, маяк хезмәтен үти торган басма булып кала.

Хезмәт, әдәбият тарихы гына түгел, татар мәдәнияте тарихы кебек, гаять киң колачлы итеп уйланыла. Әлеге китапта XIX гасырның соңгы чиреге, XX гасыр башы татар мәгърифәтчеләре һәм фикер ияләренең, язучылары һәм публицистларының – К. Насыйри, Р. Фәхретдинов, Ф. Кәрими, С. Максуди, З. Һади, Г. Камал, Г. Исхакый, Г. Тукай, М. Гафури, Дәрдмәнд, С. Рәмиев, Н. Думави, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, М. Фәйзи, Ф. Бурнаш һәм тагын бик күп, хәтта каләм сынау баскычындагы сәнгать әһелләренең тормышы, иҗат биографияләре, иҗат эшчәнлеге һәм иң күренекле әсәрләренә анализлар урын алган. Автор әдәби материалны иҗтимагый-мәдәни контекстта тикшереп бара, үзен югары тоемлы филолог итеп таныта. Әдипләр, хәтта яшь язучылар иҗатындагы бер генә яңа күренеш, бер генә үзгәлек тә аның игътибарыннан читтә калмый.

Ни өчен Г. Сәгъди татар әдәбияты тарихын тикшерүгә кереп китә соң? Моның сәбәпләре күп, алар арасында галимнең махсус заказ башкаруы да билгеле. Ләкин бу эшкә алынуның шәхси

сәбәпләре дә булгандыр. Чөнки татар әдәбияты тарихын тикшерү XX гасыр башында гомуми милли күтәрелешнең аерылгысыз өлеше кебек кабул ителә. Вакытлы матбугат битләрендә әдәбият тарихына караган язмалар белән күренекле шәхесләр: Җ. Вәлиди, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, Р. Фәхреддинов, Ф. Кәрими һ. б. даими рәвештә чыгыш ясыйлар. Матбугатта исә һәрдаим мәктәп-мәдрәсәләр өчен кулай әдәбият тарихы дәреслеге язу хакында сүз бара.

Бу өлкәдә беренче зур уңыш, нәтиҗә булып 1922–1925 елларда өлешләп дөнья күрә килгән, Гали Рәхим һәм Газиз Гобәйдуллин каләме белән язылган «Татар әдәбияты тарихы» тора. Анда борынгы төрки язмачылыктан алып XIX гасырның беренче яртысына кадәр билгеле булган язма истәлекләр, аларның тарихи язмышы өйрәнелә. Хезмәт гаять күп материалларны берләштереп, барлык төрки халыкларның язма мәдәниятенә күзәтү ясый һәм, әдәбият тарихы белән чикләнмичә, мәдәният тарихы дәрәҗәсенә күтәрелә. Г. Сәгъди язган «Татар әдәбияты тарихы» исә XIX–XX гасырның 20 нче елларын колачлый. Ул хронологик яктан Г. Рәхим һәм Г. Гобәйдуллиннар хезмәтен «дәвам итә», эчтәлеге буенча татар әдәбиятындагы юнәлеш һәм агымнарны да, зур әдипләрнең иҗатын да, яшьләр әсәрләрен дә, татар әдәбиятындагы традицияләр һәм яңачалыкны да күз уңында тота. Татар әдәбиятын Яңа заманнан башлап дәверләргә бүлеп өйрәнү омтылышы да башлап шушы хезмәт эчендә башкарыла. Бигрәк тә «Фикри хәрәкәттә Курсавиның эшләре», «Татар әдәби теленең гыйльми-нәзари эшләнүе юлында Каюм Насыйри», «Матур әдәбиятта аурупалашу», «Татарда беренче роман» кебек бүлекләр XIX гасыр әдәбиятын, иҗтимагый аңын, фәлсәфәсен ныклы фәнни нигезләрдә аңлаткан беренче мөстәкыйль фәнни хезмәтләр булалар. Татар пролетариат әдәбиятына, Г. Коләхмәтов, Г. Исхакый, Г. Ибраһимов кебек язучылар иҗатына автор комплекслы, тирән анализ ясый. Аның яшь язучылар иҗатына күзәтүләре, әдәби хәрәкәттәге яңа агымнарны барлавы, татар прозасы, поэзиясе, драматургия үсешенә бәяләмәләре бүген дә актуальлеген югалтмавы белән гаҗәпләндерә.

Галимнең «Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре» китабы, үзе аңлатуынча, башта «Татар әдәбияты тарихы»ның бер бүлеге рәвешендә язылып, соңыннан аерым моно-

графия итеп эшләнә. Анда тел, халык әдәбияты һәм әлифбалар барлыкка килү тарихлары эзлекле күзәтелә, аларның тууын һәм үсешен галим рус, Көнбатыш Европа һәм Шәрыкта билгеле тәгълиматларга таянып аңлата, төрки халыкларның, татар халкының бик тирән тамырлы бай матди һәм рухи мәдәнияткә ия булганлыкларын дәлилли. Телләрнең генә түгел, аерым татар сүзләренең килеп чыгышын, генезисын һәм этимологиясен билгеләү белән дә мавыгып ала.

Татар теле һәм әдәбияты тарихының чишмә башын Г. Сәгъди VI–IX гасырларга илтеп тоташтыра, рун язуындагы борынгы төрки язма истәлекләрдән башлый. Ул тел, әдәбият һәм фольклор күренешләрен бер үремтәдә карарга омтыла, бер үк вакытта татар мәдәниятен киң төрки контекстта күзәтә. Әйтик, татар җырлары турында сүз барганда, ислам дөньясындагы һәм кардәш халыклардагы халык җырларының үзенчәлекләренә туктала, аларны үз халкы җырлары белән чагыштыра.

Китапның методологик нигезләре җитди булуын аерып билгеләргә кирәк. Г. Сәгъди Көнчыгышны өйрәнүче рус галимнәре карашларына да, төрки акыл ияләренең хезмәтләренә дә бердәй җиңел мөрәҗәгать итә. Кешелек дөньясында борынгы заманнарның мәдәни байлыкларын килер буыннарга тапшырып баруда Г. Сәгъди телне иң кыйммәтле чара дип саный, язуның җәмгыятьтә фикер үзгәрешенә, үсешенә киң юл ачуын билгели. Шуның белән бергә, әдәбият үсешендә дә иҗтимагый барышның, сәяси-тарихи вакыйгаларның зур роль уйнавына игътибар итә. Нәтиҗәдә галим әдәбиятны «иҗтимагый табигатьле сәнгать күренеше» дип карауга килә, тарихилык принцибын калкуландыра. Аның әдәбиятны җәмгыять белеме белән бәйләп тикшерү концепциясе чор таләпләренә җавап бирә, билгеле. Әмма аерым өлешләрдә социологик анализ белән мавыгу да үзен тискәре яктан сиздерә. Аныңча, иҗтимагый-тарихи методка эстетик, психологик анализ табигый килеп кушыла, өстәлә ала.

Г. Газиз, Г. Гобәйдуллин, Г. Сәгъди хезмәтләре татар әдәбияты тарихы дигән фәнне формалаштыра. Бер үк вакытта алар чикләрендә татар тарихы, этнографиясе, культурология кебек фәннәргә сукмак салына. Шулай итеп, татар әдәбияты тарихын язу татар милләте хакындагы мөстәкыйль фәннәр барлыкка китерүнең аерылгысыз өлеше булып чыга. Күрәсең, шуны алдан фаразлау – чорның иң

күренекле галимнәрен әлеге хөрмәткә лаек эшкә җәлеп иткән сәбәпләрнең дә берседер.

Г. Сәгъдинең 1932 елда басылып чыккан «Символизм турында» китабы галимнең әдәбият тарихын синхрон (мәдәният тибы, әдәби юнәлеш, әдәби агым, стиль) яссылыкта, теоретик позициядән торып анализлау баскычына күтәрелүе хакында сөйли. Галим, Шәрык әдәбиятының стильләр-өслүбләр үзгәрешен күздән кичереп, бөтен Көнчыгыш һәм татар әдәбиятын бәйләнештәге система итеп карарга омтыла һәм төрки әдәбиятлардагы стильләр тарихына типология тәкъдим итә. Ул һәр стильгә хас үзенчәлекләрне билгели, әдәби материалда дәлилли. Аерым алганда, шәркый суфи әдәбият һәм модернизм, символизм агымнары арасындагы бәйләнешләргә кагылышлы күзәтүләре бик тә кызыклы. Дәвер өслүбен иҗтимагый формация белән бәйле караса да, автор аның аерым әдәбиятларда милли, талант иясе алып килгән хосусый үзенчәлекләр белән баетылуын искәртә. Г. Сәгъди стиль элементлары буларак образ, пейзаж, интонация һәм, иң мөһиме, автор мөнәсәбәте, кичереше кебек төшенчәләргә мөрәҗәгать итә, бүгенге фән эзләнүләр алып бара торган язучы өслүбе механизмына якынлаша.

1929 елда Г. Сәгъдине Көнчыгыш педагогия институтына әдәбият методикасыннан профессор итеп сайлыйлар. Бер үк вакытта Казанда аны совет идеологиясеннән тайпылуда гаепләгән язмалар дөнья күрә. Күрәсең, мондый катлаулы мохиттә яшәргә теләмичә, 1930 елның башында Г. Сәгъди кабат Урта Азиягә китеп бара һәм Сәмәрканд Педагогия академиясендә эшли башлый, үзбәк әдәбияты кафедрасы оештыру, тел һәм әдәбият бүлеге ачу эшләрен башлап йөри. 1932 елда ул Ташкентка чакырыла, берьюлы берничә уку йортында укыта. 1933 елның көзендә Г. Сәгъди Фирганә дәүләт педагогия институтына үзбәк әдәбияты профессоры итеп билгеләнә. Биредә дә кафедра оештыра һәм 4 ел дәвамында аны җитәкли. 1936 елда Үзбәкстан Халык мәгариф комиссариаты карары белән филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала. 1938–1941 елларда ул Нәваи иҗаты буенча өч томлык докторлык диссертациясе әзерли. «Үзбәк классик әдәбияты үсешендә югары этап буларак Нәваи иҗаты» («Творчество Навои, как высший этап в развитии узбекской классической литературы») дигән бу диссертация 1949 елның 6 октябрендә Мәскәүдәге Шәрык институтының

Гыйльми советы утырышында яклана. 1950 елның 22 апрелендә ЮАК карары белән Г. Сәгъдигә филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә бирелә.

1937 елның августыннан 1941 елның ноябренә кадәр Г. Сәгъди Сәмәркандтагы ҮзДУда үзбәк әдәбияты кафедрасын җитәкли. Бөек Ватан сугышы башлангач, Сәмәрканд университетын Ташкент университетына кушалар. Г. Сәгъди дә Ташкентка күчерелә һәм 1952 елның октябренә кадәр профессор, кафедра мөдире булып эшли. 1946 елның 8 мартында галим «профессор аттестаты» ала, шул елны «Хезмәт Кызыл байрагы» ордены белән бүләкләнә. Шул рәвешле, Г. Сәгъди тормышының да бер өлеше башка төрки халыклар мәдәниятенә хезмәткә багышлана. Бу юлда да татар галиме күпсанлы талантлы укучылар да, кардәш халыкларда фән юнәлешләренә нигез салган саллы хезмәтләр дә, югары уку йортларында кафедралар да әзерли.

1939–1944 елларда Г. Сәгъди СССР Фәннәр академиясенең Үзбәкстан филиалында, 1944–1949 елларда ҮзССР Фәннәр академиясенең Тел-әдәбият институтында гыйльми тикшеренүләр алып бара. 1944 елның көзендә Г. Сәгъди Казанга килә, «Совет әдәбияты» журналында аның «Татар халкының үсешендә Каюм Насыйриның роле» дигән мәкаләсе дә басылып чыга. Бу – галимнең Казан белән хушлашуы була. 1956 елның 6 ноябрендә, 67 яшендә, каты авырудан бакыйлыкка күчә.

Г. Сәгъди – филология белгечлеге буенча татарлардан беренче профессор һәм беренче фән докторы дигән гыйльми дәрәҗә алган шәхес. Әмма аның эшчәнлеге филология белән генә чикләнми. Бүгенге татар гыйлемендәге күп тармакларның тарихын Г. Сәгъди исеменнән башка күз алдына да китерү мөмкин түгел. Татар әдәбияты тарихы, теориясе булсын, педагогика һәм тел белән әдәбиятны укыту методикасы булсын, Шәрык мәдәниятләрен өйрәнү булсын, символизм тарихы булсын, әдәбият укыту методикасы тарихы булсын – әлеге юнәлешләр хакында лекцияләр, хезмәтләр һәрчак галим мирасына хөрмәт белдереп, аның төрле фәннәрне гамәлгә куюга керткән өлешен барлап башлана. Бу тармакларда татар фәне Г. Сәгъдиләр, башка күренекле фикер ияләре сызган юлдан барды, аларның эзләнүләрен дәвам итте һәм үстерде. Гомер буе гыйлем җыеп, көчен һәм белемен милләткә хезмәткә куеп, үз адресына язылган бер генә

репликаны да җавапсыз калдырмыйча – үзе инанган хакыйкатьне раслап һәм башкаларны да үз артыннан ияртергә ашкынып яшәгән бу тынгысыз җан фәндә объективлыкка омтыла, аның 1930 еллар сәяси басымы астында Г. Исхакый кебек шәхесләр иҗатына карата олы бәясен үзгәртмәве генә дә игътибарга лаек. Бүгенге әдәбият фәне исә бу шәхесне кайта-кайта ача, аның киң колачлы эшчәнлеге, гыйльми хезмәтләре заман галимнәрен сокландыра.

Күп телләр белүе (гарәп, фарсы, төрек-госманлы, рус, үзбәк, казакъ һ. б.), бик күп халыкларның мәдәниятләре белән якыннан танышлыгы, даими укуда, хезмәттә, эзләнүдә булуы Г. Сәгъди эшчәнлегендә үз эзен калдыра. Аның әдәбиятка, әдәби әсәргә, язучы иҗатына фактлар аша гына түгел, тоемлап, чагыштырып якын килүе күтелмәгән нәтиҗәләргә китерә. Бу мирастан безне тулы бер гасыр аерып торса да, үзенең актуальлеген югалтмаган, искермәгән кызыклы фикер-карашлары, анализ үрнәкләре белән танышу бүгенге укучы өчен дә файдалы булыр дип исәплибез. Галимнең «Татар әдәбияты тарихы» (1926), «Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре» (1926), «Татар театр әдәбияты һәм аның үсү тарихы» (1926), «Символизм турында» (1932) кебек хезмәтләренең бүгенге гуманитар фәннәрдә үз шәрәфле урынын алуына, бүгенге фәнни барышка кушылып китүенә шигебез юк.

*Д.Ф. Заһидуллина,*
*филология фәннәре докторы*

# ТЕЛ ВӘ ӘДӘБИЯТ МӘСЬӘЛӘСЕНДӘ ФАЙДАЛЫ АГЫМ

Дөньяда ике төрле юл бар: 1) эшләү һәм төзәтү юлы; 2) эшләнгән вә төзәтелгән эшне даимән бозып, ватып, кырып тору юлы (ләкин тәнкыйть башка, ул төзәтү юлына керә). Менә шул ике юлның әүвәлгесе никадәр кыен булса, соңгысы шулкадәр җиңел булган юл. Чөнки эшләнмәгән бер эшне башлап эшләү яки искесен төзәтү өчен, әллә нихәтле көч һәм әллә никадәр корал вә материал илә бергә, бетми-төкәнми торган иҗтиһад[1] вә гайрәт лазем. Әмма вату, җимерү өчен беразрак батырчылык булу өстенә әз генә коралың һәм әз генә көчең булса, шул җитә. Шуның белән әллә нинди зур бер эшне булса да, зир-зәбәр китереп[2], җимерәсең дә ташлыйсың. Ни өчен җимергәнлегеңә сәбәп вә дәлилләр дә тиз табыла. Ул эшнең ничек кенә булса да бер җәһәттән зарарын күрсәтергә мөмкин. Чөнки дөньяда сыйрыф[3] файда гына яки сыйрыф зарар гына хөкем ителә торган бер нәрсә дә юк. Син сыйрыф файда гына дип тапкан бер нәрсәнең икенче берәүләр бер җәһәттән зарарын таба, сыйрыф зарар дигән нәрсәләрнең дә бер яктан файдасын күрсәтәләр. Милли философымыз Йосыф әфәнде Акчуринның[4] «Дөньяда катгый бер нәрсә юк» дигән хикмәтле сүзе дә шуңа ишарә кыладыр.

Мәсәлән, бөтен дөнья вә бөтен милләтләрнең «мәдәният» дип авыз сулары корыган нәрсәне алыйк. Инсаннарның зур фиркасы[5] моны бәшәрият[6] өчен гайне сәгадәт[7] дип хөкем иттекләре хәлдә, икенче фирка аннан йөз дүндерә[8] вә аннан бизә, аны җимереп, бәшәриятне әүвәлге халәтенә кайтарырга тырыша. Дәлил итеп тә «мәдәният» сәбәбеннән инсаннар башына яуган бәгъзы бер фәлякәт[9]

---

[1] Иҗтиһад – тырышлык.
[2] Зир-зәбәр китереп – астын өскә китереп.
[3] Сыйрыф – фәкать.
[4] Йосыф әфәнде Акчурин – Йосыф Хәсән улы Акчурин (1876–1935), сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, журналист.
[5] Фиркасы – төркеме.
[6] Бәшәрият – кешелек.
[7] Гайне сәгадәт – бәхет чыганагы.
[8] Йөз дүндерә – йөз чөерә.
[9] Фәлякәт – бәхетсезлек.

вә һәлакәтләре күрсәтә. Мәдәниятнең, бер бүлек инсаннарның сәгадәт вә рәхәте өчен, икенче бүлеге корбан итүе, аларны шуның өчен әллә нинди куркыныч фәлякәт вә һәлакәт упкынына батыруы һәм мәдәниятнең киткән саен дөнья йөзен кан дәрьясы ясый баруы бу фирканы тәмам үзенә дошманлаштыра. Аны тәмам үзенә яман күз белән карауга мәҗбүр кыла.

Шулай ук алыйк һәр милләтнең хәят вә бәкасы[1] үзенә барып бәйләнгән дип бөтен дөнья тарафыннан хөкем кылынган вә бөтен мәдәни милләтләрнең азау тешләре белән ябышкан «әдәбият» дигән нәрсәне. Менә моны да бит бер фирка философлар җәмгыяте бәшәриянең[2] сәгадәте өчен гаять дәрәҗәдә зарарлы итеп күрсәтә вә кирәк нәрсә түгел диләр. Шул әдәбият, билхасса[3] драма вә трагедия кеби нәрсәләрне уку нәтиҗәсендә меңнәрчә адәмнәр үзләренең газиз җаннарына үзләре касд итә[4], җаннарын хәят вә тормыш нигъмәтеннән мәхрүм кылуга мәҗбүр булалар диләр.

Кыскасы, гомум тарафыннан файдалы күрелеп, кабул ителгән вә эшкә куелган нинди генә бер нәрсәне вә нинди генә бер эшне булса да бозыйм, җимерим диденңме, шуның өчен мотлак[5] бер сәбәп табарга, бер җәһәттән ничек тә аның бер зарарын күрсәтеп, астын өскә китереп, ватып, кырып ташларга мөмкин, бу кулай.

Менә шул хикмәт өчен дә һәр тугрыда гаклы сәлим[6] ияләре тарафыннан корылып куелган гомуми канунга баш имичә чара юк. Ул канунда: бер эшкә файдалы дип керешеләчәк булса, иң элек аның файдасы белән зарарын үлчәп карап, файда ягы авыр килсә эшләү, югыйсә ташлаудан гыйбарәт.

Тел вә әдәбият мәсьәләсендә дә шул канунга ябышырга тиешлемез.

* * *

Инде килик максатка, шушы югарыда сөйләнгән ике юлның җиңелрәген ихтыяр итүчеләремездән Хәлил әфәнде Әбелха-

[1] Хәят вә бәкасы – тереклек вә яшәеше.
[2] Җәмгыяте бәшәриянең – кешелек җәмгыятенең.
[3] Билхасса – аерым әйткәндә.
[4] Касд итә – явызлык эшли.
[5] Мотлак – һичшиксез.
[6] Гаклы сәлим – сәламәт акыл.

нов[1] бу елгы «Шура» мәҗмугасының[2] 11 нче, 12 нче гадәдләрендә[3] «Тел вә әдәбият мәсьәләсендә яңа агым» дип бер мәкалә язган. Мәкалә иясенең мәзкүр[4] мәкаләсе илә төзеп аткан нөктәсе[5] вә аннан төп максаты шул – ул, шуның илә сарыф вә нәхү[6] һәм әдәбият кагыйдәләре кебек һәммә мәдәни милләтләр тарафыннан файдалы вә лазем күрелеп, күптән бирле нигезе корылып эшләнеп килгән вә һаман корылып утырган нәрсәләрне, үзенчә берьяктан зарарларын күрсәтеп, ватып, кырып ташлый һәм әфкяре гомумияне[7] шул якка аудармак була. Байтак кына тәнакызларны[8] вә тугры һәм сәламәт булмаган фикерләрне бер җиргә җыйнап булса да, сарыфы да, нәхүе дә әдәбият кагыйдәләре дә берсе дә кирәк түгел, алар безнең өчен сыйрыф зарар гына, алар тик безне агулыйлар гына, алар укучыга һичбер төрле гакыл да, фикер дә бирмиләр вә әдәбият белән таныштыруга һич хезмәт итмиләр, ди.

Х. әфәнде, мәкаләсенең әүвәлге бүлемендә үзенең сүзен куәтләү өчен, дәлил урынында бәгъзе рус филолог вә педагогларының фикерләрен күчерә. Хәлбуки[9] дикъкатьләбрәк укылса, аларның фикерләре мәкалә иясенең файдасына күп хезмәт итә алмыйлар, бәлки аларның сүзләре аңа зарар гына булалар. Чөнки ул филологлар, сарыф вә нәхү бер дә кирәкми дигән тарафта түгелләр. Анлар тик хәзерге көндә рус мәктәпләрендә дәрес китабы итеп укытылган сарыф вә нәхү рисаләләренең начарлыгыннан, ысулы тәгълим[10] вә тәрбия кануннарына муафикъ[11] язылмаганлыгыннан гына зарланалар. Шуның өчен дә аларга шиддәтле[12] сурәттә һөҗүм итәргә һәм сарыф вә

[1] Хәлил әфәнде Әбелханов – Хәлиулла Габделвәли улы Әбелханов (1887–1919), язучы, журналист, педагог. 1912 елдан «Шура», «Мәктәп», «Мәгариф» журналларында, «Йолдыз», «Кояш», «Корылтай» газеталарында актив языша.

[2] Мәҗмугасының – журналының.

[3] Гадәдләрендә – саннарында.

[4] Мәзкүр – әйтеп кителгән.

[5] Нөктәсе – мәгънәсе.

[6] Сарыф вә нәхү – морфология һәм синтаксис.

[7] Әфкяре гомумияне – җәмәгатьчелек фикерен.

[8] Тәнакызларны – каршылыкларны.

[9] Хәлбуки – ләкин.

[10] Ысулы тәгълим – укыту методы.

[11] Муафикъ – яраклы, туры килгән.

[12] Шиддәтле – ныклы, көчле.

нәхү рисаләләре мөмкин кадәр кыска, истисна[1] вә иститрад-фәлән[2] белән тутырылмаган булырга тиеш, андый нәрсәләр белән балаларның башын каңгыратырга, зиһеннәрен чуалтырга ярамый диләр.

Бу филологларның сарыф вә нәхү һич кирәк түгел фикерендә булмаганлыкларын мәкалә иясе бер ике-өч урында үзе дә игътираф кыла[3]. Вә мәга зәликә[4] анларны «кирәкми» дигән тарафта итеп күрсәтә вә шуны үзенә дәлил итеп тота.

Мәкаләсенең 2 нче бүлемендә сарыф вә нәхү рисаләләремездә мисалларны әдәбияттан алырга кирәкме, түгелме дигән моназарәләрне[5] вә бер мөгаллимнең «кирәк» дигән якны куәтләр әфкяре гомумияне шул тарафка мәел иттерергә[6] тырышканын сөйләгәннән соң, Х. әфәнде менә болай ди: «Бу фикерне әсасән инкяр итеп булмый. Чөнки боннан максат – әдәбиятымызны тарату вә әдәбиятны гомумләштерүдер. Әлбәттә, һәр милләт баласы үз әдәбиятының таралуын яратырга тиеш. Фәкать мәсьәлә монда гына: бу юл белән барганда, чын мәгънәле әдәбият берлә таныштырып буламы? Әдәбияттан өмид ителгән нәтиҗәләр чыгармы? Укучыга бер төрле гакыл вә фикер бирәме? Менә эшнең бу тарафлары авыр! Бу хакта: «Юк, мәгаттәссеф[7], һич бирәү дә юк, җавабы бирелер», – ди. Х. әфәнде мәсьәләгә өстәнрәк караган булырга охшый. Чөнки бер телнең сарыф вә нәхүсен укудан асыл максат әдәбият белән генә таныштыру түгел бит, бәлки аннан төп максат әдәбиятның калыбы вә киеме булган «тел»нең нәкъ үзе белән таныштыру, сүзләрнең ничек оешуы, кәлимәләрнең фикер вә мәгънәме ифадәдә[8] ни суратта вә кайсы юл белән һәм никадәр хезмәт иткәнлекләре хакында мәгълүмат бирү була. Шул ноктаи нәзардан: «сарыф вә нәхүләр укучыга бертөрле гакыл вә фикер бирәме?» дигән игътиразыңыз[9] бик урынсыз.

Һәм һәр милләт баласы үз әдәбиятының таралуын яратырга тиеш булган шикелле, теленең ничек оешуын, телендәге фигыль,

[1] Истисна – чыгарма.
[2] Иститрад-фәлән – *биредә:* чигенеш-фәлән.
[3] Игътираф кыла – таный.
[4] Вә мәга зәликә – шуның белән бергә.
[5] Моназарәләрне – фикер алышуларны.
[6] Мәел иттерергә – омтылдырырга.
[7] Мәгаттәссеф – кызганычка каршы.
[8] Ифадәдә – аңлатуда.
[9] Игътиразыңыз – каршы төшүегез.

әдат[1] вә башка төрле кәлимәләрнең уемызны (фикеремезне) башкаларга аңлату өчен ни тарик[2] белән хезмәт иткәнен дә бик ачык иттереп белергә тиешле. Моны милләтен сөюче адәм шаяд инкяр кыла алмаз.

Мисалларны әдәбияттан алырга тиеш диючеләр дә, сарыф вә нәхү фәкать әдәбият белән таныштыру өчен генә укыла вә шуңа гына васита[3] була да шуның өчен мисаллар әдәбияттан алынырга тиеш дими торганнардыр. Тик бары кагыйдәләрне изах[4] өчен мисал китерергә кирәк, шулай булгач, үзең яңадан мисал тәртип иткәнчә әзер мисаллар алынса һәм җиңелрәк һәм рухлы вә файдалырак булыр. Моның белән бергә шуның аркасында сарыф вә нәхүләрнең шул телнең урынына алынып ясалганлыгын һәм тел башлыклары әдип вә шагыйрьләр булганын зыймный сурәттә[5] булса да, балаларга аңлатыла барылган булыр. Вә болай итү, кагыйдәләрнең күңелдә калуына да ярдәм итәр дип шул өмид белән генә мисалларны әдәбияттан алу ягын куәтлиләр.

Затән,[6] сарыф вә нәхү җәһәтен тәфтиш итеп[7] аңлатканнан соң, мисалдагы фикер, хис вә хыял белән дә таныштырылачагыннан мисалларны әдәбияттан алу балаларның фикер, хис вә хыял орлыкларының яшь вакытларыннан ук шыта вә үрчи баруына ярдәм итәчәге дә шөбһәсез. Бу яктан караганда, мисалларны әдәбияттан алу аркасында, сарыф вә нәхү укыганда ук (гәрчә күп булмаса да), балаларны әдәбият белән таныштыра барыла дип була. Хасыйл[8], һәрхәлдә мисалларны әдәбияттан алу артыграк.

Х. әфәнде тагы әйтә: «Мин әдәбияттан бер нәрсә укыйм икән, мин фәкать аннан чыккан гомуми мәгънә вә фикергә карыйм, алардан кирәк булганларыны үз хәзинәмә җыям. Бер әдәби әсәрне укыганда, мәсәлән, шунда очраган фигыльләрнең кай заманны белгерткәләре вә ма әшбәһеләр[9] тугрысында мин уйлап та карамыймын,

[1] Әдат – кисәкчә.
[2] Тарик – юл.
[3] Васита – корал, чара.
[4] Изах – аңлату.
[5] Зыймный сурәттә – сүз уңаеннан.
[6] Затән – нигездә.
[7] Тәфтиш итеп – тикшереп.
[8] Хасыйл – кыскасы.
[9] Вә ма әшбәһеләр – һәм шуның ишеләр, моңа охшашлылар.

бөтен игътибарым вә бөтен зиһенем мөхәррирнең[1] акрын-акрын гына киңәйтә килгән мәсләгене[2] вә әсәрдә күрсәтелгән типларның торыш-йөреш вә әхлакы берлә мәшгуль була, бу тарика[3] укып чыкканда, минем әсәрдән калган тойгым мөкәммәл[4] булырга тиеш, чөнки мин төгәл картина берлә танышам, әсәрне бу төрле укуга әдәбият берлә васитасыз[5] танышу дип әйтәләр», ди.

Хәер[6]! Кабалык[7] тарафыннан булмаучылар, ягъни әдипләр, сәнгать вә нәфасәт (искусство, художество) ияләре алай сез дигәнчә әсәрнең фәкать мәүзугы[8] вә әсәрдән чыгачак гомуми мәгънә вә фикерләр белән генә канәгатьләнмиләр. Бәлки мөхәррирнең әсәрендә алган мәүзугын, сезнең тәгъбирчә[9], үзенең акрын-акрын гына киңәйтә килгән мәсләген һәм әсәрдә күрсәтелгән типларның торыш-йөреш вә әхлакын тасвирдагы мәһарәтен[10] дә тикшерәләр. Гомуми мәгънәне тудыра торган хосусый мәгънә вә фикерләрне үзенең тиешле урынына куеп шунларны телнең фитърый[11] булган бәлягать вә фәсахәт[12] канунына муафикъ итеп[13] бәян кыла алып – алмавына да дикъкать итәләр.

Хасыйл, анлар, бер әдәби әсәрне укыганда, әсәрнең өслүбен[14], аның телнең матурлык вә нечкәлегенә күпме хезмәт итә алганын үлчи баруны, милли телнең тәрәккый вә тәкәммеле намына[15] иң беренче һәм иң зур вә иң мөкаддәс бер эш дип карыйлар вә шуңа мәҗбүр булалар.

Затән, милли әдәбиятның тәрәккыйсыннан беренче максат вә беренче өмид: телне чарлау – аны кабалыктан аеру вә матурлау түгелме?

---

[1] Мөхәррирнең – әдипнең.
[2] Мәсләгене – юлыны.
[3] Тарика – юл белән.
[4] Мөкәммәл – камил.
[5] Васитасыз – арадашсыз.
[6] Хәер – юк.
[7] Кабалык – тупаслык.
[8] Мәүзугы – темасы.
[9] Тәгъбирчә – аңлату буенча.
[10] Мәһарәтен – осталыгын.
[11] Фитърый – табигый.
[12] Бәлягать вә фәсахәт – төзеклек һәм матур теллелек.
[13] Муафикъ итеп – туры китереп.
[14] Өслүбен – стилен.
[15] Тәкәммеле намына – камилләшү хакына.

Кызларның начар вә килбәтсез кием кигәндә матурлык вә җазибәлекләре[1] ничек кими торган булса, фикер вә мәгънәнең дә шулай ук килешсез өслүб вә чыгышсыз ифадә сәбәпле тәэсир вә нөфүзе[2] азая. Ләззәте кими, төзе[3] кача, ниһаять укучыны ялыктырып, мәзкүр әсәрне икенче мәртәбә кулына алмаслык итеп куя. Әдәбият белән күп шөгыльләнүчеләр шаяд моны инкяр кылмаслар.

Ярый, бер әдәби әсәрне укыганда, син шунда очраган фигыльләр вә ма әшбәһеләр тугрысында бер дә уйлап да карама! Соң ул вакыт әсәрдән ничек иттереп гомуми мәгънә чыгарыла соң? Дөрес, син фигыльләр вә әдатләр һәм дә башка кәлимәләрнең исемнәрен ихтимал һич хәтереңездә китермәссең һәм аның әсәрдән мәгънә чыгару өчен лөзүме дә булмас. Монысында күп хикмәт юк. Ләкин аларның фикер вә мәгънәне ифадәдә нинди хезмәтне үти барганлыкларын мотлак уйлыйсың. Әгәр, юк, берсен дә уйламыйм дисәң, әсәрдән мәгънә чыгарам вә хәзинәмә фикерләр җыям диюең тик көлке генә булып калачак.

Чөнки без берәүнең уен, фикер вә мәгънәсен, анчак[4] шул фигыльләре, әдатлар вә башка кәлимәләр аркылы вә шунлар васитасы белән генә аңлый алабыз бит!

Җөмләдән әсәрдәге вакыйгаларның кай заманда булганын ничек аңлыйсың? Фигыльләр аркылы түгелме? Шул хәлдә димәк, укыган әсәреңдәге фигыльләр вә башка кәлимәләр, ни заманга дәлаләт иткәнлекләрен[5] вә ни хезмәт үти барганлыкларын үзең дә сизмәстән һаман уйлый барасың. Берәү белән сөйләшкәндә дә хәл шулай ук. Вә иллә[6] әсәрдән яки берәүнең сөйләгән сүзеннән алган тойгыңыз түгел мөкәммәл, хәтта өзек-тәтек дә булмаячак.

Кәлимә вә җөмләләре һәр каюсы үз урынына төшкән булсалар һәм үзләренә тиешле булган хезмәт иттерелсә, бәлки сарыф һәм нәхү җәһәтенә артык дикъкать итмәсәңез дә итмәссез. Ләкин мәшһүр мөхәрриремез Гаяз Исхакый[7] әфәнденең менә шул

[1] Җазибәлекләре – җәлеп итүчәнлекләре.

[2] Нөфүзе – үтемлелеге.

[3] Төзе – төсе.

[4] Анчак – фәкать.

[5] Дәлаләт иткәнлекләрен – караганын.

[6] Вә иллә – я булмаса.

[7] Гаяз Исхакый – Мөхәммәтгаяз Гыйлаҗетдин улы Исхаков (1878–1954), язучы, публицист, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе.

түбәндәге куш эченә алынган: «Табак янындарак күлмәкчән, яланаяк, кыска гына ыштаннан бер карт сузып-сузып бик кычкырмаенча гына камыт төшерә иде. Сәгадәт, бу кешене күргәч, әллә нинди бер хәлгә килде. Бүген күргән кешеләргә, бүген күргән эшләргә Сәгадәт үзен бөтенләй ят итеп карый (мондагылар һәммәсе дә Сәгадәткә башка кешеләр кебек түгел һәммәсендә дә ышаныч юк төсле күрсәткән иде. Бу кешене күргәч, Сәгадәт үзе әллә нинди икенче бер халык арасына илтеп ташланган кеше, үзенең җиреннән килгән, телен аңлый торган кешене күргән кебек булды)» («Теләнче кызы», сәхифә[1] 38) сүзләре кебек гыйбарәләр алдыңызга килеп чыкса (мондый чыгышсыз гыйбарәләрне Гаяз әфәнде әсәрләреннән байтак табарга мөмкин), болар әсәрдән чыгачак гомуми мәгънәгә зарар бирмиләр диеп кенә ташлап качмасаңыз, сарыф вә нәхү җәһәтенә дикъкать иткәнлекеңезне тоймый да калырсыз!

Кыскасы, әдәбият белән һич васитасыз танышам, диюеңез мәгънәле сүз булырга охшамый.

Әгәр алай сарыф вә нәхү укытудан максат ялгыз[2] әдәбият, ягъни роман вә хикәя кебек нәрсәләр белән генә таныштыру була торган булса, аның өчен генә ана теленең һич лөзүме калмый. Бу ансыз да мөмкин. Мәсәлән, башка бер тел – рус теле белән танышсаң. Моңарчы күп мөхәррирләремез шулай иткәннәр ич! Бер телнең сарыф вә нәхүе илә танышуның әдәбияты белән танышу өчен һич лөзүме вә файдасы юклыгын, бәлки әдәбият белән танышу өчен сарыф зарар гына икәнен исбат кылып бирү өчен, махсусатән[3] «өстәл»не мисалга алып, тагы менә болай ди: «Өстәл – анда язасың, китап куеп укыйсың, ашый вә эчәсең. Димәк, өстәлдән төрлечә файдаланасың. Әмма шул вакыт өстәлнең нинди агачтан ясалуын вә ничә аягы вә нинди булуларын тәфтиш итмәк һичкемнең исенә дә кереп чыкмый, өстәлдән күрелгән файданың мөкаммәлияте өчен моның һич тә хаҗәте юк. Шулай ук бер әдәби әсәрне укыймыз икән, без аннан үземезнең рухымыз кабул иткән, кирәксенгән фикер хәзинәсе аламыз, әмма ул әдәби әсәрдә җөмләләрнең фәләндәй булуы, җөмләләрдә «ия»нең исемнән яки сыйфаттан вә шуңа охшашлы нәрсәдән тәртип ителүләрен тәфтиш исемезгә дә кереп чыкмый. Димәк,

[1] Сәхифә – бит.
[2] Ялгыз – бары тик.
[3] Махсусатән – махсус рәвештә.

әсәр берлә әдәбият ноктаи нәзарыннан танышканда, сарыф вә нәхү җәһәтеннән тәфтиш хасыйл булмый» илх[1]...

Менә бу мисал мантыйксызлыктан гына китерелгән нәрсә. Бу мисалы илә Х. әфәнде үзенә файда итми. Бу тик үзенә зарар гына. Әүвәлән[2], әдәбияттан файдалану илә өстәлдән файдалану арасында ни мөнәсәбәт бар?

Икенче, без өстәлнең вә шуның шикелле арамызда истигъмаль кылынып[3] йөрелгән нәрсәләрнең нидән вә ничек ясалганлыкларын бер кәррә[4] дә тәфтиш итмимез түгел, итәмез. Чөнки без, анларны әүвәл күргән вакытымызда бер дәфга[5] бик нык тикшереп, шунларның сурәтен хыялымызда тәмам урынлаштырган буламыз. Шуның өчен үзләренә берәр зыян ирешеп алардан күрә торган файдамызга хәләл[6] килмәсә, без аларны яңадан тәфтишкә лөзүм күрмимез.

Мәсәлән, өстәлнең бер аягы сынган яки башка берәр җире ватылган булса, менә шул вакыт өстәлдән килә торган файданың мөкаммәлияте өчен өстәлнең аякларына вә такталарына дикъкать иткәнеңезне сизми дә калырсыңыз!

Андый нәрсәләрне без бер дә тәфтиш итеп үтмәгән булсак, өстәлнең ничә аягы вә ул ничек эшләнгән була? дигәндә аптырап калуымыз лязем булып килә ич! Хәлбуки мәкалә иясе шаяд мондый сөальләргә аптырап калмый торгандыр. Менә шуның шикелле үк бер әдәби әсәрдә үткәндәге Гаяз әфәндедән китерелгән мисал кебек килешсез гыйбарәләр очраса, шул сәбәпле гыйбарәнең аңлатырга теләгән мәгънәсен җиңел генә аңлый алмасаң, өстәлнең аякларына дикъкать иткәнең кебек, дәрхаль[7] телнең табигый булган сарыф вә нәхүенә дә мөрәҗәгать итеп карауга мәҗбүр буласың!

Бу урында мотаябә[8] тарикынча күңелгә бер сөаль килә: сез, сарыф вә нәхү әдәбияттан килә торган файдага тик зыян гына итә дисез, алай булгач өстәлнең ничек ясалганын вә ничә аяклары булганын тикшерү өстәлдән киләчәк файдага да зарар итәмени? Аны

[1] Илх – һәм башкалар.
[2] Әүвәлән – беренчедән.
[3] Истигъмаль кылынып – кулланып.
[4] Кәррә – тапкыр.
[5] Бер дәфга – бер кат.
[6] Хәләл – зарар.
[7] Дәрхаль – шунда ук.
[8] Мотаябә – шаяру.

тәфтиш итә башласак, әллә өстәл өстендәге чынаяклар яки китаплар вә каләмнәр шылтырап вә тәгәрәп төшә башлыйлармыни!?

Дәгъваңызны исбат өчен китерелгәч, мисалыңыз менә бу яктан да муафикъ[1] булырга тиеш.

Мин бер вакыт гавамнан[2] су эчеп торган берәүгә: «Менә, фән укыган кешеләр су белән һаваның нинди нәрсәләрдән (гонсырлардан[3]) җыелганын беләләр. Фән аркасында аларда нинди маддәләр барлыгын аңлыйлар», дигәч, «су белән һавадан файдалану өчен аны белүнең хаҗәте бармыни? Менә мин берсен дә белмим дә су белән һавадан ала торган файдамны һаман алам ич! Сусаганда суны эчәм, һаваны һаман сулап йөрим, анларның нидән ясалганлыкларын (гонсырларын) тикшерү тик сезнең кебек эшсез, тик ята торган шәкертләрнең генә эшедер инде ул!» – дигән иде. Х. әфәнденең дә телемезнең сарыф вә нәхүсен тәртип итү, тикшерү һәм шуны шәкертләремезгә укытуны «көчләнеп эшләгән хаталарымыз» диюе шул кабилдән булмаса ярар иде!

Инде килик Х. әфәнденең әдәбият кагыйдәләре хакындагы сүзләренә. Ул бу тугрыда сүзен менә болай башлый: «Дәхи[4] безнең әле болардан башка да эшләргә уйланган әллә никадәр хаталарымыз бар. Мәсәлән, бу көндә безнең әле әдәбият кагыйдәләремез юк, ихтимал, Русиянең бер почмагында хәзер эшләнә торгандыр. Сарыф вә нәхүнең әдәбиятка тәгаллекы[5] җөзьи генә[6] булса да, әдәбият кагыйдәләре аның белән бик каты бәйләнгән. Һәм әдәбият үзе хакындагы кагыйдәләр өчен чишмә булып хезмәт итә».

Бу соңгы сүзе тугры һәм сәламәт. Шулай, әдәбият кагыйдәләре әдәбият белән бик нык бәйләнгән. Шуның өчен алар безгә лазем дә. Һәм әдәбият, үзе хакындагы кагыйдәләр өчен чишмә булып хезмәт итә. Ягъни әдәбият кагыйдәләре шул әдәбият дигән нәрсәнең үзеннән алынып эшләнгән. Читтән килеп катышкан вә әдәбият белән мөнәсәбәте булмаган нәрсәләр түгел. Х. әфәнденең бу сүзе хәтереңездә торсын. Ул соңыннан шул асыл булган сүзенә каршы сөйли башлар әле!

---

[1] Муафикъ – туры килгән.
[2] Гавамнан – халыктан.
[3] Гонсырлардан – элементлардан.
[4] Дәхи – тагын.
[5] Тәгаллекы – бәйләнеше.
[6] Җөзьи генә – өлешчә генә.

Тагы аның сүзен тыңлыйк. Ул тагы менә болай ди: «Безгә күрше булган милләтнең әдәбият кагыйдәләре китапларын тәфтиш итеп карасак, аларның баш фасыллары менәниләрдән гыйбарәт: әсәрләрне халык әдәбияты берлә берәр кеше тарафыннан язылганларга бүлү, шигырь вә нәсер берлә язылган әсәрләр, аларны төрле кыйсемнәргә[1] бүлү, роман, драма, хикәя, комедия ... илх. Һәр кыйсемнең хосусиятләре дәхи[2] шундый әллә никадәр нәрсәләр монда һәрбер әсәргә шул кагыйдәләр, тәгърифләр[3] ноктаи нәзарыннан[4] киленә. Укучыны, һәр әсәрне тәфтиштә шунда күрсәтелгән нәрсәләр берлә коралланып, бер җәһәттән генә тәхлилгә[5] үгрәтә. Һәм шуңа гадәтләндерә. Мәсәлән, драма булырга әсәр фәләнчә пәрдәдән гыйбарәт булырга, һәр эш эшләнеп гамәлдә күрсәтелү кирәк, бер баш каһарман була. Ул төрле уңгайсызлыклар берлә көрәшә, беренче пәрдәдә чын максат башланып, икенчесендә кәмальгә җитеп[6], ахырында да эш йә бүлеп, яки бетеп кала.

Димәк, һәрбер кешенең язган әсәре шушы кагыйдәләргә тугры килсә, ул әсәр әдәби булып, фәлән кыйсемгә керә. Монда күрсәтелгән кагыйдәләр, монда кылынган тәгърифләр, монда эшләнгән тәхлилләр шулкадәр коры, әсәрнең фәкать тыш игътибары берлә эшләнгәнгә, алар буенча, күптән түгел генә дөньяга чыгып татар әдәбиятын баеткан (!) Ш. Саттаровның[7] "Бәхетсез татар кызы" кеби әсәрләр, әдәбиятның тәмам югары җиренә менә дә торалар. Чөнки барлык тәгърифләр аңа тугры килә. Димәк, бу кагыйдәләр нә кадәр мөкаммәл вә нә кадәр нечкә кылып эшләнгән булсалар да, әдәбиятны тәфтиш өчен чын корал була алмыйлар. Булулары мөмкин дә түгел. Чөнки ул кагыйдәләрдән эшләнгән күзлек аркылы әдәбиятның фәкать тышкы тарафы гына күренә аладыр – әдәбиятның тамырына, әдәбиятның рухына һич тәгаллекъләры[8] юктыр», – ди.

---

[1] Кыйсемнәргә – өлешләргә.

[2] Дәхи – тагы.

[3] Тәгърифләр – билгеләмәләр.

[4] Ноктаи нәзарыннан – карашыннан.

[5] Тәхлилгә – анализга.

[6] Кәмальгә җитеп – җитешеп, өлгереп.

[7] Ш. Саттаровның – Шәриф Шәриф улы Саттаров (1887–1972), драматург, мөгаллим.

[8] Тәгаллекъләры – бәйләнешләре.

Әүвәл, безгә күрше милләтләрнең, җөмләдән русларның, бәлягать[1] китапларында (теория словесностиләрендә), баш фасылларында әдәбиятның нигезе хөкемендә булган фикер, хис вә хыялдан һәм бонларның хасиятләреннән бәхәс итү була. Шуннан соң фигура вә троплар. Аннан соң гына мәкалә иясенең әйткәненчә китә.

Икенче, әдәбият вә бәлягать кагыйдәләре алай сез дигәнчә, роман, хикәя, драма вә комедия кебек тәкъсимнәрдән[2] вә шулай әдәбиятның тышкы киеменнән генә гыйбарәт булмыйлар, бәлки, әсәрләрне драма, комедия вә саирә[3] кебек нәүгъларга[4] бүлеп, драма булса шулай, комедия булса болай булырга тиеш диелү, әдәбиятның кагыйдәсе булудан бигрәк, аның планы – юлы (ысулы) була. Әмма бәлягать вә әдәбиятның асыл кагыйдәләре менә нәрсәләр: тәшбиһ[5] (сравнение[6]), истигарә (метафора[7]), мәҗазе мөрсәл (метонимия[8]), киная вә тәгъриз (ирония[9]), табигыят, муаффәкать (туры килүчелек), монәкъкахият[10], әсаләт[11], аһәң, илтифат (обращение[12]), тәшхыйсе интак (олицетворение[13]), мөбаләга[14], тәкрар (повторение[15]), тәсад (противоположение[16]), тәртип, вәхдәте иҗад[17], тәдриҗ вә саирә[18].

Менә болар әсәрнең эчке халәтенә – рухына, тамырына гаид булган[19] һәм өслүб вә мәгънәсен тикшерүгә ярдәм итә торган, хасыйле әдәбият белән якыннан таныштыра торган асли[20] кануннар.

---

[1] Бәлягать – матур сөйләм.
[2] Тәкъсимнәрдән – өлешләрдән.
[3] Саирә – һәм башкалар.
[4] Нәүгъларга – төрләргә.
[5] Тәшбиһ – охшату, чагыштыру.
[6] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[7] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[8] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[9] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[10] Мөнәкъкахият – лаконизм.
[11] Әсаләт – кабатлаулардан тыелу.
[12] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[13] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[14] Мөбаләга – гипербола.
[15] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[16] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[17] Вәхдәте иҗад – иҗади бөтенлек.
[18] Тәдриҗ вә саирә – әкренләп үсү һәм башкалар.
[19] Гаид булган – караган.
[20] Асли – асыл.

Әсәрләрне драма фәлән кебек нәүгъләргә бүлеп, шул ноктадан тикшерү илә менә бу кануннар илә тәфтиш итүне аерып белергә тиешле. Бу икесен бергә бутарга ярамый. Дөрес, әдәбиятны андый нәүгъларга бүленү ягыннан карау, сез әйткәнчә үк, әдәбиятны тик тышкы тарафыннан вә күзлек үтә генә күрү хөкемендә була. Әмма безнең күрсәткән җәһәттән тикшерү, нәкъ аның тамырын тикшерү кебек була.

Өченче, бер әсәрнең драма яки комедия планына салынып эшләнүе белән генә аның әдәби әсәр булуы нидән лазем килсен? Мәсәлән, бер үк планда эшләнгән ике бина – өй фараз итеңез. Шуның берсе сәнаигы нәфисә[1] канунына муафикъ итеп[2], үзенең маһирлары – мигъмарлар[3] тарафыннан эшләнсен дә, икенчесе гади балта осталары, яки гади ташчылар тарафыннан ясалсын. Менә шул ике өйгә дөрес өй планында эшләнгәнлекләре өчен, икесенә дә өй дип исем бирелер. Әмма шунларның икесенә дә гүзәл вә нәфис дип хөкем кылырсызмы? Боларның бер планда эшләнүләре генә шул хөкемне вә матурлык исемен алуны лазем итәрме? Әлбәттә, итмәс. Бәлки ул хөкемне бирү өчен, әлбәттә, һәр икесенең эшендәге муаффәкыятен – шәплеген тикшерергә мәҗбүр булырсыз һәм кайсысының эше сәнгать канунына муафикъ булып чыкса, кайсысы безнең дикъкатемезне үзенә артыграк җәлеп итә алса, әлеге хөкем (мәдех[4]) шунысына бирелеп, теге начар эшләнгәне тик «өй» яки «бина» дигән исемне генә күтәрер дә калыр.

Хикәя, роман, драма вә комедияләрдә дә хәл шулай ук. Ягъни бер әсәрнең драма яки комедия планына муафикъ итеп эшләнүе белән генә аның әдәбиятның иң югары җиренә менеп утыруы лазем булмый. Бәлки моның өчен эшендәге муаффәкыяте, бәлягать вә фәсахәте канунына мотабәкате[5] шарт, өслүб вә ифадәсенең гүзәллеге, тасвирының шәплеге кирәк. Югыйсә, коры драма яки комедия кеби исемене генә алып, аңа әдиплек мәзияте[6] һич бирелмәячәк.

Тагы Х. әфәндене тыңлыйк. Ул әйтә: «Икенче язучы үзен никадәр хөр, һичбер кагыйдәләр берлә бәйләнмәгән хис итсә дә,

[1] Сәнаигы нәфисә – матур сәнгать.
[2] Муафикъ итеп – туры китереп.
[3] Мигъмарлар – архитекторлар.
[4] Мәдех – мактау.
[5] Мотабәкате – туры килүе.
[6] Мәзияте – өстенлеге.

тәхрир[1] эшендә язучыга никадәр иркенчелек бирелгән булса, шул вакытта гына мөхәррирнең таланты бөтен чишмәсе берлә ачылачак, шул вакытта гына мөхәррирнең каләменнән чибәр нәрсә күтәргә мөмкин, чөнки бирелгән кагыйдәләр, бирелгән пунктлар рамкасында гына уйлау, фикерне шул күрсәтелгән киртәдән тышка чыгармау шарты берлә язу – язу түгел. Андый камчы астыннан язылган әсәрнең һәрбер җирендә җәгълият[2] була. Аның күп җире өзек-төтек була. Шуның өчен әдәбият кагыйдәләре дигән нәрсә һәр язучының дошманы булырга тиеш. Чөнки алар язучының юлын тарайта, язучыга һәр минутта кирәк булган «эштә иркенлек» даирәсен кыса», – ди.

Без әйткән мәгънәсе белән булган әдәбият кагыйдәләре мөхәррирләрне кыса вә аларга хөррият бирми, дип булмый. Чөнки алар мөхәррирләрне һич кысмыйлар.

Моның илән бергә хөррият дигәч тә, аның да бер чиге булырга тиеш. Артык кызылланып, сулланып китү башка тугрыларда файда итмәгән кебек, әдәбиятта вә язу эшендә дә бик файдалы булып чыкмас. «Артык яктылык күзне камаштыра» дигән сүз дә бар.

Дөрес, фикер, хис вә хыял кадәресендә хөррият бирелер. Әмма аларны калыпка сукканда, ифадә кылганда[3] телнең фитърый[4] булган бәлягать вә фәсахәт канунына баш имичә чарамыз юк. Бу хакта хөрриятемезне ала икән, тел үзе ала. Безне бу тугрыда телемезнең шивәсе үзе кыса. Моның өчен һичкем гаепле түгел. Бу хакта гаепле булса «милли тел» гаепле! Һәм дә башка нәрсәләргә ияреп, һаман тәрәккый итүне теләве, тәкаммел канунына буйсынып, һаман нәфасәт, нечкәлек вә матурлыкны сөя баруы гаепле! ... чөнки әдәбият вә бәлягать кагыйдәләре читтән китерелеп куелган нәрсәләр түгел бит, телнең үзе була ич!

Мәсәлән, алыйк Гаяз Исхаков илә Ф. Әмирхан[5] яки Галимҗан Ибраһимовны[6]. Гаяз әфәнде, белмим ни сәбәптәндер, телнең фитърый булган бәлягать вә фәсахәтенә буйсынасы килми, каләмен үз

[1] Тәхрир – әсәр язу.
[2] Җәгълият – ясалмалылык.
[3] Ифадә кылганда – кулланганда.
[4] Фитърый – табигый.
[5] Ф. Әмирхан – Мөхәммәтфатих Мөхәммәтзариф улы Әмирханов (1886–1926), язучы, публицист, әдәби тәнкыйтьче.
[6] Галимҗан Ибраһимовны – Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов (1887–1938), язучы, галим, дәүләт эшлеклесе, Хезмәт Батыры (1928).

ихтыярына куя бирә. Шунлыктан фикер вә мәгънәнең тәэсирен куәт вә нөфүзен арттыру өчен һичбер хезмәт итмәгәне хәлдә, бер сүзне әллә ничә кабат тәкрар кылу, бер юл язарга тиеш урында ике-өч юл, бер бәйт белән аңлашыла торган фикер вә мәгънәне ифадә өчен дүрт, биш бит язу кебек килешсезлекләр Гаяз әфәнде әсәрләрендә тулып ята. Нәзакәт иярәрен хафалый торган әллә нинди ямьсез тәгъбирләр, сала мужиклары вә гаять кара, надан булган халык авызында гына әйтелеп йөри торган тәмсез ифадәләрне[1] дә Гаяз әфәндедән байтак кына ишетергә тугры килә.

Хасыйл, Гаяз әфәнденең күбрәк әсәрләре иясенең игътибарсызлыгыннан чүп баскан җимеш бакчасына охшыйлар. Бакчасында җимеш юк түгел, бар. Һәр нәүгътән бар. Хәтта аның әсәрләрен хис вә хыял хәзинәсе диярлгә ярый. Ләкин шул гына: бакчасының эченә, һәртөрле татлы җимешләрдән авыз итим дип кергән кешене рәхәтсезли торган санечкеле, файдасыз үләннәр үскән, бакчасын файдасыз кара билчән баскан!

Фәкать бу сүзләремездән Гаяз әфәндедә бәлигъ вә фәсыйх иттереп[2] язу кувәсе[3] бер дә юк дигән фикер аңлашылмасын. Аның ул кувәсенә әминиятемез[4] камил, касд итсә[5], мотлак булдырачак. Әсәрләрен язып беткәннән соң, анларны тәкрар тәфтиш итеп чыгу кебек тагы да бераз артыграк мәшәкатьне йөкләүгә авырсынмаса, хәтта Гаяз әфәнденең әсәрләре бәлягать вә фәсахәтнең иң югарыгы мәртәбәсен ихраз кылырлар[6] иде.

Әмма, Ф. Әмирхан белән Г. Ибраһимовка килсәң, болар милли телнең табигый һәм фитърый булган бәлягать вә фәсахәтенә чыннан әһәмият бирәләр. Әсәрләренең мәүзугы, фикер вә мәгънәсе илә бергә өслүб вә ифадә җәһәтеннән матур һәм сөйкемле булып чыгуына да соң дәрәҗәдә дикъкать вә игътибар кылалар. Хасыйл, болар милләтләрен фикер вә мәгънә җәһәтеннән алга өндәүгә тырышкан кебек, тел вә аның матурлыгы ягыннан да артка калдырмаска ижтиһад итәләр. Телнең тәрәккыйсенә хезмәт итүне дә уйлыйлар. Шуның өчен боларның әсәрләрендә һәр җәһәттән аерым бер тәм

[1] Ифадәләрне – тәгъбирләрне.
[2] Бәлигъ фә фәсыйх иттереп – төзек һәм матур иттереп.
[3] Кувәсе – куәте.
[4] Әминиятемез – ышанычыбыз.
[5] Касд итсә – теләсә.
[6] Ихраз кылырлар – ирешерләр.

була. Укыган саен укыйсы, караган саен карыйсы килә. Боларның өслүбләре, боларның ифадә вә тасвир кыяфәтләре укучыларның хәтта авыз суларын агыза.

Кыскасы, боларның бакчалары гаять дәрәҗәдә монтазам[1], вә бик тырышылып тәрбия ителгән, бик дикъкать илә тазартылган булганлыктан, тамаша итүчеләрен үзләренә тәмам җәлеп итеп алалар.

Дәхи, мәшһүр шагыйрьләремезне карыйк, мәсәлән, төпле фикерле, тирән хисле вә нечкә аңлы булган Дәрдмәнд[2] хәзрәтләре. Менә бу зат – телнең фитърый вә холкы булган бәлягать һәм фәсахәтенә үзенең әдәби тезгенен тәмам тапшырган, шул телнең муҗәзлеге[3] һәм матурлыгы өчен бөтен хөрриятен фида кылган, хасыйл, һәрвакыт шигырьләрен, бәлягать вә фәсахәт камчысы астында сөйли торган кеше.

Хуш, инде рәхим итеп шул шагыйремезнең шигырьләрен бер дикъкать илә укып караңыз! Телнең фитърый[4] булган бәлягать вә фәсахәт кагыйдәләре рамкасында вә шул киртәдән тышка чыкмыйча язуы сәбәпле, шагыйрьнең таланты – дәһа вә зәкясе[5] – бөтен чишмәсе белән ачылмыйча калганмы икән!? Аның шул эше – бәлягать кагыйдәләренә табынуы – шигырьләрен җәгъли[6] ясаганмы?! Яки өзек-төтек булып чыкканнармы?! Һич!

Тукаемыз да шулай ук бәлягать вә фәсахәт колы! Кыскасы, телнең табигый вә фитърый булган бәлягать, әдәбият кагыйдәләре мөхәррир вә шагыйрьләрне кыса, аларның талант чишмәсен томалый дигән фикерләр – өстке караштан (сатхи нәзардан[7]) гына чыккан яңлыш фикерләрдер.

Әгәрдә бәлягать вә фәсахәт кануннары, әдәби кагыйдәләр булмаса, әсәр белән әсәрнең, шагыйрь белән мөхәррирнең мәртәбәләре ни белән үлчәнеп беленәчәк? Бу тугрыда ни нәрсәне бизмән (мизан) итеп тотачакмыз? Хәлбуки[8] күп мөхәррирләр була: әсәрләрендә

[1] Монтазам – төзек.

[2] Дәрдмәнд – Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев (1859–1921), шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, берничә алтын приискасы хуҗасы.

[3] Муҗәзлеге – кыска һәм аңлаешлы булуы.

[4] Фитърый – табигый.

[5] Дәһа вә зәкясе – зирәклеге һәм зиһенлеге.

[6] Җәгъли – ясалма.

[7] Сатхи нәзардан – җиңелчә караштан.

[8] Хәлбуки – әмма.

нигез итеп алган мәүзуглары, мәсләк, фикер вә мөляхәзәләре һәммәсенең дә бертөрле була. Менә шуларны өслүб вә ифадә ягыннан тикшереп карамаганда, барысын да бер дәрәҗәдә дип хөкем итәргә тугры килә. Әмма өслүб җәһәттән бик күп аермалар табарга мөмкин.

Х. әфәнде әйтә: «Өченчеләре – әдәбият кагыйдәләрене мәктәпләрдә укыту мәсьәләсе югарыда язылганча, әдәбият кагыйдәләре берлә чын әдәбият арасында һич тә мөнәсәбәт булмагач (караңыз инде тәнакызын[1]! Үткәндә, бер урында, әдәбият кагыйдәләре әдәбият белән бик каты бәйләнгән һәм әдәбият үзе хакындагы кагыйдәләр өчен чишмә булып хезмәт итә дигән иде бит), алар фәкать коры тәфтиш кораллары гына, алар әдәбиятка карашны агулый, боза гына торган, күптән үлемгә хөкем ителгән нәрсәләрдән гыйбарәт булгач, әлбәттә, бондый әдәбият кагыйдәләренең мәктәпләрдә урыны булмаска тиеш, бондый әдәбият кагыйдәләрене шәкертләрнең белмәүләре күп өлеш артык. Исхакыйның «Алдым-бирдем»енең драма булып, «Җәмгыять»нең комедия булуын белүдән ни файда? Алай булса ни дә, киресенчә булса ни? Укучы өчен моның һич тә тәгаллекы юк. Укучыга аларның фәкать «әсәр» булулары һәм мөндәриҗатлары[2] гына әһәмиятле. Фәлән әсәрнең роман булып, икенчесенең хикәя булуын белүдән ни файда чыгачак? Шуның өчен дә руслардан «яңа агым» тарафында булган күп мөхәррир вә филологлар һәр әдәби нәрсәнең исеме фәкать «әсәр» генә булырга тиеш диләр. Искедә роман, драма, комедия вә ма әшбәһләрне ташлап, фәкать «әсәр» дип кенә йөретәселәре килә», – ди.

Х. әфәнденең сүзләрен, шул игътиразларын[3] – ут белән суның ни булганлыкларын белүдән нинди мәгънә, нинди файда чыга? Ут су булса ни дә, су ут булса ни? дигән игътираз белән бер дәрәҗәдә килешсез игътираз диясем килә. Чөнки драма белән комедия арасында шулкадәр тәфавет[4] бар, боларның өслүб вә ифадәләрендә дә бик зур аерма була. Берсе (комедия) фәкать көлдерү вә һәм җиңел гакыллы адәмнәрнең эшләгән эшләрен күрсәтү өчен языла да, икенчесе укучыларны (яңа сәхнәдә тамаша итүчеләрне) еглату, күңелләрен йомшатып, йөрәкләренә шәфкать вә мәрхәмәт хисләрен кую

[1] Тәнакызын – каршылыгын.
[2] Мөндәриҗатлары – эчтәлекләре.
[3] Игътиразларын – каршы килүләрен.
[4] Тәфавет – аерма.

өчен языла. Көлке белән еглауның ни икәнлекләрен аерып белүдән бертөрле дә мәгънә чыкмый торган булса, дөрес, комедия белән драмаларның ничек булганын аерып аңлаудан да һичбер төрле мәгънә вә файда чыкмас!

Әллә Х. әфәнде әсәрләре гел еглата торган, яки гел көлдерә торган рәвештә генә языласын, диме?

Драма вә комедияләр, гомумән һәр әдәби әсәр, тормыштан вә тормышта булган яки була торган вакыйгалардан алынып языларга тиеш булачагыннан, алай булуы тагы мөмкин түгел. Чөнки тормышта төрле хәлләр бар. Һәм андагы вакыйгалар күбесе бөтенләй маһиятьләре[1] белән үк бер-берсенә башка булалар. Моның өстенә ул хәлләрне тудыра торган сәбәпләр үзләре дә төрлечә була.

Инде үзләрендә мәүзуг һәм сәрмая[2] ителеп алынган вакыйга вә хәлләр, шуның өстенә анларның сәбәпләре дә шулай бөтен маһиятьләре белән бер-берсенә тәмам башка булгач, «Алдым-бирдем»нең драма, «Җәмгыять»нең комедия икәнен белүдән нигә файда чыкмасын? Әлбәттә, чыга. Һәм дә бик күп файда чыга.

Маһиять вә затның башкалыгы, җенеснең төрлечәлеге, әлбәттә, «исем»нең төрлечә булуын да лазем итә. Шуның өчен, инсаннар арасында, һәр тугрыда да, ике төрле исем йөртелергә мәҗбүрият күрелгән: «Исме гам[3]» вә «Исме хас[4]». Бу ике төрле исемне ташлауның һич имкяны[5] да юк. Бу мәңгегә дәвам итәчәк. Мәсәлән, һәр адәм баласына үзләрен башкалардан аера торган хас исемнәрен (атларын) билкөлли[6] ташлап, барысына да фәкать «кеше» диеп кенә йөртү мохаль[7] дәрәҗәсендә шулай ук «алма» белән «бәрәңге»гә дә, хас исемнәрен ташлап, ялгыз «ашамлык нәрсәләре» дию була торган эш түгел.

Х. әфәнде мәкаләсенең соңындарак тагы болай ди: «Һәр мөхәррирнең әсәрләренең төрле кыйсемнәргә бүленүләре, тыш игътибары берлә булмыйча, бәлки аларда максат ителгән идеяләр игътибары белән булырга кирәк».

---

[1] Маһиятьләре – асыллары.
[2] Сәрмая – төп чыганак.
[3] Исме гам – уртаклык исем.
[4] Исме хас – ялгызлык исем.
[5] Имкяны – мөмкинлеге.
[6] Билкөлли – бөтенләй.
[7] Мохаль – абсурд.

Ярый, соң Гаяз әфәнденең «Алдым-бирдем»е илә «Җәмгыять»тәге идеясен сез бер төрле «идея» дип беләсезмени?

Һәм сез әле үткәндә генә: «Һәр әдәби нәрсәгә фәкать «әсәр» диеп кенә әйтелсен» дигән идеңез ич! Алай «идея» игътибары беләп әсәрләрне төрле кыйсемнәргә бүләргә тиеш булгач, ул кыйсемнәрнең һәрберсенә тагы аерым исем куярга тугры килмиме? Шул вакыт «драма», «комедия» дигән исемне үзеңез үк атаячак түгелсезме?

Тугрысы, югарыдан бирле сөйләп килгән дәгъваңызны шушы соңгы сүзеңез, бөтенләй астын-өсткә китереп кыра да ташлый.

Гәрчә Х. әфәнденең мәкаләсендә тагы байтак кына тәнкыйтькә лаек сүзләре булса да, тәнкыйтемнең бик артык озаеп китүеннән куркып, сүземне шушы урында кисүгә мәҗбүр булам. Ләкин актык сүзем уларак шуны гына әйтеп үтүгә мөсагадә кылуыңызны[1] үтенәм: әгәр дә без дөньяда аерым вә бәхтияр бер милләт булып яшәүне теләсәк, тел вә әдәбият мәсьәләсендә дә, башка тугрыларда да, бәгъзы берәүләр тарафыннан гына чыгарылган «яңа агым»нан бигрәк, гавам[2] тарафыннан кабул ителеп, күптән бирле эшкә куелып килгән «файдалы агым» тарафын тотарга, гавам илә бергә шул «агым»га таба йөзәргә тиешлемез.

Шуның өчен мәктәпләремездә дин вә фән дәресләренә ничек әһәмият биреп укыта торган булсак, милли телемезнең сарыф вә нәхүсенә, бәлягать вә әдәбият кагыйдәләренә шулкадәр, бәлки артыграк әһәмият биреп укытырга тиешлемез. Югыйсә мәктәпләремезне миллилек юлына корган, гомумән миллиятемезне вә милли телемезне саклый алган, аның тәрәккый вә тәкәммеленә хезмәт иткән булып табылмаячакмыз. Вәс-сәлам.

*Мөгаллим: Габдрахман Сәгъди. «Атау»*
*Шура, 1912, № 19, 20*

[1] Мөсагадә кылуыңызны – ярдәм итүегезне.
[2] Гавам – халык.

# ТАТАР ТЕАТР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ АНЫҢ ҮСҮ ТАРИХЫ

**Мөндәриҗә[1]:**

Театр әдәбиятының башка әдәбият формалары белән бәйләнышы; әдәби дәверләребез; театр әдәбияты кайсы дәвердә туды.

***Икенче дәвер һәм яңа әдәбият***. Аның икътисады, иҗтимагый шартлары, уяну, реформаторлык хәрәкәтләре, шуның сәбәп вә зәминнәре[2]. Татарчылык, төрекчелек агымнары. «Ысулы җәдит» хәрәкәтләре. Госманлы һәм рус әдәбияты белән таныша башлаулар. Яурупа, яурупалашу юлында беренче реаль хикәя. Татарда беренче драма. Аңа тәнкыйди караш. Мөндәриҗә ягыннан аның, киресенчә, икенче драма. Татарда беренче комедия. Яшерелгән җепнең очы табылды.

***Татар буржуасының иҗтимагый хәрәкәте***. Татар буржуазиясе үсә бара. Русчага тартылу. Җәдитчелек хәрәкәте көчәю. Идеология көрәшләре. Яшь татар буржуасының яңа дине. Милли, иҗтимагый реформаторлар. Искегә һөҗүм. Матбугатта гыйльми, әдәби көрәш.

***Театр әсәрләре тудыруда яңа тәҗрибәләр.*** Боларның зәмин вә сәбәпләре. Татарда сәнгатьле драма адымы. Бу адымның каһарманы. Аның әсәрләренә тәнкыйди караш. Сәүдәгәр драматургы, аның драмалары.

***1905 елдан соң.*** Революция дулкыны. Иҗтимагый-сәяси хәрәкәт. Татарда пролетариат, буржуа сыйныфы. Буржуаның көч алуы. Иске белән яңаның, «кадим» белән «җәдит»нең көрәше; ике лагерь. Бу көрәшнең матбугатта кыздырылуы. Тезмә әдәбиятта, лирикада искегә каты һөҗүм. Милли хисләр көчәю. Рус театры һәм рус әдәбияты тәэсире. Аннан яңа формалар керү. Татарда сәнгатьле театр әдәбияты үсә башлау. Анда мәүзуг[3] һәм мөндәриҗә. Һәр язучы үз әйләнәсен, үз күргәнен язды. Татар буржуа драматургларының әсәрләре ничек каршы алынды. Татар театр әдәбиятында пролетариат фронты.

[1] Мөндәриҗә – эчтәлек.
[2] Зәмин – җирлек, нигез.
[3] Мәүзуг – тема.

Бу фронтның беренче каһарманы. Аның әсәрләренә тәнкыйди караш. Реакция дәверендә әдәбиятта татар буржуа идеологлары. Беренче чыгыштагы әдәби манифест ничек җимеш бирде. Кара идеология өчен гыйльми-тарихи нигезләр эзләнү.

***Октябрьдән соң.*** Октябрьнең әдәбиятка тәэсире. Әдәбиятта пролетариат идеологиясе. Әдәбиятның оештыручылык хезмәте. Пролетариат идеологиясе сызыгында шул хезмәтне үтәүчеләр. Хикәяләр, романнар, лирикалар, театр әсәрләре. Октябрьгәчә театр әсәрләрендә эшче-крестьян тормышы, әдәби реакция. Октябрь әдип вә шагыйрьләрнең итәкләреннән тартты. Пролетариат идеологиясе белән сугарылган соңгы театр әсәрләре. Татар драма әдәбиятында Октябрь тәэсире белән яңа дәһрилек. Октябрьдән соңгы театр әдәбиятыбызның сәнгатьчә эшләнүе, тел-өслүб яклары. Гомерле тормыш типлары кирәк. Типлар аркылы икътисадлы сөйләшергә өйрәтегез. Балалар театры өчен язылган пьесалар. Театр әдәбиятыбызда тәрҗемәләр.

## I

Театр әдәбияты ул матур әдәбият формаларының соңгы үсү баскычы булып туа килгән. Иң элек тезмәләр – көйле сүзләр, әкиятләр, кыйссалар, лирика формалары, поэмалар (дастаннар), аннан соң хикәяләр, иң соңында роман, драмалар мәйданга чыккан.

Шигырьнең, әдәбияттагы формаларның бөтен кешелек дөньясында ничек туу һәм ничек тармакланып үсеп китү тарихы безгә шуны күрсәтә.

Бу эш бездә дә шулай булды: элек көйле сүзләр, тезмәләр, әкиятләр, кыйссалар, лирика формалары һәм хикәяләр тудырылды, шулардан соңгы үсү баскычы булып драмалар килеп чыкты.

Шуның өчен драмаларны әдәбиятның, әдәби хадисәләрнең башкаларыннан бөтенләй аерып алып, тик аларның үзләрен генә тикшерү уңайсызрак бер нәрсә. Бу, гомумән, идеологиянең тәрәккыйсе, аның икътисади, иҗтимагый нигезләре ягыннан да шулай. Шунлыктан мин мәкаләмдә драма әдәбиятыбызны башкалары белән бергә баглабрак бару юлын тотачакмын.

## II

Татарның 16 нчы йөздән соңгы көрәш тарихы өч зур дәвергә аерыла:

1) 19 нчы йөзнең соңгы ярымынача булган бер дәвер. Татарның иҗтимагый-фикри хәрәкәт тарихын дәверләргә аеруда соңгы уңышлы сызыкларны күрсәтә алган Галимҗан иптәш Ибраһимовның атамасы белән әйтсәк, бу дәверебез «кадим Шәрык» дәвере була. Моны, икенче төрле әйткәндә, феодаллык, алпавытлык нигезендә, шуның коллыгында яшәү дәвере дияргә дә мөмкин.

2) 19 нчы йөзнең ярымыннан Октябрь революциясенәчә (1917 елгача) булган бер дәвер. Бу инде татарның феодаллыктан капиталистлыкка, буржуалыкка омтылу, шуңа әйләнү дәвере. Бу дәвер «җәдит»лек, яңару, яурупалашу һәм татар буржуазиясенең динимилли хәрәкәте дәвере булып үсте.

3) Октябрьдән соңгы дәвер. Октябрь революциясе белән ишеге ачылган бу дәвер буржуалыкны, буржуа капиталистлыгын җимереп, хосусый коммунизм тормышын төзергә керешү дәвере.

**III**

Менә шушы өч төрле дәвернең берничәсендә без татарда театр әдәбияты тудырылганны белмибез. Гомуми хәлләр ягыннан карганда Русиядәге крестьяннарның җиргә беркетелгән, «крепостное право»ның мәйданга чыккан (XVI–XVII йөзләрдә), Русиядә шәһәр хуҗалыгы башланып, натураль хуҗалыктан бакча хуҗалыгына күчелгән, сәүдә капитализмы башланган (XVII йөздә) һәм дә шушы нигездәге Русия падишаһлыгының татар крестьян халкын икътисади яктан да, иҗтимагый вә мәдәни яктан да аерым рәвештә изү сәясәте йөртелгән бу беренче дәвердә татар дөньясы театр әдәбияты шикелле андый бер әдәби форманың хәтта дөньяда бар икәнен дә белми; ул вакытларда аның моннан бөтенләй хәбәре дә булмый (иске мәдрәсәләрдәге бәгъзе бер драмага охшаш уеннар моңа башка нәрсәләр, аларны әдәби мәгънәдә алып булмый).

Чөнки бу дәвердә татар тормышының икътисади, сәяси, иҗтимагый вә мәдәни шартлары аны «кадим Шәрык» идеологиясенә нык баглап, шул идеологиянең телдә гәүдәләнү формаларын да нәкъ шәрык методына суктырды. Икътисади, иҗтимагый хәлләре аны тәмам Шәрык калыбына салуга мәҗбүр иттерде. Чөнки татарның икътисади бавы бер яктан сахра халкы, Урта Азия, Бохара белән бәйләнеп барды. Шул сәбәпле татарга идеология орлыгы, мәдәният йогынтысы, әхлак, фәлсәфә, әдәбият та шул яктан килә торды.

Әдәбияттагы идеология шикелле, аны сурәтләндерүче әдәби форма, тел, өслүб ягыннан да бу дәвердәге татар әдәбияты Шәрык, Урта Азия сызыгында нык торды. Үзен рус–Яурупа тәэсиреннән күп заманаларгача читтә тотып килде.

Шуның өчен без бу дәвердә баш-аягы белән Шәрык, Урта Азия тибындагы дини, хыялый кыйссалар (хикәя түгел), дастаннар (поэма) һәм суфилык-дәрвишлек рухындагы тезмәләрдән артыкны күрә алмыйбыз. Ул вакытларда әле хәзерге хикәя, роман формалары да, драма формалары да татарда тудырыла алмый.

Татарда хикәя, романнар шикелле театр әдәбияты тудырылуның да башлангыч галәмәтләрен без икенче дәверебезнең беренче илле елы эчендә күрә башлыйбыз. Бу дәвернең икенче илле елының беренче уны эчендә инде чын мәгънәсе белән сәхнәгә куярга ярарлык сәнгатьле татар драма әдәбиятының беренче үрнәкләре мәйданга чыга һәм шулар белән татар драма әдәбиятының сәнгатьчә тәрәккый юлы ачылган, шуның төп нигез ташлары ныклап салынган була.

**IV**

Русиядә татар халкының икътисади, сәяси, иҗтимагый вә мәдәни тормышлары 16 нчы йөздән башлап, хәзергәчә күп яктан түбәндә бөтен Русиядәге икътисади, сәяси, иҗтимагый вә мәдәни хәлләрнең гомуми барышлары белән бәйләнеп, шулар тәэсире астында була килде. Бу хәл әле дә шулай дәвам итә.

Русиядә 19 нчы йөзнең соңгы ярымында башланып, киңәеп киткән гомуми икътисади, сәяси, иҗтимагый шартлар, шиксез, татар халкына да үзенең тышкы тәэсирен күрсәтә башлый. Шундый шартлар астында туып килгән яшь татар буржуа сыйныфы, татар мещаннары үзенең эчендә реформаторлык хәрәкәтләре башлаттыра. Дини, гыйльми, мәдәни яңалыклар сорый башлый.

Бер яктан, Яурупа-рус тәэсире белән нык очрашу, капиталистлык юлына төшү, икенче яктан да үз эчендә шуны кирәксенү, шуңа психологик бер хәзерлек ясалып өлгерү татар буржуазиясеннән шундый яңалыкларны нык таләп иттертә. Нәтиҗәдә, яңа иҗтимагый-фикри хәрәкәтләр кузгала, төрле яктан уянулар, яңару – «җәдит»ләнүләр, реформаторлыклар башлана.

Яңалык, реформаторлык бездә бигрәк өч яктан кузгала: 1) әдәбигыйльми, 2) дини-әхлакый, 3) тәрбияви.

Әдәби-гыйльми реформаторлык хәрәкәтенең көчле һәм беренче баш каһарманы, юлбашчысы булып Каюм Насыйри, дини реформаторлыкның каһарманы булып та Мәрҗани мәйданга атыла. Тәрбияви реформаторлыкның, тагын да дөресрәге, татарда мәктәпләр, мәдрәсәләр реформаторлыгының баш каһарманы булып Хөсәен Фәезхани (1866 да вафат) килеп чыга; шул юлда ул нык хәрәкәт башлый (ләкин эшен уңдырып чыгара алмый – вафат була; соңыннан, XX йөздә аның башлаган эшен башкалар дәвам иттереп алып китәләр. «Хөсәения», «Буби», «Галия», «Мөхәммәдия»челәр кебек).

Каюм Насыйри белән телдә, әдәбиятта татарчылык агымы да туып, шуңа каршы Гаспринский юлбашчылыгы белән Кырым ягыннан, Кара диңгез буйларыннан төрекчелек агымы кузгала. Мәрҗани, Каюм Насыйри, Гаспринскийлар тәрбияви реформаторлыкта өчесе дә нык тәэсир күрсәтәләр. Габделхәбир әл-Мөслими[1] кебекләр дә шуларның ярдәмчеләре була.

Татар буржуазиясе эченнән шуларны куәтләүче, яклаучы адәмнәр дә чыгалар. Җәдитчелек, «ысуле җәдидә» хәрәкәтләре киңәя бара. Төрле шәһәрләрдә байлар башлангыч «ысуле җәдидә» мәктәпләре ачарга керешәләр. «Ысуле җәдидә» мөгаллимнәре гөруһы», «җәдитче» интеллигентлар баш күтәрә.

Шулар өстенә госманлы һәм рус әдәбиятын уку, шулар белән шөгыльләнү һәм шулар аркылы яңа әдәби формалар белән таныша башлау хәрәкәтләре дә кузгалган була. Бара торгач, көнбатышлылар (гареблеләр) формасында сентиментализм, рационализм рухындагы хикәяләр, драмалар тууның зәминнәре хәзерләнә.

Татар дөньясында кузгалган шушы иҗтимагый-фикри хәрәкәт нәтиҗәсендә татарның үз тормышыннан алынып, Муса Акъегетзадә[2] дигән бер татар зыялысы тарафыннан татарда беренче мәртәбә роман языла. «Хисаметдин менла» исемендәге бу роман 1886 елда басылып та чыга.

Шулай итеп, рус мәктәпләрендә укыган, яурупалашкан һәм фикер-мәсләктә Исмәгыйль Гаспринский юлын тоткан бу мөхәррир та-

[1] Габделхәбир әл-Мөслими (1824–1879) – татар зыялысы, Ш. Мәрҗанинең укучысы.

[2] Муса Мөхәммәдҗан улы Акъегетзадә (1864–1923) – татар язучысы, мәгърифәтче. XIX йөзнең II яртысында иҗат ителгән беренче татар романнарыннан «Хисаметдин менла» авторы.

тарда беренче мәртәбә көнбатыш ысулында роман язучылык юлын, шулай ук реализм ишеген ачып биргән булды. Шул ук вакытта моның белән татар драма әдәбияты туу өчен дә зәмин хәзерләшелгән, юл күрсәтелгән булды.

Хикәяләр белән бергә үк татар буржуазиясенең иҗтимагыйәдәби хәрәкәте һәм дә шушы сыйныфның яңаруы, яурупалашу кузгалышы татар драма әдәбияты тудыруны яисә татарның буржуа тормышын драмаландыра башлауны да ашыктырды.

Нәтиҗәдә Казанда Габдрахман Ильяс[1] дигән (Галиәсгар Камалның риваятенчә, халык телендә Дәмин хаҗи Габдрахманы дип мәшһүр булган) җәдитче бер драматург аркылы татар дөньясында драма әдәбиятының иң беренче тарихи адымы атланды. 1887 ел, 27 октябрьдә («Хисаметдин менла» хикәясеннән бер ел соң) кечкенә генә кулда, 24 бит зурлыгында «Бичара кыз» исемендә дүрт пәрдәлек «драм» басылып чыкты. Габдрахман Ильясиның шушы драмасы, Галиәсгар Камалның биргән мәгълүматына күрә, шул ук вакытларда мөхәрриренең үзенең өендә чаршаулар корып уйнап та каралган була. Татар дөньясында шушы беренче драманың беренче артисты да Габдрахман Ильяс үзе булган булса кирәк дип уйлана. (Рәшит казый Ибраһимовның[2] беренче җүз «Миръат» («Көзге»)сендә әйтелүгә караганда, Касыймда 1900 елларга кадәр үк Касыйм шәһәрендә рәсми театр уйналган була. Әнә шунда уйналган әсәрләрнең берсе шушы «Бичара кыз» булуы бик мөмкин).

Татар драма әдәбиятының бу беренче карлыгачы турында бу урында озаграк туктала төшәргә мәҗбүрбез. Чөнки беренче тарихи адымнарга тиешле бәһане биреп үтәргә кирәк. Бу – безнең зур бурычыбызның берсе. Укучыларның да бу беренче адымга күбрәк тукталуыбызны сораячаклары табигый.

Әсәрнең мөндәриҗәсе болай:

«Кара» надан бер татар баеның Маһитаб исемле «бик матур» бер кызы була. Әти-әнисе аны икенче бер «бик бай кеше»нең «ямьсез, аңгыра» бер улына бирмәк булалар. Кыз моның өчен кайгыра.

[1] Габдрахман Мөхәммәдәмин улы Ильяси (1856–1895) – мәгърифәтче, драматург, археограф. Китап рәвешендә басылып чыккан беренче татар драма әсәре – «Бичара кыз» авторы.

[2] Габдерәшит Гомәр улы Ибраһимов (1857–1944) – дини һәм сәяси эшлекле, мәгърифәтче. «Миръат» («Көзге») дип аталган журнал тибындагы китаплар һәм брошюралар сериясе нашире, мөхәррире.

Газетлар укый торган, үзе тәрәккыйче Җанбай исемле «бик яхшы гына галим бер егет» үзенең бер дусы аркылы бу хәбәрне ишетә дә, Маһитабны бу һәлакәттән коткару чарасына керешә.

Маһитаб янына кияү ябабыз дип, теге «ямьсез, аңгыра» бай малаен көтеп торган чакларында ишектән Җанбай килеп керә. Чаршауны ачып, кыз янына бара. Аны бу бәладән коткарырга килгәнен әйтә. Икенче яктан, кияү килде бугай, дип килеп кергән яучы карчык, бу хәлне күреп, кызның әти-әниләренә чыгып әйтә. Кыз белән Җанбай кочаклашып торалар. Шул вакытта кызның әтисе белән әнисе, яучы карчык, асрау кызлары дүртәү килеп керәләр дә, боларның кочаклашып торганнарын күреп, моңа хайран калалар. Җанбай кызның әти-әниләрен бу җинаятьләре өчен каты сүгәргә, кыздырырга тотына.

Шул арада кызга кияү булачак теге «ямьсез, аңгыра» бай малае килеп керә. Үзе бөтенләй исерек бер хәлдә, кияүне каршы алмаганлыклары өчен лыгырдап, абына-сөртенә килә. Үзенә хатын булачак Маһитабның Җанбай белән кочаклашып торганын күрә дә, Җанбайга бәйләнә башлый. Җанбай аны кызга якын җибәрми. Маһитаб исә һаман Җанбай куенына керә барып, аннан үзен тегеңә бирмәвен сорый. Кызның атасы бу хәлгә чыдый алмый, кыз янына килеп сүгә, аны орыша башлый. Җанбай аңа каршы каты усал тел белән җавап кайтара. Кызга да «дөньяда вә ахирәттә» үзе белән бергә булачагын әйтеп, аны юата. Кызның атасы моңа тагы аптырап кала. Кияү булачак теге бай малае һаман исерек хәлдә бер асрау кызга, бер Маһитабка таба килергә маташа. Ахырда ул бик каты исереклегеннән егыла да, сүгенә, янаша башлый; Маһитабка «талак» дип кычкыра, кыз моны ишетеп шатлана. Җанбайга «мин синеке» дип куана. Җанбай да «минеке булдың» дип, Маһитабны кат-кат үбә башлый. Бу хәлне күреп, кызның атасы һәм башкалар, «авызына бармагын кабып», исләре китеп торалар.

Шуның белән соңгы – дүртенче пәрдә төшә.

Бу беренче татар драмасына инде үзәк тәнкыйди бер караш ясап карыйк. Әсәрнең техника яклары, әлбәттә, хәзерге тәнкыйтьчеләр карашында бик түбән. Күп җитешсез. Әсәрдә тип диган нәрсәне эзләргә дә, сорарга да ярамый инде. Тик шунысы бар: монда бик яхшы, табигый, реаль бер характер бирелә ала. Ул да булса имче карчыкның характеры. Төгәл үк булмаса да, һәрхәлдә, мондагы

Сахибә карчык (имче карчык) характеры аркылы бар татар имче карчыкларының да уртак кайбер сызыкларын күреп кала алабыз. Бу карчыкның сүзләре, хәрәкәте, эше, мөгамәләсе, итенеше-кыланышлары да бер-берсе белән яраша ала. Монда арттыру, көчләнү дә юк. Ул безгә чынында ничек булса, шулай күренә ала.

Байның кызы Маһитабка килгәндә болай: аның аркылы мөхәррир үзе көчләнеп, яңа бер табигать бирергә маташкан, иҗтимагый аңы ачылган, үткен, батыр табигатьле яңа бер туташ ясап чыгарырга тырышкан. Нәтиҗәдә ясалма бер Маһитаб килеп чыккан.

Менә моның белән мөхәррир кызны госманлы тәсаувыф шагыйрьләреннән Исмәгыйль Хәккыйның «Мәгърифәтнамә»сен укып, тәсаувыфның илаһи-фәлсәфи фикерләре белән әшнә булган бер кыз – укымышлы бер кыз хәленә куя. Хәлбуки кызның укымышлы булып үскән бер кыз булу процессы пьесаның һичбер урынында күренми. Кызның:

– Миңа ир зәхмәте тигән, – дигән кебек урынсыз сүзләре дә юк түгел. Икенче яктан, кызның Сахибә карчык белән сөйләшкән сүзләреннән аның им-томга, сихер кебек нәрсәләргә нык ышанучы бер кыз икәне ачык күренә. Монысы, әлбәттә, ул вакыттагы шундый кара гаилә эчендә тәрбияләнгән бер кызда күрелү табигый.

Җанбай белән кызның кочаклашып, бер-берсенә мәхәббәт, иптәшлек игълан итешү кебек хәлләре дә процессыз күренәләр. Ягъни болар кайдан болай әле бер-берсенә якынлашып алган булалар. Хәлбуки кыз бервакытта да Җанбайны аныңча теленә алмый, берәр мәртәбә генә булса да исемен әйтеп үтми.

Җанбай дигән «бик яхшы гына галим бер егет»нең дә кызны коткарырга дип чыгып китүе дә алдан хәзерлексез. Кинәт, гайре табигый (процессыз) булган бер хәл.

Пьесаның менә шуның кебек күп кимчелекләре бар. Хәзерге үлчәүгә салып әйткәндә, мөндәриҗә ягыннан да, техника ягыннан да моны сәхнәгә куелырлык чын бер пьеса дип әйтеп булмый, әлбәттә, дөресен әйткәндә болай: бу «драм» – берәр өйдә чаршаулар корып эшләү өчен төзелгән җиңел диалоглардан, җиңел, катлаусыз хәрәкәтләрдән оештырылган, әле җитлегеп тумаган бер уен китабы гына.

Ләкин шунысы бар: бу пьеса – яңа икътисади шартлар эчендә матди тормышта, идеологиядә иске «төрки»лектән, Урта Азия

чыгтай тәэсиреннән котылу юлына төшеп, Яурупа тәэсиренә әйләнергә итә башлаган яңа бер тормыш әдәбиятының драма ишеген иң беренче мәртәбә башлап ачып биргән иң тарихи бер уен китабы ул. Тагын да чынын әйтсәк, бу – иске, надан татар байларының тормышы белән яңа гына баш күтәрергә итә башлаган яшь татар буржуазиясе тормышы арасында көрәш башлануның иң беренче тарихи сигналы иде.

Бу ике тормыш арасында чын көрәш сәгате шуның белән суккан булды. Без монда Җанбай кебек замана гыйлемен, Яурупа белемен ала башлаган һәм газетларда укый торган татар хатын-кызларының хокуларын таләп итү, шуны саклау фикере башларына кергән «бик яхшы гына галим бер егет»ләрне очрата башлыйбыз инде. Драманың баш каһарманы Маһитабның да татар кызларын, кызның үз ризалыгыннан башка үзе сөймәгән егетләргә көчләп кияүгә бирү гадәтенә каршы беренче мәртәбә каты һәм гамәли бер юл белән протест ясаучы бер каһарман булып чыкканын күрәбез. Аның үзалдына сөйләнеп:

– Юк, Маһитаб, көлмә, көлмә... җыла, җыла... уф! Мине Җантимергә (үзенең барырга теләмәгән бай малаеның исеме) бирсәләр, мин ул вакыт ни эшләрмен? Юк! Юк! Бармам, бармам... минем ризалыгымнан башка бирмәсләр! Аһ, гүзәл кыз, гүзәл кыз! Чынлап укмы син шул кабахәт Җантимер куенында булырсыңмы? Аһ, минем бу сөалемә җавап бирүче бер дә юк... Аһ, җавап, җавап... – дигән сүзләре дә бит татар кызының беренче кузгалышындагы беренче гыйсъян сүзләре.

Вакытында бу драма халык арасында көчле бер тәэсир, зур гына бер йогынты да калдыра алган. Моны да без икенче бер аның тугагы булган «драм» аркылы күрәбез.

Габдрахман Ильясиның шушы «Бичара кыз» драмасы татарда үзе артыннан икенче бер драманың тууына да сәбәп булган, шуңа юл ачкан. Димәк, ул үзенә ияргүчеләр дә тудыра алган була.

Бу икенче драма да Фатих Халидинең[1] кечкенә кулда 30 бит зурлыгында «Рәдде бичара кыз» дигән китабы булып, «Бичара кыз» драмасыннан өч ел соң языла һәм 1890 елда май аенда басылып чыга.

[1] Фатих Хаммат улы Халиди (1850–1923) – мәгърифәтче әдип, тәрҗемәче, татар язма әдәбиятында драматургия жанрына нигез салучыларның берсе.

Бу пьесада:

– «Теге драм “Бичара кыз” китабында әйткән»,

– «Маһитаб, Җантимерләр кыйссасы»,

– «Ник бирсен Әхмәд бай Фәрханәне Ислам мулла углына? Ахрысы матур дип барырга Фәрханә җүләр түгел, матурлыгына кызыгып, бер ярлыга барырга. Ул теге “Бичара кыз китабы”нда әйткән: “Маһитабка туй булгач, кияү кергән кичне Маһитаб Җантимерне ямьсез дип, Җантимердән аерылып, Җанбайга муллалыгы бар, үзе дә матур, ярлы булса булсын, Җанбайга барам, дип язган. Мин, кунаклар бу Маһитабны, ямьсез дип, бай егеттән аерылып, матур дип, бер ярлы егеткә барганына бер дә ышанмыйм, ахрысы, бу була торган эш түгел. Хатыннар сөяр байны, ирләр сөяр сауны, дигәннәр. Бай иргә бару бик кыйбат. Әгәр нәфесе теләгән кеше бай иргә баргач, кирәк булса, матур егетне табып була” – дип, Мәхмүд бай хатыны елмаеп көлде», дигән кебек, «Бичара кыз» китабына таянып әйтелгән сүзләр очрый (4, 5, 6, 15, 23 нче битләрдә).

Андагы менә шундый сүзләр, бер яктан, Габдрахман Ильясиның «Бичара кыз» драмасы һәм андагы вакыйганың халык арасында үрнәк, гыйбрәт ителеп йөртелгәнен күрсәтсә, икенче яктан да, «Рәдде бичара кыз»ның аңа каршы бер юл белән язылганын ачып бирә. Мәхмүд бай авызыннан сөйләтелгән сүзләр шуны ачык белдереп торалар.

Г. Ильясиның «Бичара кыз»ы шикелле үк, «Рәдде бичара кыз» да – тарихи яктан әһәмиятле бер әсәр. Әсәрдә Ф. Халиди пәрдәләрне дә «действие» дип йөртә. Моннан аңа рус тәэсире көчлерәк булганны аңлап була.

Ф. Халидинең бу драмасыннан башка тагы басылуы өчен 1905 елда 6 нчы июньдә рөхсәт алынып, шул ук елда басылган биш пәрдәлек «Морад Сәлимов» дигән «драм»ы (кечкенә кулда 40 бит) белән, шул ук елда 7 мартта рөхсәт алынып, 1906 елда басылган алты пәрдәлек «Мәхрүсә ханым» исемле драмасы да бар (бусы кечкенә кулда 48 бит зурлыгында).

Аның бу драмалары «Сәйяр» труппа тарафыннан уйналганнар да.

«Морад Сәлимов»ның 1908 елда уйналуы «Әлислах»ның шушы елда чыккан 38 нче санында «Казак» дигән кушаматлы берәүнең тәнкыйтендә әйтелеп үтелә. Шул уңай белән бу әсәр турында шушы түбәндәге сүзләр дә языла:

– «...11 июльдә Эрмитаж бакчасында тамашага “Морад Сәлимов” дигән бер нәрсә куелган иде, мин аның хакында тәнкыйть күтәрерлек бер муаффәкыять тә таба алмадым, шуның өчен аны бик кузгатырга да муафикъ күрмимен. Ул шул көенчә исе чыкмыйча гына ятсын да калсын».

Әсәрнең тәмам сәнгатьчә эшләнә алмавы һәм техникасы начар булу ягыннан, әлбәттә, бу әсәр муаффәкыятьле түгел, шулай булса да, Ф. Халиди драма язу техникасында шушы соңгы ике драмасы аркылы «Рәдде бичара кыз»ны язган вакыттагыга караганда күп тәрәккый ителгәнлекне күрсәтә. Бу әсәрнең икесе дә алган мәүзуглары, мөндәриҗәләре ягы белән әһәмиятлеләр. Болар шул дәвердә русча, французча укырга, гыйлемгә, мәдәнияткә, яңаруга омтылучы «җәдитче» яшьләр белән[1]) «кадим» татар байлары арасындагы моментларның берсен күрсәтәләр. Иҗтимагый тарихыбызны тикшерүчеләр өчен боларның әһәмиятләре тагы да зур. Һәрхәлдә, хәзердә боларны «исе чыкмыйча гына ятсын да калсын» дип, аска күмеп ташлау ахмаклык булыр иде.

19 нчы йөзнең ахырларында без, югарыда әйтелгәнчә, «Бичара кыз», «Рәдде бичара кыз»лар шикелле «драм»лар белән генә дә калмыйбыз әле. 1894 елда 7 июньдә рөхсәт алынып, 25 июньдә Казанда Домбровскийның «табгыханә»сендә (типографиясендә) басылган «Комедия» исемле бер комедияне дә күрәбез. Китапның башына «Комедия Чистайда» дип куелган.

Кечкенә кулда 28 бит зурлыгында өч пәрдәдән гыйбарәт булган бу комедия үзенең теле, өслүбе, инша техникасы белән үзенә игътибарны аеруча тарта. Шуның өстенә хәтта чын типка якынлатып ук кайбер табигатьләрне әдәби эшләп чыгаруы белән дә йөзне кызартмаслык бер әсәр. Үзе алынган мәгълүматларга күрә, төрле җирләрдә һәвәскәрләр тарафыннан уйналгалаган була.

Гәрчә мөндәриҗәсе ягыннан сыеграк булса да, матур, табигый язылуга бу комедия хәтта Галиәсгар Камалның комедияләре артыннан тәпәйләп ияреп китә алырлык бер дәрәҗәдә дияргә мөмкин.

[1] Драманың баш каһарманы булган Морад Сәлимов үзендә риязият, табигыят, фәлсәфә кебек төрле фәннәр укыла торган бер мәдрәсәдә «хәтме көтеб» кылып (укыла торган барлык фәннәрне укып бетеп), соңыннан Парижда университет бетергән һәм «алтын нишан диплом» алып кайткан бер фәкыйрь егет була. Үзе кайткач, берәр байга керергә урын эзли. – 21. *(Авт. иск.)*

Үкенечкә каршы, бу комедиянең мөхәррире кем булганын ачык белә алмадык. Китабында моңа бер ишарә дә юк. Ничек булганда да моны язучы кеше тиктән тик бер адәм булырга охшамый. Аны талантсыз, тәҗрибәсез, гади бер каләм тибрәтүче генә дип тә уйлап булмый, аның инша техникасын яхшы белүе һәм тыныш билгеләрен дә һәр төрләрен урынлы куя белүе аның тәхрир эшендә[1] тәҗрибәсе булуын, әдәбияттан да яхшы ук хәбәре бар икәнен күрсәтеп тора.

Әдәби телебезнең эшләнүе, тәрәккыйсе һәм аның кайсы дәверләрдә башланып китүе, гомумән, әдәби тарихыбызны ачык аңлау өчен кирәкле таянычларның берсе булган бу комедияне мин хәтта хәзердә дә бастыртып тараттырырга, шулай итеп, әдәби телебезнең баш документларын көтебханәләребездә берәр нөсхәсен генә булса да булындырырга тиеш дип беләм.

Нәтиҗә:

Югарыда драмаларны тикшерү нәтиҗәсендә, мин шундый ачык бер фикергә килдем: бездә хикәяләр язу һәм алар аркылы реализм сукмагын салу Муса Акъегетзадәләрдән башланган булса, драма язу һәм алар аркылы драма вә комедияләребездә чын реализм юлы сызылу Габдрахман Ильяси, Ф. Халиди һәм язучысы мәгълүм булмаган әлеге «Комедия»ләрдән башланган икән. Шулай ук матур әдәбиятта татар әдәби телен башлап, шуның нигезен салып җибәрүчеләр дә шулар, бигрәк тә соңгы өчесе булганнар икән.

Шуның белән бергә, бу әсәрләр аркылы телдә, өслүбтә Гаязлар кебек соңгы татар буржуазиясе язучыларының юлбашчылары, остазлары да шулар булганы тәмам ачылганлыкны күреп, яшерелгән җепнең очын табып утырабыз.

## V

Татарда эре сәүдәгәрләр, фабрикантлар, алтын чыгаручылар, завод тотучылар күбәеп, татар буржуасы һаман үскәннән-үсә барган кебек, ул икенче яктан рус буржуасының мәдәни дөньясында якынайганнан-якыная бара. Бай балалары, мирза кызларының һәм шәһәрдәге мулла балаларының рус мәктәпләренә, гимназия, университетларга тартылулары күренә башлый. 70 нче елларда татарлар өчен ачылган «Учительская школа» да татарларны рус дөньясына, рус мәдәнияте һәм рус әдәбиятына якынайтышуга ярдәм итешә.

[1] Тәхрир эшендә – язу, язучылык эшендә.

Икенче яктан, татар мәдрәсә шәкертләрендә дә шушы мәктәпкә керергә җилкенүләр сизелә башлый, Мәрҗани һәм Каюм Насыйрилар да шул мәктәп тирәсендә, Радлов[1] кебек тюркологлар янында йөриләр. Аннан татарга файдалырак нәтиҗәләр бирдертү юлында тәэсир итешәләр, шунда мөгаллимлек кылалар.

Татарда җәдитлек һаман да көчәйгәннән-көчәя, киңәйгәннән-киңәя бара. «Кадим» белән «җәдит»нең соңгы каты көрәшләре хәзерләнә. Моның да Казанда беренче оясы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе була.

Бер яктан, Каюм Насыйриның әдәби идеологиясе, икенче яктан, Мәрҗанинең Курсави нигезенә салынган дини-фәлсәфи идеологиясе, дини-мәдәни уяну дәвам итә.

Нәтиҗәдә шушы идеологиянең һәм шушы яңаручылыкның Акмулла аркылы, беренче мәртәбә башлап, көйле шигырьләргә, тезмәләргә дә килеп кергәнен күрә башлыйбыз. Соңыннан Заһир Бигиевнең дә шул юлда романнары чыгалар.

Шулар рәтеннән үк тагы драма формасында яңарак әдәби әсәрләр тудырылу хәрәкәтләре дә бара. Югарыда әйтелгәнчә, татарда «Комедия» исемендә беренче комедия дә язылып басыла.

Феодалчылык, боярчылык, мирзачылык идеологиясенә каршы көрәш кузгаткан татар буржуазиясе инде өстенлекне, хакимиятне бөтенләй үзенә сорый. Яшь буржуа өчен бу юлдагы көрәштә гыйльми көчләр дә хәзерләнә, Төркия, Мисырларда укып кайтучылар, яисә Төркия, Мисырның ачык фикерле дин галимнәренең әсәрләрен укып, шулар аркылы фикерләрен ачучы татар дин галимнәре арасыннан татар буржуазиясенең идеологиясен күтәреп килүче, шуны яклаучы тагын да батыррак яңа динле реформаторлар да (Рәшид казыйлар, Ризалар, Муса вә Зыялар кебек адәмнәр) җитешәләр. Шулар аркылы Хөсәен Фәезханиләрнең кузгаткан нигезләрендәге мәдрәсәләр реформасы башлану сәгатьләре дә якынлаша килә. Дини-милли хисләр дә һаман үстерелә, көчәйтелә бара. Мөселман төрекчелек агымы галәбә кыла[2], шуның байрагы күтәрелүгә хәзерләнелә.

---

[1] Василий Васильевич Радлов (1837–1918) – шәркыятчы галим, төрки телләр белгече, этнограф, тәрҗемәче. Төрки телләрне чагыштырма-тарихи өйрәнүгә нигез салучыларның берсе.

[2] Галәбә кыла – өстенлек ала.

Татар буржуазиясе инде динне үзенә гыйльми буяулар белән матурлап, корал иткән хәлдә, шушы байрак астында иске феодалчылык тормышына, аның борынгы ямьсез гадәтләренә, традицияләренә каршы соңгы каты көрәшкә тотына.

Көрәш тә гыйльми, әдәби юлдан бара, вакытлы матбугатта үзенең «Тәрҗеман» газетасы аркылы Исмәгыйль Гаспринский[1] шуңа юлбашчылык итә, командалык кыла, Кавказ матбугаты аңа юлдаш булып, ярдәмгә җитешә.

Даими матбугатта бу көрәш, бер яктан, Рәшитнең «Миръат»лары һәм башка әсәрләре, Ризаның «Асар»ы кебек гыйльми-тарихи әсәрләр аркылы ачык күрелсә, икенче яктан, «Фирәнгстан мәктүбләре», «Дар әр-рәхәт мөселманнары», «Мәгыйшәт», «Әсма», «Сәлимә», «Җиһангир мәхдүм», «Шәкерт белән студент» шикелле хикәяләр, «Себер тимер юлы» шикелле тезмәләр аркылы матур әдәбиятта үзен нык чагылдыра башлый.

Бара торгач, яшь буржуа, иске феодал тормышыннан, аның урта гасыр нигезендәге иске гаилә төзелешеннән һәм яңа туып килгән яшь буржуа теләгән яңалыкларга аның каршылык күрсәтүеннән, аның реакционерлыгыннан, тәгассыбыннан[2], наданлыгыннан көләсе килә. Шушы тормышның иҗтимагый фаҗигаларын, трагедияләрен әдәбиятта төрле юллар белән ачып бирә башлауны кирәксенә. Икенче төрле әйткәндә, яшь, вак татар буржуа нәселендә шуларны сәхнәдә терек хәрәкәтләр аркылы көлкеле, фаҗигалы, аянычлы кылып күрсәтергә омтылулар башлана. Шулай итеп, яшь буында яңа психология туа. Шуңа уңайлы зәмин дә хәзерләнеп өлгергән була. Кыскасы, ничек булганда да яшь буржуаны иске феодал карашлардан, иске гадәтләрдән биздерү, аны яңа техника нигезендәге яңа капитализм тормышына яракландыру, шуңар уңайлану, шушы нигездәге яңа мәдәният юлына төшерү һәм яңа рус-яурупа гадәтләренә таба авыштыру хәрәкәтләре һаман көчәйгәннән-көчәя бара. Бу юлда төрле чаралар күреләә башлый. Ахырда шушы иске тормышны һәм иске тормыш белән яңа тормышның көрәшүләрен драма рәвешендә

[1] Исмәгыйль Мостафа улы Гаспринский (1851–1914) – җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, педагог, нашир. Сәяси, фәнни һәм әдәби «Тәрҗеман» газетасының нашире һәм мөхәррире. Бөтенроссия мөселманнары съездларын һәм «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясен оештыручыларның берсе.

[2] Тәгассыбыннан – фанатизмыннан.

шигъри бер калыпка салып, җанлы хәрәкәтләр аркылы күрсәтергә җилкенүнең яңа практик галәмәтләре килеп чыгалар.

**IV**

Иске феодалчылык, шәрыкчылык нигезендә яшәп килгән надан татар байлары гаиләсендәге бозык иҗтимагый тормыш фаҗигалары татар дөньясында Габдрахман Ильяси аркылы беренче татар драмасын тудырткан булсалар, инде бу хәлләр шул башланган эшнең яңарак, тулырак бер юлда дәвамын сорый һәм шуны ашыктыралар, нәтиҗәдә «Бичара кыз», «Рәдде бичара кыз», «Комедия» кебек әсәрләрнең җитешкәнрәкләре чыгалар, бу юлда тагын да яңарак тәҗрибәләр эшләнә башлый.

Татар дөньясында әдәбиятның бу яңа формасы иң элек башланган чагындагы кебек, соңыннан дәвамында да рус, госманлы драма әдәбиятының, рус театрының тәэсире белән була. Татар буржуа сыйныфы һәм татарның яшь зыялылары рус театрларына йөри башлап, анда тормыш картиналарының хәрәкәтләре аркылы яңадан эшләнеп күрсәтелүләрен күрәләр. Үзләренә шулардан зәвык алалар. Моның татарда эшләнүе бик мөмкин булуы һәм шуның кирәк икәнен сизенәләр. Татар тормышын драмаландырырга җилкенүче яшь талантларда бу юлда чынрак тәҗрибә адымнарын башлау һәвәсе кузгала.

1896 елларда иң элек үзендә шундый бер һәвәс кузгалучы яшь талантларның берсе дә Галиәсгар Камал була.

Әнә шундый юл белән каләмгә алынган әсәрләрнең беренче үрнәге Г. Камалның хәзерге 5 пәрдәлек «Бәхетсез егет» дигән драмасының урта кулда вак хәреф белән 20 бит зурлыгында басылган беренче басмасы була (хәзерге нөсхәсе 1907 елда басыла). Инде күптән җимерелү вакытлары җиткән иске татар байлары тормышыннан алып, Г. Камал 1898 елда 6 пәрдәлек әлеге «драм»ын язып ташлый. Үзен бастыруга 1899 елда 18 июньдә рөхсәт алынып та, 1900 елда Кәримовлар матбагасы ачылганда иң беренче китап булып, Истанбулның нәсех хәрефе белән басылып чыккан драма да шушы әсәр була)[1].

[1] Бу әсәр дә Г. Камалның ул вакыттагы учителе – рус теле мөгаллиме булган Миргаяз Иманаевның димләве һәм шуны басарга бирергә вә бастырырга кызыктыруы белән басыла. *(Авт. иск.)*

Зур тарихи әһәмияте булган өчен шушы беренче басма «Бәхетсез егет»нең ахырында басылган «ихтар»ыннан[1] бу урында түбәндәге юлларны күчереп үтәбез (үз имласы белән): Бәгъзе кешеләр бу китапны бигрәк тә урам телендә чыгарган икән дип көләрләр бәлкем, ни зыян? Көлсеннәр, дәхи дә шундый бар кеше дә аңларлык урам телендә булган китаплар булучылыгы насыйп булсын. Ярый ла бар кеше дә галим булып бетсә, ул чагында фарсыча һәм гарәпчә чыгарсак та зыян юк».

Ул чакта «урам теле» дип кимсетелгән хәзерге гавами әдәби татар теленең үсү тарихын, Каюм Насыйриларга каршы башлап кузгалган бу көлүнең алардан соң да әле һаман дәвам ителгәнлеген күрсәтү өчен дә бу юллар ачык бер документ була ала.

Шуның өстенә без татар дөньясында «Бичара кыз», «Комедия»-ләрдән соң, иң гавамча, ачык, җиңел татар әдәби теленең дә нигезе Галиәсгар Камал тарафыннан киңәйтелеп, үстерелеп киткәнен аңлый алабыз.

Соңыннан шушы башланган тәҗрибәләр һаман тармаклана баралар, 1902 елларда шул ук Г. Камалның соңыннан «Уйнаш» исеме белән төзәтелеп басылган (1911 елда) «Өч бәдбәхет» дигән әсәре басылып чыга. Госманлычадан һәм русчадан тәрҗемәләр дә башланып китә (бу хакта сүз соңыннан булыр).

Икенче яктан, 1902 елда Бозаулык шәһәренең сәүдәгәрләреннән Ярулла Вәлинең[2] «Оят, яки Күз яше» дигән дүрт пәрдәлек драмасы басылып чыга. Казанда 6 нчы елда рәсми рәвештә уйналган пьесаларның берсе дә шушы пьеса була.

Галиәсгар Камалның «Бәхетсез егет»е Казан байлары (вә кыйсмән Уфаның яурупалашкан яшь буржуасы) тормышыннан алынып язылган булса, «Оят» та Сембердәге фабрикант бер татар баеның бозык гаилә тормышыннан алынып языла.

Ярулла Вәлинең соңыннан «Ачлык кушты» кебек башка драмалары да басылып чыгалар. Ләкин алар мөндәриҗә ягыннан да, сәнгатьчә эшләнү ягыннан бик үк өстенлек казана алмыйлар. 1908 елларда яшь татар буржуазиясе матбугатындагы тәнкыйтьләрдә дә («Әлислах»ның 26–29 нчы саннарында «Дамелла» Ф. Әмирхан

[1] Ихтарыннан – искәрмәсеннән.

[2] Вәли Ярулла ( (1879–1937) – драматург. «Оят, яки Күз яше» (1907), «Ачлык кушты» (1911) пьесалары, проза әсәрләре авторы.

тәнкыйте) аңа, бераз хаксызлык күрсәтеп булса да, түбән, начар бәһа бирелә. Ләкин шуңа кармастан, Казанда ул вакытта рәсми театрларда куелырга яраклы булып табылган әсәрләрнең берсе «Оят» була. «Ачлык кушты» да төрле урыннарда күп уйнала. Тәнкыйтьне яклаусыз йөрткәндә, мәсьәлә болай тора: никадәр генә зәгыйфь эшләнгән булмасын, һәрхәлдә, беренче мәртәбәсеннән үк сәхнәгә куярга яраклы иттереп эшләнгән оригиналь драмаларның берсе – шушы «Оят» пьесасыдыр. Бу инде «Бичара кыз», «Рәдде бичара кыз»ларның байтак кына үсеп өлгергән иптәшләренең беренчесе.

Әмма тел ягыннан да, мөндәриҗә ягыннан да, чын сәнгатьчә эшләнү ягыннан да татар драма әдәбиятында иң беренче карлыгачлар Галиәсгар Камал әсәрләре булды. Димәк, татар драма әдәбиятының чын сәнгатьчә (художество) юлы белән эшләнгән беренче үрнәкләре башлап шушы көчле талант тарафыннан бирелде.

Бу көчле драматургның сәхнә өчен эшләнгән «Бәхетсез егет», «Беренче театр»лары мәйданга чыгу белән, татар әдәби тәнкыйть дөньясы («Әлислах»ның 33 нче һәм 41 нче саннарында «Дамелла» мәкаләләренә, «Аң»да Г. Кәрам мәкаләләренә каралсын) мактап каршы ала. Аның әдәби көчен буржуазия дә игътираф итә[1]. Болай каршы алынуда ул бик хаклы иде, чөнки, беренчедән, моның драмалары тулы мөндәриҗәле булалар. Ул әсәренә татар тормышының аянычлы, көлкеле, серле якларын ачык, тулы иттереп ала белә. Икенчедән, ул типларны сәнгатьчә зур осталык белән эшләп чыгара ала.

Күп драматурглар була, алар әсәрләрендә алынган каһарманнарына үз миләрен, үз йөрәкләрен бирәләр, аларны драма язучының нәкъ үз теле, үз өслүбе белән сөйләштерәләр. Шуның белән аларны табигыйлектән, чынлыктан аералар. Үзләрен каһарманнар тормышында һәм аларның табигатьләре белән яшәтеп, шуларның чын тормышларын үз башларыннан кичереп карый алмыйлар. Аларга үзләренең шәхси табигатьләрен яисә үз башларыннан уйлап чыгарылган бер табигатьне йөкләтәләр дә, нәтиҗәдә каһарманнарының табигатьләре, сүзләре, эшләре, хәрәкәтләре бер-берсе белән оеша алмый торган булып чыга.

Галиәсгар Камал мондый драматурглардан түгел. Ул каһарманнарын нәкъ үз тормышлары белән яшәтеп, аларга тәмам үз таби-

[1] Игътираф итә – таный.

гатьләренә яраклы сүзләр, хәрәкәтләр бирә. Табигать, эш, хәрәкәт, итенеш-кыланыш – аның каһарманнарында бер-берсе белән тәмам берләшә ала торган нәрсәләр. Шундый осталыгы аркасында ул шулар аркылы безгә яхшы гына эшләнгән сәнгатькяранә типлар да бирә алды.

Өченчедән, ул әсәрләрен бер дә көчләнмичә яза ала. Тагын аның әсәрләре – үгет-нәсыйхәттән саф һәм нәгыз[1] реаль әсәрләр. Башка күп язучылар шикелле, Галиәсгар әсәрләре аркылы үзен күрсәтергә, күрсәтелергә дә теләми, бәлки ул үзе, чынында ничек булган булса, тик шулай булып күренә ала. Дөресе, ул әсәрләрендә үзеннән элек каһарманнарын күрсәтергә тырыша.

Дүртенчедән, аның әсәрләре садә эшләнгән, матур әдәби татар теленең драмада беренче үрнәкләре булып тордылар.

Татар драма әдәбияты дөньясы да һәрвакыт үзенең иҗаби ягы белән иң элек танылып, татар гаммәсе арасында бик тиз мәшһүр булып китүе дә аның менә шушы яклары өчен булды.

Минем бу мәкаләмдә бу драматургка озак тукталуым һәм шулай тукталуны тиеш күрүем дә аның әнә шушы яклары өчен, аның чын художество юлы белән эшләнгән, чын татар драма әдәбиятының атасы булганлыгы өчен икәнен артык сүз озайтып сөйләп торуга да хаҗәт юктыр дип беләм.

Тагын да җиткеребрәк әйткәндә, татарның сәнгатьле драма әдәбиятында ул беренче классик чын драма сәнгатьчесе (художнигы) булу ягы белән әле аннан уздырган татар драматургларын, бәлки, хәзердә дә очрата алмый торганбыздыр.

Татар халкының иҗтимагый-әдәби тарихында Г. Камалның иң кыйммәтле мәңгелек бер әсәре – бигрәк аның «Беренче театр» дигән комедиясе булыр.

Аның бу әсәре, чыннан да, сәнгатьле (художестволы), мөндәриҗәле бик матур бер комедия булып чыкты. Монда кешеләр, характерлар бик табигый, бик килешле. Тел дә бик эшләнгән, садә әдәби бер татар теле.

Бу әсәрне кеше, сәхнәдә әллә ничә мәртәбәләр күргән, әллә ничә мәртәбә укып чыккан булса да, аны бер дә ялыкмыйча, көлә-көлә тагын да укып чыга ала. Менә бу инде үзе үк әсәрнең оста кул белән

[1] Нәгыз – әйбәт.

язылган бер әсәр булуыннан килә, Галиәсгарның көчле бер драматург, оста бер комик икәнен күрсәтүгә бу әсәр үзе генә дә җитә.

20 нче йөз башларына таба иске татар байларына, шуларның иске тормышлары, мәдәни тәрбияләренә каршы татарның либераль вак буржуазия сыйныфы аерым бер җәмгыять булып мәйданга чыга. Иҗтимагый-мәдәни тарихыбызда менә шушы сыйныфның үсеп килә башлаган мөһим моментлары бар. Иҗтимагый-мәдәни көрәшләрнең шундый бер моментын матур татар әдәбиятында матур эшләнгән бер сурәт белән яшәтеп калдыруда «Беренче театр» тиңсез бер әсәр булып торачак.

Икенче төрле әйткәндә, Галиәсгар Камалның бу әсәре – надан, иске татар байларының яңа яшь татар буржуа җәмгыяте төзелә башлау алдыннан күрсәткән җимерелү, бетү хәрәкәтләреннән татар сәхнәсендә эшләнеп калган иң тарихи кыйммәтле бер картина.

Галиәсгар драмаларындагы аерым бер сызык тагы менә шушы: ул хәйләкәр, ара бозгыч, имче-томчы карчыклар, бай хатыннар һәм асрауларның типларын аерым бер табигыйлек һәм осталык белән бирә ала. Надан, тәрбиясез байлар тибын ясауда янә зур бер осталык күрсәтә. («Беренче театр»дагы Хәмзә бай һәм асрау, «Бәхетсез егет»тәге Мәгъри, «Бүләк өчен»дәге бай хатыны – шуларга мисал.).

Г. Камал әсәрләрендә бу урында әйтелеп үтелергә тиешле булган бер кимчелек бар. Ул да – бәгъзеләрендә монологларның артык озын булып китүе. (Мәсәлән, «Бәхетсез егет»тә бай хатынының улы Закир турындагы монолог кебек, 4 нче пәрдәдә Гайни белән карчыкның диалоглары да шулай озын.)

Бу әсәрдә Уфа сәүдәгәрләреннән Сәгыйть Сабитовлар гаиләсе нәкъ яшь яурупалашкан яңа татар буржуазиясенең вәкилләре итеп алынганда, иске Кәрим баеныкына каршы иҗтимагый көрәш күренеше булып чыккан.

Галиәсгар Камалның башка әсәрләренә тукталып торырга монда урын сыйдырмый, шуның өчен аның турында шул югарыдагы ике әсәре таяныч ителеп әйтелгән сүзләребез белән хәзергә канәгатьләнеп торабыз.

1905 елгы революция татарны пролетариат һәм буржуа сыйныфына нык аерып ташлаган кебек, алар арасында күптән килгән «җәдит», «кадим» дигән көрәшне дә ике зур лагерьга аера: байлары шу-

лай икегә аерылган кебек, аларның идеологлары булган муллалар да шулай икегә аерылалар. Җәдид мулла гөруһы баш күтәрә, мәдрәсә шәкертләре дә шулай икегә: «җәдидткә, «кадим»гә бүленәләр. Иске тормыш белән яңа тормыш арасында үзләренең шушы ике төрле каһарманнары аркылы соңгы каты көрәш башлана.

1905 елдагы иҗтимагый-сәяси дулкын белән туган татар матбугатында, газет, журналларында да бу ике көрәш ачык күзгә ташлана (бу турыда «Әлислах» тагын да аерым бер урын тота). Иске идеология белән туып килгән яңа идеологиянең болай бер-берсе белән каты бәрелешүләре соңыннан янә журналларда кыздырыла: бер яктан, «әд-Дин вә әл-әдәб», «Шура», «Аң», икенче яктан да, «Дин вә мәгыйшәт» кебек журналлар шундый көрәш лагерьларын тәшкил итәләр.

Тезмә әдәбиятта, көйле шигырьләрдә, лирикада Мәҗит Гафури, Тукай кебек иске мәдрәсә, иске тормыш җимеше булып та, шул тормышка каты дошман булып килеп чыгучы шагыйрьләр яңа тойгылар, яңа хисләрне җырлый башлыйлар. Иске тормышка, иске тәрбиягә татар тезмәләрендә каты һөҗүмнәр кыздырыла (Тукай шигырьләре моңа аеруча ачык мисал), һөҗү-көлке журналлары чыга. Халык йөрәгендә искелекккә таба каратылган каты, ачы һөҗү тойгылары Тукай шигырьләре аркылы татар дөньясын нык яңгырата башлый. 19 нчы йөзнең ахырында туып үстерелә башлаган милли хисләр аерым бер иҗтимагый хис рәвешендә куәтләнә һәм куәтләндерелә бара. Хикәяләр дә шул сызыкта баралар.

Бай, мещан һәм бәгъзе ачык фикерлерәк мулла балалары, шулай ук бәгъзе ятим шәкертләр, кайбер ярлы халык балалары тырышып-тырмашып урысча укырга биреләләр: рус әдәбиятыннан да нык тәэсир ала, алардан төрле формалар күрә башлыйлар. Менә шуларның нәтиҗәсендә татар драма әдәбиятына яңадан чынлап кузгалу, чынлап туу моментлары якынлашкан була. Тукай кебек халык психологиясендә яңа кузгалган җилкенүләрне, яңа теләк, яңа дулкыннарны, яңа хәрәкәт, яңа эшләрне алдан ук сизеп эләктерә һәм шуларны үз йөрәге аркылы үткәреп чыгара баручы шагыйрьләр халыкның театрга булган арзуларын да шигъри бер формага салып җырларга тотыналар. Театрны, сәхнәне мактый башлыйлар. (Тукайның «Театр» дигән шигыре кебекләр шулар рәтеннән тора.) Ниһаять, Галиәсгар Камал тарафыннан нигезе утыртылган татар драмасы

1905 ел революциясеннән соң һәр яктан үсә, киңәя башлый. «Кадим» белән «җәдит» яки иске белән яңа көрәше уртасында үскән, шуны үз башыннан кичергән яки кичереп торган яшь татар әдәби көчләре ничек булса да шушы ике якның көрәшен драмаландырырга җилкенәләр. Аларга драма язу өчен җиңел мәүзуглар, сурәтләр дә шушы әйләнәдә генә табыла ала һәм аларның шуннан ары китәргә, башка мәүзугларга күчәргә көчләреннән дә килерлек булмый. Драма язу бит ул уен түгел. Аның өчен алына торган мәүзуг иң элек үзеңә я бик яхшы таныш, яки язылачак вакыйганы иң элек син үзең бик нык башыңнан кичергән яисә аны бер фәнни тикшерүче шикелле нык тикшереп, өйрәнеп алып та, шул вакыйгада гүя үзеңне булындырып караган кебек бер хәлгә килгән булырга тиешсең. Шунсыз түгел драма. Хәтта әдәбиятның башка формаларын хикәя, романнарны да уңдырып чыгара алу мөмкин түгел.

Менә бу бездә шулай булды да. Ягъни һәр язучы үзе әйләнгән, үзе яхшы белгән мохитне, үз тирә-юнен драмаландырырга, шуны сәхнәгә китереп кертергә итә башлады. Шәһәр, иске байлар тормышы; мулла, хәзрәтләр, суфилар, остазбикәләр, сөннәтче бабайлар дөньясы; татар вак буржуа яшьләре, мещан балалары тормышы. Аларның яңаруга таба төрлечә омтылулары, аларның төрлечә итенеш-кыланышлары, җилбәзәкләнүләре, милләтен сөю яки милләтеннән көлү кебек хәлләре; эшче-крестьян яшьләре тормышы әдәбиятка драма аркылы шушы юл белән китереп кертелде.

Бигрәк тә драмада, бер яктан, иске байлар, муллалар, хәзрәтләр, суфилар, гомумән, кадимчеләр тормышыннан көлү, аларның фаҗигаларын, трагедияләрен тамаша иттерү һәвәсе тагы да ныграк куәтләнеп, шул модага кереп китсә, икенче яктан, вак буржуа яшьләренең, мещан балаларының иске гаилә тормышы белән көрәшләрен, аларның яңага, яурупача тормышка омтылуларын сәхнәгә куйдырту һәвәсе кузгалды. Нәтиҗәдә мулла, мәзиннәр, хәзрәтләр, остазбикәләр, суфилар, сөннәтче бабайлар, иске мәдрәсә шәкертләре һәм «җәдит мөгаллимнәре»нең язучылары килеп чыгып, шулар тарафыннан шушы халык тормышыннан хикәяләр, озын-озын романнар, драма һәм комедияләр языла башлады. «Өч хатын белән тормыш», «Кыямәт», «Алдым-бирдем», «Мөгаллим» вә «Мөгаллимә»ләр һәм ачыктан-ачык кара, кабахәт идеологияле «Зөләйха»лар килеп чыктылар.

Вак буржуа, мещан балалары һәммәсе Ф. Әмирханов аркылы «Көндезге сәхәр», «Кадерле минутлар», «Хәят», «Урталыкта» дигән хикәя вә романнары белән бергә «Яшьләр», «Тигезсезләр» кебек нәгыз типлы вак буржуа, мещан пьесалары тудыртты.

Татарның шушы күтәрелеп килгән яшь милли буржуа мөхәррире – гимназист вә гимназистлар шагыйре бу юлда башлап беренче ачык адымны салды. Татар яшь буржуа җәмәгате, татар буржуа тәнкыйте дә бу адымны зур шатлык белән куәтләп, алкышлап каршы алды.

– Бу яңа уенны күрергә шәһәребезнең бөтен кибаре, ислам гаиләсе, зыялылары, яшьләре, укучылары килгән иде. Сәхнәбездә сәләмә киемнәрдән, ямьсез җиһазлардан, аның өстенә бәлки меңәр мәртәбә тәкрар ителгән тозсыз, мантыйксыз фәлсәфәдән гыйбарәт булган уеннарны күреп туеп беткән халкыбызга бу назик[1] уен үзенең матур манзаралары, таза вә нәфис мөхавәрәләре[2] белән гүзәл бер «сюрприз» булды. («Аң», 1915 ел, 4 сан, Г. Кәрам).

Татар буржуазиясенең театр тәнкыйтьчесе Г. Кәрамның шушы сүзләре бу турыда мәсьәләне ачып салу өчен иң характерлы бер таяныч була ала. Димәк, татар буржуазиясе инде Г. Камал әсәрләреннән дә канәгатьләнмәү дәрәҗәсенә килеп җиткән, инде аннан башка әсәрләрне кирәксенә, динчелек, тар шовинистлык һәм буржуазияне мактаучылык, шуны күккә күтәрүчелек белән сугарылган әсәрләрне ашыгычлык белән сорый башлаган була.

Ф. Әмирханның «Тигезсезләр»е вә Гаяз Исхакыйның «Зөләйха»лары кебек әсәрләр динче, милләтче буржуазиянең әнә шушы сөальләренә, аның шундый психологиясенә, шундый идеологиясенә җавап булып төшәләр. Шуның өчен нәтиҗәдә татар милли буржуазиясе боларның әсәрләре чыгу белән бәйрәм ясый, аларны зур шатлыклар белән алкышлап каршы ала.

Югарыда 1905 елгы революция татарны пролетариат һәм буржуа сыйныфына нык аерып ташлады дигән идек.

Әйе, шулай булды. Моның башлангыч галәмәте татар драма әдәбиятында да килеп чыкты. Татар пролетариат сыйныфының татар драма әдәбиятын һәм сәхнәне үз ягына әйләндерергә теләве белән Гафур Коләхмәтов каләме аркылы өченче бер әдәби фронт

[1] Назик – нәфис, нәзакәтле.
[2] Мөхавәрәләре – әңгәмәләре.

ачылганын күрдек. Моның белән татар социалист зыялылары, татар большевик эшчеләре тарафыннан татар сәхнәсенә пролетариат сыйныфының таләпләре куелды. Матур әдәбиятта да буржуазия һәвәсләренә каршы, шулай итеп, татар пролетариатының сыйнфый һәвәсләре кузгалып аяк баскан булды.

Большевик Хөсәен Ямашевларның партия фикерләрен тарату эшендә ярдәмчеләреннән булган Гафур Коләхмәтовның (1881–1918) 5 пәрдәлек «Яшь гомер» дигән драмасы әнә шул юлдагы адымнарның беренчесе иде. Бу беренче революционер татар драматургы, шушы әсәре белән татар социалист зыялыларын, татар эшчеләрен, аларның партия әгъзаларын татар драмасының баш каһарманнары итеп алуның беренче юлын ачып биргән булды. Әсәрдәге Гали, Вәли, Йосыф дигән каһарманнар ул вакытта татар драма әдәбиятында чыннан да беренче мәртәбә күренгән каһарманнар иде[1].

[1] Әсәрнең каһарманнарыннан дөньяны күп күрүче, укымаган, ләкин үзенең эшче булуы, байлар һәм самодержавие кулында изелүе белән генә сыйнфый мәнфәгатен ачык аңлый алучы Йосыфның: «Менә бу агачларда да минем хакым бар. Бу җирдә дә минем хакым бар. Бөтен дөнья малында да минем хакым бар. Хакым күп җирдә бар. Әмма акчам юк. Бу ник болай икән?

– Шулкадәр беләләр, шулкадәр кара халыкны алдыйлар. Һич тә сизәрлек түгел!.. Менә безнең татар байлары Мәкәрҗәдә җыелган булдылар да, мөселман иттифакы партиясе оештырган булдылар. Үзләренә күрә комитет та сайлап куйдылар. Комитетка кемнәр керде?.. Һәрбер член комитет кушканча эшләсен, имеш! Мәсәлән, Думага сайлау турысында, әйтик, комитет тотар да менә шуны, шуны сайлагыз, дияр. Ягъни байларны сайлагыз, дип әйтер. Член булдың исә, сайламый хәлең юк шул, юк. Башка кешеләрне алдасагыз да, без эшчеләрне алдый алмассыз!..

– Алар пычакка пычак килә торган ике сыйныфны бергә катыштырмакчы булалар. Катыштырмый торыгыз әле...» дигән сүзләре һәм алган юлында нык торучы эшче социалист Вәлинең дә:

– Гали эчемне пошыра башлады... И интеллигентлар, интеллигентлар!.. Шушы интеллигентларга карап гаҗәпкә калам. Гаҗәпкә калмый хәлең дә юк шул. Менә еракка бармыйча Галигә генә карыйк. Ул йөз утыз миллион Русия кешеләре шакшы җан ияләре кебек былчыракта коенып торган вакытта, халыкка хезмәт итәм, дип, Зөләйханы коткара, имеш!... Бу Зөләйха артыннан йөри-йөри никадәр вакыты әрәм үтте. Никадәр эш калды. Кирәкле кәгазьләр вакытында язылмаган. Кирәкле урыннарга вакытында барылмаган. Сәбәбе ни? Зөләйха! Шушы интеллигентларны күтләренә тибеп, партиядән куалап чыгарасы иде. Ярамый! Аларның фикерләре эшче фикереннән җиңел булса да, эшчеләргә юл күрсәтеп торулары һәм эшчеләрнең фикерләрен ачулары кирәк шул...» дигән сүзләре мөхәррирнең алган каһарманнары нинди типтагы кешеләр икәнен безгә ачып салалар. Шуларга аларның эшләрен башкалар белән булган мөгамәләләрен дә кушарга кирәк. *(Авт. иск.)*

Драма 1906–1907 елларда язылып, 1908 елда ук басылып чыккан, шуның өстенә үзе турында «Әлислах» газетасының 30 нчы санында «Дамелла» кушаматлы бер тәнкыйтьче (Ф. Әмирхан) каләме белән вак буржуа күзлегеннән каралып, кыскача иҗаби бер тәнкыйть тә булып үткән иде.

Ләкин ачыктан-ачык революция рухы белән сугарылып язылганга күрә, аның татар сәхнәсенә килеп керүе өчен хөкүмәт тарафыннан рөхсәт ителмәгәнлектән һәм бу татар буржуазиясе өчен дә бигүк кирәкле нәрсә дип табылмаганлыктан, әсәр Октябрьгәчә уйнала алмады. Татар массасы арасында да таныла алмыйча басылып калды.

Шушы мәкаләне язып утырганыбызда СССР халыкларының үзәк нәшрияты тарафыннан 1925 елда басылган «Гафур Коләхмәтов мәҗмугасы» дигән бер китап кулга төште. Мәҗмугага әдипнең ике әсәре кергезелгән, берсе югарыда әйтелгән «Яшь гомер» исемле драмасы булып, икенчесе дә, аның моңарчы матбугатка чыга алмыйча торган һәм «Яшь гомер»дән элек язылган ярым символизм юлындагы «Ике фикер» дигән 3 пәрдәлек фәлсәфи бер пьесасыдыр. Пьесаның теле турында Агиев[1]: «Гафурның өслүбен һәм телендә булган кайбер авырлыкларын төзәтү минем тарафымнан булды» дигәне өчен аның теле, өслүбе турында катгый бер сүз әйтеп булмаса да[2]), фикер, идеологиянең, һәрхәлдә, Коләхмәтов каләменеке булуында шөбһә юк. Әсәр чыннан да пролетариат революциясе һәм каты көрәш рухында булып, марксизм идеологиясен матур бер әдәби, фәлсәфи калыпка салып биргән. Кыскасы, Гафур Коләхмәтовның беренче иҗаты булган бу пьеса егерме еллык татар драма әдәбиятында чын революция рухындагы әдәби кыйммәткә ия булган әсәрләрнең берсе, бәлки беренчесе.

Мөндәриҗә ягыннан да, сәнгатьчә эшләнү ягыннан да бу шулай.

«Кара фикер» белән «Кызыл фикер» (самодержавие белән марксизм-большевиклык идеологиясе) арасында калып, каты бер

[1] Агиев Фәхрелислам Нигъмәтулла улы (1887–1938) – язучы, журналист. 1913–1916 елларда «Ак юл» журналының нашире һәм мөхәррире. Балалар өчен уку ярдәмлекләре авторы.

[2] Ләкин бер әдәби әсәрне төзәтеп, телен үзгәртү тарихны яңлыштыру була. Агиев бу эшендә хата иткән, ул тарихи пьесаның, һәрхәлдә, үз телендә, үз өслүбендә бастырылуы кирәк иде. *(Авт. иск.)*

көрәш, рухи бер тартыш тудырып, ахырда «Кызыл фикер»не үзенә юлбашчы итеп «алга!» юнәлгән Давыд – монда баш каһарман. Бу тип – чын марксист-революционер тибы. Аны сөюче Галия дә – шушы нык идеаллы беренче татар марксист революционерын аңлап, аның юлына төшеп, аның белән бергә «Кызыл фикер» артыннан «алга!» омтылучы акыллы бер татар хатыны.

Шул югарыдагы ике әсәр турында күпме озак тукталганда да урынсыз булмаячагын беләм.

Ләкин монда урын тар булганлыктан, аларга озак тукталуны икенче вакытка калдырып, сүзне кыскартырга мәҗбүрмен.

Шулай да сүз ахырында үзе аркылы татар драма әдәбиятына чын революция тамыры, пролетариат идеологиясе орлыгы беренче мәртәбә килеп кергән бу әсәр һәм андагы Давыт тибы турында язганнарыбызга таяныч булсын өчен, аның характерлы сүзләреннән берничә юлын күчереп үтмичә булдыра алмыйм:

– «Адәм нихәтле нык табигатьле булса да, нихәтле аның гыйлеме зур, фикере киң булса да, тарихны тудыра алмый, бәлки адәмне үзен тарих тудыра. Нәрсә ул тарих? Тарих – гавамның ничә мең еллар эчендә килә торган сыйныфлар көрәшенең тезмәсе, тарихсыйныфлар көрәшенең көзгесе. Ялгыз кеше дөньяда бу көрәштә берни дә итә алмый. Адәм тик гавам эчендә генә яши ала. Тик шул көрәштә генә үзенә ләззәт таба ала. Кешеләрнең бер төркеме дөньяда булган барлык байлыкны үз кулларына кертергә тырышалар, гавамны, маңгай тире, үз кул көче белән яши торган гавамны үзенә кол итәргә, богауда тотарга тырыша... Ә гавам шул коллыкка эләкмәс өчен, эләккәч, азат булыр өчен көрәшә, кулына салынган богауларны өзеп ташларга тели.

– Көлешәләр... шатланалар... уйнашалар... Димәк, аларга күңелле... Әнә теге йөзләре ябык, күзләре сүнгән, куллары богаулы гавам нигә көлми? Ул ник ыңгыраша?!. Маңгаеннан тир агыза, үзе ут азабы эчендә яши... Ә алдында тик... өмете генә бар... Бу уен-көлке арасында түгел, әнә шул гавам арасында яшисе. Аның белән бергә азап чигәсе, аның белән бергә үләсе килә...» – ди Коләхмәтовның пьесасындагы баш каһарман Давыт.

Шуңа пьесадагы «Кызыл фикер»дән сөйләтелгән тирән, хикмәтле, корыч сүзләрне дә китереп кушсагыз, мәсьәлә бөтене белән үзүзеннән ачыла. Әдипнең Давыты белән бергә «Кызыл фикер»е 5 нче

ел белән Октябрь революциясе арасында татар драма әдәбиятында утыртылып калган беренче тарихи кызыл маяклар икәне дә үзеннән ачык күрелер.

* * *

Тагы татар милли буржуазиясенең әдәбиятына, аның идеологиясенә бер күз ташлап үтик әле.

Бигрәк тә вакытында идеологиядә, иҗтимагый һәм әдәби-фикри хәрәкәттә татар буржуазиясенең каһарманы булырга тырышкан Гаяз Исхакыйның кирәк романнарында, кирәк драма әсәрләрендәге төп идеологиясенә бу урында бераз гына булса да аерым тукталып булмый.

Җиңел акыллы, киң хыяллы, ләкин әдәби тел ягыннан сакау булган бу җилкуар язучы үзенең иң элек «Тәгаллемдә сәгадәт»е[1] белән борынлап, тишелеп чыгып, «Инкыйраз»ы белән тәпәйләп, йөгереп китә башлаган чагыннан ук «Тәрәккый милләт» шигаре астында татар буржуазиясенең оешып килгән яңа идеологиясе белән чыккан иде. «Инкыйраз»ына язган мөкаддимәсендә татарны тәрәккый иттермәүче сәбәпләрне, манигъларны[2] санап килеп:

– «Өченче манигы тәрәккый һәм дә иң сизелә торган манигы тәрәккый милләтебездәге хезмәткә ярарлык кешеләрнең һәм хезмәт итә торганнарның бик фәкыйрь сыйныфтан чыгулары» дип күрсәтеп, шуның өчен бик нык ачынып кайгыруы һәм шуңар өстәп тагын:

– «Ләкин бу эш безнең болгарларның бәхетсезлегенә каршы, башка милләтләрнең хилафынадыр. Башка халыкларда күбрәк әрбабы хәмият[3], бигрәк әрбабы каләм[4] зур байлардан вә зур дәрәҗәле затлардан чыкмыштыр»[5] дип көрсенеп куюы әнә шундый бер идеология белән чыгуның беренче манифесты иде.

---

[1] 1899 елда басылган беренче хикәясе. *(Авт. иск.)*

[2] Манигъларны – киртәләрне.

[3] Әрбабы хәмият – яклаучылар.

[4] Әрбабы каләм – каләм ияләре.

[5] «Ике йөз елдан соң инкыйраз». 4 нче бит. Гаязның бу әсәре – аны татар буржуазиясенә үзенең арка таянычы була торган бер әдибе иттереп таныткан иң мәшһүр бер әсәре. Вакытында татар дөньясын бу әсәр бик нык шаулатып алды. Әсәр 1903 елда язылган һәм шул ук елда рөхсәт алынып басылып чыккан. *(Авт. иск.)*

Менә бу сүзләре белән Гаяз ачыктан-ачык буржуазия-аристократия әдәбияты тудыру һәм «зур байлардан, зур дәрәҗәле затлардан әрбабы каләм җитештереп чыгару» сызыкларыннан хәрәкәт башлаган иде. Үзенең шулай тилереп килеп чыгуы белән үк татар аксөяк буржуа-мещан балалары һәм шуларның тәэсирләре, шаулатулары астында хәтта татарның күп кенә җәдит мөгаллимәләре, җәдит муллалары тарафыннан да телгә алынып мактала башлаган бу мөхәррир шушы төп идеология орлыгын үзенең «табигъ юлдагы дине ислам»[1] идеологиясе белән тагын да нык тамырландырып, аны шул юлда үстереп алып китте. Иң ахырда «Мөгаллимә», «Зөләйха» дигән драмаларын язып, татар сәхнәсен тәмам шул кара якка әйләндерергә теләде.

17 нче елда Казанда беренче мәртәбә уйналганыннан соң: «репертуарыбызның пире», «һичбер вакыт сәхнәбездән төшәчәк түгел вә татар театры дәвам иткән мөддәттә классик бер әсәр булып калачактыр» дип, татар буржуа тәнкыйтьчесе тарафыннан макталган һәм: «Искедән бирле күңелемездә сакланып килгән яшерен вә тирән гадавәтебез[2] мең кат артты», – дип, яңадан әһле салиб[3] сәфәрләренә хәзерләтерлек бер дәрәҗәдә кабахәт тәэсир бирүе өчен зур шанлык күрсәтелгән («Аң» – 3–4, 7 сан, 1917 ел, Г. Кәрам) шушы «Зөләйха» драмасы турында хәзерге госманлы газеталарының карашын да бу урында күреп үтү зарарлы булмас, чөнки «Зөләйха» китабының һәм аны язучы татар буржуазия идеологының эч-йөзе хәзер яңа Төркиядә дә ачылып бирелде инде. Бу урында моңа ачык бер факт итеп, «Әнкара»да чыга торган «Хакимияте миллия» газетасының 1925 ел ноябрьдә чыккан 1582 нче саныннан («Төрек йорды» журналы турындагы мәкаләдән) мәкаләнең сүзләрен һичбер үзгәртмичә, характерлы урыннарын сайлап күчереп үтәбез:

«Зөләйха» сәрләүхәсе атында Гаяз Исхакый бәк өч нөсхәдә бере дәвам идән вә һәнүз аркасы улынмайан пьесасыннан бер шәй аңламадык.

Гаяз Исхакый бәк безә рухымызы тәтмид идән бер әсәр китермәмештер, бу, анчак дине җөдалек[4] дәвам иттеке бер мохит вә бер

[1] «Инкыйраз» – 2 нче бит. *(Авт. иск.)*
[2] Гадавәтебез – нәфрәтебез.
[3] Әһле салиб – Тәре сугышын оештыручылар.
[4] Дине җөдалек – диннән аерылу.

заманда бәлки бер тәэсир япа биләчәк бер театру ула билирде! Театру ула билирде, диюрыз. Чөнки театру – бер сәнгатьтер. Бер кәррә мәүзугы фикере мохитә тәмамилә япанчы, соңра театр вә сәнгате намәне һичбер шәй юк.

Иң мөһим нокта – бу пьесаның кодрәте ифадәйә малик уламамысыдыр. Ифадә чук бәяндыр. Сәхнә үзәрендә бер кәлимәнең бойлә әгъзаме җанлылыгы лаземдер. Моннан башка лазем гүзәл төрекчәмезе бозан җөмләләр бар. Хәтта сарыф вә нәхү хаталары вар.

Соңра безем өчен иң мөһим улан нокта – Төрек йорды, яки төркек кукмыш гакыйдәләрә зарбә индермәктә үк куәтле силахыдыр, хорафатың биәман[1] дошманыдыр. Буеныннан нөсхә чыкартан вә хорафайә тапынмагы тәлкыйн идән бер мөхәрририң бу фикерене Төрек йордында заляләт[2] гадү идәрез».

Бөтен җидалемез[3] бу хорафе кырмакдыр вә Зөләйха маҗарасының кичдеке мохит бу хорафатың корбаныдыр! Боны озатмаялым, чөнки Төрек йорды да иң чук тәнкыйдә мөстәхикъ[4] бер әсәрдер.

Мәкалә имзасыз, димәк, мондагы фикерләр «Хакимияте миллия» газетасының үз фикере, ягъни аерым бер язучыныкы гына булмыйча, гомуми фикер шулай.

Менә шулай итеп, татарның буржуазия идеологиясе үзенең тәрәккый баскычында, ниһаять, Гаязлар аркылы әнә шундый «Зөләйха» шикелле хәзер дә үзенә Төркиядә дә урын табыла алмый торган мәгънәсез, кабахәт әсәрләр тудыртып, шуңа бәйрәм ясау дәрәҗәсенә килеп җитте.

Шуның белән бергә, бу кара әдәби реакция үзе артыннан «Таһир-Зөһрә»ләрнең тууларына да зәмин, юл хәзерләшеп калдырган булды.

Хәтта шушы иделогияне өстенә йөкләп бара торгач, ахырда сәясәттә монархия юлына ук әйләнеп китте.

Үзенең ахыр ноктасына кадәр шулай үсә барганда иң соңгы таянычы монархия яисә, алай ук булмаса да, шуңа якын бер власть булачагы ачык сизелгән бу куркыныч, кара идеологиянең бөтен татар

---

[1] Биәман – рәхимсез.
[2] Заляләт – ялгыш юлга керү.
[3] Җидаль – талаш-гауга.
[4] Мөстәхикъ – хаклы, *биредә:* урынлы.

аристократиясе, татар буржуазиясе дөньясында җәелеп, киңәеп барганын Яурупа сугышы алдыннан без ачык күреп үттек.

Җитмәсә тагы, икенче яктан, монда бер идеологиянең гыйльми-тарихи нигезләре эзләнеп табылу юлына да керелеп кителгән иде. Нәтиҗәдә татар милли буржуазиясенең игътибарлы журналларыннан берсе булган «Аң»да без, бу журналның мәйданга чыккан беренче елында ук, менә нәрсәләрне укый башладык:

– «Менә хәзер күрдек ки: бу Земский соборга Русиянең бөтен сыйныф кешеләре белән бергә без татарларның да югары сыйныфы, аристократиясе сайланган икәне ачык күренеп тора».

– «Ничек булса булган, әмма безнең татарлар Романов сөлялəсеннән[1] Михаил Федоровичны Русия тәхетенә сайлаган соборда бар иделәр.

Менә шуңар күрә дә без бу сөляләне үзебез сайлашып куелган сөлялә, үз падишаһларыбыз дип, бер дә шикләнми әйтә алабыз». («Аң», 5 нче сан, 1913 ел. Газиз Гобәйдуллин мәкаләсе). Менә бу инде ачыктан-ачык монархиягә таба карап үсү иде.

Бу гына җитмәгән әле: Октябрьдән соң да (22 нче елда) шул ук вак татар буржуа театр тәнкыйтьчеләре тарафыннан «Мөгаллимә» һәм «Зөләйха»лар кебек кара буржуазия идеологиясе әсәрләрен, аның язучыларын мактау бара:

15–16 нчы еллар татар театрының иң парлак сәхифәләрен ача. Татарның мәдәни, иҗтимагый хәяты киңрәк эз салып бара башлаганга, театр әдәбияты да үзенең тар рамкасыннан чыгып, гомумирәк, тазарак нигез өстенә корыла башлый. «Сәйяр» труппасы көчәя, атаклы драматургларыбыздан Исхакый «Мөгаллимә», «Зөләйха» кебек иң яхшы әсәрләрен биргән шикелле...

– Бу әсәрләр инде мәгънә ягыннан да, нәфасәт ягыннан да моңар кадәр уйналып килгән әсәрләрдән күп өстен торалар, диелә. («Кызыл шәрык яшьләре», 11–12 нче сан, 1922 ел. Г. Кәрам.)

Шуның каршысына революция драмаларыннан күз йомыла. Гафур Коләхмәтовның сәнгатьче татар буржуазиясе драмаларының берсеннән дә ким язылмаган, ә үзе чыннан да пролетариат революциясе рухында булган «Яшь гомер»е турында бу тәнкыйтьче каләм бөтенләй «ләм-мим»сез үтә. Шуны сәхнәгә тартырга

[1] Сөлялəсеннән – династиясеннән.

теләми. Хәлбуки бу каләм ул әсәрнең 1908 елда басылып, ул хакта «Әлислах»та иҗаби[1] тәнкыйть язылып үткәнен дә бик яхшы белсә кирәк.

## VII

***Инде килик өченче дәверебезгә – Октябрь революциясе белән башланган дәвергә.***

Татар матур әдәбиятының крестьянны ачыктан-ачык сүккән, аның тормышын, хезмәтен яманлаган, хурлаган бер вакыты бар. 1850 елда вафат булган Габделҗаббар Кандалый әнә шуның беренче каһарманы иде. Моның аркылы татар матур әдәбиятына без крестьянның эттән алып эткә салып сүгелеп килеп кергәнен күрәбез:

Сука белән сабан сөреп,
Тузан-туфрак үзә йөреп,
Каралубән килеп кереп,
Ки охшап кара калмыкка.
Йөрер көндез катып, калҗып,
Эшен эшләп, үзеп, яньчеп,
Кичен ятыр сасып, тончып,
Нәҗес усрак, катып букка.
Дурак, дүндер булыр дурман,
Накәс[2] каты, агыр торман
Шүрәле тик тоташ урман,
Бик үтәр кышы-җәе иләә.
Үзенә гауна тик, юк честь,
Проклятые, собаки, пес,
Тоташ ул җир-казадыр, ләйсә
Корытмактыр абыйстайла –

дигән кебек, тагы болардан башка әллә нинди сыйфатлар белән крестьян халкы тәмам адәмчелектән чыгарылып, иң түбән, иң начар итеп күрсәтелде. Һәм шул ук шагыйрь тарафыннан «пахатный бер мажик» һәм «әләкче знаком кеби тәне салкын» дип тә сыйфатланган татар крестьянына, шушы изелгән сыйныфка каршы көчле, югары

[1] Иҗаби – уңай.
[2] Накәс – түбән, әшәке.

хаким бер сыйныф итеп, янә ачыктан-ачык руханилар белән байлар сыйныфы куелды:

> Я күп елга, күп айларга ирадәң бармы сайларга?
> Я муллага, я байларга барырмы соң? Әй, җанкәйлә!

рәвешендә муллалар белән байлар икесе дә югары, яхшы бер сыйныф итеп күрсәтелде, әдәбият аркылы шундый фикерләр таратыла башлады, матур әдәбият шуның коралы ителде.

Октябрь исә крестьян турындагы шундый начар карашны бөтенләй җимерде. Һәркаюбызга ачык мәгълүм: Октябрь революциясе бөтен икътисади, сәяси, иҗтимагый-әдәби хәрәкәтләрдә пролетариат идеологиясен күтәреп чыкты. Бу көчле идеология, әлбәттә, татар матур әдәбиятында үзенең кискен эзләрен күрсәтә башларга тиеш иде. Шуның белән бергә, Кандалыйлар төркеме тарафыннан сүгелүгә, хурлануга каршы крестьян үзенең тормышы белән хокуклы бер рәвештә татар сәхнәсенә килеп керү моментларын да көтә иде. Октябрь әнә шуның киң ишеген ачты. Хәтта бөтен әдәбиятны да, сәхнәне дә бөтенләй эшче-крестьянның үзенеке итте.

Эшче-крестьян тормышының болай әдәбиятка, сәхнәгә керүен, бер яктан, эшче-крестьян яшьләре тормышыннан, эшче-крестьян массасы арасындагы революция хәрәкәтләреннән башланганын күрсәк, икенче яктан да фронт, кызыл гаскәрләр тормышыннан, көрәш, революция күренешләреннән башланганын күрдек.

Гомумән, әдәбият, сәнгать дигән нәрсәнең һәр сыйныфы өчен бик зур бер хезмәте бар. Ул да – аның оештыручы, тәшкил итүче бер көч булучылыгы. Җәмгыятьнең күп тармаклы булган матди вә мәгънәви тормышын, идеологиясен, тойгыларын оештыра, җәмгыятьтәге фикер һәм хисләрне системландыра ул. Икенче төрле әйткәндә, әдәбият, сәнгать (искусство)[1] дигән нәрсә билгеле бер формага салынган яисә салыну алдында торган бер тормыштагы фикерләрне, хисләрне, карашларны бергә оештырып, шуларны мәгълүм бер тәртип астында бөтен бер идеология рәвешендә бер калыпка салу белән шөгыльләнә. Бу эшнең дә яңа төзелеп килгән бер җәмгыять яисә үзенә властьны алган, алырга теләгән яңа бер сыйныф өчен берничә төрле методы бар:

---

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

1) искегә, үзенә каршылык күрсәтүче идеологиягә каты һөҗүм, аның төрле ярамас якларын ачып, аннан көлү, үз сыйныфын аннан тәмам биздерү;

2) яңа сыйныф яисә яңа бер төркем уртасындагы үзара уртак бер максатка караган яңа фикер, яңа хисләрне, яңа караш, яңа омтылышларны бергә оештырып, тәртипләндереп, шулардан ныклы, ачык системалы бөтен бер идеология тудыру һәм шул яңа идеологияне саклап, аны һаман матурландыра, йогынтысын арттыра бару;

3) яңа идеал тудыру, тагы шул яңа идеалга багланган фикер вә тойгыларны кешене үзенә сокландырырлык, үзенә тартып торырлык матур бер сурәткә кертә бару;

4) шуларга баглап, үткән һәм хәзерге типлар тудыру. Татар буржуазия язучылары: Акъегетзадә, Габдрахман Ильясилардан башлап та, соң көннәренәчә үз сыйныфлары өчен өсләренә йөкләнгән шундый вазифаларны шушы методлар белән тәмам үтәп килделәр.

Бу зур вазифаларны шундый ук төрле методлар белән төрле яктан тиздән үти башлауны Октябрь революциясенең дә үз язучылары өстенә йөкләтүе бик табигый иде, тиеш иде.

Йөкләтте. Карт революционер әдипләребез дә, Октябрьнең үзе җитештергән язучылар да әнә шушы вазифаларны шундый методлар белән үтәү юлында хәрәкәт башладылар.

Гомумән, драма әдәбиятының туу-үсү, киңәю тарихлары әдәбият формаларының башкалары белән багланып бара. Хикәяләр, романнар, лирикалар аңар күп ярдәм итешә киләләр.

Бу хәл Октябрьдән соң да шулай булды. Иң элек Октябрь сызыгында хикәяләр, романнар мәйдан алды, утлы, ялкынлы лирикалар, ораторлык тезмәләре кайный башлады. Шулар рәтеннән Октябрь сызыгында драмалар туды.

Бу сызыкта хикәя, романнар язуда әүвәлге адәмнәр Галимҗан Ибраһимов, Ф. Сәйфи каләмнәре аркылы күренде. Шуларга, гәрчә сәнгатьчә эшләнүе зәгыйфь булса да, Шамил Госмановның хикәяләре ялганды. Ике революция арасында җитешкән шагыйрьләрдән Гафурилар, Сәгыйть Сүнчәләйләр, Кәрим Әмириләр, Бабичлар, шулай ук «тәңре»челек һәм тәмам идеализм юлы белән 1916 ел «Аң»да башлап язучылардан Н. Исәнбәт белән Ф. Бурнаш кебек шагыйрьләр лирика, поэма юлын кыздырып, шулар аркылы Октябрь рухын бирергә тырыштылар.

Әмма Октябрьнең үзе белән бергә кызыл гаскәрләр арасыннан җитешкән мәгълүматлы, талантлы, көчле шагыйрь Кави Нәҗми белән аннан соң мәйданга чыкканнардан Толымбайский[1], М. Максуд[2] кебек яшь әдәби куәтләр хикәяләре аркылы да, лирикалары аркылы да, әдәбиятта, әдәбиятның барышында пролетариат идеологиясе сызыгын тагы да ачык, тагы да аныграк бер тон белән сыза башладылар. З. Бәшировлар[3], Юлтыйлар,[4] давылланып килеп чыккан Такташлар, Кутуй кебек «шәһәр кияве» булган акырынучы лириклар, Гомәр Галиев[5], Афзал Таһир кебек кыска хикәячеләр дә шул юлда хәрәкәт иттеләр.

Боларга Муса Җәлил, Ф. Ягудин, Ф. Әсгать[6], Вил Уразай, Г. Дәмин, Гали Галиев, Туфан, Г. Садри, Х. Гайнан, Ш. Булат, К. Гайнан, Ш. Салаватов, Г. Шәмсетдинов, М. Кәримов, Хәйруллин, Имаметдинов, А. Азаматов, И. Госманов, Афзал Шамов, Г. Мохтаров, Г. Ильяс, Г. Ганиев, Әбүзәр Түрәй[7], Г. Сәгыйть, К. Гыйсмәт, Камал Зәлиев, Имал, «Авыл җегете», Димьян Фәтхи, Ш. Әмири, Г. Урманче, Ш. Шәһәретдинов[8], Ә. Исхак, Г. Таипов кебек, кайсысы өйрәнү, сыналу күпереннән узып барган, кайсы әле аңа яңа килеп аяк баскан

[1] Гомәр Толымбай (Шаһиәхмәтов Габделхак Җәләлетдин улы; 1900–1939) – язучы, әдәбият галиме. 1929–1931 һәм 1934–1937 елларда Казан педагогия институтында эшли, профессор (1934).

[2] Мәхмүд Гыйсаметдин улы Максуд (1900–1962) – язучы, тәрҗемәче. «Яз жыры» (1929, 1990), «Канлы бож̧ралар» (1929), «Изге көрәшкә (1941), «Яңа тормыш язында» (1980) хикәя җыентыкларының авторы.

[3] Зариф Шәрәфетдин улы (1888–1962) – язучы. «Язгы кояш» (1908), «Иртәнге азан» (1909) исемле шигы Бәшири рь җыентыклары, «Чуваш кызы Әнисә» исемле повесть авторы.

[4] Даут Исхак улы Юлтый (1893–1938) – язучы, җәмәгать эшлеклесе. «Яңа юл», «Белем», «Октябрь» журналлары, «Әдәби удар» газетасы мөхәррире.

[5] Гомәр Билал улы Гали (1900–1954) – язучы, әдәби тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе. 1925–1927 елларда «Безнең юл» журналы мөхәррире. «Г. Гомәр хикәяләре» (1931), «Кубан буйларында» (1927) исемле җыентыклар авторы.

[6] Әсгать Фәхри (1901–1926) – татар язучысы. «Тормыш кочагында» (1925), «Сүзләрдән чәчәкләр» (1927) исемле лирик хикәя җыентыклары авторы.

[7] Әбүзәр Зариф улы Түрәев (1906–1938) – татар шагыйре. «Ала бозау», «Барыр юллар», «Бишне – дүрттә», «Спортчылар», «Сыйныфташлар» исемле шигъри җыентыклар авторы.

[8] Шиһабетдин Шәһәретдин улы Шәһәр (1904–1941) – татар язучысы. «Эш таңында» (1927), «Кызыл караван» (1931), «Станоклар арасында» (1931) исемле хикәяләр җыентыгы авторы.

яшь каләмнәр дә килеп кушылып, Октябрь сызыгындагы хәрәкәтне ленинизм рухында тагын да кыздыра башладылар. Боларның әле яшьрәкләре, ягъни пионер, комсомол-комсомолкалары өчен «кеч-кенә иптәшләр», «яшь эшче» кебек чынлап та игътибарга алына торган үз органнары туды. Дөрес, болар әле өйрәнчек кешеләр. Шулай булса да, болар киләчәкнең сызыгын күрсәтешә башладылар.

Әнә шушы хикәяләр, поэмалар, лирикалар белән бергә театр әдәбияты да Октябрь сызыгында хәрәкәт башлады. Революция дулкыннары, революция көрәшләре, эшче-крестьян тормышлары драмаларыбызга килеп керде, шул сызыкта яңа драмалар баш күтәрде.

Бу – шулай.

Ләкин татарда революция хәрәкәтләрен, эшчеләр тормышын, пролетариат идеологиясе орлыгын матур әдәбиятка кертү һәм эшчеләрне драмаларның каһарманнары итеп алу юлындагы беренче кыпырдаулары 1905 ел революциясе белән үк башланган иде. Югарыда әйткәнебезчә, Коләхмәтов әсәрләре шул юлдагы баш адымнар иде.

Яурупа сугышы алдыннан исә эшче-крестьяннар тормышын әдәбиятка алу, аларны әдәбиятның хокуклы гражданнары итү хәрәкәтләре зәгыйфьрәк бер рәвештә булса да, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал кебек эшче-крестьян тирәсендә әйләнүне ярата торган әдипләр каләме аркылы күренде. «Көтүчеләр», «Карт ялчы» хикәяләре, «Хикәяләр төркеме», «Акчарлаклар» – шул юлдагы иҗатлардан иделәр. 1915 елда «Аң» журналында «Авыл егетләре» дигән хикәяләре белән башлап күренгән М. Галине[1] дә, гәрчә Октябрьдән соңгы хикәяләрендә дә әле революция-пролетариат идеологиясен ачык төсе белән күрсәтә алмаса да, бу урында әйтеп үтәргә була. (Революция рухын, Октябрь сызыкларының ачык эзләрен бу каләмнән, бәлки, моннан соң күрергә булыр).

Шул вакытларда ук татар крестьян массасында, бигрәк тә аның яшьләре арасында үз тормышларын, үз көрәшләрен, үз кызыкларын татар драма әдәбиятында, татар сәхнәсендә күрәсе килү һәвәсе дә кузгалган, шуны көтү туган иде. Авыл сәхнәләрендә гел шәһәр байлары, шәһәр хәзрәтләре, «мөгаллим», «мөгаллимә»ләр тормышы-

[1] Мөхәммәд Вәли улы Галиев (1893–1952) – язучы, әдәбият галиме. «Тормыш юллары» (1940) җыентыгы, «Каюм Насыйри» (1945) исемле тарихи пьеса авторы.

ның кабатлана бирүе үзенә каршы яктан шундый һәвәсләрне дә тудыруның сәбәпләреннән берсе булды.

Кыскасы, эшче-крестьян тормышын татар драма әдәбиятына мәүзуг, мөндәриҗә итеп ала башлау өчен Октябрь революциясенә чаклы ук бераз зәмин хәзерләнгән, халык психологиясендә шуңар хәзерлек, шуны сорау туган иде.

Тик бу турыда беренче адымны башлап җибәрү өчен, крестьянның үз эченнән берәр талантлы батыр егетнең килеп чыгуы гына кирәк иде.

Чыкты. 1911 елда ук «Яшьләр алдатмыйлар» дигән 2 пәрдәлек пьесасы белән сәхнә әсәрләре язу адымын башлаган һәм 13 нче елда «Авыл бәйрәме»н язган Мирхәйдәр Фәйзи 1916 елда «Галиябану»ын язып, татар сәхнәсенә ыргытты. Сәхнә, публика моны шаулатып каршы алды.

Гәрчә бу драманың идеология ягы ачык бер төс ала алмаса да, һәрхәлдә, крестьян яшьләре арасындагы хәрәкәтләр, тартышлар татар сәхнәсенә шуның аркылы килеп керде.

«Тигезсезләр» кебек пьесаларның татар буржуазия сәхнәсенә килеп керүләре татарның нечкәргән, нәзекләнгән шәһәр публикасын, «әһле ислам»ын, «кибар гаилә»ләрен, вак буржуа балаларын ничек шатландырган булса, «Галиябану» кебек крестьян драмаларының татар сәхнәсенә аяк басуы да татар крестьян яшьләрендә, авыл публикасында шулкадәр үк зур шатлык тудырды.

Драма әсәрләрен ничә мәртәбә уйналулары ягыннан, ягьни статистика методы белән дә үлчәүчеләр бар. Драма әсәренең халкының кирәгенә, таләбенә күпме туры җавап биреп-бирә алмавын да алар шул яктан күрсәтергә тырышалар.

Сәхнә әсәрләренә бәя биргәндә, менә шушы методның да, әлбәттә, кирәге бар. «Галиябану»га бу метод белән үлчәү куйганда, аның тик бер Казанда гына 20–30 мәртәбәләр уйналуын игътибарга алу гына да җитә. Шуның белән бергә, марксизм-пролетариат тәнкыйть дөньясы да башта ук моны күтәреп алды. («Галиябану»га мөкаддимә итеп язылган тәнкыйть – Галимҗан иптәш Ибраһимов тәнкыйте.)

Октябрь алдыннан «Галиябану»лар аркылы драма әдәбиятыбызның шул рәвешчә, бер яктан, чын реализм юлында эшче-крестьян тормышына таба әйләнгәнен күрсәк, икенче яктан, аның мәүзуг,

мөндәриҗә ягыннан «кадим Шәрык» сызыгына борыла башлаганын да күреп калдык.

Бу да болай булды:

Русиядә көчәйгән реакция, сугыш вакытында аеруча көч алып, татар арасында да моның фикере, кара нәтиҗәләре күренә башлады. Мөндәриҗәсе борынгы шәрыктан алынган яки шуларга тәкълид ителгән хыялый шәрыкча поэмалар туфаны кузгалды.

«Шура» журналында, бигрәк тә «Аң»да, болар, белен пешергән кебек хәзерләнеп, дөньяга таратыла тордылар.

Соңыннан Октябрь сызыгында яза башлаучы романтик шагыйрь Ф. Бурнаш та беренче кузгалышын шул яктан күрсәтте. Бу шагыйрь хәтта революциядән соң да шушы сызыктан китеп, үзенең «Таһир-Зөһрә»ләрен китереп чыгарды. Шулай итеп, ул драма язудагы беренче тәҗрибәсен, беренче куәтен иске шәрык хыялындагы бер вакыйга аркылы һәм ханнар сараендагы фаҗигалар арасында күрсәтеп алды.

Ахырда революциядән элек башланган бу әдәби реакция чире башкаларга да йокты: «Бүз егет»ләр, «Йосыф-Зөләйха»лар, «Ләйлә-Мәҗнүн»нәр килеп чыкты. Адәм белән Хаваларгача барып җитү юлы ачылды.

Бу әдәби реакция, әле матбугатның йомшаклыгыннан файдаланып, үзен яклаучыларны да тапты.

Бу вакыттагы (19 нчы елларда була) иң күңелле әсәрләрдән Фәтхи Бурнашның «Таһир-Зөһрә» исемле шигъри әсәре революциядән соң бөтен татар сәхнәсен җанландырып җибәрә («Кызыл шәрык яшьләре». 11–12 нче сан, 1922 ел. Г. Кәрам мәкаләсе).

Ханнар сараеннан әле күзләрен ала алмаган буржуазия һәм алар тәэсиреннән әле котылып җитә алмаган театр тамашачылары өчен моның шулай булуы, шулай макталуы бик табигый иде.

Ләкин әдәбияттагы бу реакция юлыннан тиз аерылдык. Октябрь язучыларны үз сызыгына тартты. Драма әдәбиятыбызны да ул үз йогынтысы, үз җитәге[1] астына алды. Пролетариат идеологиясе драма әдәбиятыбызга килеп керә башлады. Аерым бер идеологияле көчле бер сыйныф булу яклары белән хезмәт ияләрен, эшче-крестьяннарны драмаларыбызның баш каһарманнары итеп алу

[1] Җитәге – җитәкчелеге.

юлына керелде. Татар эшче-крестьян тормышлары, гомумән, революция хәрәкәтләре, пролетариатның тылда да, фронтта да өстенлек казанучы аерым көчле бер сыйныф булып, буржуазиягә каршы көрәшүе, буржуазияне җиңеп, өстенлекне үзенә алу вакыйгалары драманың төп мәүзуглары, төп мөндәриҗәләре ителде.

Татар эшче-крестьян халкының революционер карт мөхәррире иптәш Галимҗан Ибраһимов үзенең «Яңа кешеләр»е аркылы авылның Хәйри байлары, Батырхан, Тимеркәй, Шәйбәк, Шәңгәрәй кебек авыл ярлылары, авылның ялчы егетләре, ярлы картлары аркылы гражданлык сугышы моментларында авылда күренгән картиналардан берсене драма әдәбиятыбызга китереп кертте. Шулай итеп, бу әсәр пролетариат драмалары өчен мөндәриҗә чишмәсенең бер ягы авыл тормышы, крестьяннар хәрәкәте, алар арасындагы интересларның көрәшләре икәнен күрсәтү юлында башланган сукмакларның берсе булып калды.

Завод эшчеләре тормышын драмаларның мәүзугы ителү, аларга мөндәриҗәнең бер ягын завод-фабрик эшчеләре тормышыннан алу кирәклекне күрсәтү юлында Ф. Сәйфинең[1] «Дошманнар»ы чыкты. Баембитның[2] «Патша төшерәләр»е, «Асылган»ы басылды.

Менә бу пьесалар, техника һәм сәнгатьчә эшләнү ягыннан бигрәк, алган мәүзуглары, мөндәриҗәләре ягыннан әһәмиятлеләр иде, әдәбият тарихы боларны бигрәк драма әдәбиятын авылга, революционерланган, үз сыйныфы мәнфәгатен аңлый яисә аңларга итә башлаган эшче-крестьян тормышына һәм завод-фабрик эшчеләре дөньясына каратышучы, аны шул якка таба каерып, шуның өчен башлап сукмак салышучылар иде дип аңлаячак.

Революция сызыгында драма язарга башлаучыларның берсе Шамил иптәш Госманов иде. Аның «Канлы көннәрдә» дигән драмасы үз вакытында татар эшче-крестьян публикасын канәгатьләндерүче драмаларның берсе булды. Бу драманың уйналган чагында халыкта аерым бер дикъкать һәм эчке бер дулкын белән тамаша итү кебек хәлләр күренде.

[1] Фатих Камалетдин улы Сәйфи-Казанлы (1888–1937) – язучы, җәмәгать эшлеклесе. 1923–1929 елларда «Кызыл Татарстан» газетасы, «Яңалиф» журналының җаваплы мөхәррире.

[2] Гыйлемдар Солтан улы Баембәтов (1886–1933) – сәясәт эшлеклесе, журналист. 1917 елда Уфада Мөселманнар эше буенча комиссариат оештыручыларның берсе. Милләт Мәҗлесе депутаты (1917–1918).

Октябрь рухы белән сугарылган фронт хикәяләре язучы бу иптәшнең югарыда әйтелгән драмасыннан башка тагы «Беренче адым», «Бай кызы» кебек драмалары чыкты. Вакытында болар да нык кына роль уйнадылар.

Ләкин бу мөхәррирнең әсәрләре, әдәби кыйммәттән бигрәк, алынган мәүзугының, мөндәриҗәнең революция, фронт вакыйгаларына баглы булуы ягыннан игътибар казандылар.

1917 елда үзенең «Шомлы адым», «Соңгы сәлам», «Беренче чәчәкләр» шикелле драмаларын язып, бу юлда шулар белән беренче адымнарын башлаган һәм 18 нче елда «Җилкуар» комедиясен, 19 нчы елда «Сакла, шартламасын», «Назлы кияү», «Йосыф-Зөләйха» (тарихи «Йосыф-Зөләйха түгел, Казан мещаннары тормышыннан алынган «Йосыф-Зөләйха»)ларын язып сәхнәгә керткән артист Кәрим Тинчурин да соңыннан Октябрь сызыгына таба әйләнде.

«Шомлы адым»ын үзгәртеп, Совет эшчеләре тормышына әйләндереп, шуларны тәнкыйть юллы яңадан эшләп, 25 нче елда шуннан «Нәни абый» пьесасын сәхнәгә куйды.

Ләкин аның әле кульъязма хәлендә уйнала башлаган бу пьесасы, башкалары шикелле үк, мөндәриҗәсезлек һәм сәнгатьчә яхшы эшләнеп чыга алмау кебек кимчелекләрне күрсәтү өстенә, идеология ягыннан да буталчык бер рәвештә күренде.

Публиканы канәгатьләндергән кебек күренгән җырлы-музыкалы «Казан сөлгесе» (23 нче елда язылган һәм уйналып килә торган) белән шул ук елда язылып, уйналып килгән һәм 25 нче елда басылып чыккан «Американ» исемле 4 пәрдәлек әсәрен, шул ук музыкалы, көчле драмасы булган «Сүнгән йолдызлар»ын да бу урында теркәп үтүдән артыкка уздырып булмый. Сәнгатьчә эшләнү һәм мөндәриҗәсе ягыннан мактауны күтәрә алмыйлар.

Февраль революциясе вакытында «Таһир-Зөһрә»не язган Ф. Бурнаш аннан соң «Яшь йөрәкләр» драмасын бирде. «Яшь йөрәкләр» драмасы «Галиябану»ның революционерланган яңа бер иптәше иде. Әсәрдә вакыйга дөнья сугышы башланган вакытлардан алып, февраль революциясе вакытлары белән тәмам була. Шушы вакыйга анда ярлы крестьян яшьләре тормышыннан алынып язылган. Әсәрнең мөндәриҗә ягыннан әһәмияте дә шундадыр.

Публиканы да бу драма яхшы ук канәгатьләндерә алган күренде. Вакытында сәхнәдә ару гына роль уйнады.

25 нче елның ноябрендә шул ук Ф. Бурнашның авылда комсомоллар тормышыннан алынып язылган «Камали карт» дигән 4 пәрдәлек пьесасы Татар дәүләт театры сәхнәсенә килеп аяк басты. Публика яхшы каршы алды алуын, ләкин бу комедияне күбрәк артистлар (бигрәк тә Тархан кебекләр) тутырып уйнаган күренделәр. Шуның өстенә Камали карт һич табигый булмаган бер рәвештә һәм циркларыдагы көлдерүчеләргә охшаулы бер характер (тип түгел) булып чыккан. Мондый картларны чын татар тормышыннан алынган дип булмый. Хосусан, уллары, кызлары комсомол булып әйләнгән бер заман вә мохиттә бу дәрәҗәдә тилеләрчә мөгамәләле бер авыл картын очрату кыен булыр.

Янә никахка килүче мулла-хәзрәт тә 18–19 йөздәге тәмам феодал тормыш руханисы һәм Бохара тибы булып эшләнгән. Хәлбуки Октябрь революциясе, комсомол ячейкалары төзелү вакытындагы муллаларның һәммәсе диярлек – «җәдит» муллалар. Никахка килүче хәзрәт тибы янә шундый муллалардан алынган булса, әсәр бәлки табигыйрәк бер комедия булып чыккан булыр иде. Һәрхәлдә, бу әсәр дә бигрәк мәүзуг, мөндәриҗә ягыннан игътибарга алына.

Шулай итеп, Октябрь бу шагыйрьне дә күктән җиргә, хыялдан вакыйглыкка тартып, пролетариат сызыгына төшерде, әлеге әсәрләре шуны ачык күрсәтәләр.

Революция рухында, Октябрь сызыгында язучыларның бу урында әйтеп үтәргә тиеш булганнарыннан берсе Афзал иптәш Таһир булыр. Бу иптәшнең «Күчү чорында» дигән әсәре ярышта да үткән иде. Чит җөмһүриятләрдә эшләп йөрүе белән әле арабызга ныклап кереп [китә] ала алмаган бу драматург һәм хикәяче бу көнгәчә бигрәк шаулатып китә алмаса да, үзендә көч барлыкны күрсәтә килә. Тел, өслүбендә дә, гәрчә бигүк шома эшләнгән булмаса да, үзенә күрә бер аерымлык та юк түгел.

Инде соңгы вакытларда драма, комедияләр язу эшен кыздыра башлаган Кәрим Әмиригә[1] азрак аерым рәвештә тукталып үтик.

[1] Кәрим Хөсәен улы Әмири (1893–1962) – язучы. «Казан кызы» (1924), «Печән базары» (1925) исемле пьесалар авторы, 1969 елда «Таң вакыты» исемле сайланма әсәрләр җыентыгы дөнья күрә.

Башта «Йосыф-Зөләйха» (тарихи Йосыф-Зөләйхалар), «Ләйлә-Мәҗнүн» кебек драмалар белән чыгып, әдәби реакция эзеннән кадим шәрык сызыгы буйлап китә язган һәм баш адымында Дәрдмәнд мәктәбеннән чыккан яисә аның өслүбе тәэсире астында булган бу шагыйрь үзенең соңгы хикәяләре, лирикалары һәм поэмалары аркылы тәмам Октябрь сызыгына төшкәнен ачык күрсәткән иде.

1925 елда басылып чыккан 4 пәрдәлек «Печән базары» дигән комедиясе (дөресе, пьесасы) аның сәхнә әсәрләре язуда да шушы юлда нык, зур адымнар белән атлаячак өметен бирде. Бу шагыйрь үзенең «тишек борын»лы Гыймадилары аркылы бу әсәре белән чын тормыш типлары ясап чыгара алырлык куәте бар икәнен дә сиздерде.

Гыйльми үзәк ярышында үткән драмаларның берсе булган, уйналып үткән «Пайтәхет җәлладлары» да – аның әһәмиятле драмаларыннан.

Гәрчә сәхнәгә 25 нче елның ноябрь аенда гына килеп кергән һәм әле басылып чыкмаган, шуның өстенә сәнгатьчә эшләнүе дә «Печән базары» дәрәҗәсенә җитә алмаган булса да, публиканы канәгатьләндергәне, шулай ук уйналуы белән ул үзенә газеталарда мактаулы рецензия ала алганы өчен аның 4 пәрдәлек «Казан кызы» комедиясен дә бу урында әйтеп үтәргә була.

Февральдән соңгы татар буржуазиясенең хәрәкәтләреннән, аның милләт мәҗлесләреннән көлә, шуларны сәхнәдә драмаландыра башлауны да күрдек. Исмәгыйль иптәш Рәминең «Милләт мәҗлесе» шундый адымнарның берсе булды.

Бу урында Октябрь тәэсире белән дингә каршы басылып чыккан һәм күп уйналган комедияләрдән Мөхәммәд иптәш Парсинның[1] «Бал графинясы» белән «Ураза бәйрәмендә»сен, шулай ук Афзал Таһирның «Динчеләр һәм динсезләр»ен дә өстәп китәргә кирәк. Болар дингә каршы көрәшүнең сәхнәгә килеп кергән беренче адымнары булдылар.

«Көннәр көнендә» (Әхмәд Гомәров) һәм «Гаскәр» (Шәрәф Мәхмүд) дигән пьесаларны да шул югарыгылар рәтеннән санап үтәргә

---

[1] Мөхәммәд Зариф улы Парсин (1900–1963) – журналист, публицист, әдәбият һәм театр тәнкыйтьчесе. 1922 елда «Кызыл Шәрык яшьләре» журналы, 1925 елда «Татарстан» газетасы мөхәррире.

кирәк һәм икесе дә басылганнар. «Көннәр көнендә» гражданнар сугышы вакыйгасыннан алынып, тәмам революция сызыгында язылган, каһарманнары эчендә «Милли идарә» башлыклары да бар. Сәхнәгә куелган чагында да бу әсәр начар чыкмады.

«Гаскәр» пьесасы – «иске һәм кызыл гаскәриләр тормышыннан алынып язылган тарихи пьеса». Бу әсәр эшләнү ягыннан кимчелекле булса да, мөндәриҗәсе һәм идеологиясе ягыннан бик әһәмиятле. Революционерланган, советлашкан крестьян яшьләре, коммунистлар, комсомоллар, комсомолкалар, кызыл армиялеләрнең хәрәкәтләрен, шуларның иҗтимагый, сәяси тормышларын сурәтләндерә, ләкин агитациясез түгел. Бигрәк тә авылларда куела торган әсәр.

Тагын шуны да тарихның бер читенә эләктереп үтәргә кирәк: Октябрьдән соң драма әдәбиятыбыз бер яктан «Таһир-Зөһрә»ләр, «Йосыф-Зөләйха»лар дөньясын ташлап, үзенә эшче-крестьяннар тормышын мәүзуг вә мөндәриҗә итеп ала башлаган булса, икенче яктан, аның «Адәм-Хава» турындагы легендаларны «гыйсъян» юлында хәрәкәтләндереп куюы да күренде.

Октябрьнең киң «гыйсъян» иреге тәэсире астында туган «Җир угыллары» дигән көйле драма шул юлда беренче һәм соңгы адым булды.

«Нәләт»че яшь шагыйрь Такташ, Октябрь азатлыгы эчендә котырынып, шушы драмасы аркылы татар әдәбият дөньясына яңа бер дәһрилек – татар нигилизмы күтәреп чыкты. Бу – символизм юлында ачы «каргыш»лар, «нәләт»ләр белән тулы шашкынлы бер «гыйсъян» һәм шагыйрьнең иҗаты куәтен күрсәтү өчен дә көчле бер символ иде. Шагыйрьнең танылуы да бигрәк шушы әсәре аркылы булды.

Ләкин идеология ягыннан гаять болганчык булган бу драманың шау-шуы, гыйсъяны озакка сузыла алмады, тиз басылды. Октябрь бу шагыйрьне дә итәгеннән тартып, иске «Адәм-Хава» юлыннан яңа адымнар юлына төшерде. Соңгы лирикаларына караганда инде бу шагыйрьнең лирикаларында да Октябрь сызыгына төшеп, яңа тормыш симфонияләрен көйли башлаганлыгын күрәбез.

Гомумән, үзенең шигырьләре аркылы укучыны үзе артыннан кызыктырып ияртеп алып китеп, кешене башын әйләндерерлек юлсыз бер мәйданга китереп кертеп тә, соңыннан аны үзе ташлап

кача торган бу шагыйрь шул юлда «Җир угыллары» шикелле куәтле драмаларны бирә алырмы, нишләр – анысы киләчәк эш.

Инде Октябрьдән соңгы драма әдәбиятыбызның тел ягыннан һәм сәнгатьчә эшләнүләренә каратып, берничә сүз әйтеп үтик.

Телләре матур, һаман садәләшеп, эшләнеп баралар. Ләкин шунысы: аңлатуда, өслүбтә, тәгъбирләрдә һаман иске әдәби традицияләрдән, буржуазия әдәбияты юлыннан бөтенләй аерыла алмыйлар.

Сыек, сай мөндәриҗәле булганнары да аз түгел.

Тип, характерларга килгәндә мәсьәлә болай: вак-вак характерлар яки ярым-йорты типлар, типка охшый язган әсәрләрне очратып була, әмма сәнгатьчә чынлап эшләнеп чыккан төгәл бер тормыш типлары әле безнең Октябрьдән соңгы драмаларда ачык күренә алмый.

Хәер, инде татар буржуа драмалары да (бик азларын истисна[1] белән) бу турыда нык аксыйлар иде.

Революция алдыннан крестьян тормышын беренче мәртәбә сәхнәгә китереп кертүе һәм теленең матурлыгы белән мактала торган «Галиябану»да да без төгәл бер тип бирә алырлык куәт күрә алмаганыбыз шикелле, аның революционерланган туганы «Яшь йөрәкләр»дә дә бер тотып күрсәтерлек тип очрата алмыйбыз. «Галиябану» кисәк-кисәк табигатьләр, вак характерлардан артыкны эшләп чыгара алмаса, «Яшь йөрәкләр» дә шуннан күп уздыра алмый.

Мөндәриҗә яклары тулы гына, телләре садә, җиңел, матур.

Менә боларның бөтен сыйфатлары, бөтен макталына ала торган яклары. Әмма төгәл тормыш типлары бирә алу ягыннан әле боларны күтәреп чыгарга ашыгып булмый.

Кыскасы, Октябрьдән соңгы драмаларыбызны, кирәк басылып чыкканнары, кирәк әле басылмастан уйналып йөргәннәре булсын, реаль яки идеаль бер тип эшләп чыгару ягыннан алып, гомумән әйткәндә, эш бик шәптән түгел әле, бу яктан тагын үсәсебез бар.

Чыннан килештереп, сәнгатьчә чын бер тормыш типлары ясап чыгару бит ул, гомумән, сүз сәнгатенең, бигрәк тә драма әдәбиятының иң югары бер баскычы санала.

Бер драма әсәренең әдәби гомере дә, һәр нәрсәдән элек, андагы типларга, аларның сәнгатьчә дөрес эшләнеп чыга алу якларына бәйләнгән.

[1] Истисна – искәрмә.

Менә мондый типларны эшләп чыгару өчен, күп белем, аерым бер осталык, талант, күп тәҗрибә һәм күпләрне баштан кичереп үтү кирәк. Шуның өчен әле яңа туып, күтәрелеп килгән эшче-крестьян драматургларының бу юлда уңышлылык күрсәтүләрен алдарак бер заманда күрергә туры киләчәк.

Шулай булса да, мин драма язучыларыбызның һәммәсенә, бигрәк тә пролетариат драматургларына каратып:

– Һәр нәрсәдән элек безгә сез гомерле тормыш типлары ясап бирергә тырышыгыз, шулар аркылы пролетариатка, эшче-крестьяннарга тормышны аңлауны җиңеләйтешегез, үзара аңлашу, сөйләшүләребезгә дә шулар аркылы икътисад кертегез! Шулар аркылы без конкрет мисаллар белән генә аз вакыт эчендә тулы фикерләр аңлатыша башлыйк, – дияр идем.

Безнең эшче-крестьян публикабыз да инде үзенең драматургларына шушы таләпне куярга якынлашып килгән күренә. Бу яңа публика да инде сәхнәдән ялгыз матур-матур сүзләр, моңлы-моңлы җырлар, кисәк-кисәк табигатьләр, вак-вак характерлар күрсәтелү белән генә канәгатьләнә алмас. Яңа тормышны яңа картиналар аркылы, сәнгать-әдәбият дөньясы өчен гомерлек итеп эшләнгән типлар белән сурәтләндерелүен сорый башлар.

Кыскасы, эшче-крестьян драматурглары хезмәт ияләренең һәм дә кулына власть алган җиңүче пролетариатның яңа тормышын, аның бөтен тормыш картиналарын, аның социализм-коммунизмга бару юлында төрле авырлыклар, төрле көрәшләр эчендәге хәрәкәтләрен, шул көрәшләрдә башыннан кичергәннәрен, кичереп торганнарын, чын үз каһарманнары белән телләрдә мисал ителеп йөртерлек рәвештә чын художестволы үз типлары аркылы тиздән бирә башларбыз.

Моңар өмет зур. Хәзерге язучылар эченнән болар чыга алмаганда да, яшь буын эченнән, комсомол-пионерлар арасыннан җитешеп килгән яшь куәтләрнең бу турыда зур адымнар атлый башлаячакларында шик юк.

* * *

Бу урында татар драма әдәбиятында күргән соңгы яңа бер зур адымны әйтеп үтмәсәк, бу турыдагы тарихи-тәнкыйди карашыбыз зур кимчелекле булган булыр иде.

Татар драма әдәбиятындагы бу яңа зур адым Татарстан җөмһүриятенең һәм аның әдәбият көчләренең, музыкасының үсүе нәтиҗәсендә «Сания» исемендә татар дөньясында беренче опера тудырылуы булды.

Бу әсәр 1925 елның июнь аенда Татарстан җөмһүрияте төзелүгә биш ел тулу бәйрәме ясалу уңае белән Казанда беренче мәртәбә башлап татар сәхнәсенә дә килеп керде. Матди яктан Татарстан җөмһүриятенең зур гына дәүләт булышлыгы аркасында мәйданга чыга алган бу операны да мәшһүр татар-башкорт җырчысы Газиз иптәш Әлмөхәммәдов[1] белән татар композиторы булган Солтан Габәши[2] һәм рус музыкачысы Виноградов[3] иптәшләр тарафыннан төзелгән коллектив тудырды.

Ләкин бу әсәр болай бердән генә, капылт кына килеп чыккан бер иҗат икән, дип уйланмасын. Моның өчен моннан элгәре төрле яктан хәзерлек баскычлары эшләнеп өлгергән иде.

Татар дөньясында музыканың игътибарга алына башлавы һәм бигрәк тә Татарстан җөмһүриятенең татар музыкасына аерым бер әһәмият белән карап, аны үстерергә тырышу, көнчыгыш музыка техникумнары мәйданга китерелү, аларда татар җыры, татар музыкасы аерым бер игътибар белән өйрәнелә башлау кебек эшләр әнә шушы операның тууы өчен эшләнгән хәзерлек баскычларының берсе иде.

Моның икенче бер хәзерлек баскычы янә соң елларда татар драма әдәбиятында җырлы-музыкалы драмаларга охшаш пьесаларның туулары, татар сәхнәсенә шуларның килеп кереп уйнала башлаулары булды.

Бу юлда беренче адым Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану»ында күренде.

---

[1] Газиз Салих улы Әлмөхәммәдов (1895–1938) – җырчы, композитор. Беренче татар опералары «Сания», «Эшче» (С. Габәши, В. Виноградов белән берлектә), вокаль һәм инструменталь әсәрләр авторы.

[2] Солтан Хәсән улы Габәши (1891–1942) – композитор, музыка белгече, хормейстер. Беренче татар опералары «Сания», «Эшче» (Г. Әлмөхәммәдов, В. Виноградов белән берлектә), вокаль һәм инструменталь әсәрләр авторы, халык җырларын эшкәртүче.

[3] Василий Иванович Виноградов (1874–1948) – композитор, скрипач, педагог. Татар һәм башкорт музыкасына нигезләнгән симфоник әсәрләр, драма спектакльләренә музыка авторы, халык җырларын эшкәртүче.

Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә»се, Кәрим Тинчуринның «Казан сөлгесе», «Сүнгән йолдызлар»ы һәм Такташның «Җир угыллары», тагын әле басылмаган берничә көйле пьесалар кебек әсәрләр шулар рәтеннән булган нәрсәләр иде.

Әнә шундый хәзерлек баскычларын үткәреп, ниһаять, «Сания» операсын күрә алдык.

* * *

Мин бу мәкаләмдә драма әдәбиятыбызның күбрәк басылып чыкканнарын һәм аларның характерлырак булганнарыннан тик мисал вә таяныч булу өчен фәкать берничәләрен генә сайлап алып күрсәттем. Уйналып йөргән һәм басылып чыгып, матбугат дөньясына аяк басмаган пьесаларыбыз да аз түгел.

Егерме еллык татар драма әдәбиятына тарихи карашыбыз төгәлләнә төшсен өчен, бу урында татар сәхнәләрендә уйналып йөреп тә, басылмастан калган әсәрләрнең кайберләренең исемнәрен генә булса да әйтеп үтүне тиеш табамын.

Артист Уральскийның[1] Октябрьдән соң язылган:

«Бал-куаслы туй» (4 пәрдә, 23 нче елда языла һәм уйнала) дигән комедиясе, «Тәңре ярлыкады» (23 нче елда языла һәм уйнала) дигән пьесасы, «Малик Ширкән» (5 пәрдәдә. 23 нче елда языла, уйнала), «Туктамыш хан» (5 пәрдә, 24 нче елда языла, уйнала) дигән драмалары. «Кәҗә Якуб» (25 нче елда языла, уйнала – 3 пәрдәдә) дигән комедиясе.

Артист Ильясовның:

«Идегәй батыр» (4 пәрдәдә. 23 нче елда языла, уйнала), «Сөембикә» (5 пәрдә, 25 нче елда языла, уйнала) дигән драмалары һәм «Мин – комиссар хатыны» (3 пәрдә, 25 нче елда языла, уйнала) дигән музыкалы комедиясе.

Артист Гыйззәтовның[2]:

«Бабур хан» (5 пәрдә, 23 нче елда языла, уйнала) дигән драмасы, «Талир тәңкә» (4 пәрдә, 23 нче елда языла, уйнала) исемендә музы-

---

[1] Уральский I (Габдулла Насыйбулла улы Насыйбуллин; 1903–1942) – актер, режиссер һәм сәхнә әсәрләре авторы.

[2] Таҗи Кәлимулла улы Гыйззәт (1895–1955) – драматург, беренче музыкаль комедия – «Башмагым» либреттосы авторы.

калы комедиясе һәм «Наемщик» дигән комедиясе (3 пәрдә, 20 нче елда язылa, уйнала) – шулар рәтеннән булган әсәрләрдер.

1908 елда «Килен» атлы бер пәрдәлек комедия язып бастырган артист Мангушевның[1] «Бәхет эзләүчеләр» дигән 3 пәрдәлек комедиясе дә шулар рәтенә тезелә. (Бу артист тарафыннан 1913 елда «Мөхәррир» исемендә 2 пәрдәлек бер комедия язылып та уйналган иде.)

Болардан башка янә шулар рәтеннән булган пьеса, драма, комедияләр аз түгел. Ләкин артист Мохтар Мутинның әйтүенчә, һәммәсен җыеп үлчәгәндә, хәтта авырлыклары биш потларга тартырлык дәрәҗәдә саннары күп булып җыелган ул әсәрләрнең барын бу урында санап утырып булмый.

Югарыда китерелгән, басылмыйча калган әсәрләрдән без бер кирәкле нәрсәне ачык аңлый алабыз. Ул да булса – татар артистларының күпләре тик башкаларның әсәрләрен уйнап йөрүчеләр генә булмыйча, үзләре дә каләм тотып, үзләре дә язып, сәхнәне материалга, әсәргә баетыша килгән булучылыкларыдыр.

Бу урында Октябрьдән соң мәйдан алган балалар пьесалары турында да берничә сүз әйтеп үтик.

Татар әдәбиятында Октябрьдән соң балалар өчен хикәяләр язылу белән бергә, алар өчен пьесалар язу мәйданында да хәрәкәтләр барды.

Балалар өчен хикәяләр язу эшләре 1905 елдан Октябрьгәчә булган татар буржуазия әдәбияты дәверендә дә бар иде, шулар белән бергә «Чәчәкләр арасында» дигән пьеса кебек балалар пьесасы язылу да башланган иде, ләкин татар милли буржуазиясе дәверендә өлкәннәр өчен тудырылган матур әдәбиятның бик күп өлеше буржуазия сыйныфы теләген юлга, аның максатына, аның идеологиясенә каратып, шуңа яраклы итеп тудырылган кебек, балалар матур әдәбияты да шул юлда иде. Балаларны динле, тәүфикъле итеп җитештерү, Аллага итагатьчән, өлкәннәргә, ата-аналарга, муллаларга, хәзрәтләргә, остазбикәләргә буйсынучан, аларга хезмәт кылучан итеп тәрбияләү өчен язылалар иде.

[1] Габдрахман Габделкәрим углы Мангушев (1887–1919) – актер, журналист, драматург. 1910 елда «Сәйяр» труппасында эшли башлый, 1915 елдан «Ширкәт» труппасына күчә. «Мөхәррир» (1914), «Бәхет эзләүчеләр» (1918) һ. б. пьесалар авторы.

Октябрь боларның юлын да үзгәртте. Октябрьдән элек яза башлаган шагыйрьләрне балалар өчен хикәяләр язуда да Октябрь үз сызыгына тартты. Кәрим Әмиринең «Завод мәктәбендә», «Фабрик баласы» дигән хикәяләренә охшаш хикәяләр чыга башлады. Октябрьнең үзе җитештергән яшь әдипләр балалар өчен чын Октябрь сызыгында хикәяләр тудыра башладылар. Толымбайскийның «Үксез»е, Гомәр Галиевнең «Биктимер ничек эшче булды?»сы, «Бәхет» кебек хикәяләре чыкты. «Яшь эшче», «Октябрь яшьләре», «Кечкенә иптәшләр» кебек журналлар хәзерге пионерларга, ленинчы яшьләргә азык булырлык хикәяләр бирә башладылар.

Менә шулар рәтеннән Октябрь балалары өчен пьесалар да тудырыла башлады. Октябрьдән элгәре матур гына шигырьләр язып килүче Фазыл Туйкинның[1] бер пәрдәлек «Салих бабай» пьесасы, Чаллы 2 нче баскыч «Карл Маркс» мәктәбендәге пионерлар коллективы чыгарган «Октябрь чәчәкләре» исемле өч пәрдәлек пионерлар пьесасы, С. Әдһәмованың[2] ике пәрдәлек «Авыл тормышыннан бер күренеш» дигән пьесалары басылып чыктылар. Касыйм Шамилнең[3] «Тычканга үлем, мәчегә көлке»се, «Галинур», «Бездә һәм аларда», С. Әдһәмованың «Хәзер бул!»ы шикелле пьесалар һәм башкалар уйналып йөри башладылар. Хәзер без Татарстан дәүләт театры янында аерым балалар труппасы төзелгәнен дә күрәбез. Бу эш безгә балалар театр әдәбиятының баюы өчен дә сәбәп булачактыр.

Тәрҗемәләр.

Башка телләрдән театр әсәрләрен тәрҗемәбез дә XX йөз белән башлана. Моны башлап җибәрүче Галиәсгар Камал булды. Ул 1900 елда госманлы буржуа шагыйрьләренең мәшһүр драматургларыннан Нәмык Кәмалнең ул вакыттагы татар хәятына туры килә торган «Зәваллы чуҗык» дигән драмасын «Кызганыч бала» исеме белән тәрҗемә итеп, бу юлда беренче адымны салды. Бу тәрҗемә

[1] Фазыл Кәрим улы Туйкин (1887–1938) – язучы, фольклорчы. «Тормыш корбаннары» (1912), «Ватан каһарманнары» (1912) исемле пьесалар, «Нардуган» (1915) исемле шигырьләр җыентыгы авторы.

[2] Сәрвәр Сәет кызы Әдһәмова (1901–1978) – язучы, тәрҗемәче. Балалар өчен «Дуслар», «Тубалбаш» исемле хикәя җыентыклары, пьесалар, мемуарлар авторы.

[3] Касыйм Шамил улы Шамил (1892–1981) – актер, режиссер, педагог. ТАССР-ның халык артисты (1940). 1924, 1932 елларда Казанда Татар балалар театрын оештыручыларның берсе.

әүвәл өй театрларында уйналып йөреп, соңыннан рәсми татар сәхнәсе дә беренче адымнарын шуны уйнау белән башлады.

Шулай итеп, тәрҗемә эшләре дә татарның сәнгатьле оригиналь театр әсәрләрен язуда беренче сукмакны салучы Г. Камал белән башланып китте.

Ләкин театр әсәрләрен чит телләрдән тәрҗемә итү эшләре 1915–1916 елларгача бик әкрен бара. Аңача татар драматурглары күбрәк татарның үз тормышыннан оригиналь әсәрләр язу белән шөгыльләнәләр.

Моның бер сәбәбе әле татар дөньясында тәрҗемәләр өчен базар ачыла алмыйча тору булган булса кирәк. Моны да без татар әдәбиятына русчадан байтак кына гыйльми-әдәби китаплар тәрҗемә итеп бастырган һәм мәшһүр «Русча-татарча лөгать» иясе булган Солтан Рәхманкуловның[1] «Дым» («Төтен») дигән романын тәрҗемә итеп бастырырга наширләр таба алмыйча йөрүеннән ачык аңлыйбыз.

Хәтта «Әлислах»ның 1908 елда чыккан 43 нче санында без бу турыда идарә тарафыннан сызык астына төшерелеп басылган менә шушы сүзләрне укыйбыз: «Дым» сахибе мәкалә тарафыннан (С. Рәхманкуловны әйтә. – *Г.С.*) тәрҗемә ителеп, тизлектә басылып та чыкса кирәк. Безнең Казан китапчылары, очсыз төшеп, күп сатылырлык китаплар бастыру максатына гына бирелгәнлекләреннән, алар арасыннан шулкадәр әһәмиятле әсәрне нәшер итәрлек җөрьәтле көтебханә дә табыла алмады. Шерлок Холмсның икенче җөзье чыкса, сугышып-сугышып бастыралар иде.

Менә шушы характерлы хәл, бер яктан, әлбәттә, театр әсәрләрен, тәрҗемә хәрәкәтләрен кыздырып алып китә алмауга да тәэсир иткән булачагында шөбһә юк.

Шулай булса да, без 1906–1907 елларда русчадан Гогольнең «Өйләнү» дигән театр әсәренең Дәүләтшин[2] тарафыннан тәрҗемә ителгәнен күрәбез.

1911 елдан инде Галиәсгар Камал русчадан тәрҗемәләрен башлый. Аннан соң аңа башкалар ялганып китәләр.

---

[1] Солтан Габделмәннан улы Рәхманкулов (1888–1916) – язучы, тәрҗемәче, сүзлекче. «Русча-татарча мөкәммәл лөгать» (1920, Г. Кәрам белән берлектә), «Русча-татарча кесә лөгате»н төзүче.

[2] Габдрахман Дәүләтшин-Хөсәенов – тәрҗемәче, китап сәүдәсе белән шөгыльләнүче.

Мәшһүррәк һәм уйналган тәрҗемәләр түбәндә еллары белән күрсәтелеп үтелә.

*1911–12–13 нче елларда.*

1. «Хөкемдә хаталык» – Г. Камал тәрҗемәсе. (11 нче елда тәрҗемә ителә һәм уйнала).
2. Островскийдан – «Гроза». Г. Камал тәрҗемәсе (11 нче елда тәрҗемә ителә һәм уйнала).
3. Мольердан – «Саран». Г. Камал тәрҗемәсе (12 нче елда тәрҗемә ителеп, шул ук елда басыла һәм уйнала).
4. Һенрих Һейне – «Әлмансур». Сәгыйть Сүнчәләй тәрҗемәсе (1913 елда басыла һәм уйнала)[1].

*1915–16 нчы елларда.*

1. Максим Горькийдан – «Мещаннар». Г. Кәрам тәрҗемәсе (шул ук елларда уйнала).
2. «На дне».
3. Островскийдан – «Төшемле урын». Шәһит Әхмәдиев[2] тәрҗемәсе.
4. «Гөнаһсыз гаеплеләр» (шул ук елларда уйнала).
5. Гогольдән – «Ревизор». Г. Камал тәрҗемәсе.
6. Мольердан – «Ирексездән табиб» (шул ук елларда уйнала).
7. «Икенче кат яшьлек». Русчадан Г. Камал тәрҗемәсе.
8. «Кара пәрдә». Г. Камал тәрҗемәсе (шул ук елларда уйнала).
9. Намык Кәмальдән[3]. – «Ватан». Г. Камал тәрҗемәсе (шул ук елларда уйнала).
10. Хаҗибәкевтан. – «Аршин мал алан» (шул ук елларда уйнала).

1916 елда тәрҗемә ителеп уйналган шушы музыкалы комедия, бездә опереткалар тудыру өчен, беренче үрнәк була һәм шул турыда

[1] Ләкин бу тәрҗемәнең уңышлы чыга алмавы һәм яңлыш бер тәрҗемә булуы турында 1914 ел «Аң» журналының 4–5–8–9 нчы саннарында Ф. Сәйфинең озын һәм әһәмиятле тәнкыйте булып үтте. *(Авт. иск.)*

[2] Шәһит Гыймадетдин улы Әхмәдиев (1888–1930) – дәүләт эшлеклесе. язучы. «Аваз» газетасы мөхәррире, Милләт мәҗлесе депутаты (1917–1918). Г. Ибраһимов белән берлектә «Мәгариф» журналын оештыручы.

[3] Намык Кәмаль (1840–1888) – атаклы төрек язучысы, драматург, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе.

хәрәкәт кузгаттыра. Бу оперетканы татар сәхнәсенә китереп кертүчеләр дә артист Җәләл Байкин[1] беләп артистка Байкиналар булалар.

11. Нариман бәк Наримановтан – «Надир шаһ». Ф. Сәйфи тәрҗемәсе. (Казанда беренче мәртәбә 17 нче елда куела. Соңыннан Мохтар Мутин идарәсендә Әстерхан һәм Уфада уйнала).

12. «Кара пәрдә». Г. Камал тәрҗемәсе (шул ук елларда уйнала).

13. «Кызыл калфак» – Сакаева тәрҗемәсе. Балалар театры өчен (уйнала).

*1917–1918 елларда.*

1. Гординнан – «Үксез кыз». З. Нуркин[2] тәрҗемәсе (шул ук елларда уйнала).

2. Островскийдан – «Урман». Сакаева тәрҗемәсе (шул ук елларда уйнала).

3. Островскийдан – «Эш бусагасында». Сакаева тәрҗемәсе (шул ук елларда уйнала).

4. Найденовтан – «Ванюшин балалары». Сакаева тәрҗемәсе. Казан тормышыннан (Казанда беренче мәртәбә 1917 елда уйнала).

5. «Колдунья». Сакаева тәрҗемәсе (шул ук елларда уйнала).

6. «Өч сөаль». Сакаева тәрҗемәсе. Шул ук елларда уйнала.

7. Шиманскийдан. – «Кан». И. Кули[3] тәрҗемәсе (шул ук елларда уйнала).

8. «Яңа драма». Русча аркылы Испания әдәбиятыннан. Ә. Кули тәрҗемәсе.

9. Шиллердан – «Юлбасарлар» (Разбойники). Шәриф Камал тәрҗемәсе. Казанда беренче мәртәбә 1918 елда, Уфада 23 елда уйнала. Рецензияләр «Эш» (132 нче сан, Г. Кәрамнеке) һәм «Башкортстан»да (76 нчы сан, Х. Кәрим рецензиясе).

10. Гоццидан – «Хан кызы». К. Тинчурин тәрҗемәсе ( шул ук елларда уйнала).

---

[1] Җәләл Мөхәммәтҗан улы Байкин (1886–1954) – актер, режиссер, педагог. Әстерхан шәһәрендә татар театрын оештыручы.

[2] Заһид Садретдин улы Нуркин (1888–1966) – журналист, тәрҗемәче. «Кояш» газетасында эшли, 1922–1927 елларда Гыйльми үзәк коллегиясе сәркатибе.

[3] Ибраһим Габделвахит улы Кули (1885–1936) – журналист, тәрҗемәче. «Татарча-русча сүзлек» (1927), «Татар теленең орфография сүлеге»н (1930) төзүдә катнаша.

*1919 елда.*

1. Карповтан – «Юлбасар галим». Артист Солтанов һәм И. Кули тәрҗемәләре.

2. Г. Дригиллидан – «Яхшы тегелгән кием». Комедия. И. Кули тәрҗемәсе (шул ук елда басыла).

3. Джакометтидан – «Җинаятьче гаиләсе».

4. Гауптманнан – «Тукучылар» (уйналмаган).

5. Стриндбергтан – «Ата». Ш. Байчура[1] тәрҗемәсе (уйналмаган).

6. Стриндбергтан – «Сауди». Г. Хәсәни тәрҗемәсе (уйналмаган).

*1920 елда.*

1. Шекспирдан – «Отелло». Г. Кәрам тәрҗемәсе.

Бу трагедия Казанда беренче мәртәбә 1921 елда 15 апрельдә «Большой театр» сәхнәсендә куела. Бу әсәрнең тәрҗемәсе һәм аның уйналуы, уйнаучылары, бигрәк тә монда Отелло тибын иҗат итеп уйнаучы Мохтар Мутин турында «Татарстан»ның шул ук елда чыккан 85 нче санында әһәмиятле рецензиясе бар. Шул ук әсәрнең Казанда икенче мәртәбә уйналуы уңае белән (22 нче елларда) Татарстан Үзәк Башкармасы тарафыннан чыгарыла торган русча («Известия») газетаның шул елдагы 88 нче санында да «Г» имзалы берәү тарафыннан шулай ук әһәмиятле рецензия басыла.

«Отелло» Уфада-Башкортстанда 1923 ел декабрьдә уйнала. «Башкортстан»ның шул ук елдагы 154 нче санында «Кара сакал»ның рецензиясе бар.

2. Шекспирдан – «Һамлет». Гали Рәхим тәрҗемәсе. Бу әсәр Казанда беренче мәртәбә 1922 ел, 21 апрельдә уйнала. Бу классик трагедиянең тәрҗемәсе, уйнаучылары турында шул ук елгы «Татарстан»ның 93 нче санында Г. Кәрамның әһәмиятле рецензиясе бар.

Әсәр 24 нче елда куела. «Башкортстан»ның 144 нче санында башкорт телендә «Кара сакал» кушаматлы берәүнең һәм 45 нче санында Мәҗит Гафуриның рецензияләре бар. Тарихи яктан әһәмиятле рецензияләр.

3. А.Д. Лавровтан «Өлешсезләр». Учитель Кули тәрҗемәсе (шул ук елда басылган).

4. Писемскийдан – «Күрәчәкне күрми, гүргә кереп булмый». Артист Шамильский тәрҗемәсе (шул ук елда уйнала).

[1] Шәриф Хәсән улы Байчура (1892–1972) – журналист, тәрҗемәче.

5. Шиллердан – «Вильгельм Телль». С. Җәлал тәрҗемәсе. (1920 дә басылган).

6. Н. Макаровтан – «Бер забастовканың тарихы». Ф.А. тәрҗемәсе (1920 дә басылган).

7. «Саташкан». Артист Солтанов тәрҗемәсе (уйнала).

*1921–22 нче елларда.*

1. Мольердан – «Скапенның хәйләләре», Г. Камал тәрҗемәсе (21 нче елда уйнала).

2. Гординнан – «Иблис». Г. Камал тәрҗемәсе (22 нче елда уйнала).

3. «Имам Хәмзә». Русчадан Г. Камал тәрҗемәсе.

4. Любовь Столицадан – К. Тинчурин тәрҗемәсе (22 нче елда уйнала).

5. Гординнан – «Убой». К. Гобәйдуллин тәрҗемәсе (уйнала).

*1924–1925 елларда.*

1. Мольердан – «Хәстә». Г. Камал тәрҗемәсе (шул ук елларда уйнала).

2. Гоццидан – «Пәри кызы». Артист Шамильский[1] тәрҗемәсе (уйнала).

3. Норвегия шагыйреннән – «Мең бер кичә» (уйнала).

4. Богдацкидан – «Хәлвәфруш» (уйнала).

5. Софоклдан – «Эдип хөкемдар». С. Рәми тәрҗемәсе (уйналмаган). Бу әсәрнең Ф. Бурнаш тарафыннан тәрҗемә кылынганы да булса да, дөрес тәрҗемә С. Рәминеке диләр.

6. И. Гехтманнан – «Коммуна көннәрендә». Ф. Бурнаш тәрҗемәсе (1925 тә басылган, 2 пәрдәдә).

*1925 елда.*

1. «Чит илләрдә» (үзгәртелеп тәрҗемә) («Машиналар бунты» дигән әсәрдән). К. Тинчурин тәрҗемәсе.

2. Шекспирдан – «Кароль Лир». Г. Кәрам тәрҗемәсе.

Менә болардан без тәрҗемәләрнең 15–16 нчы елларда күбрәк эшләнгән, 25 нче елда инде тәмам азайганын күрәбез. Шуның

[1] Шакир Гани улы Шамильский (Вахитов) (1892–1945) – актер, режиссер. ТАССРның атказанган артисты (1945). «Һиҗрәт», «Мәрьям» (1925, 1943, Н. Исәнбәт), «Язулы яулык» (1931, С. Баттал) һ. б. спектакльләрне сәхнәгә куя.

белән бергә, гражданлык сугышы вакытларында күбрәк тәрҗемә эшләре барганлык күренә. Сугышлар тукталып, яңа тормыш төзү эшенә керешелгәннән соң, тәрҗемәләр азаеп, бигрәк татарның үз тормышыннан оригиналь әсәрләр иҗат ителүгә керешелә.

Монда әйтеп үтәргә тиешле ике нәрсә бар. Берсе – тәрҗемәләрнең иң күбе Галиәсгар Камал тарафыннан эшләнүе. Хәтта аның уйналган һәм уйналмаган, басылган һәм басылмаган барлык тәрҗемәләрен йөзгә җитә, диләр, ләкин күп тәрҗемәләрен ул үзе онытып та бетергән күренә.

Артист Мохтар Мутинның әйтүенчә, бу драматург бер вакытларда тәрҗемә эшләрен машина шикелле бере артыннан икенчесен тупырдатып эшләп чыгарып кына торган була.

Аерым әйтелеп үтелергә тиешле булган якның икенчесе – рус һәм дә Яурупа классик әсәрләренең тәрҗемә ителеп, татар сәхнәләрендә уңышлы рәвештә уйнала башлауларыдыр. 1913 елларда Сәгыйть Сүнчәләй аркылы Һенрих Һейнедан «Әлмансур» белән башланган бу адым Гоголь, Островский, Максим Горькийларны үтеп, Шиллер, Шекспир кебек иң зур дөнья классикларының эшләрен тәрҗемә белән төгәлләнде. «Ревизор», «Юлбасарлар», «Һамлет», «Отелло»ларның тәрҗемәләре һәм аларның татар сәхнәләрендә уйнала алулары татар әдәбиятында сәнгать ягыннан тәрәккый адымнарының күзгә нык ташланганнарыннан берсе иде.

Татар сәхнәләрендә бу әсәрләрдәге трагик баш каһарманнарның мәсьүлиятле[1] зур рольләрен уңышлы иттереп уйный алучы зур талантлы татар артистлары җитешүдә бу юлдагы иң зур тәрәккый адымнарыбызның берсе булды.

Шөбһәсез, мәсьәләнең бер кыен ягы мондый бөтен мәдәният дөньясында классик саналган зур иҗатларны татар телендә дөрес, тулы һәм сәнгать ягын бик нык саклап тәрҗемә итә алуда булса, икенче – иң кыен ягы да – аларны уңышлы иттереп уйный алуда, бигрәк тә алардагы зур осталык белән эшләнгән трагик типларны татар сәхнәсендә яңадан иҗат итә белүдәдер.

Менә шуларны иҗат итүче беренче тарихи талантны да татар дөньясы үзендә Мохтар Мутин аркылы күрде. Шушы әсәрләр уйналганнан соң, бөтен татар газеталарындагы рецензияләр (шулар өстенә дә рус газеталарының бәгъзеләрендәге рецензияләр)

[1] Мәсьүлиятле – җаваплы.

беравыздан диярлек Мохтар Мутинның татар сәхнәсендә мәдәни дөньяның классик типларын иҗат итте дип табалар)[1].

[1] «Мутин – шөбһәсез, талантлы бер артист» («Эш», 1918 ел, 132 сан. *Г. Кәрам.* «Юлбасарлар» уйналганда) «городничий ролен уйнар өчен («Ревизор»да) иптәш Мутин труппабызда бердәнбер артистыбыздыр, бу кичәдә дә Мутин мөкәммәл бер тип бирде («Татарстан», 1921 ел, 268 нче сан. *Г. Кәрам*). «Артист Мутин классик әсәрләрдә каһарман рольләрен оста уйнавы белән яхшы танылган бер артист» («Татарстан», 1922 ел, 93 нче сан, «Һамлет» уйналганда – *Г. Кәрам*), «Ул (Мутин) татар-башкорт сәхнәсенә, шиксез, Шиллерларны кертте һәм безнең яшь сәхнәбездә Һамлетны беренче уйнау аңа насыйп булды» («Башкортстан», 1924 ел, 144 нче сан – «Кара сакал»), «Мухтар Мутин» Һамлет ролен тамашачыларны хәйран калдыру дәрәҗәсендә үз ролен шәп иҗраэ итте (*башкарды)*», «Мохтар Мутин даһи язучының тирән әсәрен рәнҗемәслек рәвештә эченә кереп уйнады. Ул үзенә бик зур мәхәббәт һәм өмет баглатып калдырды» («Башкортстан», 1924 ел, 45 нче сан, *Мәҗит Гафури*) «Мохтар Мутин кебек Карл ролен оста уйнаучыны моңарчы Башкортстан сәхнәсе күргәне юк иде. Ул шундый көчле трагик рольләрдә бердәнбер яхшы артистыбыз» (Башкортстан», 1923 ел, 76 нчы сан, *Х. Кәримов*). «Фаҗигалы рольләрне уйнау белән танылган артист Мохтар Мутин «Һамлет» ролен муаффәкыять белән башкарды, былтыргы «Отелло» аның бу юлда беренче зур муаффәкыяте булса, билгеле, «Һамлет» икенче дип хисапланырга тиеш» («Татарстан», 1922 ел, 97 нче сан, *Гали Рәхим*), «Инде безнең татар сәхнәсендә бу типны (Отелло тибын) беренче тапкыр уйнаган Мохтар Мутин аны кирәгенчә чыгара алдымы? Чыгарды һәм гаять муаффәкыятьле вә тулы рәвештә бирә алды», «Отелло ролен иҗат иткәннән соң, ул үзенең зур бер талантка малик артист икәнлеген һәм беренче татар трагик артисты булуын исбат итте» («Татастан», 1921 ел, 85 нче сан, *Г. Рәхим*), «Татар-башкорт дөньясында җиһан типларын уйный алучы бердәнбер артист Мохтар Мутин», «Мутин безнең сәхнә дөньябызда үзенең бөек талант һәм остаз икәнлегенә азрак мәдәни зәвык иясе булган кешеләрне мең дә беренче кат ышандырды» («Башкортстан», 1923 ел, 154 нче сан, «Кара сакал» – «Отелло» уйналу уңае белән). «Мутин несомненно большая величина в истории татарской сцены. Его игра искренна. Полна внутреннего огня и лишена «нарочного пофоса» (Известия, 1921 г., № 88) (бу да Отелло уйналу уңае белән). «Нариман бәк Наримановның «Надир шаһ»ы уйналганда: аңар (Мутинга) бөтен бәни бәшәр өчен гомуми булган типлар вә шәхесләр кирәк» («Татарстан», 1919 ел, 212 нче сан. *Г. Кәрам*. Шул ук санда идарә Мутинны «пролетарский артист» дип атый). «Әдәбият галәмендә зур урын тоткан Шиллер вә Шекспир әсәрләреннән татар сәхнәсенә Һамлет, Отелло шикелле зур рольләр иҗат итәргә муафикъ булган бер эшчебездер» («Башкортстан, 1923 ел, 79 нчы сан, *«Хәбири»).* «Бай, көчле таланты белән фаҗигави рольләрдә Идел буеның Араблинские булган артист Мохтар Мутин...», «Нир ролен Мохтар Мутин үзенең бөтен фаҗигави талантын күрсәтеп чыгара алды», «...мине Мутинның бөек талантын алкышлап туя алмаслык дәрәҗәдә мәфтүн (*сокланучы*) иткәләде», «хәтта Мутин вә имсале кебек көчле талантлар җитештереп бирүе игътибары белән: “Сәхнәсенә караганда бу милләт яши!” – дигән сүзне мин сәвекы табигы белән әйтеп җибәрдем» (1918 ел, «Сарай» газетасы. 35 нче сан. *Камал «Н. Гасрый»*). – 65–66. *(Авт. иск.)*

Инде моннан соңгы пролетариат театр әдәбияты мондый зур талантлы татар артистларының хезмәт ияләренә аларның үз тормышларыннан уйнап бирүләре өчен нинди трагик тәрҗемәләр яки оригиналлар тудырыр – анысын киләчәк күрсәтер.

Һәрхәлдә, татар сәхнәсе үзенең егерме еллык татар театр әдәбияты 40 еллык бер гомере эчендә һәммә әдипләре, драматурглары, артистлары белән бергә төрле баскычлардан үтте дә. Ахыр ноктасында Октябрь сызыгына төшеп, тикшерүче күзләргә зур гына гәүдәле мәдәни бер үсү булып күренерлек бер хәлгә килә алды.

Татар театр әдәбиятының тарихын тикшерү вә безгә нәтиҗә итеп әнә шуны күрсәтә.

Инде сәхнәбезне дә, театрыбызны да, театр әсәрләребезне дә баш-аягы белән бөтенләй пролетариат революциясе, марксизм идеологиясе нигезенә корып, аны шул нигездә чын сәнгатьчәлек юлы белән кызу үстереп алып китәргә һәм тиздән шуның чәчәкләнү бәйрәмнәрен күтәргә генә калды.

Татар пролетариат язучылары, татар пролетариат артистлары шул алдагы бәйрәмнең баш каһарманнары булырлар.

Шушы егерме еллык театр бәйрәменнән соң, безнең киләчәккә ташлаган зур бер өметебез шул.

* * *

Мәкаләгә кирәкле кайбер тарихи материалларны табышып биргәнлекләре өчен сүз ахыры итеп, егерме еллык театр бәйрәмебезне уздыру эшен башкаручы комиссиягә, бигрәк тә аның рәисенә, ярдәмчесе Мөхәммәд Парсин белән секретаре Мохтар Мутин иптәшләргә чын күңелдән рәхмәт әйтеп үтәргә бу урында үземне бурычлы саныймын.

*Габдрахман Сәгъди.*
*1925 ел, декабрь, Казан*

# ФАТИХ ӘМИРХАН

Ф. Әмирханов турында язылачак фикерләребезгә аның үзеннән ачык бер таяныч булсын өчен, иң элек әсәрләреннән берничә мисалларны укып үтик. Мисаллар да үз гыйбарәләре, үз имлалары белән күчереләләр.

1. «Татарның мәгыйшәтен асылыннан сүтеп төзәтергә кирәк! Безгә аның урынына яңа мәгыйшәт кирәк: әүвәлдәге наданнар урынына галим вә зыялылар, әүвәлдәге мөтәгассыйблар[1] урынына ачык фикерле вә яңа хәрәкәтләрне алып баручылар, әүвәлдәге үз кулларында булган нәрсәләрне дә ычкындыручылар урынына һөнәр вә сәнәгатьле мәгыйшәт сугышында мәгълүб булмаслык[2] татарлар кирәк! Әүвәлге сыйныф икенчесенә урын бирергә, үзләре андый тәрбия ала алмаганнар вакытлары узмаганнарга шундый тәрбия бирергә кирәк, ягъни тәрбия вә гыйлемханәләребезне әсасыннан[3] ислах итәргә[4] кирәк!» («Әл-Ислах», 1 нче сан, 1907 ел. Баш мәкалә).

Һәм:

«Гыйлем юлларын һәрбер сыйныфка бертигез ачык итә торган сәяси вә икътисади сәбәпләрне үзләренә максат иткән сәяси хизебләр[5] – безнең дусларыбыздыр».

«Әлхасыйль[6] лозунгымыз «Гыйлем, мәгарифнең милләтебез арасына интишары[7] вә «сәгадәте гомумия[8]«дер». (Шул ук сан, шул ук мәкалә).

2. «Бездән мәгыйшәт[9] хакыйкый яурупист булуыбызны таләп итә» (Ф. Әмирхан). («Әлислах». 29 нчы сан, 1908 ел – «Яшьләр колагына бер сүз» дигән мәкаләсеннән).

---

[1] Мөтәгассыйб – фанатик.
[2] Мәгълүб булмаслык – җиңелмәслек.
[3] Әсасыннан – нигезеннән.
[4] Ислах итәргә – яңартып корырга.
[5] Хизебләр – партияләр.
[6] Әлхасыйль – нәтиҗәдә.
[7] Интишары – таралуы.
[8] Сәгадәте гомумия – гомуми бәхет.
[9] Мәгыйшәт – яшәеш, тормыш.

3. «Төшемдә гает көнен күрдем, Яурупа ысулынча, ләкин Шәрыкның да иң гүзәл әсәрләре катыштырылып зиннәтләнгән татар клубында меңләп зыялы яшь татар егетләре вә ханымнары арасында бер-беребезне шатлыклы гает көне белән тәбрик итешергә җыелган идек. Җыелган яшьләр арасында татар гимназияләренең талиб вә талибәте, татарлар тарафыннан ачылган һөнәр мәктәпләренең шәкертләре, төрле хосусый дарелфөнүннәрнең[1] студентлары, рус вә госманлы (идарәи машруталы) мәктәпләрендә укучы татар яшьләре, милли театрларыбызда уйнаучылар, өстенә төрле йөзле, мөлаем чәһрәле карт хокук профессоры Гали, тыйб[2] профессоры вә шәһәрнең беренче табибы Гомәр, риязият[3] профессорларыннан Русиядә мәшһүр риязый Мостафа, фәлсәфә мөтәхассыйсларыннан[4] Ибраһим, икътисад голәмасыннан[5] мәшһүр социалист Әхмәд, электрик фасылында берничә кәшәфият ихтирагасы[6] белән мәшһүр электротехник Сөләйман, мөһәндис мигъмар[7] Рәшид, татар адвокатлар, табиблар, мөһәндис, мөгаллимнәр, мөслимә табибәләр, юристкалар, мөгаллимәләр, әсәрләре Яурупаның төрле телләренә тәрҗемә ителгән мөхәррир вә мөхәррирәләр бу җәмгыятьтә бар иделәр. Җәмгыятьтәге кешеләрнең бәгъзысы бөтенләй яурупача, бәгъзысы бик матур, килешле сурәттә тектереп, бөтенләй шәрыкча, бәгъзысында һәр икесен дә иң гүзәлләрен алып, яурупача да, шәрыкча да, бәгъзысы кәләпүшле, бәгъзысы кәләпүшсез, ханымнарның бәгъзысы бөтенләй яурупача, бәгъзысы бик латыйф сурәткә китереп, бөтенләй шәрыкъчә киенгән иделәр. Төрле яктан ишетелгән татарча дөрес сөйләшү к, г ларсыз гына булып, колакка бертөрле йомшак вә кәефле ишетелеп тора иде. Аһ, никадәр күңелле бер җәмгыять». («Әлислах», 4 нче сан, 1907 ел. «Дамелла» кушаматы астында. «Гарафә көн төшемдә» хикәясеннән. Беренче хикәясе).

4. Менә мин гыйбадәт кылырга тотынам, бөтен җаным, күңелем, хыялым белән каядыр, үзем дә белми торган гали галәмгә юнәләм.

---

[1] Дарелфөнүннәрнең – *биредә:* университетларның.
[2] Тыйб – медицина.
[3] Риязият – математика.
[4] Мөтәхассыйс – белгеч.
[5] Голәмасыннан – галимнәреннән.
[6] Ихтирагасы – ачышы.
[7] Мөһәндис мигъмар – архитектор.

Укыйм, ул да ләззәтле, елыйм, ул да ләззәтле. Куанам, ул да мәхыз[1] ләззәт кенә... Менә мин терелдем, мин әүвәлге күк кеше булып киттем. Җаным да, күңелем дә, тәнем дә үзләренең теләгәннәрен таптылар, тынычландылар, рәхәтләнделәр...». («Әлислах», 51 нче сан, 1908 ел – *Ф.А.* имзасы белән).

5. «Менә тиз көннән бер үзебез алда барачак йортка ул бездән берничә дәкыйкаләр алдарак барып тора икән, без үзебез тиз көндә шуңа күчәчәк тереклеккә, яңа тереклеккә, моңа кадәр дөньяда мөсафир булып үткән һәммә изгеләр шунда күчкән, үзләренең мәңге тынычлыкларын, мәңгелек рәхәтләрен шунда тапкан тереклеккә, ул безгә караганда бер күз ачып йому кадәр вакыт алданрак күчкән икән, аның өчен шулай ачы елап торырлык эш бармыни? Җылама, җыламыйк, сабырсызланма, сабырсызланмыйк, карчык!» («Безнең юл», 2).

Һәм:

«Кабер баш очларына утыртылган агачлар хәзер анда яшь яфракларга батып, тыныч кыштырданып, тәсбих әйтеп утыралар».

Һәм:

«Без үлем астына яшерелгән яңа тереклекне күрә торганнар, үлем пәрдәсе белән капланган сернең иҗмален[2] йөрәкләребез белән абайлап өлгергәннәр – үлгәннәр өчен ачы күз яше түкмик; өметсез карарсызлыкка илтә торган хәсрәткә бирелмик. Ул газапларны, ул өметсезлекне без матдәнең аргы ягына идракьләре[3] ирешми торган, күзләре күргәннән башканы гакыллары гына түгел, йөрәкләре дә сизми торган кызганыч бәндәләргә, динсезләргә калдырыйк: сабырлары җитә икән, алар йөкләсеннәр шул газапларны, алар көйсеннәр шул өметсезлек белән! Ә без, без – бу тереклектән башка тагы бер тереклек барлыкка ышанучылар, ул икенче тереклекнең безнең тереклегебезгә караганда чынрак, әһәмиятлерәк, галирәк икәнен аңлыйк; аңлыйк та ул тереклеккә күчкәннәр өчен өметсезлеккә төшмик!».

«– Я Алла, нинди караңгы, нинди өметсез караш! Бөтен шул каинәткә зур рәхмәт булган тереклекне күргән, бөтен шул безнең күзгә күренгән һәм күренмәгән нәрсәләрнең барысына үзләренә

[1] Мәхыз – саф.
[2] Иҗмален – күләмен.
[3] Идракьләре – аңлау, кабул итүләре.

мөнасиб тормыш биреп, бетмәс-төкәнмәс рәхмәт белән тәҗәлли иткән[1] мөдир, тәрбияче шул безнең алда тора торган икенче тормыш, чын тормышта да үзенең кодрәтенә мөнасиб зур рәхмәт тәҗәлли итмәсмени?». «Бу җаннар читлекләреннән котылгач, бу җаннар үз өсләрендәге тупас кабыкларын салгач, иң гали ләззәтләргә, иң нәзек тойгыларга юл ачылмасмыни?»

«Бер син генә түгел, миллиардларча адәм балалары, бер адәм балалары гына түгел, хәтта бик күп хайваннар бу гомуми мәрхәмәттән хиссән чыгарган рәхмәт хәзинәсенең никадәр зур, никадәр киң һәм тирән булырга кирәклеген аңлар өчен, безнең гакыллар, безнең идракьләр дә җитә алырлык бит!».

«Ләкин тупас кабыклары шул җир тирәсендәге һавадан башка тора алмый торган тән аларга күкләргә ашарга, тәгали итәргә[2] ирек бирмәс тә, җан сыкраныр, хыял үзенең читлегеннән тарсыныр. Ләкин кайчан да булса бер шул күкләр, шул фәза[3], аның эчендәге шул серле тереклек, шул серле тормыш аларга ачылырга, аларга мәгълүм һәм ирешелмәле булырга тиеш бит».

«Вәл-халь[4], без белгән табигатьтә генә дә кирәксез, максатсыз бер нәрсәнең юклыгы, була алмаганлыгы инде шул гаҗәеп надан адәм балаларына да ачылып мәгълүм булып җиткән бер хәл. Бер безнең кояшыбыз галәме түгел, саннары безгә мәгълүм булмаган күп кояшлар, үзләренең безгә хәзерге хәлебездә ирешелмәле булмаган, була алмаган галәмнәре белән читлекләреннән котылган безнең җаннарыбыз алдында ачылырга тиешләр һәм ачылачаклар».

«...менә шуларны аңлап, шуларда тәфәккер ит[5], карчык! Бөтен гасырларның төрле-төрле китаплары, диннәренә мәнсуб тәсаувыф әһелләре тәфәккерне иң зур гыйбадәт саныйлар, зикерне үзләренең тәрәккый юллары хисаплыйлар икән, алар моны юкка гына эшләмиләр. Шуларда алар үзләренең бер нәрсә белән дә бозылмый торган дөньяның һәм кайгыларыннан, һәм шатлыкларыннан өстен,

[1] Тәҗәлли иткән – бөеклеккә ирешкән.
[2] Тәгали итәргә – үсәргә.
[3] Фәза – күктәге бушлык.
[4] Вәл-халь – шулай итеп.
[5] Тәфәккер ит – уйла.

тынычлыклар табалар. Китапларның берсендә: «Агяһ булыгыз[1], күңелләр Аллаһ зикерендә тынычлык табалар», – диелә.

«– Үлгәннәр өчен кайгы юк. Бары мәңге үлмәстәй булып алданып тора торган сукырлар, идеаллары шул чери, бетә торган вак хәшәрәтләр тудыра торган, рәхәте шулар тереклегенә багланып калган рухани мещаннар кызганычлар».

«– Әйе, мин дә синең шикелле үк, синең кадәр үк зәгыйфь адәм. Әйе, минем дә күзләрем яшьләр коялар, тавышым кайгылы яңгырый, йөрәгем парчалана. Ләкин мин боларның барысы өчен дә мин сәҗдәи шөкер итәм, әйе, сәҗдәи шөкер...». Фатих Әмирхан. («Ярдәм мәҗмугасы». Икенче китап. 1922 елда басылган. 209 биттән 209 биткәчә. «Тәгъзия» дигән юанычыннан имласы шундагыча алына).

## II

Фатих Әмирханга ике яктан үлчәү куя алабыз:

1) татар иҗтимагый-мәдәни хәрәкәте ягыннан;

2) әдәби яктан.

Ф. Әмирхан – 1905 ел революция дулкыны эчендә баш күтәреп килеп чыккан татар әдипләренең берсе. Безгә мәгълүм: 1905 ел революциясе татарларны да нык кузгатып җибәрде. Татар дөньясында көчле бер иҗтимагый-мәдәни һәм кыйсмән[2] сәяси хәрәкәтләр, дулкыннар, болганулар башланып китте.

Нәтиҗәдә бер-берсенә капма-каршы ике зур сыйнфый хәрәкәт күзгә нык ташланды:

1) татар буржуа хәрәкәте;

2) татар пролетариаты хәрәкәте.

Табигый, әле үзенең азлыгы, көчсезлеге белән татар пролетариаты хәрәкәте ул вакытта көч алып китә алмады, шуның өчен өстенлек буржуа хәрәкәте ягында калды. Буржуа хәрәкәтләре тышкы яктан караганда аерым күренгән, ләкин төбендә бер үк тамырның ботаклары рәвешендә икегә аерылды:

1) урта яисә тәрәккыйчы либераль татар буржуазиясенең хәрәкәте. Икенче төрле әйткәндә, «Русия мөселманнары иттифакы»

[1] Агяһ булыгыз – белеп торыгыз.

[2] Кыйсмән – өлешчә.

(«Иттифакы мөслимин»), яки тагын да дөресрәге, руслардагы «Кадетлар партиясенең татар бүлеге» адәмнәренең хәрәкәтләре.

Татарның алпавытлары, мирзалары, фабрикантлары, эре сәүдәгәрләре, тәрәккыйчы, «җәдит»ләнгән зур руханилары, хәзрәтләре, вакытындагы зур дини вә иҗтимагый галимнәре, картрак җәмәгатьче мөхәррирләре шушы хәрәкәтнең башында тордылар. Бигрәк тә җәмәгатьче мөхәррирләрдән, шул хәрәкәт башында торган идеологлардан күзгә иң нык ташланганнары Гаспринскийлар, Рәшид казый[1], Риза[2] вә Мусалар[3], Акчурин[4] вә Фатих Кәримиләр[5], адвокат Тупчибашевлар[6], Тәфкилев[7] вә Сыртлановлар[8] иде;

2) вак татар буржуа хәрәкәтләре. Бу хәрәкәтләрнең башында да вак буржуа «социалистлары», яисә, икенче төрле итеп, Галимҗан Ибраһимовның тәгъбире белән әйтсәк, «буржуазия хәрәкәтенең иң радикаль сул канат фракциясе»н тәшкил итүчеләр тордылар.

Болар:

1) реформачы – «Әлислах»чы шәкертләр,

2) приказчиклар,

3) «таң»чы эсерлар,

4) «дума»чы трудовиклардан[9] гыйбарәт дүрт тармакка аерылдылар.

---

[1] Рәшид казый – Габдерәшит хәзрәт Ибраһимов (1857–1944), мәгърифәтче, дин һәм сәясәт эшлеклесе.

[2] Риза – Риза Фәхреддинов (1859–1936), танылган дин галиме, тарихчы, публицист һәм педагог.

[3] Мусалар – Муса Ярулла Бигиев (1873–1949), танылган татар философы һәм дин галиме, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, публицист, җәдитчелек хәрәкәте лидерларының берсе.

[4] Акчурин – Йосыф Хәсән улы Акчурин (Йосыф Акчура; 1836–1935), сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, журналист.

[5] Фатих Кәрими – Фатих Гыйльман улы Кәрими (1870–1937) – күренекле татар язучысы, нашир, журналист, җәмәгать эшлеклесе.

[6] Тупчибашевлар – Галимәрдән Галиәкбәр улы Тупчибашев (1863–1934) – I Дума әгъзасы, юрист вә мәшһүр җәмәгать эшлеклесе.

[7] Тәфкилев – Котлыгмөхәммәд Батыргәрәй улы Тәфкилев (1850–1917) – җәмәгать эшлеклесе, эре җирбиләүче.

[8] Сыртлановлар – Шаһихәйдәр Шаһгардан улы Сыртланов (1847–1916) – дворян, I һәм II Дума депутаты, Конституцион демократ.

[9] Болай төркемләндерү Галимҗан Ибраһимов юлынча алына. «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре»нә каралсын. 178–219 бит. – 11 бит. *(Авт. иск.)*

Беренчеләре – мәдәни хәрәкәтчеләр, икенчеләре – «сәясәткә бик нык чумдырылган профессия хәрәкәте»нең батырлары, өченчеләре – сәяси-иҗтимагый агым каһарманнары, ягъни үзләренә ачыктан-ачык «социалист» исемен бирүче «эсер партиясенең татар группасы» адәмнәре иделәр. Татар вак буржуазиясенең «сул радикаль канаты» булган бу өченче тармак сүздә социалист, эштә татар буржуасы белән кулга-кул тотынышып баручы бер гөруһ[1] – Гаяз Исхаков, Туктаров[2] вә Сәгыйть Рәмиевләр[3] гөруһы иде. Болар төбендә «Иттифакы мөслимин»челәр белән кодаланучылар, «дин, мәдәният, идеология мәсьәләләрендә буржуазиягә кул суза» торган социалистлар иде. Болар татар дөньясында беренче мәртәбә «сүгенү», «мактану» методын алып ду килделәр, дөнья куптардылар. Дүртенче тармакта «Дума» газеты каһарманнары, яисә «Мөселман иттифак партиясенең сул кабыргасыннан яралган» бер төркем «мөселманнарның хезмәт таифәсе» адәмнәре иде. Бу дүртенче төркем, боларны мактаучы Туктаровның сүзләре белән әйткәндә, «диннең, милләтнең һәм халыкның бөтен хаҗәтләренә муафикъ программа ясап» алучылар, «ул халыкның һәм мөселманнарның дини вә милли файдаларын күзәтер өчен ясалган «Хезмәт таифәсе»ннән гыйбарәт бер төркем иде.

Менә шушы югарыда саналган бөтен татар буржуасының иҗтимагый төркемнәренә каршы көрәш алып барган татар пролетариат хәрәкәтенә һәм ул хәрәкәтнең татарда юлбашчылары вә идеологлары уралчыларга Ямашев[4], Сәйфетдинов[5] һәм шул юлдагы беренче драматург Коләхмәтовка[6] бу урында тукталмыймын. Чөнки минем

---

[1] Гөруһ – төркем.

[2] Туктаров – Фуад (Мәхмүтфуад) Фәсах улы Туктаров (1880–1938) – сәясәт эшлеклесе, юрист, публицист.

[3] Сәгыйть Рәмиев – күренекле татар шагыйре, мөгаллим, публицист.

[4] Ямашев – Хөсәен Минһаҗетдин улы Ямашев (1882–1912) – революционер, беренче татар большевигы, публицист.

[5] Сәйфетдинов – Галимҗан Җамалетдин улы Сәйфетдинов (1882–1918) – педагог һәм революционер, сәясәт эшлеклесе, 1907 елның гыйнвар-апрель айларында Х. Ямашев белән берлектә социал–демократларның татарча «Урал» газетасын нәшер итүдә катнаша.

[6] Коләхмәтов – Гафур (Габделгафур) Юныс улы Коләхмәтов (1881–1918) – язучы, публицист, драматург, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе.

теге иҗтимагый төркемнәрне аңлатып үтүем мәкаләмнең мәүзугы[1] итеп алынган, Ф. Әмирханның иҗтимагый хезмәтен ачу өчен туры-дан-туры кирәк булган бер нәрсә иде. Әнә шушы эре һәм вак буржуа төркемнәрен югарыдагыча, бик кыскача гына аңлатып үткәннән соң, инде Ф. Әмирханга иҗтимагый яктан карау мәсьәләсенә күчәмен.

## III

Ислахчы шәкертләр, ягъни иске дини мәдрәсәләрдә укучылар эченнән чыккан реформачылар кузгалышы татар иҗтимагый-мәдәни хәрәкәтендә иң әһәмиятле вакыйгалардан иде. Вакытында болар татар дөньясын бик нык шаулаттылар. Иске мәдрәсәләргә, аның тәрбиясенә, укыту ысулларына, андагы тәртипләргә каршы көчле бер гыйсъян күтәрделәр, бунт чыгардылар.

Әнә шундый хәрәкәтнең Казандагы төркемнәренең башында торучыларның берсе Ф. Әмирхан иде. Бу әдип шул хәрәкәттә нык эшләде һәм иптәшләренең тәшәббесе[2] белән 1904–1905 елларда үзләренә аерым бер организация булып оешу башланды, «Әлислах» комитеты төзелде. Бу комитет та «татар социал демократлар тәэсирендәрәк барырга» тырышты[3].

Бу урында ислахчы яисә әлислахчы шәкертләрнең хәрәкәтендә күренгән берничә моментларга тукталып үтик. Бу хәрәкәттә түбәндәге моментларны күрәбез.

1) 1905 ел революциясе башланган заманнарда болар (ислахчы шәкертләр) Рәшид казыйлар эзенә басып, аның «Өлфәт» дигән газеты беләнме, вә акылларын ризыкландырып килүчеләр иде. Бу хәл дә «татар шәкертенең фикере үсүендә беренче баскыч» булып алды. Бу баскычта мөселманчылык куәте белән христианлыкка һәм христианлык сакчысы булган «самодержавие»гә, кадимчелеккә, схоластикага каршы тору баскычы иде.

2) Сыйнфый, сәяси вә иҗтимагый мәгънәсе белән революция хәрәкәтләренә кушылып алу баскычы. Ягъни «Уян, шәкерт!» дип җырлаудан Марсельезаны җырлый башлау моментларына күчү баскычы. Революция хәрәкәтләренә кушылып, «социалист» булырга

[1] Мәүзугы – темасы.
[2] Тәшәббесе – инициативасы.
[3] Бу комитетка каршы Фуад, Гаязлар тарафыннан «Таң»чы эсерлар оешмасы төзелде. («Татарлар арасында революция хәрәкәтләре». 183 бит.). – 12 бит. *(Авт. иск.)*

тырышу; буржуага, капитализмга дошманлык авазларын чыгара башлау – вак буржуа социализмына омтылу шушы икенче баскычның хосусиятләреннән иде.

3) Революция бастырылып, реакция кузгалу белән әүвәлге җилкенүләрнең һәммәсеннән кайтып, урта буржуа сызыгында тик мәдәни бер көрәш алып бару баскычы һәм шушы баскычта ныгып алып, уңланып эш күрү.

Бу өченче баскычны яхшы характерландырганы өчен, бу турыда Галимҗан Ибраһимовның түбәндәге сүзләрен күчереп үтүне кирәкле табамын:

«Революция басылу белән, һәммәсенең төсе ачылды. Бары да асылына кайтты. Хәрәкәт үзенең нәтиҗәсе буенча мәдәни бер көрәш булып чыкты. Уку-укыту, мәктәп-мәдрәсә эшләре искечә, ярым искечә куелганнар. Болар шәкерткә тормыш өчен ярамый. Моннан ник муллалар гына чыга?

Шәкертнең, башка милләт зыялылары кебек, адәмчә яшисе килә.

Ата-ана, гаилә, өс-баш, гыйлем, мәгърифәт эшләрендә рус-Яурупа буржуазиясе нигезендәге кебек, мәдәни рәвештә буласы килә. Дин, дин, дин дип кенә ми черетүдән котылып, рус, Яурупа мәктәпләрендәге кебек, тәрбия аласы килә. Болар һәммәсе, әлбәттә, бик кирәкле нәрсәләр иде. Иске көнчыгыш хәерчелегеннән, наданлыгыннан Яурупа буржуа мәдәниятенә таба бару, әлбәттә, зур бер адым алга атлау иде. Реформа хәрәкәтенең нык үсүе иде. Ләкин монда бер тиенлек тә социализм юк иде.

Бу шул XIX йөзнең соңгы яртысында ялланган татар буржуазиясенең яңалык, реформачылык, яурупачылык хәрәкәтенең ачык кискен куелган рәвеше татар либерализмының, вак буржуа социализмы рәвешендә чыккан нык революционер радикаль фракциясе генә иде.

Революция дулкыны кайткач, аның шулай икәне ачык күренде. Бөтен ул хәрәкәт үзенең тарихи мәгънәсе буенча татар мәдәниятенең зур бер бүлеге булган уку-укыту мәсьәләсен Яурупа буржуазиясе дөньясындагы нигезгә кую, татар шәкертен буржуазия мәдәниятендәге мәдәни зыялы адәм дәрәҗәсенә менгерү кебек табигый иҗаби бер максуд өчен булып калды.

Моның табигый рәвештә ачылуы 1907, 1908 елларда чыккан “Әлислах” газетасында булды.

Бу газетаның беренче номерында баш мәкаләсендә социальлекне аңлаткан “Сәгадәте гомумия” сүзе бар иде. Елдан артык дәвамында бу газета турыдан-туры безнең мәдәни һәм тәгълим эшләребезне Яурупа мәдәнияте нигезендә корырга чакыручы, либеральләнүче шәкертләргә бер үрнәк булып чыкты.

Социализмнан һич нәрсә калмады. Бөтен хәрәкәт өчен менә бу кечек мисал булды».

Ф. Әмирхан да татар шәкертләренең шушындый берничә баскычлы булган иҗтимагый-мәдәни хәрәкәтләрендә эшләшеп барган хәлдә, ул баскычларның һәммәсен үтеп, ахырда Галимҗан Ибраһим каләме аркылы югарыда ачык аңлатылган өченче баскычта туктап, шунда ныгып, шул ноктада эшен дәвам иттерде. Шул юлда «Әлислах» газетасының башында торып, аңа шушы тонны ачык бирә барды.

Ф. Әмирханнан мәкаләнең башында1, 2, 3 рәсемнәр астында китерелгән мисаллар шуны бик ачык күрсәтеп торалар. Башта җилем басма белән яшерен чыгарылган һәм шул беренче адымында «Уяныгыз, бөтен шәкертләр!» дип кычкырып чыккан «Әлислах» газеты соңыннан (1907 елда) шул ук Фатих Әмирхан кул астында шәкертләрнең рәсми бер газетлары булып чыга башлагач, инде ачыктаначык «хакыйкый яурупист булу» фикерен нык тарата башлады. Шул турыда Ф. Әмирхан тарафыннан махсус мәкаләләр язылды.

«Кояш» газеты дәверендә инде Ф. Әмирхан иҗтимагый-мәдәни хәрәкәттә вак буржуа социализмыннан тәүбә итеп, тәмам гомуми татар буржуа либерализмы сызыгына, Акчуриннар һәм «Вакыт»лар юлына төшеп җиткән иде инде. Бу да аның «Әлислах»та ташлаган «хакыйкый яурупист булу» шигаренең табигый бер нәтиҗәсе иде. Ул хәтта бер вакытлар (шул ук «Кояш»та эшләгән дәверендә) Коръәннең хата басылуы өчен зур тавыш күтәреп тә алды.

Кыскасы, «Әлислах»ның 1907 елдагы 4 нче санында басылган «Гарәфә кич төшемдә» дигән хикәясендә татарның дини гаетен мәдәни гаеткә алыштыру хыялының картиналарын биргән Фатих Әмирхан, соңаннан шул ук ике гаетне «хакыйкый яурупист» буржуазия Яурупасы булу сызыгында берләштерү, ягъни дини-мәдәни гает итеп күрү юлына төште.

Шул ук хикәясендә ул татарларның яурупалыларның сөйләшкәне шикелле, «к, г ларсыз гына булып, колакка бер нурлы, йомшак,

кәефле ишетелеп тора» торган бер рәвештә «дөрес сөйләшү»ләрендә хыял итсә дә, соңыннан аның болай сөйләшүгә кызыгып язганнары күренмәде.

## IV

1905 ел революциясеннән соңгы реакция Фатих Әмирханга да бик нык тәэсир итеп өлгерде. Сәяси яктан гайре мөгаен бер суллык белән булса да «Әлислах»ның 12 нче санына кадәр сәяси мәкаләләр язып килгән Фатих Әмирхан[1] шуннан соң, ягъни 1907 елның 24 декабреннән соң, андый мәкаләләр язудан туктады. Инде тик әдәби тәнкыйтьләр, хикәяләр язуга гына бирелде. Бәгъзе имзасыз мәкаләләр булса да, зәгыйфь чыгар иде. Хасыйл, реакция Ф. Әмирхан каләмен дә тәмам өркетте, бугалады. 20 нче сан «Әлислах»тагы «Казан 23 нче февраль» дигән имзасыз баш мәкаләдә без инде реакция тәэсире астында тәмам бер өметсезлек чаткылары чәчрәгәнен күрәбез. Бу мәкалә бу юлда чынлап та бик характерлы тарихи бер мәкалә булып чыккан. Анда:

«Бөтен Русиядә халыкның рухы күтәренке вакытта безнең дә рухларымыз күтәрелде, халыкның рәсми табәкасындагы[2] бу рух төшкәч – бездә дә төште» – дип, үз-үзләрен юатырга тырышу да күренә.

## V

«Әлислах» дәвере Фатих Әмирханның чынлап та нык җанланган, һәр якка ташланып эшләгән бер дәвере иде. Ул анда сәяси мәкаләләрдән башка тагы иҗтимагый, әдәби мәкаләләр дә язды: «Тел мәсьәләсенә бер караш» (24 нче сан), «Яшьләр колагына бер сүз» (29 нчы сан), «Әдәбиятка гаид» (44, 47 нче сан) дигән мәкаләләре шундый мәкаләләреннән булып, «Дамелла» кушаматы белән басылдылар. Бу соңгы мәкаләсендә ул кыскача татар әдәбият тарихыннан мәгълүмат бирә. Монда күзгә ташланган бер ягы – аның Каюм Насыйрины тәкъдир итә белүедер.

[1] Аның «Әлислах»тагы сәяси мәкаләләре шулар: «Думалар» (1 сан), «3 нче июнь кануны вә партияләре» (2–3 сан), «3 нче Дума» (4 сан), «Дума ачылды» (5 сан), «Думада центр» (6 сан), «Дума» (9 сан), «Сәясәт галәмендә» (11 сан), «Беренче Дума әгъзаларына хөкем» (12 сан). – 13 бит. *(Авт. иск.)*

[2] Табәкасындагы – катламындагы, дәрәҗәсендәге.

Ф. Әмирхан «Әлислах»та байтак фельетоннар да язды. Бу фельетоннар да иҗтимагый рухта булып, һөҗүви[1] булалар иде. Фельетоннарында кушаматы «Ташмөхәммәд» иде. «Әлислах»та барысы 9 фельетоны булды.

Кыскасы, Ф. Әмирханов татарның иҗтимагый-мәдәни хәрәкәтенең әһәмиятле бер өлеше булган шәкертләр кузгалышында, бигрәк тә «Әлислах» дәверендә зур эшчәнлек күрсәтүчеләрдән һәм шуның юлбашчыларыннан берсе иде. Шул ук вакытларда Фатих мөтагассыйб[2] картлар белән күзе ачыла башлаган буржуа яшьләрен капма-каршы куеп, шул вакыттагы яшьләр тарафыннан сугыш командасы биреп торды.

Шуның өчен Фатих Әмирхановның гомерендә вә аның әдәбиижтимагый тарихында аның «Әлислах» дәвере – аеруча әһәмиятле бер дәвер. Соңгы «Кояш»та хезмәт дәверләре исә бу яктан аның «Әлислах» дәвере белән үлчәнә алмый. Монда инде ул һәр яктан уңлашкан иде.

## VI

Инде килик Ф. Әмирхановның әдәби ягына. Монда аңа ике яктан карый алабыз. Берсе – әдәби тәнкыйтьләре, икенчесе – әдәби әсәрләре ягыннан.

1905 ел революциясе белән бергә, безнең матбугатта әдәби тәнкыйтьләр дә туган иде. Әмма 1907 елдан башлап, Фатих Әмирхан моны дәвам иттереп алып китте.

Ул үткен акыллы, җитез мөхакәле[3] бер тәнкыйтьче иде. Шуның өстенә ул, гомумән, куркусыз, кискен ачы телле, каты тәнкыйтьле бер адәм булды. Шулай да ул тәнкыйтьләрендә кайбер әдип вә шагыйрьләр турында үзен артык керпеләнүдән тыя алмаган шикелле, кайберәүләрне ефәк вә ягымлы тел беләнрәк тә уздыргалады. Бу хәл аннан мәгълүм бер тенденция барлыкны да сиздертеп куя иде. Татар дөньясыннан мәйданга иң беренче чыккан татар драматургы Габдрахман Ильяси һәм аннан соңгы Ф. Халиди кебекләргә, ни өчендер, заманына карап, туры бер үлчәү бирергә дә теләмәде.

[1] Һөҗүви – көлкеле, сатирик.
[2] Мөтагассыйб – фанатик.
[3] Мөхакә – имитация.

Ләкин, гомумән алганда, Ф. Әмирханның тәнкыйтьләре, заманына әлбәттә, әһәмиятле, бик вакытлы һәм файдалы тәнкыйтьләр иде.

Ф. Әмирхан, гомумән, тәнкыйтьче табигатьле бер әдип иде. Аның әдәби тәнкыйть бабындагы кызу эшчәнлеге заманы да шул ук «Әлислах» дәверенә кайта. «Әлислах»та аның 20 ләп тәнкыйте бар[1]. Аның бу тәнкыйтьләре дә «Дамелла» кушаматы астында язылдылар.

### *Фатих Әмирханның әдәби әсәрләре һәм аларның идеология, сәнәгатьчелек, тел-өслүб яклары*

Фатих Әмирханның әдәби әсәрләре хикәя, роман һәм театр әсәрләреннән гыйбарәт. Боларның эченә кереп, аларда кызыл аркан булып сузылып барган идеологияне, иҗтимагый, әдәби-фикри үсүне караганда, боларда һаман шул «хакыйкый яурупист булу» фикере белән бергә, вак буржуазия социализмыннан динче-милләтче буржуазия фикеренә күчә; шушы төп сызыкның үсә, киңәя баруын күрәбез.

1907 елда басылган «Гарәфә көн төшемдә» дигән хикәясендә сурәтләндерелгән хыялы 1908 елда «Яшьләр колагына» дип язган иҗтимагый мәкаләсендә «хакыйкый яурупист булу» шигаре белән ачык вә гаять җитди рәвештә татар яшьләре, шулай ук татар буржуасы өчен чын бер идеал итеп куелган һәм шул ук 1908 елда

---

[1] Аның «Әлислах»тагы тәнкыйтьләре шулар: «Әдәбият кичәсе» (5 нче сан), «Алдым-бирдем» (Гаяз әсәре турында)» (7 нче сан), «Габдулла Тукай шигырьләре» (9 нчы сан), «Әдәбият кичәсе» (14 нче сан), ), «Габдулла Тукай шигырьләре 4 нче дәфтәр» (17 нче сан), «Мавәраэннәһергә сәяхәт» (Заһир Биги әсәре) турында (21 нче сан), «Низамлы мәдрәсә» (С. Рәми әсәре) турында (22 нче сан), «Татарча театр уены» (23 нче сан), «Сәгадәте әбәдия нә иләдер» (Г. Шинаси әсәре) турында, «Үги балалар» (М. Гафури әсәре) турында (25 нче сан), «Әдәбият кичәсе» (25 нче сан), «Хыялмы, хакыйкатьме» (Ф. Кәрими әсәре) турында (27 нче сан), «Яшь гомер» (Гафур Коләхмәтов әсәре) турында (30 нчы сан), «Шәкерт һәм яшьләр (Гомәр Терегулов әсәре) турында (31 нче сан), «Егерменче гасыр кояшы» (Кәримбаев әсәре) һәм «Таңчылар» дигән бер китап турында (32 нче сан), «Беренче театр» (Г. Камал әсәре) турында (33 нче сан), «Тутам» (Чыгтай әсәре) турында (34 нче сан), «Ачлык кушты» (Ярулла Вәли әсәре) турында (36 нчы сан), «Татар шагыйрьләре» дигән мәүзугта Тукай белән Мәҗит Гафурины чагыштыру (37 нче сан), «Фәүзи» (Ш. Мостафа әсәре) турында (45 нче сан), «Җиһанша хәзрәт» (Закир Һади әсәре) турында (47 нче сан), «Солдат» (Г. Исхакый әсәре) турында (49 нчы сан). *(Авт. иск.)*

«Гыйбадәт» дигән кыска бер лирикасы белән дә шул идеалның лазем[1] бер ноктасына ишарә бирелгән иде.

Ф. Әмирханның соңгы бөтен әдәби әсәрләрендә һәм иҗтимагый мәкаләләрендә әнә шушы идеалы төрле картиналар, типлар аркылы һаман киңәйтелә; шулай ук аңа ирешү юллары, аның вакыйгый бер нәрсә булачагы да төрле шигъри сурәтләрдә күрсәтелә бара. Февраль революциясеннән соң, бу идеалда «Богаулар өзелделәр» дигән мәкалә («Аң», 1917 ел, 3–4 нче сан) аркылы соңгы ачык шәкелен бирде[2]. 1922 елда «Ярдәм мәҗмугасы»ның икенче китабындагы «Тәгъзия»дә шуның иң соңгы тәмамлану ноктасын күрсәтте. (Югарыдагы Ф. Әмирханнан, «Тәгъзия» лирикасыннан алынган 5 нче рәкым[3] астындагы мисалларга каралсын.)

Бу идеал, әлбәттә, Ф. Әмирханның үзенеке түгел; ягъни аны бу әдип үз миеннән генә уйлап чыгарган бер нәрсә түгел иде, бәлки ул тик шуның вәкиле, шуны әйтеп бирүче генә иде, әдипләр, шагыйрьләр бит алар үзләре мәгълүм бер икътисади, иҗтимагый шартлар астындагы мәгълүм бер җәмәгать тормышының җимешләре булалар. Шуның белән бергә, алар – шул җәмгыятьнең психологиясен, идеологиясен мәгълүм бер идеология рәвешендә калыпка салучы, шуларны шигъри сурәтләрдә гәүдәләндерүче; шуңа ачык катгый бер система бирүчеләрдер. Ф. Әмирхан да татар буржуа җәмәгатенең шундый көчле бер вәкиле иде. Югарыдагы идеалны да аның миенә, йөрәгенә татар буржуа хәрәкәте, шуның икътисади барышы, иҗтимагый-мәдәни юнәлеше салган; яшь татар буржуасы, буржуа яшьләре мохите аны шуңар хәзерләгән иде.

Ф. Әмирхан әнә шушы мохит һәм шушы хәрәкәтнең омтылышы, теләкләрен күрсәтүчеләрдән булып барды. Талантлы, көчле бу әдип үзенең әсәрләрендә аларны шул идеология белән нык сугарды. Үсеп барган татар буржуасының зыялы кыйсеме аның әсәрләрендә идео-

[1] Лазем – тиешле.

[2] Бу мәкаләсендә ул гаять куәтле дини рух белән «насыйп итсә», «Аллаһның гыйнаяте» белән киң дини, илаһи, шатлыклы тәгъбирләр белән революция булуга куанып яза. «Милли иманлы кешеләр» булуга өндәп:

– Булырга! Милләт сәҗдәгә шөкер итсен! Киң дәртләр белән язам – милли кяферләр булмаска! – дип чакыра. Хасыйл, бу мәкалә бөтене белән «Русия мөселманнары» булып, хөррият хәрәкәтендә нык эшчәнлек күрсәтергә өнди. *(Авт. иск.)*

[3] Рәкым – номер.

логия ягыннан шулай ук аны тасвирдагы форма, тел, өслүб ягыннан бик хаклы рәвештә яратып каршы алды.

Ф. Әмирханның югарыда әйтелеп үткән хикәяләре, «Яшьләр», «Тигезсезләр» дигән пьесалары, «Кадерле минутлар»ы, «Хәят», «Урталыкта»сы вә башкалары татар буржуа җәмәгатенең идеологиясе ягыннан иң сөеп укыган әсәрләреннән булдылар.

Бу әсәрләрдәге Газизләр, Йосыфлар, Рокыялар, Сөләйманнар, Гомәрләр, Закирлар, Сәлимәләр, Хәятлар, Хөршидлар, Хәсән Арслановлар алар өчен зәвык бирәчәк, үрнәк булачак типлар иде.

Икенче яктан, Фатих Әмирхан иске тормышка, феодализм тормышына каршы бик усал, агулы тел белән һөҗүви әсәрләр дә бирде. «Фәтхулла хәзрәт», «Үгетләргә килде»[1] («Аң», 1 нче сан, «Ташмөхәммәд» кушаматы белән), «Габделбасыйр гыйшкы» («Аң», 11–13–14–15 нче саннар, 1914 ел), «Салихҗан карый» («Аң», шул ук ел, 11–12 нче сан), «Сәмигулла абзый» (Шул ук ел, 19–20 нче саннар), аның саташулы, киң, уйнак, шул хыялыннан туган шундый әсәрләреннән иделәр.

Ф. Әмирханның типларына сәнгатьчә эшләнеп җитә алу-алмау, табигый булу-булмау ягыннан анализ ясауга әле хәзергә бу кыска мәкаләдә туктала алмыйм; моны икенче вакытка калдырам. Ләкин шуны әйтергә кирәк: аның алган типлары һәммәсе диярлек «хакыйкый яурупист булу» әмәленең лазем иткән типлары – буржуа яшьләре һәм дә бик килештереп яурупача итенә, яурупача нечкәләнә, боргалана-сыргалана белә торган гимназист, гимназисткалар тормышыннан алынган; яисә шундый тормыш эчендә кайнаша торган буржуаланучы типлар алар. Фатих Әмирханның

[1] Бу хикәя соңыннан, 1918 елда, «Көлке вә һөҗү хикәяләре» исеме белән чыгарылган «Беренче мәҗмугасы»нда тел, өслүб, тасвир ягыннан күп үзгәртелеп, төзәтелеп бастырылган. Әдәби бер әсәрне болай үзгәртү, әлбәттә, тиешле түгел иде. Ләкин, аңа карамастан, бу эшләнгән, шуның белән бергә, икенче яктан, бу хәл Ф. Әмирханның әдәби вә тасвири яктан 1918 елда үзенең әүвәлге тасвырыннан, өслүбеннән канәгать түгел икәнен, бәлки, тәгъбир мөмкин булса, аның әдәби сәбатсызлыгын, әүвәлге өслүбенең кимчелекләрен тутырырга тырышканын күрсәтә. Шөбһәсез, әдипләр туктаусыз үсәргә, өслүб вә тасвирда күтәрелә барырга мөмкин. Ләкин, моны, әүвәлге язганнарын төзәтеп, бастыру юлы белән түгел, бәлки яңа әсәрләр язу юлы белән күрсәтергә кирәк иде. Гыйльми бер мәкалә яки фәнни бер әсәр һәр басылган саен төзәтелергә мөмкин. Әмма әдәби әсәрләргә, шигырьләргә бу турыда юл куелырга мөмкин түгел. Бу әдәби үсү тарихын югалтырга тырышудан башка бернәрсә түгел. *(Авт. иск.)*

күп әсәрләре үзләренә шушы тормышны мәүзуг[1] итәләр. Чыннан да ул, әгәр әйтергә мөмкин булса, гимназист вә гимназисткалар әдибе, шуларның художнигы иде.

Ф. Әмирханның бер эшче тормышыннан да, авыл һәм крестьян тормышыннан да һичбер мәүзуг алып язганы юк. Аның хосусый тормыш шартлары да моңа имкян бирә[2] торган бер юлда түгел иде. Шуның өчен ул бөтенләй шәһәрдәге югары катлау тормышының әдибе булды.

Кыскасы, Фатих Әмирхан үзенең иҗтимагый, әдәби-фикри үсүендә «хакыйкый яурупист булу» идеясе белән башлап, ниһаять, тәсаувыф «вәхдәте вөҗүд – пантеизм», яисә рус тәнкыйть дөньясында йөртелгән тәгъбир белән әйтсәң, Великий пан[3] ноктасына килеп, шунда ныгып алып, ахыр гомерен янә шул ноктада тәмам итте. (Югарыда 5 нче рәкым астында «Тәгъзия»дән алынган мисаллар укылсын.) «Сәҗдәи шөкер» аның соңгы идеологик һәм әдәби сулышы булды. Беренче әдәби әсәре булган «Гарәфә көн төшемдә» һәм аннан соң язылган «Гыйбадәт»е аның әдәби, иҗтимагый юнәлешенең үсә башлаган баш ноктасы вә «Яшьләр»е шуның сәхнәдә күренгән беренче картинасы булса, 22 елда язылган «Тәгъзия»се дә әдәби-фикри үсүенең тәмамланган, төенләнгән соңгы ноктасы һәм әдәби-фикри гомеренең дә хатимәсе[4] булды[5].

### ***Фатих Әмирханның тел-өслүбе***

Фатих Әмирханның иҗтимагый, сәяси мәкаләләрендә теле кытыршы, әдәби яктан эшләнеп җитмәсә дә, әдәби әсәрләрен ул матур яза. Ләкин, тел-өслүбен матурлауга көчләнү сәбәпле, кайбер вакыт ясалмалыкка да төшкәләде. Менә шушы ясалмалык сәбә-

[1] Мәүзуг – тема.

[2] Имкян бирә – мөмкинлек бирә.

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[4] Хатимәсе – азагы, йомгагы.

[5] Аның «Тәгъзиясендәге бу соңгы әдәби тавышы, шөбһәсез, романтик төрек әдибе Халид Зыяның «Мәзардан сәсләр» (Г. Сәгъди тарафыннан бу әсәр 1910 елда «Кабердән тавышлар» исемендә татарчага тәрҗемә ителеп бастырылган иде) дигән хикәясендәге тавышларның татар буржуа әдәбиятында яңгырап алуы, ләкин сәнгатьчә бик зәгыйфь бер рәвештә эшләнеп чыккан иде. *(Авт. иск.)*

беннән, аның әдәби өслүбен һәм типларын Фатих Сәйфи[1] кебек мөхәррирләр хәтта «ялтыравыклы ялганнар» дип тә атадылар («Тормыш» газеты, 1916 ел). «Матур яза» дидем. Ләкин кемнәрчә? Әлбәттә, Думага, массага җиңел аңлашыла торган бер тел, шундый матур бер өслүб белән түгел, бәлки татар буржуа зыялыларына, гимназист, гимназисткаларның зәвыгына муафикъ булган бер тел, шундый буржуа сәнәгатьчелеге телендә. Аның матур язуы әнә шул мәгънә белән. Шуның белән бергә, ул рухи хәлләрне ача, шуларны яхшы ук төрле бер рәвештә сурәтләндерә торган бер әдип булып, аның тел-өслүб тәгъбирләре дә урыны белән шуңа бик ятышлы булып төшәләр. Ф. Әмирхан өслүбе – үзенә бер махсус өслүб.

Гомумән, татарның әдәби телен эшләшүдә Фатих Әмирханның байтак хезмәте булды. Фәкать «Тәгъзия»сендә генә аның, ни өчендер, тел, өслүбтә кирегә табарак әйләнгәне күренде.

Ф. Әмирхан татар буржуазиясенең иң типлы, куәтле, талантлы әдипләреннән берсе иде. Ул татар буржуа әдәбиятының телендә дә, идеологиядә дә, сәнгатьчелектә дә, буржуачылыкны бөтен хәлендә күрсәтә торган бер әдип булып дөньядан үтте.

*Г. Сәгъди.*

*25 март, 1926 ел. Казан.*
*«Безнең юл», 1926, № 3*

[1] Фатих Сәйфи – Мөхәммәтфатих Камалетдин улы Сәйфуллин, язучы, җәмәгать эшлеклесе.

# БЕЗДӘ ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ
## (Октябрьнең ун еллыгына)

## I

### *Мәсьәләгә гомуми бер караш*

***Тәнкыйть нәрсә*** – Кешедә ике төрле фикер эшчәнлеге, ике төрле төп гаклый процесс бар. Табигать һәм иҗтимагый тормыштагы төрле хадисәләр[1], хәлләр, эш һәм вакыйгалар кешенең миендә, гасабәләр (нервалар) системында «кеше башына күчерелгән һәм шунда яңадан эшләнеп чыккан мадди бер нәрсә» (Маркс) булып, шул ике төрле фикер эшчәнлеге аркылы өзлексез рәвештә яңадан эшләнеп чыгып торалар. Кешелек тормышының мәгълүм бер икътисади-иҗтимагый зәминендә[2] мәгълүм бер идеология мәхсуле (продукты) булып бер-бер артлы үзләренең сыйнфый төсләре белән тезелә баралар.

Кешедә генә шул ике төрле фикер эшчәнлегеннән ике төрле иҗат яисә ике төрле эшләп чыгару хасил була: 1) фәнни иҗат; 2) нәфис иҗат. Турыдан-туры аңлар, аңлаулар, мантыйкый юл белән төшенүләр аркылы фикерләүдән беренчесе; баштан кичерүләр һәм тойгылар тәэсире, шуларның катышуы белән сурәтләр (Образ)[3] аркылы фикерләүдән, шулай ук аларның нәфис сурәтләрендә гәүдәләндерелү процессларыннан икенчесе мәйданга килә.

Боларның беренчесендә гакыл, мантыйк; икенчесендә баштан кичерү, хис һәм хыял артык эшчәнлек күрсәтә. Беренчесеннән аң, белем системалары туса; икенчесеннән хис, кәеф, баштан кичерү (Переживание)[4] системалары тора. Икенче төрле әйткәндә, беренчесе, кешенең төшенүләрен, тәҗрибәләрен, сынауларын, белемнәрен системалы, мантыйкый яктан дөрес тезелмәле бер аң (идрәк) рәвешендә төрле формалар, кагыйдәләр, кануннар астына сыйса; икенчесе мөндәриҗәләре[5] күп өлешендә хис һәм баштан ки-

[1] Хадисәләр – күренешләр.
[2] Зәминендә – җирлегендә.
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] Мөндәриҗәләре – эчтәлекләре.

черүләрдән гыйбарәт булган нәфис сурәтләр системасын тудыра. Әдәби тәнкыйть янә шушы ике төрле иҗатның беренчесеннән. Ягъни ул – фәнни иҗатларның үзенә махсус бер төре. Шуның белән бергә ул – әдәбият белеменең дә бер бүлеге.

Тәнкыйтьне гомумән алып (ягъни бер әдәби тәнкыйтьне генә түгел, бәлки гомумән тәнкыйть дип аталган фикри эшчәнлекне) кыскача тәгъриф иткәндә[1] түбәндәге рәвештә аңлата алабыз: бер фикер икенче бер фикер эшчәнлегенең җитешкән һәм җитешмәгән якларын ачып, аерып бирү, шуларга бер бәя куюю ягына юнәлсә, янә шуннан «тәнкыйть» дип аталган фикер эшчәнлеге туа.

Әдәби тәнкыйть исә шушы фикер эшчәнлегенең сәнгать әсәрләренә, нәфис әдәбиятка, нәфис иҗатларга каратылган өлешеннән гыйбарәт.

Әдәби тәнкыйтьне «әдәби иҗатның бер төре», «сәнгать төрендә сәнгать, иҗат төрендә иҗат» диючеләр; шуның белән бергә, аны «сәнгать фәлсәфәсенең бер төре» булу рәвешендә «иҗаби белемнәр әйләнәсе (даирәсе) эчендә үзенә яшәү хокукы алырга чакырылган» икәнлеген дәгъва итүчеләр бар.[2]

Монда, әлбәттә, эклектизм юк түгел. Әдәби тәнкыйть һәрхәлдә «сәнгать төрендә сәнгать» булмас. Ул – «иҗат төрендә иҗат» булырга мөмкин. Ләкин әдәби иҗат төрендә әдәби иҗат түгел, бәлки фәнни бер иҗат ягы фәнни-әдәби бер иҗаттан гыйбарәт булыр.

Әдәби тәнкыйтьнең фәнни булуын, була алуын бөтенләй инкяр итүчеләр дә бар. Октябрьдән соң да урыс матбугатында шуны алга сөрүчеләрнең башлыкларыннан, остазларыннан гыйлем дөньясында атаклысы – академик Перетцин[3] булып, шул фикерне аның аңлатуы нигезендә яисә аңа аерым, аңа таяну юлында әле дә дәвам иттерүче, куәтләүчеләр килеп чыга тора[4]. Перетцин чишмәсеннән

[1] Тәгъриф иткәндә – аңлатканда.

[2] «Литературная энциклопедия» *(кирилл хәрефләре белән язылган)* – Лаврецкий мәкаләсе беренче җилддә *(томда)*, 381–386 нчы битләр. *(Авт. иск.)*

[3] Аның «Краткий очерк методологии истории русской литературы» *(кирилл хәрефләре белән язылган)* дигән әсәре. 1922 ел, 13 б. *(Авт. иск.)* Владимир Николаевич Перетц (1870–1935) – рус һәм совет филологы, әдәбият тарихчысы, педагог, академик. Чыганаклар белеме, текстология, палеография, фольклористика һәм театр тарихы буенча хезмәтләр авторы.

[4] М. Яковлевның «Плеханов как методолог литературы» *(кирилл хәрефләре белән язылган)* дигән әсәре белән (15 бит), Гроссманның «Борьба за стиль» *(кирилл хәрефләре белән язылган)* дигән әсәренә (16–20 бит, 1927 ел) каралсын. *(Авт. иск.)*

аккан бу фикерләр – түбәндә идеализм орлыгының җимеше һәм әдәби тәнкыйтькә идеалистларча бер карашның нәтиҗәседер. Түбәндә язылачак фикерләрдән әдәби тәнкыйтькә болай карашның хаталыгы һәм андый бер фикернең түбәндә нинди бер идеология адәмнәренең фикере булганлыгы тагын да яхшы ачыла алыр.

***Идеалистлар һәм материалистлар тәнкыйте.*** Идеалистлар тәнкыйте фәлсәфи тәнкыйть. Алар һәр нәрсәдән элек «сәнгать әсәренең идеясен сәнгать теленнән фәлсәфә теленә, сурәтләр теленнән мантыйк теленә әйләндерергә» телиләр.

Диалектик идеализмның һәм, шуның белән бергә, мотлаки (абсолют) бер хакыйкать системы тудырырга теләгән бер фәлсәфә мәктәбенең атаклы, зур остазы Гегель[1] карашында бу тәнкыйтьнең төп бурычы менә болай күрсәтелә: «Сәнгать әсәрен фәлсәфә яктылыгы белән яктырту дигән сүз, ул – аны бөтен дөнья тарихы, үзләренең бәрелешү һәм каршылыклары белән мәшрут булган[2] төплекләрдән (*монда* – начало[3]) берсенең ифадә ителүе[4] рәвешендә аңлау дигән сүз була. Шәхеснең рухында туган рухи (психологик) процесслар минем өчен ялгыз гомуми бер нәрсәнең, мотлакый бер идеянең тәрәккыйсендәге процессның аңлатылуы, булу сыйфаты белән генә әһәмиятлеләр алар»[5]. Шул ук Гегель фәлсәфәсе мәктәбенең шәкертләреннән (бигрәк тә үзенең әүвәлге гомерендә) булган мәшһүр урыс тәнкыйтьчесе Белинский[6] болай ди:

«Сәнгать әсәре конкрет фикерләрнең конкрет шәкелләрдә (форма) органик бер рәвештә аңлатылуыннан гыйбарәт. Конкрет идея исә төгәл булган, үзенең һәммә ягын эченә ала торган, үзенә тәмам тигез һәм үзен тәмам аңлатып бирүче хакыйкый, мотлакый бер идеядән гыйбарәт. Ялгыз конкрет идея генә конкрет, сәнгатьле бер шәкелдә гәүдәләнергә мөмкин.

---

[1] Георг Вильгельм Фридрих Гегель (1770–1831) – алман фәлсәфәчесе, алман классик фәлсәфәсенең һәм романтизм фәлсәфәсенең вәкиле, абсолют идеализм системасын булдыручы.

[2] Мәшрут булган – алшартланган.

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[4] Ифадә ителүе – аңлатып бирелүе.

[5] Плехановның «Литература и критика» *(кирилл хәрефләре белән язылган)* дигән әсәре. 33–34 битләр. *(Авт. иск.)*

[6] Виссарион Белинский (Виссарион Григорий улы Белинский (*Белынский*); 1811–1848) – рус язучысы, фикер иясе, әдәби тәнкыйтьче, публицист.

Сәнгать әсәрендә фикер шәкел белән конкрет рәвештә кушылган булырга, ягъни ул аның белән бер нәрсә булып чыгарга, аның эчендә эрергә, югалырга, аны бөтенләй үзенә үткәрергә тиеш».[1]

Шул хәлдә, димәк, фәлсәфи тәнкыйтьнең төп бурычы һәм төп характеры: сәнгать әсәрендә гәүдәләнгән идеяне билгеләүдән, «үзенең хосусый һәм соңгы зоһурында[2] гомуми, чиксез булган бер нәрсәне табудан гыйбарәт булып кала. Шуның белән бергә, бу мәктәпкә мәнсуб[3] идеалистлар карашында «сәнгать әсәрен тәмам аңлап җитү – фәкать фәлсәфи тәнкыйть аркылы гына мөмкин» булган бер нәрсә.

Моны Плехановча[4] аңлатканда түбәндәгечә булып чыга:

«Без беләбез: Белинский тәгърифенчә[5] шигырь моталәга[6] тәфәккер[7] рәвешендәге хакыйкатьтән гыйбарәт. Аның маддәсе дә (предмет)[8] шул ук фәлсәфә маддәсе. Ягъни мотлакый идея булып, бу идея сәнгатьтә сурәт аркылы зоһур итә[9].

«Әгәр дә бу шулай була торган булса, инде моннан фәлсәфи тәнкыйтьнең вазифалары нидән гыйбарәт икәнен күрү җиңел. Бу тәнкыйть хакыйкатән сәнгать теленнән фәлсәфә теленә, сурәтләр теленнән дә мантыйк теленә күчерә»[10]).

Иң идеалист һәм үз фикерен, үз карашларын бер дә пәрдәләнеп тормыйча ачык әйтеп бирүчеләр тибыннан саналган бер әдәбият тәнкыйтьчесенең, ягъни А.Л. Волынскийның[11] әдәби тәнкыйть турындагы фикер һәм карашларында Белинский карашлары артыннан тиңләп үтсәк, мәсьәлә тагын да тулылана төшәр. Ул менә болай ди: «Чын тәнкыйть сәнгатьле һәм шигъри әсәрләргә, әйтергә кирәк, идеалистик үлчәү белән килеп һәм сәнгатьнең бөтен конкрет

[1] Плехановның шул ук әсәре, 76 бит. *(Авт. иск.)*

[2] Зоһурында – беленүендә.

[3] Мәнсуб – караган.

[4] Георгий Валентинович Плеханов (1856–1918) – рус теоретигы, фәлсәфәче, марксизм тарафдары.

[5] Тәгърифенчә – билгеләвенчә.

[6] Моталәга – өйрәнү.

[7] Тәфәккер – фикерләү, уйлау.

[8] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[9] Зоһур итә – барлыкка килә.

[10] Плехановның югарыда күрсәтелгән әсәре, 160 бит. (*Авт. иск.*)

[11] Аким Львович Волынский (әдәби псевдоним, чын фамилиясе һәм исеме Хаим Лейбович Флексер; 1861 яки 1863–1926) – әдәби тәнкыйтьче һәм сәнгать белгече; балет белгече.

материалына гали фәлсәфи әсасларының азмы-күпме камилләшкән бер гәүдәләнүенең шәкеле булу рәвешендә карап, аларны эчке якларыннан тикшерергә тиеш». «Гамәли турылыкны түгел, бәлки гыйльми дөреслекне – саф фәлсәфи максатлар өчен – тәгъкыйб итеп[1] тикшерергә тиеш». «Тәнкыйть шигыре идеянең, кеше рухының серле тирәнлекләреннән заһир булып та[2], тәсавирның[3] чуар материалы һәм карашы аркылы аның ничек тишеп чыгуын күзәтергә кирәк»[4]).

Инде килик материализм-марксизм әдәби тәнкыйтенә. Бу тәнкыйть идеалистлар тәнкыйтенә бөтенләй башка. Ул – төп нигезе белән аларныкына – фәлсәфи тәнкыйтькә капма-каршы булган бер тәнкыйть. Материализм-марксизм үзе яңа бер фәнни систем булса, аның әдәби тәнкыйте дә шул системның бер өлеше булып төзелүгә омтыла. Ягъни бу тәнкыйть тарихы материализм әсасына[5] муафикъ[6] һәм шул әсас буенча фәнни бер тәнкыйть булу юлын ала.

Бу әдәби тәнкыйтьнең беренче төп нигезен күрүче һәм шуның беренче нәзариячесе Г.В. Плеханов ул турыда менә болай дип чыкты:

«Гегель мәктәбенең идеалист тәнкыйтьчеләре – һәм шулар арасында даһиләр[7] сыйфатындагы безнең Белинский үзенең тәрәккыйсенә муафикь[8] беренче дәверендә болай дип әйткәннәр иде: фәлсәфи тәнкыйтьнең вазифасы – сәнгатьче тарафыннан аның үз әсәрендә ифадә ителгән, аңлатылган) идеяне сәнгать теленнән фәлсәфә теленә, шигъри сурәтләр телендә мантыйк теленә әйләндерүдән гыйбарәт. Мин исә дөньяга материалистларча карау тарафдары бу-

[1] Тәгъкыйб итеп – күзәтеп.

[2] Заһир булып та – билгеле булып та.

[3] Тәсавирның – тасвирларның.

[4] Валериан Полянский – «Вопросы современной критики» *(кирилл хәрефләре белән язылган)* дигән әсәре, 5–6 бит. Волынскийның «Русская критика» *(кирилл хәрефләре белән язылган)* дигән әсәреннән алынган) *(Авт. иск.)*

Павел Иванович Лебедев-Полянский (туганда Лебедев фамилиясе; псевдонимы Валериан Полянский; 1882–1948) – совет әдәбият белгече, марксист, әдәби тәнкыйтьче, большевик, 1920–1940 елларда дәүләт идеология аппаратының күренекле функционерларының берсе. СССР Фәннәр академиясе академигы (1946), Мәскәү дәүләт университеты профессоры.

[5] Әсасына – нигезенә.

[6] Муафикъ – туры килгән.

[7] Даһиләр – иң югары иҗат сәләтенә ия кешеләр.

[8] Тәрәккыйсенә муафикь – алга китешенә туры килгән.

лып менә болай димен: тәнкыйтьченең беренче вазифасы – әсәрнең идеясен сәнгать теленнән социология теленә әйләндерүдән гыйбарәт. Тагы моның аркасында бер әдәби әсәрнең иҗтимагый эквиваленты дип аталырга мөмкин булган нәрсә табылган булсын»[1]).

Плеханов үзенең менә шушы чыгышы һәм шушы фикерләре белән ике төрле әдәби тәнкыйтьнең бер-берсенә каршы булган төп нокталарын ачып бирде. Шуның белән бергә, ул материализм-марксизм әдәби тәнкыйтенең иң беренче төп маягын утырткан, шуның беренче нигезен корган булды.

Шул хәлдә, димәк, идеализм тәнкыйте белән материализм тәнкыйте арасында аерма һәм төп каршылык ноктасы – берсендә (идеализмда) тәнкыйтьнең фәлсәфәгә, мантыйкка таянуында; икенчесендә (материализмда) тәнкыйтьнең төп таянычы – социология-марксизм социологиясе булуындадыр. Берсе – сәнгать әсәреннән иң элек «мотлаки хакыйкать», «мотлаки бер идея» эзләсә, икенчесе – сәнгать әсәреннән һәр нәрсәдән аның элек социологик-иҗтимагый тамырын эзли. Берсе әсәргә иң элек аның идеясе һәм шул идеянең төп чыгышы, аның агып чыккан төп чишмәсе, ул чишмәдән ничек агып килеше ягыннан бәһа бирсә[2], икенчесе аңа иң элгәре аның «иҗтимагый эквиваленты» ягыннан бәһа бирә.

Менә болар, ике төрле тәнкыйтьнең төп аермасы, бер-берсенә каршы яклары.

Шуның белән бергә боларның икесендә дә табыла торган һәм табылуы зарури булган бер як бар. Ул да боларның икесендә дә теге беренче төп бурычлары үтәлгәннән соң икенче бурыч итеп әсәрнең эстетика ягы игътибарга алыну һәм алынырга тиеш булудан гыйбарәт.

Марксизм әдәби тәнкыйтенең төп нигезен салучы бу турыда менә болай төшенә:

«Мәгълүм бер әдәби хадисәнең иҗтимагый эквивалентын (бәрабәр кыйммәтен) табуга омтылу белән бергә, ул әгәр дә эшнең, шуны (эквивалентны) табу белән генә чикләнеп калырга мөмкин түгеллеген һәм социологиянең эстетика алдында ишекләрне ябып куймаска тиеш икәнен, бәлки киресенчә аның алдында аларны бөтенләй

[1] Г.В. Плеханов *(кирилл хәрефләре белән язылган),* җилд XIV. 183–184 бит. *(Авт иск.)*

[2] Бәһа бирсә – бәя бирсә.

ачып куярга кирәклеген аңламаса, бу тәнкыйть үзенең хас табигатенә хыянәт иткән булыр иде. Үзенә хыянәт итми торган (үзенә сәдакатьле булган[1]) материализм тәнкыйтенең икенче эш (Акт[2]) – идеалист тәнкыйтьчеләрдә дә булганы шикелле, тикшерелә торган әсәрнең эстетика (нәфасәт[3]) ягыннан җитешлегенә бәһа бирүдән гыйбарәт булырга тиеш». «Башкача әйткәндә, материализм тәнкыйтенең беренче эше икенчесенә ихтыяҗны бер читкә ташлап куймый гына түгел, бәлки аны ул үзе өчен лазем булган бер тутыру дип кара»[4].

Менә шушы ике төп вазифасы белән алып, материализм әдәби тәнкыйтен Плеханов идеализм әдәби тәнкыйтенә каршы фәнни бер тәнкыйть итеп куя һәм аны шулай дип таный, шулай булырга тиеш дип белә:

«Чынында да без шул турыда ышанабыз ки, безнең белемебезнең бу көнге хәлендә без инде иске фәлсәфи тәнкыйтьне һәм гомумән эстетиканы фәнни тәнкыйть, фәнни эстетика белән алыштыру тантанасын кылу өчен, үзебезгә рөхсәт итәргә мөмкин».

«Ул (фәнни тәнкыйть. – *Г.С.*) физика шикелле, ул объектив һәм шуның өчен дә ул һәртөрле метафизикадан ерак». «Менә шушы объектив тәнкыйть никадәр фәнни булса, шулкадәр дә ул җәмәгатьче тәнкыйть була, – дибез без».[5]

Шушы цитата аркылы алдыбызга янә бик мөһим бер мәсьәлә куела. Ул да – идеализм эстетикасына каршы материализм эстетикасының (аның тәнкыйте шикелле үк) фәнни булу мәсьәләседер. Бу ике тәнкыйть әдәби әсәргә нәфасәт ягыннан бәһа бирү турында да әсасән бер-берсенә каршы ноктадан баралар.

Ягъни идеализмның нәфасәт критериясе белән материализмның нәфасәт критериясе бер-берсенә башка материализм эстетикасында идеализмдагы кебек сәнгатьнең мотлаки (абсолют) һәм мәңгелек кануннары юк. Ул аларга (сәнгать кануннарына) мәгълүм бер иҗтима-

---

[1] Сәдакатьле булган – тугрылыклы булган.

[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[3] Нәфасәт – гүзәллек.

[4] Плеханов Г.В., җилд XIV. 188–189 бит. *(Авт. иск.)*

[5] Плеханов Г.В. «Литература и критика» *(кирилл хәрефләре белән язылган)* беренче җилд, 35–41 б. (монда китерелгән цитаталар Плехановтан тик сайланып, бу урында мәүзуг өчен, мәсьәләне ачар өчен иң кирәк булган урыннары гына өзелеп алындылар). *(Авт. иск.)*

гый-мәдәни шартлар астында туа, шулар белән билгеләнә һәм шул шартларның үзгәрүләре белән туктаусыз үзгәрә бара дип карый. Шуның белән бергә, Плехановның дигәне кебек, «фәнни эстетика сәнгатькә һичбер төрле боерык бирми. Ул аңа син шундый-мондый кагыйдә һәм алымнар (прием)[1] белән эш ит дими. Ул сәнгатьнең мәңгелек кануннары бар дип игълан кылмый. Ул фәкать һәртөрле тарихи дәверләрдә хөкем сөргән кагыйдә һәм алымнарның нинди рәвештә зоһур[2] итүләрен күзәтү белән генә чикләнә». «Ул сәнгатьнең тәрәккыйсе үзләренең тәэсирләре белән машрут булган мәңгелек кануннарны өйрәнергә омтыла».

Безнең тәнкыйтебезнең Октябрьгәчә идеализм тәнкыйтенә каршы куелган төп назары, нигезләре беренче тарихи төп маяклары әнә шулар иде.

***Октябрьдән соң гомумән әдәби тәнкыйть мәсьәләсе.*** – Октябрьдән соң яңа тормыш төзү, яңа җәмгыятьне социализм җәмгыятен оештыру, гомумән, Советлар илен төзекләндерү эшләренә керешү белән сәяси, иҗтимагый-мәдәни, шул ук вакытта гыйльми мәсьәләләребезнең иң әһәмиятлеләреннән берсе булып кузгалган мәсьәлә гомумән нәфис әдәбият белән бергә әдәби тәнкыйть мәсьәләсе булды. Октябрьнең шушы беренче ун елы эчендә бу турыда күп кызу бәхәсләр, дискуссияләр, фикер алышулар, аңлашулар уздырылды. Бигрәк тә бу турыда урыс матбугаты аеруча нык кайнады. Күп мәкаләләр, аерым-аерым күп китаплар, мәҗмугалар чыкты. Бухарин, Луначарский, Троцкий, профессор Фриче, профессор Гегель һәм башкалар кебек галимнәрнең нотыклары, әсәрләре, мәкаләләре аркылы бу турыда күп нәрсәләр бирелде. Төп нокталар билгеләнде. Кирәкле юллар сызылды. Маяклар утыртылды. Ачыла алмый торган төенле күп мәсьәләләр ачылды.

Ниһаять, мәсьәлә әсасәт[3] катгый хәл ителеп, төп ноктада гомуми рәсми карар хәленә килде.

***ВКП(б) карары һәм марксизм-коммунизм әдәби тәнкыйте өчен төп маяклар.*** – Партиянең нәфис әдәбият мәсьәләсендәге сәясәте турында ВКП(б) Үзәк Комитетының карарлары эчендә марксизм-коммунизм әдәби тәнкыйтенең ничек булырга, нинди нигезләрдә

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] Зоһур – килеп чыгу, беленү.
[3] Әсасәт – нигезле.

төзелергә тиеш икәнлек мәсьәләсендә аерым бер әһәмиятле маддә бар. Бу маддә марксизм-коммунизм тәнкыйтенең төп маягын утырта. Карарның 12 нче маддәсендә бу турыда менә болай диелә:

«Партия кулында иң әһәмиятле тәрбия коралларыннан берсе булган тәнкыйтьнең вазифалары да югарыда әйтелгәннәр белән гомумән һәм бөтенләй билгеләнгән була. Коммунизм позициясен бер минутка да бирмәстән, пролетариат идеологиясеннән кыл кадәр генә дә чигенмәстән, шулай ук төрле әдәби әсәрләрнең, сыйнфый объектив мәгънәләрен ачып биреп, коммунизм тәнкыйте әдәбияттагы контрреволюция күренешләренә каршы шәфкатьсез бер рәвештә көрәшергә, «сменовехчылык»[1] либерализмын ачып салырга һәм тагы шуның шикелле эшләрне эшләргә тиеш. Шулай ук, ул шул ук вакытта пролетариат белән бергә бара ала торган һәм барып торучы бөтен әдәби катлавыклар турында бик зур бер такт, саклык, чыдамлык күрсәтергә тиеш. Коммунизм тәнкыйте үзенең кирәкләре эченнән әдәби команда тонын куып чыгарырга тиеш. Үзенең идея ягыннан булган өстенлегенә таяначак булганда гына, ул шушы тәнкыйть, тәрбия ягыннан тирән бер әһәмияткә ия була алыр. Марксизм тәнкыйте җилбәзәкле, ярым сәватлы[2] (полуграмотный)[3] һәм үзе белән генә канәгатьләнүче комчванствоны[4] үз арасыннан катгый рәвештә куып чыгарырга тиеш. Марксизм тәнкыйте үзалдына өйрәнергә дигән лозунгны куярга һәм үзенең хосусый мохитендә һәртөрле кәгазь пычратучылыкны (макулатура)[5] һәм үз белемчелекне – үз белдеге белән генә эш итүчелекне – кире кагарга, иләргә тиеш»[6]).

---

[1] Сменовехчылык – 1920 елларда беренче дулкын Ак эмиграция арасында барлыкка килгән, әмма СССРда да күп тарафдарлары булган идея-сәяси агым. Исеме 1921 елда Прагада басылган «Смена вех» мәкаләләр җыентыгыннан килә, анда бу агымның төп идеяләре формалаштырылган. Сменовеховлар Совет Россиясе белән татулашу һәм хезмәттәшлек итү яклы булалар, үз позицияләрен большевик хакимиятенең «яңадан тууы» һәм Россиянең милли мәнфәгатьләрендә эш итүе белән аңлаталар.

[2] Сәватлы – укый-яза белүче.

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[4] Комчванство – коммунистическое чванство – аерым совет коммунистларында чагыла торган тәкәбберлек, эшкә тәкәббер караш.

[5] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[6] «Искусство и литература в марксистском освещении» *(кирилл хәрефләре белән язылган)* мәҗмугасы, өченче бүлек, 505–506 бит. «Безнең юл» журналының 1926 елгы 5–6 нчы санында бу карар бөтене белән татарчага тәрҗемә ителеп басылды, фәкать төзәтебрәк укырга туры килә торган урыннары юк түгел. – Г.С. *(Авт иск.)*

Партия карарындагы 16 нчы маддәдә янә болай диелә: «партия бөтен нәфис әдәбият эшчеләренә тәнкыйтьчеләр белән әдип-сәнгатьчеләрнең функцияләрен бер-берсеннән дөрес аерып чикләүнең кирәклеген күрсәтергә тиеш» (бу соңгысына аеручы игътибар ителсен. Бу – әдәби тәнкыйтьнең «сәнгать турында сәнгать» түгеллек юлы алынганын аңлата).

Бу карарга анализ (тәхлил) ясаганда, марксизм-коммунизм әдәби тәнкыйте турында без түбәндәгеләрне аңлыйбыз:

1) Тәнкыйть – коммунизм тәрбиясенең иң әһәмиятле карарларыннан берсе.

2) Бу тәнкыйть, ягъни марксизм әдәби тәнкыйте – яңаны төзүче, яңа җәмгыятьне оештыручы бер тәнкыйть. Ул һәрвакыт коммунизм позициясен нык саклап, пролетариат идеологиясенә нык тотынып, һәртөрле әдәби әсәрләрнең сыйнфый йөзен, объектив мәгънәләрен объектив юл белән ачып бирә. Әдәбияттагы контрреволюция шаукымнары, сөремнәре белән аянычсыз рәвештә нык көрәшә.

3) Марксизм-коммунизм әдәби тәнкыйте әдәби боерык бирүче генә түгел, бәлки анда моның тоны да юк һәм булмаска тиеш.

4) Марксизм тәнкыйте тик үзенең идея ягыннан булган өстенлегенә таяна.

5) Марксизм тәнкыйте төпсезлек, җилбәзәкләнүчелек, ярым сәватлы булучылык һәм үзе белән генә канәгатьләнеп, үзенә исе китеп, үзе белән масаеп йөрүчелек кебек сыйфатлардан бик ерак. Марксист тәнкыйтьче ул – бик җитди, чынлыклы һәм төгәл сәвадлы булырга тиеш, шуның белән бергә, ул үзе белән генә канәгатьләнми, бәлки зур бер коллективка, пролетариат коллективына, аның гомуми фикеренә, тәҗрибәсенә, төп максатына, аның революцион барышына таянып эш күрә.

6) Марксизм тәнкыйте мәгънәсез нәрсәләр белән кәгазь пычратуга, һәртөрле дорфалыклар күрсәтүгә, шулай ук үзбелемчелеккә, ягъни пролетариат коллективы карашы белән хисаплашмыйча, тик үз индивидуаль карашлары тәэсире астында һәм тик үз белдеге белән генә эш итеп, уйга-башка ни килсә, авызга ни төшсә, шуны тәнкыйть исеменнән сөйли бирүгә, язуга һич юл куймый. Бу хәлләр – марксизм тәнкыйтенең иң дошман күргән бер нәрсәсе, мондый сыйфатта булучыларны ул үз мәйданыннан куа, әйдәп чыгара.

7) Марксизм тәнкыйтенең лозунгасы – өйрәнү.

8) Марксизм тәнкыйтендә тәнкыйтьчеләр белән әдип-сәнгатьчеләрнең функцияләре, вазифалары бер-берсенекеннән башка. Бу ике төрле нәфис әдәбият эшчеләре үз өсләренә икесе ике төрле функция йөклиләр.

## II

### *Үз дөньябызда*

***Татарда гомумән тәнкыйтьсезлек заманы.*** Татар дөньясында XIX йөзнең башларынача булган заманны бездә гомумән тәнкыйтьсезлек дәвере дип санарга мөмкин. Аңанчы әдәби тәнкыйть дигәнне әйтмибез дә инде. Ул юк та юк иде. Мин монда татарның гомумән иҗтимагый фикере тормышына аңанчы тәнкыйть дигән нәрсә юк иде, димәкче булам. Татар дөньясында мондый бер фикер эшчәнлеге ул замангача кузгалмады, кузгала алмады. XVI йөзләрдә рус монархиясе, Мәскәү патшалыгы тарафыннан һәр яктан эштән чыгарылып, кыйналып ташланганнан соң, бу дөнья эчендә фикри хәрәкәттә туңу башланды. Татар тормышы тәнкыйть камчысына эләкмичә, тыныч кына оеды да оеды, туңды да туңды.

***Беренче тәнкыйть уклары.*** Бездә тәнкыйтьнең беренче адымы XIX йөзнең башларында Курсави[1] белән башланды. Беренче тәнкыйть укларын атучы ул булды. Аның тәнкыйте татарның фикер туңлыгына, каралыгына, наданлыгына, тәнкыйтьчәнлегенә каратылган дини-фәлсәфи, усал, каты бер тәнкыйть иде[2]. Ләкин аның тәнкыйди фикерләре әсәр булып, ул вакытта татарда гыйлем теле саналган гарәп телендә язылды.

Шул ук рухтагы тәнкыйтьне XIX йөзнең соңгы ярымында Шиһаб Мәрҗани[3] дәвам иттереп алып китте. Бу тарихчы галимнең тәнкыйте тагын да ачы, тагын да каты, тагын да зәһәрле булды.

---

[1] Габденнасыйр әл-Курсави (тулы исеме Әбүннасыйр Габденнасыйр бине Ибраһим бине Ярмөхәммәд бине Иштирәк әл-Курсави; 1776–1812) – күренекле татар мәгърифәтчесе, галим, теолог.

[2] Курсави тәнкыйтьләре турында шушы мәкаләне язучының «Татар әдәбияты тарихы»нда беркадәр тулы тәфсилле мәгълүмат бар (20–24 бит). *(Авт. иск.)*

[3] Шиһабетдин Баһаветдин улы Мәрҗани (1818–1889) – мәшһүр татар мәгърифәтчесе, фәлсәфәче, тарихчы, дин галиме, педагог, археограф, этнограф, көнчыгыш халыклар белгече.

Аның тәнкыйте дини, гыйльми-тарихи иде: «Мөстәфад»[1] бу юлда татар телендә чыккан беренче әсәр булды.

***Бездә иҗтимагый-әдәби беренче тәнкыйть адымы.*** Бу адым бездә Каюм баба Насыйри[2] белән башланды. Картның «Календарь»ларындагы[3] кайбер мәкаләләре, «Фәвакиһел-җөләса»[4], «Бәлягат»ендәге, «Ләһҗә»[5] мөкаддимәсендәге кайбер тәнкыйди карашлары шул беренче адымның беренче тарихи эзләре иде.

Ләкин, билгеле, югарыдагы өч тәнкыйтьченең өчесенең дә тәнкыйтьләре идеалистик тәнкыйть иде.

***1905 ел һәм татарда тәнкыйть.*** Татарда башка иҗтимагый-фикри хәрәкәтләр шикелле үк, гомумән тәнкыйтьчелектә аерым бер хәрәкәт, аерым әһәмиятле бер фикер эшчәнлеге рәвешендә 1905 ел революциясе дулкыннары арасында күтәрелде. Башта, әлбәттә, системсыз, тәртипсез, болганчык иде. Хәтта бик тәмсез, ямьсез яклары да аз булмады. Тәнкыйть исеме белән күп кенә сүгенү, хурлашулар мәйдан алды.

Бу хәл табигый иде. Чөнки яңарырга, яурупалашырга, иреккә чыгарга ашкынган татар зыялысының, татар шәкертенең башы, мие иҗтимагый-фикере хәятта әле бу фикер эшчәнлегенең беренче тәҗрибәсен үткәрә иде. Шуның өчен бу тәнкыйтьләр беренче моменты башта үзләренә мәгълүм катгый бер нигездә, мәгълүм бер ысулда билгели алмыйча азапланырга мәҗбүр булдылар.

---

[1] «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») – Мәрҗанинең иң танылган әсәре. Кыскартылган, хәзерге телгә тәрҗемә ителгән тексты 1989 елда басылып чыкты. «Мөстәфадел-әхбар...» китабын кыскача татар тарихы дип атарга мөмкин. Анда татар халкының этник тарихы, мәгарифе, рухи мирасы, күренекле шәхесләре, мәчетмәдрәсәләре хакында күп төрле мәгълүматлар бар.

[2] Каюм Насыйри (Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров; 1825–1902) – танылган татар мәгърифәтчесе, тел галиме, тарихчы, тәрҗемәче, язучы, фольклорчы.

[3] К. Насыйри җитәкчелегендә 1871–1897 дә (1886, 1887, 1895 елларда туктатылып тора) ел саен «Казан календаре» басылып чыга. Анда, календарьларга хас мәгълүматтан тыш, күп кенә фәнни һәм әдәби материал да бирелә.

[4] «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» (1884) – беренче татар энциклопедиясе: кеше акылы, фән, этика, тел мәсьәләләре, фольклор, әдәбият, музыка кебек темаларга багышлана, 40 бүлектән тора, 1884–1905 елларда җиде мәртәбә басыла.

[5] «Ләһҗәи татари» (1895, 1896) – татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеге.

***«Карчыга күзле» беренче әдәби тәнкыйтьче.*** – «Әлислах»[1] газетының кайсыдыр бер санында берәү татардан да «карчыга күзле» тәнкыйтьчеләр чыга башлау бик көтелгәнлеген язган иде. Шул ук газет аркылы 1907 ел реакция чорларында шундый тип тәнкыйтьчеләрдән берсенең мәйданга атылганын күрдек.

Бу Фатих Әмирхан иде. Ул шул чакларда татар буржуазия хәрәкәтенең радикаль канатында торып эш башлаучы иң көчле мантыйклы, иң асыл каләмле бердәнбер тәнкыйтьче булды. Ул – төп табигате белән тәнкыйтьче бер тип. Гомумән, аның тәнкыйть канаты ул чорларда бөтен иҗтимагый-фикри, мәдәни мәсьәләләрдә бөтен иҗтимагый катлауларны бер кат җилпеп чыкты. Иң зәһәрле уклары, әлбәттә, «хакикый европеист» булырга омтылган яшьләргә, яшьләр кузгалышына, гыйсъянчы шәкертләр[2] хәрәкәтенә каршы килүчеләргә кадалды. Үзендә башта социалистлык очкыннары да күренә иде.

Кирәк әдәби, кирәк иҗтимагый-мәдәни булсын, гомумән, аның тәнкыйте, бу юлдагы фикри эшчәнлеге үзенең мантыйк куәте, көчлелеге, үткенлеге белән аерыла иде. Үтә күрүчәнлек, акыллылык, мәсьәләне тиз һәм җитез әйләндереп ала белүчелек һәм, шуның белән бергә, куркусызлык аның тәнкыйтендәге иҗаби хосусиятләрдән булды.

Ф. Әмирханның әдәби тәнкыйтьчелек гомере күп түгел, бер генә ел. «Әлислах»ның тукталуы белән (1908 ел) аның бу эшчәнлеге дә тукталды. Инде моннан соң бу фикри эшчәнлек аның төп вазифасы булучылыктан чыкты.

Ләкин, ул бу эшчәнлегенең кыска гомерле булуына карамастан, үз ноктасын, үз кәгъбәсен[3] нык саклаучы; үзенең сыйнфый мәнфәгатен, үз сыйныфының, үз коллективының төп идеология нигезләрен бер минутка да оттырмый торган иң каты, нык ирекле, җиңелмәс позицияле бер тәнкыйтьче булды. Әдәби әсәрләрендәге шикелле, ул әдәби тәнкыйтьләрендә дә ул үзе, үз коллективы телә-

[1] «Әлислах» («Реформа») – атналык газета, 1907 елның 3 октябреннән 1909 елның 22 июленә кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә, барлыгы 68 саны чыга. Рәсми нашире һәм мөхәррире – Ә. Бәхтияров, гамәлдә – Ф. Әмирхан.

[2] Гыйсъянчы шәкертләр – бунтарь шәкертләр.

[3] Кәгъбәсен – *биредә:* тоткан юлын.

гән «хакыйкый европеист» була торган яңа буржуазия тормышын, шуның идеологиясен оештыручы иде.

Кыскасы, Ф. Әмирхан үзенең беренче әдәби-фикри эшчәнлек адымында бер сәнгатьче – сүз сәнгатьчесе булудан да бигрәк татар буржуазиясенең «карчыга күзле» реалист бер тәнкыйтьчесе булды.

Соңыннан ул үзе сәнгатьче, сәнгать әсәрләре иҗат итүче булып китте. Тәнкыйтьләрендәге төп таләпләренә җавап бирүченең дә беренчесе, сәдакатьлесе[1] – әлеге иҗатлары аркылы үзе булды.

***Сәхнә әсәрләре тәнкыйтьчесе.*** Ф. Әмирхан үзенең тәнкыйтьчелек гомерендә әдәби әсәрләрнең һәр төрен тәнкыйть иткән иде. Аннан башка тагы шул ук 1905 ел революциясеннән соң татарда үзенең күбрәк игътибарын (бәлки бөтен игътибарын) сәхнәгә, сәхнә әсәрләренә каратучы, шуларны тәнкыйтькә башлаучы бер тәнкыйтьче дә чыкты. Г. Кәрам[2] әнә шул тәнкыйтьче иде.

Моның гомумән беренче әдәби тәнкыйди мәкаләләре 1906 елда башланды. Ул әле аның зәгыйфь беренче тәҗрибә адымнары иде. Бу мәкаләләр «Казан мөхбире»[3], «Әхбар»да[4] күренделәр. Соңыннан аның бу тәҗрибәләре тукталып торды.

1912 елда тагын башлады. «Аң»[5]да театр уеннары, уйнаучылары, сәхнә әсәрләре турында иң күп ул язды.

Г. Кәрамны вакытында идеализм, буржуазия эстетикасы һәм сәнгать әсәрләрен, шул мәктәп тәнкыйтенең, шул идеологиянең критериясеннән (мизаныннан) яурупача мәгънәсе белән яхшы аңлап тәнкыйть итә белүче мәгълүматлы тәнкыйтьчеләрдән санарга кирәк. Бу да үзенең сыйнфый ноктасында үз коллективының, үз

[1] Сәдакатьлесе – тугрылыклысы.

[2] Габдрахман Кәрәм (Габдрахман Хәбибулла улы Рәхмәтуллин; 1878–1947) – театр сәнгате белгече, тәнкыйтьче һәм тәрҗемәче.

[3] «Казан мөхбире» – иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясе органы. Казанда татарча басылган беренче газета. 1905 елның 29 октябреннән 1911 нең 23 мартына кадәр 416 саны нәшер ителә.

[4] «Әхбар» (Хәбәрләр) – иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. 1907 елның 10 декабреннән 1908 елның 30 июленә кадәр Казанда татар телендә атнага 2–3 тапкыр нәшер ителә. Барлыгы 85 саны чыга.

[5] «Аң» – әдәби-фәнни, иҗтимагый-сәяси рәсемле журнал. 1912 елның 15 декабреннән 1918 елның мартына кадәр Казанда айга 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә, барлыгы 123 саны чыга. «Гасыр» матбагасы органы. Төрле елларда мөхәррирләре: Ә. Хәсәни, Г. Ибраһимов.

гөруһының идеологиясендә нык торучы иде. Хәтта аның шул эстетика, шул идеология нигезендәге тәнкыйтьләре Октябрьдән соң да чыккалап куйгаладылар.

***1910–11 еллардан соң.*** Бу вакытларда инде татарның әдәбияты байтак үсеп өлгергән, киңәя башлаган иде. Татарның мәктәп, мәдрәсәләренә дә инде татар әдәбиятын аерым бер кирәкле нәрсә, аерым бер фән итеп кергезү хәрәкәте кузгалган иде.

Татар әдәбиятын мәктәпләрдә укыту, тикшертү эшләре башлану белән бергә һәм бәлки шуның бер нәтиҗәсе булып, бу әдәбиятны, аның әдип-шагыйрьләрен тәнкыйтьтән үткәрү хәрәкәте көчәя башлады. Әдәби тәнкыйтькә ихтыяҗ, аны кирәксенү, аны иҗтимагый-әдәби хәятта иң кирәкле бер нәрсә дип табу гомумиләшә барды. Әдип-шагыйрьләрнең үзләре ягыннан да, аларны укучылар, мәктәп укучылары ягыннан да, гомумән, татар әдәбияты белән кызыксынучылар тарафыннан да бу турыда сорау зурая бара иде.

Шушы сорауларга җавап бирүче булып мәйданга Галимҗан Ибраһимов[1], Җ. Вәлидиләр[2] чыктылар. Шушы мәкаләне язучының бу юлдагы хезмәтләре дә шул елларда башланды. Болардан соң Г. Рәхим[3], Н. Гасрый[4], Ф. Сәйфи-Казанлы кебекләр чыктылар. Хәлим Искәндәр[5], Х. Кәрим[6] кебекләрнең дә тәнкыйтьләре күренгәләде.

Монда ике тәнкыйтьчегә кыскача булса да аерым тукталып үтүгә хаҗәт бар. Боларның берсе – Галимҗан Ибраһимов, икенчесе

---

[1] Галимҗан Ибраһимов (Ибраһимов Галимҗан Гыйрфан улы; 1887–1938) – язучы, галим, дәүләт эшлеклесе.

[2] Җамал Вәлиди (Җамалетдин Җәләлетдин улы Вәлидов; 1887–1932) – татар тел галиме, тәнкыйтьче, әдәбият тарихчысы, педагог, җәмәгать эшлеклесе.

[3] Гали Рәхим (Гали Мөхәммәтшакир улы Габдрәхимов; 1892–1943) – язучы, әдәбият галиме. «Татар әдәбияты тарихы» (1–2 т., 1923–1927) китабы авторларының берсе.

[4] Нәҗип Гасрый (чын исем-фамилиясе Мөхәммәтнәҗип Аллабирде улы Мәүләмбирдиев; 1886–1937) – әдәбият тәнкыйтьчесе.

[5] Хәлим Искәндәр (Хәлим Фәттах улы Искәндәров; 1888–1958) – журналист. Төрле газета битләрендә татар язучылары әсәрләренә, «Сәйяр» труппасы тарафыннан куелган спектакльләргә рецензияләр бастыра.

[6] Хөсни Кәрим (Хөснетдин Минһаҗетдин улы Кәримов; 1887–1965) – язучы, педагог, җәмәгать эшлеклесе.

Җ. Вәлиди иде. Галимҗан тәнкыйтьтә бигрәк үзенең «Татар шагыйрьләре»[1] белән танылды.

Октябрьдән соң татарда марксизм тәнкыйтенә нигез салырга башлаучы бу әдип ул вакытта сәнгать әсәрләренең бигрәк эмоция якларына, сәнгатьчә ничек эшләнеп чыгу мәсьәләләренә ныграк кереп, аларга бигрәк шул яктан бәһа бирүдә киң алымлы, зур куәтле тәнкыйтьче иде. Бу тәнкыйтьче үзенең шул беренче тәҗрибәсендә татарның башка тәнкыйтьчеләре шикелле үк, вакыты белән идеализм эстетикасы баскычларыннан да атлап алгалады.

Дәрдмәнд белән Сәгыйть Рәми[2] үз вакытларында татар дөньясында иң иҗаби якларыннан беренче мәртәбә шул тәнкыйтьче каләме аркылы танылдылар.

Тукай турында беренче сәлби карашны[3] батырлык белән беренче мәртәбә уртага ташлаучы да ул булды.

Шул вакыттагы татар әдәби тәнкыйтьчеләре арасында әдәби әсәрләргә бигрәк акыл, мантыйк ноктасыннан торып, һәм иҗтимагыйәхлакый якларына күбрәк кагылып анализ ясаучы, аларга бигрәк шул яктан бәһа куярга тырышучылардан берсе Җ. Вәлиди иде.

Татар тәнкыйтьчеләре арасында ул вакытта иң авыр, иң сабырлысы, уртача темпераментлысы да шул булды. Үзе «фәлсәфи тәнкыйть» нигезен алган иде.

Профессор Коганның[4] кызык бер тәгъбире бар. Ул: «Сәнгать әсәрләрендә боерык сигасы (повелительное наклонение[5]) яшеренгән» була, – ди.

Ул замандагы татар тәнкыйть дөньясында Җ. Вәлиди, һәр нәрсәдән элек, әдәби әсәрләрдән янә шул «боерык сигасы»н табып аңлатырга, әдип-шагыйрьләрне дә шул яктан танытырга тырышучыларның берсе булды.

---

[1] Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» дигән тәнкыйть мәкаләсе революциягә кадәрге романтик эстетикасының үзенчәлекләре С. Рәмиев, Дәрдмәнд, Г. Тукай иҗатларын анализлауга багышланган (Оренбург, 1913).

[2] Сәгыйть Рәмиев (Сәгыйть Лотфулла улы Рәмиев; 1880–1926) – шагыйрь, драматург, прозаик, журналист, публицист, тәрҗемәче, театр белгече.

[3] Сәлби карашны – кире карашны.

[4] Петр Семенович Коган (1872–1932) – рус һәм совет әдәбияты тарихчысы, әдәби тәнкыйтьче, әдәбият белгече, тәрҗемәче, Мәскәү дәүләт университеты профессоры. Әдәби энциклопедия хезмәткәре.

[5] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

Һәрхәлдә, тәнкыйтьтә ул күбрәк акылын, мантыйкын эшләтте. Тәнкыйть иткән әсәрләренең дә бигрәк шул якларына керергә тырышты. Аның тәнкыйтьләре корыч тәгъбирле; ләкин тәгъбирләренең атамаларының күбрәге гарәпчәдән, госманлыдан алынган булганга, күпчелек өчен аңлауга авыррак булалар иде. Аннан татарның укымышлылары күбрәк файдаландылар.

Бу тәнкыйтьче Гаяз, Тукай, Риза казый һәм Гаспринскийларны танытып бирергә тырышты.

Мәкалә озынаеп барганга, башка тәнкыйтьчеләр турында бу урында тукталып тору мөмкин түгел. Монда тик бары нәтиҗә рәвешендә бер нәрсәне аерымачык әйтеп үтмичә ярамый, ул да – Октябрьдән әүвәлге татар әдәби тәнкыйте үзенең төп юнәлеше, критериясе белән гомумән идеализм нигезендә булган фәлсәфи тәнкыйтьнең үзе яисә, бер дә булмаганда, шуның туганы иде.

***Октябрь һәм бездә әдәби тәнкыйть.*** Октябрьдән соң әдәби тәнкыйть марксизм нигезен алды. Сәнгать әсәренең иң элек «иҗтимагый эквиваленты», социологик тамыры, сыйнфый ягы эзләнә башлады. Аңа беренче бәһане шул яктан бирү юлы тотылды.

Әүвәлге, ягъни Октябрьгәчә мәйданга чыгып эшләгән тәнкыйтьчеләрдән Галимҗан Ибраһимов һәм аннан башка кайберәүләр башлап шул юлны алучылардан булдылар.

***Октябрь белән чыккан тәнкыйтьчеләр.*** Октябрь үзе белән яңа тәнкыйтьчеләрне дә мәйданга чыгарды. Галимҗан Нигъмәти[1], Фәтхи Бурнашлар[2] шуларның беренчеләреннән иде. Диалектик материализм, марксизм нигезендә ныклыгы белән үзен тиз вакыт эчендә танытып өлгерүче Г. Нигъмәти булды. Фәкать аның әдәби әсәрләргә социология, «иҗтимагый эквивалент» ягыннан бәһа бирә белү янына, шуның белән нисбәтне саклау өчен, эстетика ягыннан бәһа бирү процессын бер кадәр көчәйтәсе барлык күренде.

[1] Галимҗан Нигъмәти (Галимҗан Әмирҗан улы Нигъмәтуллин; 1897–1941) – әдәбият галиме, әдәбият тәнкыйтьчесе.

[2] Фәтхи Бурнаш (Фәтхелислам Закир улы Бурнашев; 1898–1942) – шагыйрь, драматург, журналист, җәмәгать эшлеклесе.

Болар соңында яшьрәкләр тезелделәр. Хәнәф Наум[1], Гомәр Гали[2], Кави Нәҗми[3], Толымбай, Мөхәммәт Парсин[4], Кутуй[5] һәм башкалар Октябрь белән хәзерләнеп килгән яшь тәнкыйтьчеләр кадрасының вәкилләре булып чыктылар.

Яшерер хәл юк, болар – әле яшьләр. Бу юлда беренче тәҗрибәләрен әле яңа үткәреп баралар. Шулай да Октябрьнең беренче ун елы эчендәге беренче адымнарын өметле үткәрделәр. Беренче тәҗрибәләре уңышлы гына чыкты.

Әдәби тәнкыйть бабында гыйльми яктан төплерәк танылучы, марксизм методологиясе ягыннан тотнаклы булганнардан Г. Нигъмәти иптәш белән аның артыннан килүче Гомәр Гали иптәшләр үзләренең тәнкыйть юлындагы эшчәнлекләренә күбрәк вакыт бирергә тиешлеләр иде. Хәйретдин Вәли[6] дә үзенең әдәби тәнкыйть турындагы тәҗрибәләрен Октябрьдән соң башлады.

***Ныгытыну һәм остару юлында көрәшләр.*** Татар әдәби тәнкыйтендә, гомумән, татар нәфис әдәбият мәйданында Октябрьнең беренче ун елы эчендә күзгә иң нык ташланган иҗаби фактлардан, иң әһәмиятле уңышлардан берсе идеологиядә ныгу һәм әдәби әсәрләрне язуда сәнгатьчә остару мәсьәләсенең кискен бер рәвештә уртага куелуы булды.

Шау-шулы бер кузгалыш, үз дәрәҗәсендә кискен бер бәрелеш башланды. Яңа бер әдәби сугыш фронты ачылды.

Г. Нигъмәтинең «Әдәбият мәйданында» дигән әсәре белән «Татар театры» мәҗмугасы, андагы кайбер кискен, төкле мәкаләләр бу юлдагы көрәшнең беренче оеткылары, беренче тәҗрибә адымнары

---

[1] Хәнәф Наум – журналист.

[2] Гомәр Гали (Гомәр Билал улы Гали (Галиев); 1900–1954) – язучы, әдәби тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе.

[3] Кави Нәҗми (Габделкави Һибәтулла улы Нәҗметдинов; 1901–1957) – язучы, җәмәгать эшлеклесе.

[4] Мөхәммәт Парсин (Мөхәммәт Зариф улы Парсин; 1899–1963) – журналист, театр тәнкыйтьчесе, «Сәйяр» труппасы артисты, Әтнә халык театрына нигез салучы.

[5] Гадел Кутуй (Гаделша Нурмөхәммәт улы Кутуев; 1903–1945) – язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе.

[6] Хәйретдин Вәли (1893–1963) – әдәби тәнкыйтьче. Мәкаләләре Габдулла Тукай, Фәтхи Бурнаш, Гадел Кутуй, Галимҗан Ибраһимов иҗатлары турында. Аеруча билгеле хезмәтләре: «Әдәби типлар механизмы», «Татар шигыре төзелеше» (икесе дә 1929) китаплары.

иде. Кызыл гаскәр сафыннан чыккан тәнкыйтьче шагыйрь Кави Нәҗминең тилеләрчә кызучанлык белән язылган мәкаләләре, шул көрәшләрне көчле, шау-шулы бер әдәби сугыш хәленә әйләндереп җибәрү өчен, гүя беренче команданлык иттеләр.

Аңар каршы Фәтхи Бурнаш каты тавыш күтәрде. Иң кызу, гасаби мәкаләләр[1] К. Нәҗми белән шуныкы булды. Якага-яка килеп, иң нык алышучы батырлар да шул икесе иде.

Бу көрәшкә актив катышучылар Гомәр Гали, Мөхәммәт Парсин, Даут Юлтый[2], Касыйм Гыйрфан һәм башкалар булдылар. Толымбайның «Матур әдәбият фронтында» дигән кечкенә, ләкин кайбер урыннарда чиктән тыш батыр һәм дөресләнергә тиешле булган фикер-карашларны эченә алган бер әсәре дә шул юлдагы хәрәкәтнең бер җимеше булып мәйданга чыкты.

Соңгы ике елны нык шаулатып алган бу әдәби көрәш файдасыз, нәтиҗәсез булмады. «Кызыл Татарстан» шундый ук нәрсәләргә урын бирә. К. Нәҗми белән Ф. Бурнашның талашыннан, аларның шау-шуыннан нинди мәгънә чыкты?..» дигән кайбер фикерләр әлбәттә урынсыз иде. Бу – иҗтимагый-әдәби хәрәкәтне, аның динамика һәм диалектикасын, үсү-киңәю процессларын, әһәмиятләрен марксистларча аңлый алмау нәтиҗәсеннән башка нәрсә түгел иде.

«Кызыл Татарстан» бу көрәшкә мәйдан биреп, бик яхшы итте. Бу көрәшләрдән файда чыкты гына түгел, бик күп файда чыкты.

Чөнки бу көрәш тик К. Нәҗми белән Ф. Бурнаш көрәшләре генә түгел иде. Бәлки төркемнәр, әдәби гөруһлар көрәше иде. Алар тик шул гөруһларның батыррак бер вәкилләре генә булдылар.

Бу көрәштән бик күп файда чыкты, дидек. Әйе, шулай булды. Зур файда бирде. Моның аркасында әдәбиятта, идеологиядә тирбәлү, какшаулар ачылып, марксизм-коммунизм идеологиясе үз тамырын тәмам ныгытып алу юлында зур адымнар атлады.

Шул ук сугышның дәвамы яисә идеология һәм мөндәриҗә мәсьәләсе чишелгәч күтәрелергә көтеп торган шикелле булып, нәфис әдәбиятта шәкел-форма мәсьәләсе кузгатылды. Яшь шагыйрьәдипләр өчен сәнгатьчә остарырга кирәклек таләбе уртага ташлан-

[1] Гасаби мәкаләләр – көчле мәкаләләр.

[2] Даут Юлтый (Даут Исхак улы Юлтый (Юлтыев); 1893–1938) – язучы, җәмәгать эшлеклесе.

ды. Шул ук К. Нәҗми белән, кыздырылган Гомәр Гали аркылы салкын акыл, басынкылык белән гыйльми нигезләргә тагын да ныграк утыртылып киңәйтелгән, күп файдалы фикерләрнең уртага куелуына сәбәп булган бу кузгалышны янә ун елның иң иҗаби уңышларыннан санарга кирәк.

– Идеологиядә ныгу!

– Сәнгатьчә остару!

Октябрьнең беренче ун елы татар әдәбиятында, татар әдәби тәнкыйтендә әнә шушы ике мәсьәләне иҗаби хәл итү белән тәмамланды.

Шул рәвешчә, Октябрьнең беренче ун елы татар әдәбиятының турыдан-туры үз мәйданында һәм әдәби тәнкыйть мәйданында да моңача күрмәгән зур уңышларга иреште. Шуның белән бергә, алдагы ун еллар өчен, зур өметле әдәби хәрәкәтләр өчен, яңа заманнар һәм киң перспективалар ачты.

*Габдрахман Сәгъди.*

*1927 ел, 22 октябрь, Казан.*
*«Безнең юл», 1927, № 10*

# СИМВОЛИЗМ ТУРЫНДА

## Татар әдәбиятында һәм гомумән шәрык әдәбиятларында әдәби өслүбләрне өйрәнү мәсьәләсе һәм бу китапның алдына куелган бурычы

***(Кереш яисә сүз башы урынына)***

Буржуазия әдәбият теорияләрендә «әдәби агымнар» дип йөртелеп килгән нәрсәләрне (классицизм, романтизм, символизм, реализм, футуризм һ. б.) һәркем белә. Марксизм-ленинизм әдәбият методологиясе буенча әнә шул «агым»нар – өслүб төркемнәреннән башка нәрсә түгелләр.

Әдәбият һәм гомумән сәнгатьтә өслүб һәм аларга классификация мәсьәләләре белән бергә, яурупа әдәбиятындагы (кыйсмән[1] рус әдәбиятындагы) шул «агым»нар марксизм-ленинизм әдәбият методологиясендә беренче мәртәбә чын мәгънәсе белән фәнни рәвештә тикшерүгә алындылар, ягъни алар әдәби өслүбләр рәвешендә беренче мәртәбә марксизм-ленинизм әдәбият методологиясендә генә тикшерелә башлады. Аеруча бу турыда проф. В.М. Фриченың[2] классик хезмәтләре, тикшерүләре, әсасән[3], күп мәсьәләләрне ачып бирде, яңа мәсьәләләрне алдыбызга куйды. Г.В. Плеханов[4] тарафыннан марксизм әдәбият методологиясенең башлап төп аяклары утыртылган иде. Марксист-большевик Фриче, шуларны тәнкыйтьле караш астында киңәйтү һәм ныгыту өстенә, марксизм-ленинизм фәненең ***әдәби өслүб*** һәм шуңа баглы[5] булган әдәби ***жанр*** кебек яңа

[1] Кыйсмән – өлешчә.

[2] Владимир Максимович Фриче (1870–1929) – марксизм идеяләрен алга сөргән әдәбият галиме, СССР Фәннәр академиясе академигы.

[3] Әсасән – нигездә.

[4] Георгий Валентинович Плеханов (1856–1918) – марксизм идеяләрен алга сөргән рус теоретигы, фәлсәфәче, Россия социалист-демократик эшчеләр партиясенә нигез салучылардан берсе, фәлсәфә, җәмгыять белеме, эстетика, этика һәм Россиядә иҗтимагый фикер тарихы буенча хезмәтләр авторы.

[5] Баглы – бәйле.

әсаси[1] мәсьәләләрне күтәрде; шуларны чишүдә, аларны конкрет әдәби факторлар аркылы яктыртуда беренче төп хезмәтләрен мәйданга куйды[2]).

Шул рәвешчә, гомумән, марксизм-ленинизм әдәбият белеменең әсаси мәсьәләләре эшләнү һәм яктыртылу юлында, шулай ук яурупа һәм рус әдәбиятындагы әдәби өслүбләр турында кыйммәтле тикшерүләр, зур хезмәтләр бар. Ләкин татар әдәбиятында һәм, гомумән, шәрык әдәбиятларында бу мәсьәләгә, ягъни алардагы әдәби өслүбләрне тикшерү эшенә әле ныклап керешелгәне юк. Алдыгызга куелган шул кечкенә хезмәт үзенең бөтен кимчелекләре белән бергә, авторның шәрык әдәбиятларындагы әдәби өслүбләрне тикшерү тәҗрибәсенең бер өлешедер.

Шәрык әдәбиятларындагы әдәби өслүбләрне марксизм-ленинизм әсасында[3] алып фәнни тикшерә башлау мәсьәләсе ориентологиясе[4] һәм тюркологиясе алдында торган иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе икәнендә шик юк.

Бу китапның алдына куелган төп бурычы әнә шул эшне башлауга ярдәм итү яисә, һич булмаганда, шуның өчен материал бирешүдән гыйбарәт.

* * *

Шәрык әдәбиятларыннан төрк халыкларының әдәбиятларын гына алганда да, аларда бер төрле әдәби өслүбләрнең булганлыгын күрәбез. Яурупа терминнары белән әйтсәк, классицизм яки рационализм, реализм, романтизм, символизм, иң ахырда футуризм агымнары – шундый әдәби өслүбләр боларда да үзләрен күрсәтеп үттеләр.

---

[1] Әсаси – төп, нигез.

[2] Фриченың «Очерк развития западных литератур» 1927, изд. «Пролетарий»; «Социология искусства» 1929, ГИЗ; «Проблемы искусствоведения» 1930, ГИЗ дигән әсәрләре һәм шулар өстенә «Наша первоочередная задача» («Литература и Марксизм» 1928 год, № 1) шикелле мәкаләләре, тагын башкалары әнә шундый бөек хезмәтләреннән булдылар. *(Авт. иск.)*

[3] Әсасында – нигезендә.

[4] Ориентология – Көнчыгышны өйрәнү фәне (ориенталистика).

* * *

XI йөздә көнчыгыш Төркестанда тудырылган һәм «Котадгу белег»[1], «Һибәт әл-хәкаикъ»лар[2] һ. б. аркылы аерым китап рәвешендәге нәмунәләре[3] безгә килеп ирешкән әдәбият беренче төрк аристократик әдәбияты булып, бу әдәбият рационализм яки классицизм агымын, шундый бер әдәби өслүбне мәйданга куйган иде. Шуларга Мәхмүд Кашгариның лөгатендәге (китабы – «Диване лөгать әт-төрк»)[4] классицизм мисалы булырлык шигырьләрне кушарга кирәк.

Бу әдәбиятта да, яурупа классицизмындагы шикелле үк, акыл – һәрнәрсә, ул анда һәр нәрсәдән өстен. Мәдәниятнең, тәрәккыйнең, икътисади-иҗтимагый һәм сәяси төзелешнең төп факторы анда тик шул дип санала. Кыскасы, тормышның һәр ноктасында иң көчле таяныч итеп шул куелган. Ләкин шунысы бар: ул әдәбият күккә очмый, акыл ноктасыннан торып җиргә, вакыйгый тормышка

---

[1] Сүз XI гасыр төрки шагыйре, Караханилар дәүләте сараенда баш вәзир (олугъ хас-хаҗиб) булып торган Йосыф Баласагунининың (Йосыф Хас-Хаҗиб Баласагуни) «Котадгу белег» («Игелекле белем», 1069–1070) исемле дидактик поэмасы турында бара. «Котадгу белег» – урта гасырлар төрки әдәбиятында кешенең бөеклегенә дан җырлаучы, дәүләт белән гадел һәм акыллы идарә итү идеалын чагылдыручы, законны өстен куючы беренче әсәр.

[2] Сүз XII йөз ахыры – XIII йөз башында яшәгән төрки-татар шагыйре Әхмәд Йүгнәкинең «Һибәт әл-хәкаикъ» («Хакыйкатьләр җыентыгы») дидактик поэмасы турында бара. Бу әсәрдә сүз кеше гомеренең тиз үтүчәнлеге, җирдәге һәр нәрсәнең үзгәрүчәнлеге турында сөйләнелә; автор тәкәбберлекне, саранлык һәм наданлыкны кире кага; гыйлемле булуның файдасы турында яза, әдәбиятны һәм фәннәрне аеруча югары бәяли. Поэма гаруз белән язылган, текст әйтемнәргә, мәкальләргә бай, үгет-нәсыйхәтләрнең күбесе хикмәт формасында бирелә.

[3] Нәмунәләре – үрнәкләре.

[4] Мәхмүд Кашгариның «Диване лөгать әт–төрк» (1072–1074) сүзлеге – безнең көннәргә кадәр килеп җиткән бердәнбер иң борынгы төрки диалектология ядкәре. Анда тугыз меңнән артык сүз һәм сүзтезмә теркәлгән, фонетик һәм морфологик үзлекләре буенча төрки телләрнең классификациясе бирелгән, Урта Азия, Көнчыгыш Төркестан, Идел һәм Урал буе халыклары һәм төрки кабиләләре турында киң лингвистик, тарихи–мәдәни һәм этнографик мәгълүматлар туплап гомумиләштерелгән. Сүзлектә шулай ук Римнан Кытайга кадәр таралган төрки кабиләләрнең атамалары китерелгән, Мәхмүд Кашгари тарафыннан төзелгән дөнья картасында аларның географик урыннары күрсәтелгән; анда шулай ук лирик һәм йола җырлары, төрки-мөселманнарның будда динендәге уйгурларга каршы сугышлары турында героик эпостан өзекләр, А. Македонский походлары турында тарихи риваятьләр һәм легендалар, 400 дән артык мәкаль һәм әйтемнәр урын алган.

багланырга тырыша. Шулай итеп үзенә бертөрле реалистлык күрсәтә. Профессор Фриче Яурупадагы классицизмга реализмның, ләкин фикерчелек, төшенүчелек реализмының бер төре иттереп карый[1]. Дөрес караш. Көнчыгыш классицизмы, тагын да дөресрәге рационализмы да бу агымга шулай дип карауны дөресли.

Кылыч белән сәясәт, акыл, белем (белек) – менә Уйгурстан рационализмы тормышның төп регуляторлары итеп шул ике нәрсәне алга куя. «Кулына кылыч алучы бөтенен (милләтен, дәүләтен) төзер; белем аркасында ул үзенә нык юл салыр» мәгънәсендәге:

Кылыч алдый бире – бөтенен төзер;
Билик бирлә бире катгый юл сүлер, –

кебек мисраглары шуны ачык күрсәтәләр[2]. Димәк, шул рәвешчә, югарыда әйткәнебез шикелле, бу әдәбият җиһангирлек сызыгында үзенә бертөрле реализм сукмагын салырга омтылды, заманында төрк аристократиясенең интересы өчен файдалы булган гамәли-әхлакый һәм фәлсәфи фикерләрне шигырь калыбына сугып, шуның белән төрк дөньясында беренче мәртәбә фикерчелек яки агарту әдәбияты өслүбенең үрнәген биргән булды.

Гомуми рационализм-классицизм әдәбияты шикелле, ул әдәбият та – бик кысынкы рәвештә мантыйкчы әдәбият. Анда каты мантыйклы төшенчәләр шигырь калыбына салына. Ул укучыны отвлеченность[3]ка, гомумилеккә тарта. Турыдан-туры тик акыл эшчәнлегеннән туган нәзари[4] идеяләрне һәм бөтен җәмгатькә яки бөтен сыйныфка уртак булган фикерләрне, бөтен кешелек принципларын бирергә тели. Шуның өчен анда шагыйрьнең үзе – «мин»леге дә гомумилелек кабыгы эченә яшеренә. Хыял, хискә бу әдәбиятта юл бикле яки аларга монда үзләрен кабартып күрсәтергә урын юк. Алар анда акыл, мантыйкый төшенчәләр тарафыннан нык

[1] «Очерк развития западных литератур», стр. 48. *(Авт. иск.)*

[2] Шуңа Әхмәт Йүгнәкинең «Һибәт әл-хәкаикъ»ындагы: «Сөяк өчен җилек ни дәрәҗәдә булса, кеше өчен дә белем шул дәрәҗәдә; кимекнең (*сөякнең*) матурлыгы – җилек, кешенең матурлыгы – акыл», «Белемсез кеше – җилексез сөяк кебек буш нәрсә»; «Җилексез кимеккә кул сузмыйлар», «Белүче белеме белән югары күтәрелде; белемсезлек кешене түбән чүкерде» дигән мәгънәдәге тезмәләрне кушарга кирәк. *(Авт. иск.)*

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[4] Нәзари – теоретик.

авызлыкланганнар. Шуның белән бергә, бу әдәбият кытай һәм һинд фәлсәфәләре белән азыклана.

Идеологиясендә акыл каты хаким булганнан соң, билгеле, ул әдәбиятның өслүбе дә шуңа муафикъ[1] төзелде. Мантыйкый төшенчәләр системаның әдәби өслүбе булып ясалды. Хисләрне шәхси баштан кичерүләрне тәгъбир итүче[2] ялкынлы сүзләргә, хыялый тасвирларга урын бирелмәде яки алар анда юк диярлек дәрәҗәдә бик аз урын алдылар. Шигъри шәхсиятләр кабартыла яки өскә калкып чыга алмадылар, шуның өчен шәхси кәефләрне һәм өметсезлек, төшенкелек кәефләрен тасвир яки тәгъбир итүче васиталарны[3] бу әдәбият өслүбендә күрмибез. Аеруча шагыйрьнең «мин»легенә караган тасвир һәм тәгъбирләр бу әдәбият өслүбендә юк иде дияргә мөмкин.

Ләкин бу аристократик әдәби өслүб XII йөздә үзенә каршы антитеза булып тудырылган икенче бер яңа әдәби өслүб белән алмашынды. Сырдәрья буендагы Көнбатыш Төркестанда, угыз-кыпчак илләрендә шул ук дингә, дини ялганнарга таянган демократик, ягъни гавами, ләкин романтизм әдәбияты мәйданга тудырылды. Рационализмның беренче шагыйре – җир тормышын уйлаучы, салкын акыллы Йосыф Хас-Хаҗиб[4] иде, соңыннан – «Һибәт әл-хәкаикъ»ны язучы әдип Әхмәд Йүгнәкиләр, шул антитеза булып баш күтәргән дини романтизмның беренче вәкиле дә, җир тормышыннан бизеп, күңел (калеб) тәэсиренә бирелеп, дини хисләр белән шашынып дулкынланучы Хуҗа Әхмәд Ясәви[5] булды. Беренчесе – Баласагун, икенчесе – кыпчак төркләреннән. Соңгысы тәсаувыфның «әһле сөннәт»челәр канатында торучы «тарикать» башлыкларыннан иде.

Бу урында искә төшереп үтәргә тиешле характерлы ике нәрсә бар. Берсе шул: төрк әдәбиятындагы рационализм төрк аристократиясенең җиһангирлек хәрәкәте башланган төп үз илләрендә – Көнчыгышта тудырылган иде. Әмма романтизм агымы җиһангирлек сәясәте белән төрк ханлыкларының канлы чыгышлары үткәрелгән

[1] Муафикъ – ярашлы рәвештә.

[2] Тәгъбир итүче – сөйләп бирүче.

[3] Васиталарны – чараларны.

[4] Сүз Йосыф Баласагуни турында бара.

[5] Әхмәд Ясәви (Кол Хуҗа Әхмәд; 1093–1166) – Урта Азия суфи шагыйре, ясәвийә тарикатен нигезләүче. Ясәви Яссы һәм Бохара галимнәреннән, шул исәптән танылган дин галиме Йосыф Хәмәдәнидән (1140 елда вафат) белем ала. «Диване хикмәт» (1878) – мистик, рухани эчтәлекле шигырьләр җыентыгы авторы.

икенче (күчеп барып утырган) илләрендә – Көнбатыш Төркестанда мәйданга чыкты.

Бу урында искә төшерелергә уйланган икенче нәрсә моннан гыйбарәт: бу романтизмда феодаль-дворян аристократиягә, патша, мулла, мөфти, казый, түрә һәм шулар яклы укымышлылар (галимнәргә), аларның халык өстеннән йөргезгән җәбер-золымнарына, шулай ук ришвәтчеләргә каршы ачыну, хәтта һөҗүм бар. Ул шуларга каршы дини гыйсъян рәвешендә тудырыла. Моны да шуның белән изах итәргә[1] мөмкин: бу агымны тудыручылар – гарәп империализмы, солтан һәм ханнар сугышыннан икътисади бөлгенлеккә төшкән, феодаль-буржуа аристократиясенең монархия сәясәте кысынкылыгы астында имгәнгән хезмәт массасы арасында яшәүче яки шушы иҗтимагый катлауга якын торучы дәрвиш укымышлылар иде. Болар солтаннар, ханнар сараеннан читкә кагылучылар һәм хакимнәр катлавы эченә кереп, алар белән «нигъмәт», «кәеф-сафа»ны уртаклаша алмаучылар булдылар. Ясәви тезмәләрендә әлегеләргә каршы дини рух белән аеруча ачу тойгылары җырлана. Аларга заманына күрә зур батырлык белән һөҗүм итеЛә, шуның белән бергә, тормыштан бөтенләй кул селтәп, дөнья эшләреннән тәмам ваз кичеп, мистикага бирелергә өндәлә һәм шул юл белән үзләренә юаныч табарга тырышыла[2].

Бу әдәбиятның өслүбе дә теге аристократик һәм каты мантыйклы өслүбтән (шулай ук үзеннән соңгы чыгтай символизмы өслүбеннән) үзенең артык гавами[3], ачык һәм тәкәллефсез[4] булуы белән аерыла. Шуның белән бергә, монда дини хис – мөселманлык хисе – чиктән тыш көчәйтелгән шикелле, шагыйрьнең шәхсияте – «мин»е әдәбияты да бик нык кабартыла, соң дәрәҗәдә индивидуализмга кителә. Шагыйрь һәрнәрсәдән элек үз хәлен, үзенең эчке тойгыларын, үз моңнарын, үз зарарын тәгъбир белән шөгыльләнә, хәтта үзен Аллалык баскычына күтәрә.

Садәлек[5] ягыннан бу өслүб төрк халыклары әдәбиятларында үз заманында, чыннан да, дини-мистик гавами бер өслүбнең үрнәге

---

[1] Изах итәргә – аңлатырга.

[2] Ясәви һәм аның тезмәләре турында тулырак танышасы килгәннәр авторның үзбәк телендә «Инкыйлаб» журналының 1924 елгы 5 нче санында махсус мәкаләсен карый алалар. *(Авт. иск.)*

[3] Гавами – халыкчан.

[4] Тәкәллефсез – табигый.

[5] Садәлек – гадилек.

иде. Тезмәнең төзелеше ягыннан бу өслүбнең тәэсире (бигрәк тә шул мәктәпнең шагыйре Бакыргани тәэсире) хәтта татарның вак буржуа шагыйрьләрендә дә дәвам итте (Тукай һ. б.), хәтта Тукайның «тотса мәскәүләр якаң» дигәне турыдан-туры Сөләйман Бакырганиның[1] «тотса Газраил якаң»нан үзгәртелгән яки шуңа пародия (назыйрә) иде. М. Гафурида да мондый хәлне ачык күрәбез.

Төрк әдәбиятларындагы беренче романтизм һәм аның өслүбе, теле турында сүз барганда, тагын бер нәрсәне ачык күргәзеп үтмичә булмый. Ул да – заманында төрк халыкларының укымышлылары арасында модага кереп барган фарсылыкка каршы бу романтизм мәктәбенең «төрк» телне, ягъни милли телне күтәреп чыгулары[2]. Монда бу романтизмның милләтчелек хосусиятен дә күреп калабыз. Ясәви шундый укымышлыларга (галимнәргә) каршы:

Хушламайдыр галимнәр сезнең әйгән төркине,
Гариләрдин ишетсәң, ачар күңел мөлкене, –

дигән мисраглары[3] аркылы аларның «төрки» теленә мөнәсәбәтләрен ачык күрсәткәннән соң:

Мискин, зәгыйфь Хуҗа Әхмәт йитти! – Бетешеңә рәхмәт:
Фарсы телен белибән, хуб әйтәдер төркине, –

дип, фарсы телен белә торып, юри аңа каршы төрк телендә язганлыгын аңлата һәм шуның белән мактанып куя.

* * *

XV йөздә көньяк-көнчыгышта яки Чыгтай иле дип аталган мәмләкәттә төрк дворян-буржуа аристократиясенең укымышлылары та-

---

[1] Сөләйман Бакыргани (Кол Сөләйман, Хәким ата; 1186 елда вафат) – Урта Азиядә яшәгән һәм төрки телдә иҗат иткән суфи шагыйрь. Биографиясенә кагылышлы төгәл мәгълүматлар аз сакланган, булганнарының күбесе риваять рәвешендә. Псевдонимына нигезләнеп, Харәзем дәүләтендәге Бакырган кышлагында туган, Яссы шәһәрендә (хәзерге Казакстан Республикасындагы Төркестан шәһәре) Ә. Ясәвидә укыган дип фаразлана, аның вафатыннан соң гомере буе остазы хөҗрәсен саклаучы булып яши. «Бакырган китабы» антологиясендәге бик күп шигырьләр, шулай ук «Хәким ата китабы», «Ахырзаман китабы», «Хәзрәти Мәрьям китабы» исемле риваять характерындагы чәчмә әсәрләр авторы.

[2] Тюркология дөньясындагы төрк телен фарсыга каршы башлап Нәваи күтәреп чыкты, дигән фикернең бу яктан төзәтеләсе яки нәзари яктан дип тутырыласы бар, чөнки гамәли ягы – Ясәвидер. *(Авт. иск.)*

[3] Мисраглары – шигырь юллары.

рафыннан символизм өслүбе мәйданга чыкты. Ләкин бу – ясәвиләр романтизмы шикелле оригиналь түгел, бәлки Иран дворян-буржуа аристократиясенең классик әдәбияты, ягъни Иран символизмның күчермәсе иде. Һич булмаганда, аңа шуның (Иран символизмының) тәэсире зур булды. Заманында Сәмәркандта мәшһүр Сәккаки[1] белән Һиратта мәшһүр Лотфи[2] һәм башкалар шул өслүбнең беренче вәкилләре иде. Нәваи[3], Бабур[4], Хөсәен Байкаралар[5] аркылы бу өслүбтәге әдәбият үзенең үсүендә соңгы ноктасына ирешге. Шул ук

[1] Сәккаки – XV йөзнең беренче яртысында Сәмәркандта яшәп иҗат иткән шагыйрь. Әдәби мирасы, нигездә, газәл жанрында, шулай ук заманының олуг шәхесләрен зурлап язган касыйдәләре дә билгеле.

[2] Лотфи (1366–1465) – Һират шәһәрендә яшәп, чыгтай телендә иҗат иткән урта гасыр шагыйре. Яшьлегендә дөньяви фәннәрне өйрәнсә дә, соңрак суфичылык белән мавыга. Аның газәлләренә Көнчыгыш әдәбиятларына хас купшы бизәклелек ят, иҗатында төрки халыкларның фольклор традицияләре көчле чагылыш таба. Безнең көннәргә аның фарсы телендәге әсәргә назыйрә буларак язылган «Гөл һәм Нәүрүз» (1411–1412) поэмасы килеп җиткән.

[3] Галишир Нәваи (1441–1501) – Урта Азия шагыйре, фикер иясе, дәүләт эшлеклесе. Төрки һәм фарсы телләрендә яза. Беренче тапкыр төрки телдә Низами һәм Әмир Хөсрәү Дәһләвинең «Хәмсә»сенә язылган назыйрә авторы. Назыйрә «Хәйрәт әл-әбрар» («Тәкъвалар хәйраны», 1483), «Ләйлә вә Мәҗнүн» (1484), «Фәрһәд вә Ширин» (1484), «Сабъәи сәйар» («Җиде планета», 1484), «Сәдд-и Искәндәрий» («Искәндәр дивары», 1485) поэмаларыннан тора. Үзбәк һәм фарсы-таҗик әдәбиятларын, аларның бәйләнышларын өйрәнүдә Нәваи төзегән җыентыкларның әһәмияте зур. Бәхәскә корылган «Мөхәкамәт әл-лөгатәйн» («Ике телнең бәхәсе», 1499) трактат ул заман әдәбиятында хөкем сөргән, төрки тел шигырь язу өчен дорфа, килешсез, дигән фикергә каршы чыга, Урта Азия төрки теленең мәдәни һәм сәнгати әһәмиятен дәлилли. Татарлар Нәваине үз итәләр, шигырьләрен оригинал телендә укыйлар. Шигырь төзелешенә караган хезмәтләре татар мәдрәсәләрендә уку-укыту ярдәмлеге булып йөри.

[4] Заһреддин бине Мөхәммәд Бабур (1483–1530) – шагыйрь, тарихчы, Бөек Магуллар империясенә нигез салучы. Бабур төрки телдә һәм фарсыча язылган күпләгән шигъри әсәрләр (газәлләр, робагыйлар), фикъһ (ислам хокукы), сугыш сәнгате, шигърият, музыкага караган трактат-китаплар һәм автобиографик, тарихи язмаларны эченә алган «Бабурнамә» авторы буларак билгеле.

[5] Хөсәен Байкара (Әбү әл-Гази Хөсәен Мирза ибн Мансур ибн Байкара; 1438–1506) – Тимуридлар нәселеннән башкаласы Һират шәһәрендә булган Хорасан хөкемдары. Шагыйрьлеге белән дә танылa. Галишир Нәваи белән бер мәдрәсәдә белем ала. Аның идарәсе вакытында солтан сараенда язучылар, фикер ияләре һәм каллиграфлардан гыйбарәт бер даирә оеша, анда Нәваи һәм Җами да керә. «Хөсәйни» тәхәллүсе белән газәл жанрында иҗат ителгән әсәрләре тупланган җыентыгы (диваны) мәгълүм.

өслүб күп йөз еллар буенча алардан соң да хөкем сөрде. XVII йөздә Төркестанда Гомәрхан Әмириләр[1] дә шуны дәвам иттерделәр.

Шул ук йөздә көньяк-көнбатышта, ягъни Анатулыда[2] госманлы романтизм һәм символизм әдәбияты үсә башлады. XVI йөздә Фөзүли[3] аркылы Азәрбайҗан символизмы күтәрелеп мәйданга чыкты. Шуннан бу әдәбиятлар һаман бер-берсенә тәэсир итешеп бардылар.

XVII йөзнең икенче ярымында (хәзерге табылган материалларга караганда) татар әдәбиятында башлап Мәүла Колый[4] дигән мистик шагыйрь аркылы Ясәви-Бакыргани әдәби мәктәбе тибында һәм шулар тәэсирендә дини романтизм әдәбияты тудырылды. Бу да теле һәм өслүбе белән демократик бер романтизм иде.

Төрк халыкларында реализм әдәбиятының башлануын, турысы, реализм әдәбияты тудыруга авышуны үзбәкләрнең Алтын Урдадан күтәрелеп, Шәйбани кул астында Төркестанга – Чыгтай ханлыклары өстенә ябырылган һәм шунда аларны туздырып, үзләре хуҗалык итә башлаган заманнарында, ягъни шул ук символизм көчәйгән XV йөздә күрәбез. Ул да Мөхәммәт Салихның[5] «Шәйбанинамә» исемле поэмасы аркылы күренде. Көчле оригиналь шигъри талантка ия булган бу шагыйрьнең шул поэмасы, гәрчә романтизм һәм динчелек белән сугарылган булса да, һәрхәлдә, реалистик характердагы бер поэма иде. Чыгтай-үзбәк әдәбиятында үзенең тематикасы, өслүбе ягыннан бу поэма безнеңчә, заманына карата чыннан ори-

---

[1] Биредә сүз XVIII йөз Коканд ханлыгы идарәчесе Гомәр хан (1787–1822) турында бара булса кирәк. Үз ханлыгында фән һәм әдәбият үсеше өчен шартлар булдырган, Кокандны үзенчәлекле әдәби үзәк иткән ханның Әмири тәхәллүсе белән үзенең дә шигырьләр иҗат итүе билгеле.

[2] Анатулы – Анатолия (Төркиядәге шәһәр).

[3] Фөзүли – XVI гасыр төрки суфи шагыйре, фикер иясе. Азәрбайҗан шигъриятенең классигы дип санала, төрек һәм азәрбайҗан шигъриятенә зур йогынты ясый. Төрки, гарәп һәм фарсы телләрендә иҗат иткән.

[4] Мәүла Колый (1630 еллар – XVIII йөз башы) – суфи шагыйрь, төрки суфи шагыйрьләр Ә. Ясәви һәм С. Бакыргани традицияләренең дәвамчысы. Мәүла Колыйның бөтен иҗаты аларның идеяләре белән сугарылган. Йөздән артык шигыре (3800 юлга якын) мәгълүм. XX йөз ахырында табылган «Береккәннәр сыйфаты» һәм «Хәләл нәфкъә эстәгәнләр сыйфаты» («Хәләл ризык эстәүчеләр») поэмаларының авторы.

[5] Мөхәммәд Салих (1455–1535) – Урта Азия шагыйре, дәүләт эшлеклесе һәм Шәйбанилар дәүләте тарихчысы. Чыгтай телендә язылган һәм 9000 гә якын тезмәдән гыйбарәт «Шәйбанинамә» героик поэмасында Урта Азиядә 1499–1506 еллардагы тарихи вакыйгалар турында бәян итә.

гиналь бер әсәр. Аның темасы Нәваиларныкы шикелле Иран символизмының иске-хыялый темалары түгел, бәлки үз заманындагы реаль вакыйга, ягъни үзбәк-чыгтай сугышлары, шул сугышларның дәһшәтле бөлгенлекләре, ачлык фаҗигалары һәм авыл-шәһәрләрнең икътисади кризислары булды. Шагыйрь бу вакыйгаларны булганынча, җанлы, күренешле тасвир итә.

Романтизм һәм символизм өслүбләре төрк әдәбиятларында төрле сыйфатларда һәм төрле тәэсирләр астында, югарыда әйткәнебезчә, озак заманнар дәвам итте. Яки төрле төстә һаман тәкрарлана торды. Мәсәлән, XIX йөздә яурупа буржуазиясенең икътисадисәяси хәрәкәте белән баглы[1] рәвештә, төрк буржуазиясенең яңару хәрәкәте тәэсирендә Анатулы төрк әдәбиятында Яурупа тибында һәм шуның тәэсирендәге буржуа романтизмы куәт алды. Көнчыгыш романтизмы көнбатышныкы белән катыштырылып, яңа формага керде. Бөтен XIX йөзнең ахырлары – XX йөзнең башлары шундый рухтагы романтизм һәм символизм белән шаулады. Шөнасиләр[2], Зыя Пашалар[3], Намык Кәмаль[4], Рәҗаизадә Әкрәм[5] һәм Габделхак Хәмитләр[6], Халит Зыя[7], Тәүфыйк Фикрәт[8] һәм

[1] Баглы – бәйле.

[2] Ибраһим Шөнаси (1826–1872) – госманлы шагыйрь, тәрҗемәче, публицист, җәмәгать эшлеклесе. Төрек драматургиясенә һәм гомумән яңа төрек әдәбиятына нигез салучылардан санала.

[3] Габделхәмид Зыя Паша (1829–1881) – төрек шагыйре һәм прозаигы, журналист, публицист, тәрҗемәче, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе. Төрек әдәбиятын халыкчан итү идеясен алга сөргән әдип буларак мәгълүм. «Зыя шигырьләре» (1881) дип аталган диванынннан тыш, төрек әдәбиятында сатира үрнәге буларак билгеле «Җиңүләр китабы» авторы.

[4] Намык Кәмаль (1840–1888) – атаклы төрек язучысы, драматург, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе, төрек әдәбиятында роман жанрына нигез салучы.

[5] Рәҗаизадә Мәхмүд Әкрәм (1847–1913) – төрек шагыйре, драматургы һәм тәнкыйтьчесе.

[6] Габделхак Хәмит (1852–1937) – төрек шагыйре һәм драматургы. Төрек әдәбиятында романтизмга нигез салучылардан.

[7] Халит Зыя Ушаклыгөл (1866–1945) – төрек шагыйре, прозаигы һәм драматургы. Госманлы дәүләте азагында формалашкан «Җәдиди әдәбият» әдәби хәрәкәте вәкиле.

[8] Тәүфыйк Фикрәт (1867–1915) – төрек шагыйре, журналист. Хәзерге төрек иркле шигыренә нигез салучылардан санала. 1896–1901 елларда көнбатыш иҗтимагый-фәлсәфи фикерләренә таянган «Сәрвәти фөнүн» («Фәннәр байлыгы») журналының баш мөхәррире була.

Җәнаби Шиһаплар[1] һәм тагы башкалар шул әдәби өслүбләрнең вәкилләре иде.

Шул ук XIX йөзнең ахырында казак аристократиясе шагыйре Абай[2] каләме аркылы казак романтизм әдәбияты яки казак романтизм өслүбе тудырылды. Рус романтизм әдәбияты белән күп кенә азыкланган бу көчле шагыйрь рус дворян-буржуа монархиясенең үз заманында Казакстанда каты рәвештә үткәрелгән колонизация сәясәтенә каршы ачы протест һәм каты рәвешле милли тойгылар белән ярсыды. Ахырда үз халкында, турысы, үз сыйныфында зәгыйфьлек, хәлсезлек, җиңелү сизеп, вакыйгыйлыкка кул селтәде, реаль тормыштан йөз дүндерде, дин, Алла ярдәменә сыгынды һәм тәмам пессимизмга бирелде.

Яурупа һәм рус буржуазиясе әдәбиятларында без реализм өслүбенең буржуазия ныгып утырып алган, үз хакимиятен тамырландыра башлаган заманнарда мәйданга чыкканын күрәбез. Бу хәл төрк-татар буржуазиясе әдәбиятларында да шулай булды, ягъни төрк-татар буржуазиясе аякка баса башлап, үзенең сыйнфый сәясәтен ныгытырга көрәшүе белән реализмга борылды. Шуның нәтиҗәсе булып, XIX йөзнең ахырларында һәм XX йөзнең башларында, кирәк Анатулы, кирәк Азәрбайҗан, кирәк татар әдәбиятында булсын, реализм өслүбе үзен күрсәтә башлады.

Реакция елларында татарда, гомумән, романтизм өслүбе көчәйде һәм шул ук елларда көчле бер әдәби агым хәлендә символизм баш күтәреп, Октябрьгә кадәр дәвам итте. Бу дәвердә нык көч алган өслүб тә шул ике төрле өслүб булды, ләкин шуның бәрабәрендә реализм да дәвам итте. Реакция еллары тәэсирендә романтизмга бирелгән кайбер язучылар соңыннан тагын реализмга әйләнделәр.

Октябрь революциясеннән соң татар, азәрбайҗан, үзбәк, казак әдәбиятларында буржуа укымышлылары яки шулар психикасында калучы шагыйрьләр тарафыннан символизм яңадан баш күтәреп карады. Икенче яктан футуризм да үзен күрсәтергә теләде. Болар

[1] Җәнаб Шиһабетдин (1870–1934) – төрек шагыйре һәм язучысы. Иҗатына француз символизмы йогынтысы көчле.

[2] Абай Конанбаев (1845–1904) – мәгърифәтче шагыйрь, казак язма әдәбиятына нигез салучы. Шәрык дин галимнәре тәфсиреннән файдаланып, мантыйк һәм мөселман фикъһ нигезләрен, әт-Табари, Рабгузи, Рәшид әд-Дин, татар тарихчысы Ш. Мәрҗани һ. б.ның тарихи хезмәтләрен өйрәнә. Лирик һәм сатирик шигырьләр, «Мәсгуд» (1887), «Әзим кыйссасы» (1901), «Искәндәр» (1901) поэмалары авторы.

турыдан-туры рус символизмы һәм футуризмының төрк-татар әдәбиятларындагы варислары иде, ләкин гомерләре кыска булды, тиз сүнделәр.

Төрк халыкларының әдәбиятларындагы әдәби агымнар яки әдәби өслүбләргә, аларның туу, үсү тарихлары ягыннан карап, югарыдагыча (описательный характер[1])да кыскача экскурсия ясап чыкканда да, без әнә шундый күренешләрне күрәбез.

Ләкин алда, символизм турында сүз барганда, аңлашылмау чыкмасын өчен, бу турыда хәзер үк шуны әйтеп үтәргә тиешбез: төрк әдәбиятындагы югарыда күрсәтелгән өслүбләрнең шул Яурупа терминнары белән аталулары өчен аларның һәммә яктан да көнбатыш һәм рус әдәбиятындагы хосусиятләрне эчләренә алган булулары, ягъни бөтен яктан да аларныкы шикелле булулары шарт түгел. Төп яктан аларныкы белән бер үк сызыкта булулары белән бергә, үзләренең байтак кына аерым хосусиятләрен күрсәтүләре бик табигый бер хәл. Шуның өстенә тагы төрк әдәбиятларының үз араларында да мондый аерымлыклар булуны (Анатулы, Азәрбайҗан, татар-казак, үзбәк романтизмы яки символизмы һ. б. рәвешендә) истә тотарга кирәк. Гомумән, һәр халыкның әдәби өслүбләрендә, бигрәк тә романтизм яки символизмда милли хосусиятләр, һәрхәлдә, юк түгел.

Көнбатыш һәм рус әдәбиятларындагы агымнарга карата бу мәсьәлә – әдәбият фәнендә тикшерелеп үткән бер мәсьәлә. «Бөтен Яурупа илләре өчен берләшкән, ягъни аларның һәммәсе өчен дә бер төрле үк романтизм булуы мөмкинме, әллә инглиз, француз, немец, рус һәм башкаларның романтизмы рәвешендә милли романтизмнар турында сөйләргәме?» мәсьәләсе озак заманнар тартышлы бер мәсьәлә булып килгән булса да, ахырда боларга милли итеп карау ягы өстенлек ала. Тикшерүчеләрнең күпләре, аларның да бик авторитетлы булганнары шул соңгы карашны алга сөрәләр. Үзенең «Очерк развития западных литератур»[2] дигән соңгы әсәрендә бу мәсьәләгә аерым тукталган профессор Фриче: «Низаг юк, романтизм күптөрле иҗтимагый-сәяси, әдәби шартларга баглы рәвештә, чыннан да, төрле илләрдә төрлечә чыга» (89 бит), – дип, бик дөрес әйтә. Шуның өстенә бу марксист әдәбият тарихчысы, бер мәмләкәтнең үзендә үк шушы милли әдәби өслүбне мәйданга

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

чыгаручыларның кайсы иҗтимагый төркемнән яки кайсы иҗтимагый төркемне язучысы булуларына карап, төрле сыйфатта килеп чыгаруларын да бик урынлы рәвештә аеруча искә алып үтә. (Ул тик классицизмга каршы һәм аңа антитеза булу ягы белән генә берләшкән романтизм турында сөйләүне мөмкин саный.)

Төрк әдәбиятларындагы романтизм турында да мәсьәлә нәкъ әнә шулай тора. Ялгыз романтизм гына түгел, югарыда әйткәнебезчә, бөтен әдәби өслүбләр турында да бу шулай, ягъни һәр халыкта бөтен әдәби өслүбләр (реализм бигрәк тә) милли сызыкларга ия булып килделәр.

Төрк әдәбиятларындагы әдәби агымнар берсе дә, әдәби өслүб мәгънәсендә алынып, аерым рәвештә гыйльми тикшерүләргә ия түгелләр. Анатулы төркләреннән соң елларда төрк әдәбиятлары тарихын тикшерүгә киң кул белән керешкән һәм күп әдәби-тарихи материалларны эченә алган зур әһәмиятле хезмәтләрен мәйданга чыгара башлаган профессор Көпрелезадә[1] дә мәсьәләнең бу ягын игътибарсыз калдыра. Анда бу хәл табигый да, чөнки бу мәсьәлә, ягъни дөрес һәм киң мәгънәсе белән өслүбләр тарихы мәсьәләсе ялгыз марксизм методы буенча гына тикшерелә һәм чишелә алырга мөмкин. Буржуазия социологиясе методы (Көпрелезадә шул метод буенча тикшерә) ул мәсьәләне хәл итә алмый. Бу метод белән аны тикшерергә, хәл итәргә керешкәндә дә, тик формалистлык чуалчыклыгына кереп батудан башка нәтиҗә чыкмый.

Төрк телләренә гыйльми классификация ясау мәсьәләсе белән озак шөгыльләнеп килгән һәм зур гына уңышлар күрсәткән яурупа һәм рус тюркология дөньясы да төрк әдәбиятларындагы әдәби өслүбләрне тикшерүгә, аларга классификация ясау эшенә әле керешә алмады. Бу да бик табигый иде, чөнки, бердән, моңача тюркологиядә марксизм методы булмады; икенчедән, әдәби өслүбләргә классификация мәсьәләсе – фонетик һәм морфологик яктан карап телләргә классификация ясау эшенә караганда тагын да катлаулы һәм тагы да җитди тикшерүләрне сорый торган бер мәсьәлә. Бу – тагын да зуррак җаваплы бер гыйльми эш. Шуның белән бергә, бу турыларда аерым материаллар, бигрәк тә борынгы һәм соңгы аерым

[1] Фуад Көпрелезадә (1890–1966) – төрек филологы, тарихчы, дәүләт эшлеклесе, СССР Фәннәр академиясенең чит ил әгъзасы (1925). Төрек әдәбият белеменең Яурупа мәктәбенә нигез салучы, «Төрек әдәбияты тарихы» (1925) авторы.

характерлы әдәби текстлар җыйналырга, шулар гыйльми тикшерелеп, мәйданга чыгарылырга тиешлеләр.

Ләкин бу сүзләребездән тюркология фәненең төрк әдәбиятларын тикшерүдә моңа кадәр зур гыйльми хезмәте булмады дигән фикер аңлашылмасын. Орхон ташларындагы язулар, «Котадгу белег», «Дәдам Коркыт»[1], Мөхәммәт Салихның «Шәйбанинамә»се, Бабур, Нәваи һәм Мәхтүм Колый[2] шигырьләре һәм башкалар шикелле иске әдәби текстларның тикшерелеп мәйданга чыгарылулары, шулай ук гомумән төрк әдәбиятларының тарихлары турындагы соңгы тикшерүләр, аерым чыккан китап һәм җыентыклар һичшиксез, бик зур әһәмиятле гыйльми хезмәтләр, олы табышлар иде. Болар моннан соң төрк әдәбиятларындагы агымнар, әдәби өслүбләрне тикшерү өчен кирәкле, күп ярдәм итүче кыйммәтле материаллар булып торалар.

Яшерен түгел: әдәби агымнарны яки әдәби өслүбләрне үзләренә аерым тикшереп, аларның һәрберсенең аерым хосусиятләрен билгеләү һәм, гомумән, әдәбиятны өслүб ягыннан карап җәмгыятьнең культура-хуҗалык өслүбенә бәйләү, әдәби өслүбләргә классификация ясау мәсьәләсе – хәтта әдәбият белеме дөньясында да бик яңа бер нәрсә. Монда да аеруча тик Октябрь революциясеннән соң гына, анда да соңгы 4–5 ел эчендә генә рус гыйлем дөньясында марксизм методологиясе галимнәре күзгә ачык ташланырлык зур эшчәнлек күрсәтә башладылар. Советлар Союзындагы яңа шартлар һәм марксизм иҗтимагыять фәннәре шуңа юл ачты. Әдәбият тарихы аерым бер фән булу мәгънәсе белән өслүбләр тарихы булып эшләнергә тиешлек мәсьәләсе алга куелды һәм шуны тудыру юлына төшелде.

[1] «Китабы дәдам Коркыт» – X–XI йөзләр төрки-татар әдәби ядкәре. Китап угыз баһадирларының үзләре басып алган Кавказ җирләрендә кяферләргә каршы сугышканда кылган батырлыклары турында героик дастаннар циклын тәшкил итә. Дастаннарның күбесендә Кавказда яшәгән угызларның патриархаль-феодаль күчмә тормышлары тасвирлана. Хәзерге Азәрбайҗан җирләрендә һәм аның тирәсендә урнашкан шәһәрләр, кальгалар, елгалар, күлләрнең исемнәре аталып үтелә. Ике күчермәсе билгеле: Дрездендагы (унике дастаннан тора) һәм Ватикандагы (алты дастаннан тора) кульъязмалар.

[2] Мәхтүм Колый Фраги – XVII гасырда яшәгән күренекле төрекмән суфи шагыйре. Әхмәд Ясәвине үзенең остазы дип кабул иткән бу шагыйрь шигырьләрен халык сөйләменә якын язуы һәм җәмгыять проблемаларын сәнгатьчә аңлата белүе белән халыкның мәхәббәтен яулаган.

Табигый, бу урында өслүб идеалистлар яки шуларның туганы формалистларча түгел, бәлки марксизмча, ягъни материализмча, фәнни дөрес һәм киң мәгънәсендә алына. Ул монда мөндәриҗә[1] белән форманың органик берләшүе нигезендә аңлана.

Бер җәмгыять яки бер дәүләтнең хуҗалык-культура ягыннан төзелеш өслүбе, шул иҗтимагый төзелешнең таләбе буенча туган әдәби өслүбләр менә хәзер дә рус марксизм әдәбият фәне кызу рәвештә шул мәсьәләләрне тикшерү, ачу, чишү белән шөгыльләнә. Рус телендә чыгып килгән төрле иҗтимагый-гыйльми һәм әдәби журналлар, мәҗмугаларда[2] шул мәсьәлә иң беренче нәүбәттәге әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе итеп куела. Шуңа карата әһәмиятле тикшерүләрне эченә алган мәкалә һәм аерым китап рәвешендә яңадан-яңа хезмәтләр чыга тора. Бу мәсьәлә белән кызыксынып, аны күзәтеп баручылар өчен болар мәгълүм нәрсәләр. Без монда болар аркылы бары шуны гына әйтергә телибез: СССР, пролетариатының социализм ватаны булган шикелле, шул рәвешчә, ул марксизм әдәбият фәненең дә төп ватаны булу юлында уңышлы эшчәнлек күрсәтә.

Шик юк: әдәби хадисәләр[3] – алар бик катлаулы, тикшерүгә җиңел бирелми торган, чуалчык буынлы нәрсәләр. Алар әллә ничә йөз еллар буенча төрле катлаулы иҗтимагый-әдәби шартлар астында бормалы-сырмалы булып үсеп, шуның өстенә тагын һәртөрле тәэсир һәм традицияләрдән тукылып, озын баскычлы эволюция һәм революция процессларын уздыра киләләр. Шуның өчен ул хадисәләргә өслүб мәсьәләләрен бердән ачыкландырырлык, аны тәмам конкретлаштырырлык рәвештә тиз генә тулы анализ ясап бетерү мөмкин түгел. Моның өчен озак вакыт җитештерү, күп көч түгелү кирәк. Бу мәсьәлә һәр дәвернең әдипләре, шагыйрьләре марксизм әдәбият методологиясе буенча яңабаштан тикшерелеп чыгуны сорый.

Марксизм әдәбият методологиясенең үзенең әле эшләнү өстендә булучылыгы мәсьәләнең авырлыгын тагын бер кат арттыра. Хәтта

[1] Мөндәриҗә – эчтәлек.

[2] «Вестник Комакадеми» мәҗмугасы, «Литература и Марксизм», «Печать и революция», «На литературном посту», «Культура и революция», «Родной язык и литература в трудовой школе» һәм башкалар. *(Авт. иск.)*

[3] Хадисәләр – күренешләр.

1928 елның 23–27 гыйнварлары арасында дәвам иткән рус теле һәм әдәбияты укытучыларының конференциясендә иптәш Луначарский[1] марксизм әдәбият методологиясенең Плеханов тарафыннан утыртылган кайбер төп маяклары яки төп принциплары булуын әйтү белән бергә: «Бездә әдәбият фәне юк әле», – дип, мәсьәләне бик кискен куйган иде. (Бу сүз, әлбәттә, марксизм әдәбият фәне турында әйтелә.) Шуның өстенә ул рус дөньясының чын, Плеханов нигезендә әдәбият тарихыннан һәм әдәбият теориясеннән бик аз тикшерүләр бирүче азсанлы әдәбият тарихчыларына ия булганлыгын да дөрес беркетеп үтте. Иң соңгы вакытта гына күренә башлаган азмы-күпме бөтенлекле хезмәтләргә карата янә: «Болар турында туры таш артыннан таш салу рәвешендә марксизм әдәбият тарихы өчен таянычлар (предпосылки[2]) төзергә телиләр»[3], – дигән бик дөрес характеристиканы бирә иде.

Буржуазия илләрендә буржуа социология методологиясе (буржуа сәнгать социологиясе) турында хезмәтләр булса да (Гаузенштейн[4] һәм башкаларның хезмәтләре), марксизм әдәбият методологиясе турында беренче кул хезмәтләрне хәзерге шартлар эчендә алардан, әлбәттә, көтеп булмый. Бу бөек хезмәтне хәзер дә ялгыз «азсанлы» рус марксист әдәбият галимнәре башкарып баралар. Бу сүзләрнең һәммәсе дә мәсьәләнең кыенлыгын аңлатыр өчен сөйләнәләр. Шулай да марксизм әдәбият методологиясенең нигезләрен билгеләү дә, Яурупаның төрле мәдәни мәмләкәтләрендәге әдәби өслүбләрне бер-берсе белән чагыштырып тикшерү дә һәм шуларны Яурупа халыклары әдәбиятларының күбесеннән төрле иҗтимагый-әдәби фактлар алып ныгыта баруы да, аеруча рус әдәбият фәне дөньясының зур уңышларга таба эре адымнар атлаганлыгы – күз алдыбызда торган ачык бер факт.

Шуның белән бергә, бу урында рус марксист әдәбият тарихчыларына карата гомуми бер җитешсезлекне дә әйтмичә үтеп булмый.

[1] Анатолий Васильевич Луначарский (1875–1933) – рус инкыйлаб хәрәкәтләрендә катнашучы совет дәүләт эшлеклесе, язучы, тәрҗемәче, публицист, тәнкыйтьче, сәнгать белгече.

[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[3] «Родной язык и литература в трудовой школе», 1923 г., № 1, стр. 69–70. *(Авт. иск.)*

[4] Вильгельм Гаузенштейн (1882–1957) – алман тарихчысы, сәнгать белгече, язучы, публицист һәм дипломат.

Ул да шуннан гыйбарәт: бөтен шул югарыдагы мәсьәләләр турындагы тикшерүләр ялгыз көнбатыш һәм рус әдәбияты өстенә корыла.

Көнчыгыш әдәбиятлары (аеруча гарәп, Иран, төрк халыклары әдәбиятлары) әдәби өслүб һәм агымнарны билгеләүдә, гомумән, бөтен кешелек мәдәниятендәге уртак әдәби эволюциянең төрле нокта яки моментларын яктыртуда читтә калдырыла, аларга игътибар ителми узыла.

Шик юк: марксизм әдәбият фәне бөтен пролетариат дөньясы өчен уртак принциплы, төгәл, нык системалы бер фән булып туа.

Бу методология бөтен пролетариатның әдәбият белемендә уртак гыйльми-әдәби революция теориясе булачак. Менә шул чын мәгънәсе белән фәнни методологиянең төп нигезләре, принциплары иске һәм яңа культура илләренең төрле характерлыгы, төрле тарихи-әдәби фактлар белән төрле яктан ныгытыла барырга тиеш. Бу да әдәби хадисәләрне чагыштырып өйрәнү яурупа әдәбиятлары эчендә генә калдырылмыйча, көнчыгыштагы әдәби хадисәләргә дә җәелергә тиешлекне алга куя. Мисал өчен, яурупа һәм рус әдәбиятларындагы романтизм һәм символизм өслүбләрен генә алыйк.

Менә боларны көнчыгыштагы (гарәп, Иран һәм төрк дөньясындагы) шул агымнар яки өслүбләр белән чагыштырып өйрәнү бик күп яңа нәрсәләрне китереп чыгарырга мөмкин. Байтак мәсьәләләрнең изахларын[1] башкарырга яки ул изахлар тагын да тулыланырга, тагын да төгәлрәк яктыртылырга мөмкин.

Шуның белән бергә, игътираф итәргә[2] тиешбез: кирәк яурупа, кирәк рус буржуа тюркология фәненең һәм гомумән буржуа ориентологиясенең, югарыда әйтелгәнчә, Көнбатыш белән Көнчыгышны чагыштыру өчен (әдәби өслүбләр турында әйтәбез) күп ярдәм итәрлек материаллары аз түгел. Бу фәннәр моңа кадәр марксизм кайчысы өчен байтак материаллар хәзерләп бирделәр. Ләкин без хәзер дә әле, гомумән, рус марксист әдәбият галимнәре һәм әдәбият тарихчыларының шулардан файдалана башлауларын күрә алмыйбыз.

Бу – бер. Икенчедән, буржуазия гыйлем дөньясында тудырылган бөтен иҗтимагый фәннәрнең марксизм кулында бөтенләй яңа нигезгә утыртылулары һәм, иҗтимагый хадисәләргә аларның биргән изахлары марксизм кайчысы белән киселеп ташланып, яңа

[1] Изахларын – аңлатмаларын.
[2] Игътираф итәргә – кимчелекне таныырга.

яктыртуларга ия була барулары күз алдында. Шуның шикелле үк, тюркология һәм ориентология дөньясында да марксизм-ленинизм методының тормышка үткәрелә башлавы кирәк. Бигрәк тә без моны гомумән көнчыгыш һәм төрк халыклары әдәбиятларына карата әйтәбез, ягъни без моның белән тюркология дөньясының моңа кадәр биргән материаллары үзләре дә яңа изахларга мохтаҗ димәкче булабыз. Моның өчен дә ачык бер мисал итеп шул ук көнчыгыш (Иран һәм төрк) әдәбиятларындагы романтизм белән символизмны ала алабыз. Болар яурупа символизмы белән яки, киресенчә, һичбер төрле дә чагыштырмыйча, үз башларына аерым тикшерелер, алар «тасаувыф әдәбияты» дип кенә бер якка төрелеп куелырлар. Хәлбуки боларны бер-берсе белән чагыштырып тикшерү безне тагын да гомумирәк һәм дөресрәк нәрсәләргә ирештерәчәк. Шуның өстенә, төрк халыкларының әдәбиятлары аерым тикшерелгәндә дә, алар марксизм-ленинизм социологиясенең методы белән яңадан яктыртылырга тиешләр.

* * *

Октябрьдән соң марксизм-ленинизм әдәбият фәне юлында шул югарыдагы тикшерүләр, ирешелгән казанышларны һәм алар турында үз карашыбызда күренгән бер кимчелекне әйтү белән бергә, Советлар Союзындагы төрк халыкларының үз тикшерүләренә дә кыскача тукталып үтик.

Советлар Союзындагы төрк халыкларының әдәбиятларын марксизм методы буенча тикшерү тәҗрибәләре шул халыкларның үз гыйльми көчләр тарафыннан акрынлап булса да эшләнә килә. Октябрь революциясе һәм пролетариат тәрбиясе үз әдәбиятларын марксизм методы буенча тикшерү юлына төшерде, шуның беренче мөмкинлекләрен тудырды. Аеруча бу турыда рус әдәби-гыйльми яңа тикшерүләрне һәм шул турыдагы һәртөрле бәхәс һәм каралыкларны турыдан-туры нык күзәтеп, шулардан файдаланып баралар. Рус теле бу турыда алар өчен бердәнбер гыйлем иде. Чыннан да, бу шулай булырга тиеш тә, чөнки, югарыда да әйтеп үткәнебезчә, марксизм методологиясеннән беренче төп мәнбәгълар[1] шул телдә бирелә.

[1] Мәнбәгълар – чыганаклар.

Аз гомер эчендә күренгән уңышларны искә алу белән бергә, тагын тәкрар шуны әйтергә мәҗбүрбез: төрк татар әдәбиятларындагы әдәби агымнарны марксизмча әдәби өслүб мәгънәсендә алып тикшерү һәм аларга классификация ясау мәсьәләсе – кул тиелмәгән бер мәсьәлә. Рус тюркология дөньясында, югарыда әйткәнебезчә, ул турыда үзенең адымнарын күрсәтергә ашыкмый яки өлгерә алмый тора.

Мәсьәлә, әлбәттә, җиңел түгел, моны чишү өчен, киң һәм һәрьяклы тикшерүләр, анализлар, чагыштырулар кирәк. Монда, гомумән, көнчыгыш[ны] Яурупа һәм рус әдәбиятлары, алардагы әдәби өслүбләр белән дә чагыштыра бару юлы тотылырга тиеш. Мәсьәләне кыенлаштыра торган як та әнә шул. Мондый чагыштыру юлы тотылмыйча янә мөмкин түгел. Чөнки Союздагы төрк әдәбиятларына, гомумән алып әйткәндә, Көнчыгыш (иран, гарәп, төрк, чыгтай) әдәбиятларының кирәк идеология, кирәк өслүб якларыннан тәэсирләре аз түгел. Табигый, бу хәл бер төрк әдәбиятлары турында гына түгел, бәлки бөтен әдәбиятлар турында да шулай, чөнки идеологик өскорма (надстройка[1])ларның башка тармаклары шикелле үк, бөтен дөнья әдәбиятлары бер-берсенә бәйләнеп, берсе икенчесенә тәэсир итешеп килгәннәр һәм киләләр.

Икенче яктан, көнчыгышның экономикасы, иҗтимагый хәрәкәт тарихы марксизм күзлегеннән әле тикшерелмәгән булу, ягъни аның иҗтимагый хәрәкәт тарихыннан пролетариат сыйныфы нигезеннән карап эшләнгән тикшерүләр өчен системалы, тулы кулланмалар булмау да – мәсьәләне кыенлаштыра торган сәбәпләрнең берсе.

Ләкин шушы кыенлыкларның һәммәсен искә алган хәлдә, һаман мәсьәләне чишү өчен ныклы көрәшергә тиешбез. Бу эшкә керешүнең беренче адымнары да кисәк-кисәк ярдәмче материалларны уртага кую, мәсьәләнең кайбер өлешләренә аерым тикшерүләр бирү булыр.

Һәр тарихи дәвернең әдәби өслүбе мәсьәләсен чишүгә яки шуны чишү өчен ярдәмче материаллар бирешүгә төрле яктан керешергә мөмкин.

1. Аерым әдипләрнең үзләре өчен дә, дәвер өчен дә әдәби яктан характерлы булган әсәрләрен элек аерым-аерым, аннан соң

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

шуларны бергә алып тикшереп, иң элек һәрбер әдипнең әдәби өслүбен билгеләү, аның бөтен әсәрләре арасында өслүб ягыннан уртак хосусиятләрен, өслүб берлеген табу.

2. Шуннан мәгълүм бер сыйныф яисә мәгълүм бер иҗтимагый гөруһ[1] әдип, шагыйрьләрнең өслүбләрен бер-берсе белән чагыштырып, шул сыйныфның уртак өслүбенең төп хосусиятләрен, ягъни бөтен бер сыйнфый яисә иҗтимагый гөруһ өслүбенең берлеген табу.

3. Әдәби агымнарны яки әдәби өслүбләрне аерым алып тикшереп (Яурупадагы агымнар яки өслүбләр белән дә чагыштырып), мөндәриҗә[2] һәм форманың органик берләшүе нигезләрендә һәрбер агымның өслүб төзелешенә анализ ясау һәм шуларның туу, яшәп килү, үлү шартларын билгеләү.

4. Шуларның һәммәсенең нәтиҗәсендә, әдәбият тарихының экономикадан эшләнеп чыккан сыйнфый идеология, сыйнфый психология туфрагында үскән әдәби өслүбләр тарихы булып төзелү юлын ачу, шуның төп нигез ташларын салу.

Бу китапта тикшерүгә алынган тема – әдәби агым, әдәби өслүбләрдән символизм. Тикшерү башта тик татар әдәбиятындагы символизмга гына каратылган һәм анда да бик тар һәм кысынкы алынган иде. Ләкин, тикшерә торгач, татар әдәбиятындагы символизм рус әдәбиятындагы кебек үк бик катлаулы бер әдәби хадисә булып чыкты. Бер яктан, анда борынгы төрк әдәбиятларындагы символизм, икенче яктан, көнбатыш, бигрәк тә рус символизмы тукылган икәнлеге күренде. Өченчедән, кирәк көнчыгыш, кирәк көнбатыштагы булсын бөтен дөнья әдәбиятларындагы символизм төбендә бер үк төрле идеологик һәм психологик хосусиятләргә ия булганлыгы ачылды. Икенче төрле әйткәндә, болардагы символизмның һәммәсе дә бөтен буржуа (дворян) һәм вак буржа әдәбиятларындагы уртак бер әдәби хадисә булып чыкты. Шуның белән бергә, бу әдәби хадисәне элек бөтен бер әдәби хадисә итеп алып, яхшылап танышып үтмичә торып, татар әдәбиятындагы символизмның эч йөзен аңлауның кыенлыгы күренде.

Шуларга баглы рәвештә, иң элек төп символизмның үзенең нидән гыйбарәт булуы кебек уртак бер гыйльми мәсьәләгә тәфсилрәк тукталып, шул турыда азмы-күпме тулырак мәгълүмат бирү кирәк

[1] Гөруһ – төркем.
[2] Мөндәриҗә – эчтәлек.

булды. Чөнки татар матбугатында гына түгел, бәлки рус матбугатында да бу мәсьәлә әле кирәгенчә ачылган яки ачыкландырылган бер мәсьәлә түгел.

Шуңа тагын символизмның Яурупада туу тарихына карап, аны XIX йөздә генә мәйданга чыкты дип аңлау кебек хаталануларны һәм хәтта татар әдәбиятындагы символизмны да Октябрьдән соң туды дип, аны тик Такташка гына бәйләп йөртүчеләрнең булганлыгын кушарга кирәк. Менә боларның һәммәсе дә символизм турында татар телендә тулырак тикшерүләрнең яки шул турыда тулырак мәгълүматны эченә алган аерым хезмәтләрнең мәйданда булмавыннан икәнлегендә шик юк.

Бөтен әнә шул югарыдагы сәбәпләр буенча, без бу китапта символизм өслүбенә нигезеннәнрәк һәм киңрәк туктауны, шулай ук бөтен көнчыгыш һәм көнбатыш символизмы арасында төрле чагыштырулар ясау юлы белән тәфсиллерәк мәгълүмат бирергә тырышуны тиеш күрдек. Моның өчен китапның беренче бүлеген хаслап, икенче бүлегендә, ягъни төп татар символизмында сүзне кыскарак тоттык. Чөнки беренче бүлемдәге һәм китапның шушы «Кереш» өлешендәге тикшерүләр һәм шуларда бирелгән мәгълүматлар икенче бүлемендә кыскалык юлы белән дә мәсьәләне аңлау һәм аңлатуны җиңелләштерә алды. Монда күбрәк мисалларга һәм шуларга анализ ясауга, шуларны шәрехләп, ачып бирүгә әһәмият бирдек. Бу бүлемдә кыскалык юлы тотылуның икенче сәбәбе итеп янә шул ук татар символистларының иҗатлары турында авторның 1926 елда басылган «Татар әдәбияты тарихы» белән 1929 елда язылып, [19]30 елда басылган «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты» исемле хезмәтләрендә кирәкле мәгълүматлар, тикшерүләр булганлыгын күрсәтергә кирәк.

Шуның белән бергә, [19]20 елда язылып басарга бирелгән бу китапның кирәк беренче бүлемендә, кирәк икенче бүлемендә булсын әле тикшерүләрнең, бирелгән мәгълүматларның тулылыгын һәм марксизм-ленинизм методологиясе ягыннан кимчелексез булуын дәгъва итүдән автор бик ерак тора. Бу турыда күп кимчелекләр булу бик нык истә тотыла. Шулай булганы хәлдә, бу яңа хезмәтне уртага куюны автор, һәрхәлдә, файдасыз булмас дип уйлый. Күрсәтелгән кимчелекләрне тутыра баруга автор һәрвакыт хәзер тора һәм шундый күрсәтүләрне ышанып көтеп кала.

**Беренче бүлек**

# ДӨНЬЯГА МӘГЪЛҮМ БЕР КАРАШ БУЛУ ЯГЫННАН ҺӘМ АЕРЫМ БЕР ӘДӘБИ ӨСЛҮБ БУЛУ МӘГЪНӘСЕ БЕЛӘН СИМВОЛИЗМ НИДӘН ГЫЙБАРӘТ

## I. Романтизм һәм символизм

Символизм дигәч тә, фикер романтизмга юнәлә, чөнки боларның икесе дә төбендә дөнья турында бер үк төрле карашка, бер үк идеологик тамырга ияләр. Болар шул ук идеологизмның ике аерым тармагыннан башка нәрсә түгелләр. Шул хәлдә символизмны романтизмның соңгы эволюция баскычы дип аңлый алабыз.

Чыннан да, романтизмнан символизмга чыгу өчен юл озак түгел. Романтизмның соңгы ноктасына барып җиттеңме инде, шунда символизмның ярына килеп җиткән буласың. Аннан символизмга батып китеп, тик хыял һәм «вәһәмнәр» (мечты[1]) эчендә чуала башлауга юл бик кыска кала. Шуның өчен дә символизмны «яңа романтизм» һәм «модернизм» дип атыйлар. Аны болай дип атаучылар бу яктан хаксыз түгелләр.

Яурупа әдәбиятларын тикшерүчеләрнең биргән мәгълүматларына күрә, «романтизм» сүзе иң элек XVIII йөзнең урталарында Англиядә йөртелә башлый. Шул ук вакытта аның урынына «Готически»[2] (Урта гасырлар) дип тә йөртелгән була[3]. XVIII йөзнең башларында инде яурупа әдәбиятларында шул термин урнашып кала.

Мәсьәләнең тарихи ягы түбәндәгечә: XVIII йөзнең ахырларында Көнбатышта классицизм яки рационализм дип аталган агым дәвам итә. Бу агымда акыл каты хаким була (шуның өчен бу рационализм дип тә атала). Әдәбиятны ул тәмам үз кысуы астына ала. Шигъри иҗатларда хис, хыял һәм шәхси кәефләрнең тәгъбир ителүенә юл булмый.

Гомумән, әдип-шагыйрьләрнең шәхси азатлыклары акыл һәм мантыйкчылык кысасы эчендә булып килә. Әдәбият тик «гомуми

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] Фриче В.М. «Очерк развития западных литератур», 1927, стр. 89. *(Авт. иск.)*

кешелек» фикерләрен, гомуми принципларны яки шундый уртак кәефләрне тәгъбир итүче генә булып бара. Аристу[1] һәм Буало[2] поэтикасы әдип-шагыйрьләрнең кул-аякларын богаулап тота, ягъни язучылар шул иске, туңган норматив политика, шул үлек һәм кысынкы кагыйдәләр коллыгында эш итәргә мәҗбүр булып киләләр.

Шуның өстенә классицизм тик шәһәргә, шәһәрләр тормышына гына бәйләнеп кала. Ул әдәбиятта дворянлык аристократиясенең зиннәтле, тәкәллефле[3] тормышы, шул тормышка бәйләнгән күтәренке кәефләр тәгъбир ителә. Классицизм урта гасырны инкяр итә, аны вәхшилек дәвере дип санап, аңа дошманлык күрсәтә. Шуның белән бергә үк, ул борынгы юнан-рума[4] мәдәниятендә һәм сәнгатендә карана, шуңа тартыла.

XVIII йөзнең ахырларында – XIX йөзнең башларында әнә шул өслүбкә (классицизмга) каршы, ягъни аңа антитеза булып, яңа бер өслүб мәйданга килә. Гомумән, XIX йөз яурупа әдәбиятларында классицизмга каршы туган шул өслүб белән башлана. Шуннан бу өслүб, тәнкыйть дөньясында һәм әдәбият фәнендә ***«романтизм»*** дигән термин белән аталып, мәшһүр булып килә.

Шул ук романтизмга антитеза булып XIX йөзнең урталарында реализм һәм натурализм дип аталган өслүбләр баш күтәрә. Боларга антитеза булып, янә шул ук йөзнең соңгы ун елы башланганда, символизм мәйданга чыга. Болар һәммәсе дә дворян-буржуаның авыр фаҗигалы тормышындагы төрле иҗтимагый психологиянең җимешләре булып туалар.

Романтизмның классицизмга каршы булучылыгын аның түбәндәге хосусиятләрендә күрәбез. Романтизмда акылга каршы беренче урынга хис, хыял куела, заманындагы мәдәнияткә кул селтәнә, аннан качыла. Классицизмның дошман күргәне урта гасырга кайтыла. Бөтен борынгы, иске тормыш идеаллаштырыла башлый. «Мин»нәргә һичнәрсә белән чикләнмәгән ирек таләп ителә, шәхесләр азатлыгы күтәрелә. Әдип-шагыйрьләр үзләрен бөтенләй ирекле, ягъни иҗтимагый-сәяси интересларның берсе белән дә чикләнмәгән са-

---

[1] Аристотель (б. э. к. 384–322) – борынгы юнан фәлсәфәчесе.

[2] Никола Буало-Депрео (1636–1711) – француз шагыйре һәм әдәбият тәнкыйтьчесе, классицизм теоретигы.

[3] Тәкәллефле – ясалма.

[4] Юнан-рума – грек-рим.

ный башлыйлар. Башка ягы белән ирекле сәнгать тудырырга телиләр. Шуның белән бергә үк, диннең әһәмияте төшүгә кайгырыла. Динне шигырь белән алмаштырырга телиләр, ягъни шигъри иҗатлар дин вазифасын үтәргә керешәләр, шагыйрьләр «пәйгамбәрлек» итәләр. Шулар өстенә тагын, классицизмның шәһәргә бәйләнүенә каршы, романтизм табигатькә, авылга, халык эченә юнәлә, милли тойгылар кабартыла, халыкның үткәне сагыныла. Иске тарихларга, халыкның тарихи каһарманнарына, әкият, интригаларына күңел бәйләнә. Сергә, һәртөрле серле нәрсәләргә тартылалар.

Дөньяга караш (мировоззрение[1]) ягыннан романтизм, классицизм шикелле үк, идеализмның дуализм чишмәсеннән сугарыла, ягъни бер-беренә башка һәм икесе дә үзләренә аерым барлыкка ия булган ике дөнья – матдә һәм рухлар дөньясы булу карашына таяна. Шуларның икесен дә бар итүче Алла барлыкка ышана.

Романтиклар карашында дөнья, тормыш – кеше өчен газап урыны. Кешенең җаны тән кабыгында әсир булып, фани дөнья тормышында интегүгә мәхкүм[2]. Аңа шул газаптан котылу юлы бер генә – үлем. Тормыш газабына чыдавы, андагы төрле җәберләргә түзүе һәм үзен үзе юатуы, шулай ук иң ахырда «Алланың рәхмәтешәфкате»нә ирешүе өчен дини хисләр – аңа бердәнбер туклыклы азык.

Романтизмның дөньяга карашы һәм төп идеологик күчәре әнә шул. Бу ягы белән ул символизмга да, югарыда әйткәнебезчә, юлны кыскартты яки аңа да юл ачып куйды.

Үзенең сугарылган шундый иҗтимагый психологиясенә һәм дөнья турындагы шушы карашына, шушы төп идеологиясенә муафикъ рәвештә, романтизмның үзенә аерым (классицизмга башка) әдәби өслүбе эшләнде. Хисле-ялкынлы сүзләр, дини тәгъбирләр, Аллага ялварулар, Алла тарафыннан куелган мәхәббәт тойгылары, шәфкать һәм мәрхәмәт белән сагышланулар, әкиятләр, төшләр, оҗмах, тәмуг, фәрештәләр, шайтаннар, төрле хыялый типлар, бердә куркынычлы, бердә күңел юаткыч табигать хадисәләре, серле диңгез, серле таулар һәм күк йөзенең сихерле күренешләре, моңлы-зарлы күз яшьләре, аһ-ваһлары, изгелек-явызлык, бәхетлек-бәхетсезлек, елау-сыкрау, үткәнне – ата-бабаларны сагыну, «үлекләр галәме» белән тойгылар яки

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] Мәхкүм – дучар.

шатлык-кайгылар уртаклашу, хыялны каберләргә юнәлтү һәм башкалар романтизм өслүбен билгеләүче төп хосусиятләр булдылар.

Авылга, халык эченә юнәлгәнлек өчен, романтизм өслүбендә тәгъбир яки тасвир ителергә теләгән фикер, тойгылар яки вакыйгалар булганынча ачык һәм җиңел тел белән бирелделәр. Киная һәм истигарәләре[1] дә артык катлаулы, төенле булмады.

Дөньяга карашы, идеологиясе һәм өслүбе ягыннан әнә шундый хосусиятләргә ия булган романтизм агымыннан символизм үзенең кай яклары белән аерыла? Символизмның нидән гыйбарәт булуын ачык күрү өчен, фикер хәзер әнә шул сорауга туктала. Бу сорауга китапның алдагы аерым бүлекчәләрендә тулы җавап чыга барачак. Шулай да, романтизм белән чагыштыру ягыннан, ул сорауга бу урында алдан ук кыскача җавап биреп үтмичә булмый. Элек бу аерымлыкны дөньяга караш ягыннан күреп бирик.

Романтизмда – дуализм, символизмда идеалистик монизм бар. Дөньяга караш ягыннан символизмның романтизмнан төп аермасы, безнеңчә, әнә шунда. Дөрес, профессор Коган кебек мәшһүр әдәбият галимнәре символизмны да дөньяга караш ягыннан дуализмга кайтаралар, ләкин бу фикер төзәтелүгә мохтаҗ күренә. Чөнки кирәк Көнбатышта һәм рус әдәбиятында, кирәк Көнчыгышта булсын, түбәндә дә ачык күреләчәк булганынча, символизм шигыре пантеизм (вәхдәте вөҗүд) шигыреннән башка нәрсә түгел. Бу исә дуализм белән берләшә алмый.

Символизмның романтизмнан икенче аермасы – аның әдәби өслүбендә. Шул ук дөнья турындагы идеалистик монизм һәм пантеизм карашына бәйле бер рәвештә һәм шуның ук чарасыз бер нәтиҗәсе булып, анда өслүб символлардан төзелгән. Символлы тәгъбир һәм символлы тасвир – болар символизм өслүбендә иҗатның төп алымы. Романтизмда бу алай түгел. Дөрес, анда да шуның аз-маз элементлары бар, ләкин алар анда, һәрхәлдә, иҗатның төп алымы иттереп саналмыйлар. Ничек караганда да, романтизм булганынча ачык, томансыз бер телгә ия. Тасвирлар анда символизмга караганда ачыклыкка һәм тәфсилләнүгә омтылучан булалар. Аннан соң ул тормышның реаль вакыйгаларына күбрәк, якыннанрак бәйләнешле күренә. Хәтта романтизмның бу ягы әдәбият тикшерү эшенә

[1] Истигарәләре – метафоралары.

яңа керешкән кайбер яшь тәнкыйтьчеләрне хатага төшереп, бу агым шигырьләрен реализм шигырьләре белән бутауларына сәбәп булырга мөмкин[1]. Мондый яңлышулар да реалистлыкны ялгыз темаларны реаль тормыш вакыйгаларыннан сайлаудан тора дип уйлаудан килә. Андый яңлышуларның төп сәбәбе әнә шунда. Хәлбуки реалистлык аннан гына тормый. Бу, дөрес, романтизмда да бар. Монда мәсьәләнең төп үзәге шул вакыйгаларны әдип-шагыйрьнең ничек, нинди кәеф белән тасвирлавында, шагыйрьнең шуларга ничек каравында, аларны нинди тойгылар белән сугаруындадыр. Кыскасы, шагыйрьнең ул вакыйгаларны үз субъективы аркылы дөньяны нинди караш һәм нинди идеология белән сындыруында романтизм белән реализм аермасын карарга кирәк. Тагын да кыска әйткәндә, монда бөтен хикмәт объектив (тасвир ителгән нәрсә) белән субъектив (тасвир итүче)нең ничек берләшүендә. Романтизм белән реализм өслүбе әнә шул үзәктә нык аерыла.

Төп мәсьәләгә кайтыйк. Шулай, романтизм, һәрхәлдә, ачык телгә ия. Романтик шагыйрь үзенең сизгәннәрен, башыннан кичергәннәрен башкаларга ачык сиздертергә, фикерен томансыз итеп бирергә тырыша. Символист шагыйрь аннан кача, томан, пәрдәләр астына яшеренә, символларга төренә. Яки романтик шагыйрь әйтә, ачык сөйләп моңлана, символист әйтми, ачык сөйләми, бәлки ул төенне символлар һәм сүз музыкасы, сүз уеннары аркылы ниндидер «сер дөньясы»на карап, тик, нәрсәгәдер ымланып көйләү белән азаплана.

Төп мәгънәсе бикле символлар аркылы фикер һәм тойгыларга ымлау, ниндидер серләргә карап сигнал бирү сиздертергә тырыша. Көнчыгышта да, Көнбатышта да бу шулай. Тәсаувыф башлыкларына һәм тәсаувыф шагыйрьләренең өслүбләренә каратып, ибн Халдун[2]: «Аларның күп сүзләре төенле сүзләрдән гыйбарәт. Алар бик аз вакытта гына ачык сөйлиләр», – дип, бик дөрес әйтә[3]. Рус

[1] Мәсәлән, татар әдәбиятында барып торган романтик, хәтта татар романтизм шигыренең иң типлы вәкиле Тукайда «романтизм элементлары юк» дип чыгучылар булды. *(Авт. иск.)*

[2] Ибн Халдун (Әбү Зәид Габд әр-Рахман ибн Мөхәммәд әл-Хәдрами; 1332–1406) – гарәп мөселман фәлсәфәчесе, тарихчы.

[3] «Мөкатдимәте ибн Халдун», 192 бит. *(Авт. иск.)*

символистларыннан Вячеслав Иванов[1] та: «Символизм сәнгате – символларга нигезләнгән бер сәнгать. Ул әйберләрне аңлау-фәһемләүне символлардан, символларны да мифтан гыйбарәт дип игълан кылуы белән үзенең принцибын тәмам ныгыткан булды[2]», – дип, символларның символистлар шигырендә төп иҗат алымы итеп алынганлыгын бик ачык куя. Символлы һәм шыңгырап торган аһәңле тезмәләр символистларның үз тарафларыннан аларның «рухларын» берләштерүче бердәнбер васита дип санала. Шулай итеп, алар аңлап, белә торып, үзләренең төп аңлашу телләре итеп символларны һәм сүзләрнең аваз хосусиятләрен куялар.

## II. Көнчыгыш һәм көнбатыш символизмы

Романтизм шикелле үк, символизм да – бөтен дөнья әдәбиятларында гомуми бер әдәби хадисә. Ул, көнбатыш һәм рус әдәбиятында булган кебек, көнчыгышта да бар. Элек символизм – боларның һәркайсында да дворян-буржуа тормышының һәм шәһәр мәдәниятенең җимеше. Аны шул сыйныф тормышының төзелеше тудырды. Икенчедән, дөньяга караш, идеология һәм шигъри өслүбләре ягыннан болар төбендә бер үк тамырга кайталар. Болар һәрхәлдә, үзләренең кайбер аерымлыклары белән бергә, феодаль-буржуа мәдәнияте дөньясындагы ерак һәм якын үтмеш дәверләрнең бере артыннан икенчесе ялганып килгән уртак мираслары. Шуның өчен бу агым яки бу әдәби өслүбне, моңа кадәр әдәбият һәм тюркология фәнендә күрелмәгән булуга карамастан, ***көнчыгыш һәм көнбатыш символизмы***[3] рәвешендә ике тармаклы бөтен бер әдәби хадисә иттереп алабыз. Болар монда бер-берсе белән чагыштырыла яки янәшә куела барылачаклар. Методологик яктан да бу хата булмас дип уйлана.

Көнчыгыш символизмы дип без монда рус ориенталистлары һәм тюркологлары тарафынанн «тәсаувыф шигыре» дип йөртелгән әдәбиятны алабыз. Бу әдәбият, югарыда аңлатылганча, Яурупа һәм рус дөньясында символизм шигыре дип аталган әдәбиятның яки

[1] Вячеслав Иванович Иванов (1866–1949) – рус символист шагыйре, фәлсәфәче, тәрҗемәче, драматург, тәнкыйтьче, педагог. Символизмның идеологы, рус әдәбиятының Көмеш гасырында иң төп фигураларның берсе.

[2] Г.Е. Горбачев «Капитализм и русская литература». 1925 г., 131 стр. *(Авт. иск.)*

[3] «Көнбатыш» дигәндә, рус символизмы да кергезелә, шуның белән бергә, ачыклык бирү өчен, урыны белән аңа «рус» дигән сүз дә кушылып йөргезеләчәк. *(Авт. иск.)*

шундый әдәби өслүбнең икенче вариантыннан һәм көнчыгыштагы борынгырак төреннән башка нәрсә түгел.

Һәр халыкның романтизмы, төрле иҗтимагый яки сәяси һәм әдәби шартларга карап, үзләренә хас бер сыйфатта булганлыгын яки аларның милли характерда булучылыкларын югарыда «Кереш» бүлемендә әйтеп үттек. Көнчыгыш һәм көнбатыш, бигрәк тә рус символизмы бер-берсеннән тик әнә шундый специфик яклары белән генә аерылалар. Боларның берсе – XIV–XV йөзләрдәге, икенчесе – XIX йөздәге символизм, ягъни боларның берсе – Көнчыгышның иң иске заман тормышыныкы, икенчесе – Яурупаның яңа мәдәни тормышының малы. Берсе – мөселманныкы, икенчесе – христианныкы. Менә аларның бер специфик аермасын шуннан эзләргә кирәк.

Чыннан да, XV йөздәге икътисади-иҗтимагый төзелеш, мәдәни корылыш белән XIX йөздәге төзелеш һәм үсеш бер түгел. Берсе – феодаль-дворянлык төзелеше, шул төзелешнең мәдәнияте. Икенчесе – яңа техникага – машина техникасына корылган буржуа, капитализм төзелеше, буржуа мәдәнияте. Шулай булганы хәлдә, икесендә дә төбендә бер үк төрле әдәби агым, икесендә дә символизм дәвам итте. Менә моны ничек аңларга, ничек изах итәргә дигән сорау бу урында бик тиз башка килергә мөмкин.

Ләкин монда, минем карашымча, артык аптырый торган яки изах ителүе мөмкин булмаган бернәрсә юк. Теләсә генә нинди формаларда, теләсә генә нинди техника башкалыклары астында булмасын, икесендә дә шул ук хезмәт күпчелегенең көче белән яшәүчеләр хаким, икесендә дә эксплуатация. Шуның ук нәтиҗәсе булып икесендә дә дөньяга караш һәм идеологиядә шул ук Алла, рух, шул ук дин, дини тәрбия дәвам итте. Чөнки боларның һәр икесендә дә югары аксөяк катлау өчен шулар кирәк иде. Шулай булгач, боларның сәнгатьтә дә нәтиҗә игътибары белән төбендә бер үк ноктага килеп чыкмыйча хәлләре булмады. Бу алар өчен табигый, гомуми бер хәл иде.

Шуның өстенә тагын аралары ничә йөз еллар белән аерылган бу ике төрле җәмгыятьнең икесендә дә символизм бер үк төрле иҗтимагый психологиягә, бер үк төрле кәефкә бәйләнеп туды яки икесе дә бер үк төрле психологияне тәгъбир итте. Бу агым һәр икесендә дә үзен тудырган җәмгыять яки сыйныфларның икътисади-сәяси һәм иҗтимагый кризис башланган, егылу-бетү куркынычлары алдында

калган заманнарында (символизмның иҗтимагый тамыры каралганда, мәсьәләнең бу ягы ачылачак) мәйданга чыкты. Менә бу як – бу турыда аерым характерлы бер нокта. Бу Көнчыгыш һәм Көнбатышның икесендә дә символизм туу яки боларның дөнья турында бер үк төрле карашка җыйналуларын һәм әдәби өслүбләре бер-беренә охшау мәсьәләсен аптырашсыз аңлауга ярдәм итә ала.

Яшерен түгел: капитализм җәмгыяте, хосусый милек илләре дөньяда караштa, төп идеологиядә шул ук үзеннән элекке феодаль-дворянлык җәмгыятьләренең карашларыннан, гомумән, төп сызык һәм төп юнәлеш ноктасы булу ягыннан аерыла алмады. Бу бик табигый иде, чөнки феодал-дворян хакимнәр белән дворян-буржуа хакимнәр чыннан да бит болар бер-берсен алмаштырган, икътисади-иҗтимагый һәм сәяси көрәштә җиңелеп, икенчесенә урынын бирергә мәҗбүр булган ике игез туганнар иде. Икесе дә дворянлык, буржуалык, аристократлык һәм эксплуататорлык сыйфаты белән аерылдылар. Тик берсендә феодаллык ягы көчле булса, икенчесендә дә буржуалык сызыгы тирәнрәк салынды. Шуның өчен әдәбиятта болар, сызык аша куелып, бик хаклы рәвештә феодаль-буржуа яки дворян-буржуа җәмгыяте дип бик урынлы йөртеләләр дә. Шулай итеп, үткәннәр белән җиткәннәр, гарәп терминологиясе белән әйтсәк, «сәләф» белән «хәләф» бер-берсенә табигый рәвештә бәйләнеп куела.

Билгеле, яңа буржуа – капитализм буржуасы – иске белән генә калмады. Күп, бик күп яңа нәрсәләр кушты: яңа икътисади-иҗтимагый һәм сәяси шартлар эчендә искегә яңа система кергезде. Үзенең сыйнфый интересына яраксыз якларны өзеп ташлады, кыскартты, яңартты, шуның бәрабәренә үзенә кирәкле яки файдалы булган шул ук феодаль карашларга, шул феодаль фәлсәфәләргә, нигез һаман да шул көенчә сакланган хәлдә, тәфсил бирде, аларны киңәйтте, ачыкландырды һәм яңа конкрет аңлатуларга ия итте. Аеруча фәлсәфә, гомумән, гуманитар фәннәр тарихыннан хәбәре булганнар өчен болар яшерен түгел.

Бер яктан, үзенең бөтен төрләре белән идеализм, икенче яктан, диалектик материализм – дөнья һәм тормышка караштa, төп идеологиядә бер-берсенә капма-каршы булган, бер-берсе белән һичбер вакытта да бергә җыела һәм килешә алмый торган ике төп нокта ялгыз әнә шулар. Бөтен мәдәни-фикри төзелештә иске белән яңа-

ның бер-берсе белән кушылып китмәслек рәвештә кискен аерылып куелуын, әнә шул рәвешчә, ялгыз пролетариат тормышында һәм пролетариат кулында гына эшләнгәнен күрәбез. Бу – артык изах сорамый торган мәгълүм бер нәрсә.

Бөтен кешелек җәмгыяте XIX йөзнең ахырларына кадәр үзенең төрле баскычларын үткәзеп, беренче караштa килде. Дөньяны, җәмгыятьне Алла яки фикер-идея идарә итә дип аңланды һәм шулай өйрәтелә килде. Буржуа җәмгыятенең әдәбиятындагы романтизм һәм символизм гына түгел, аның дөнья турында механик материализм карашының татбигыннан[1] гыйбарәт булган реализмы да, ягъни наив реализм өслүбе дә төбендә шул ук идеализм карашы белән сугарылды яки төбендә шул ук ноктага барып бәйләнә торган характерда булды.

Аның пролетариат реализмыннан аерылган бер ягы да әнә шунда.

Шулай, көнчыгыш һәм көнбатыш рәвешендә символизмның ике тармагы бар. Болар икесе дә мистикачылык шигыреннән гыйбарәт; боларны берләштергән, идеологик бер тамырга кайтарган төп нокта – һәрнәрсәдән элек, әнә шул. Тик төп аерма шунда: берсендә – ислам, икенчесендә христиан буявы ялтырый.

Соң, мистика нәрсә? Мистика (мистицизм) шул – эчке сизү, ягъни күңел (калеб), тойгы аркылы бөтен барлыкның «сер»ен төшенергә тырышу. Күңелнең шул эчке сизү эшчәнлеге көнчыгыш мистикасы телендә «моракабә» яки «вокуфе кальби» дип йөртелә. Моңа «вөждани шөгур», «күңел моталәгасы» дип тә әйтелә. Барысы да «эчке сизү», «эчке төшенү», «үз эчеңә чуму» мәгънәсендә. Бу мәгънәне русча «созерцание»[2] термины белән аңлата алабыз. Аның нәтиҗәсе, ягъни мистикачылык аркылы хакыйкатькә ирешү хыялы тәсаувыф телендә «кәшф» дип атала. «Табу», «ачу» мәгънәсендә. Мистикачылыкның бер галәмәте – акылга, акыл эшләренә каршылык. Мистик ялгыз эчке сизү, тойгыны белә. Күңел һәм күңелнең әнә шул эшчәнлеге мистикада – һәрнәрсә, мистик өчен гүя ул хакыйкать көзгесе яки аның өчен барлык дөньясындагы бөтен серләрнең ачкычы шул. Мистик шуның аркылы үзенең хыял

[1] Татбигыннан – чагылышыннан.
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

кылган «абсолют хакыйкать»не, Алланы табарга тырыша, кешенең һәм бөтен галәмнең төп барлыгы-асылы нидән гыйбарәт булуын, шулай ук гүя абсолют хакыйкать яки Алла белән шуларның ничек бәйләнешләрен (мөнәсәбәтләрен) ачарга тиеш. Моны да ул элек үзенең эчке дөньясын сизенүдән башлый, ягъни элек үз «рух»ын төшенүдән, үз барлыгын танудан тотына (көнчыгыш суфиларында моңа «рөэя»[1] диләр), шуннан ахырда үзен башка «рухлар» һәм «төп рух» яки Алла белән берләштерү баскычына үрли. Шулай итеп, иң ахырда бөтен барлыкны бер барлыкка кайтара да, берлек эчендә – күплек, күплек эчендә берлек күреп, гүя рухи яктан җитлегү (камилләшү) ноктасына ашкан була. Шуның белән бергә, мистик үзенең хыялындагы шушы «рухи хадисә»ләр яки «рух эшләре»нең протестлары эчендә әллә нинди хыял, искиткеч матурлыклар, мәхәббәт күренешләре күрә дә шуларның гыйшкы белән исереп яши башлый. Кешелекнең иң соңгы җитлегү ноктасы һәм «мәңгелек бәхет» көрсисе[2], мистик карашынча, гүя әнә шул.

Тюркология дөньясында «тасаувыф шигыре» дип аталган әдәбиятның (көнчыгыш символизмының), көнбатыш һәм рус әдәбиятында символизм дип мәшһүр булган сүз сәнгатенең икесенең дә үзәге әнә шул мистикачылыкта. Шуның ук нәтиҗәсе булып дөньяга караш ягыннан икесендә дә төп буын рәвешендә пантеизм (вәхдәте вөҗүд) һәм идеалистик монизм ята. Икесендә дә неоплатонизм бар.

Бу урында «пантеизм», «идеалистик монизм» терминнары турында аңлату бирүне сораучылар булырга мөмкин.

Табигать галәмендәге бөтен нәрсәләрне бер асылдан яки бер төплектән чыгарып та, ул асылны да шул ук галәм яисә табигатьнең үз эчендәге Алла яки «рух» дип карау дөнья турында пантеизм карашы була. Кыскача әйткәндә, пантеизм Алла белән табигатьне берләштерү, боларны бер үк нәрсә иттереп караудан гыйбарәт. Бу караш ахырда чынбарлык ялгыз рухлар барлыгыннан гына тора, матди нәрсәләрнең чынбарлыгы юк, дөньядагы матди нәрсәләрнең процессы яки матди хадисәләр һәммәсе дә – төбендә рухи хадисәләр, шуларның тик тышкы күренешләре генә диган нәтиҗәгә китерә. Менә инде шуннан идеалистик монизм [формалаша].

[1] Рөэя – төш.
[2] Көрсие – тәхете.

Ленин үзенең «Материализм и империократицизм»[1] темасында язган фәлсәфи-тәнкыйди тикшерүендә, идеалистик монизмны материалистик монизмга каршы куеп, менә мондый аңлату бирә: «Идеалистик монизм шул: анда рух – җисем (тело[2]) функциясе түгел, рух – шулай булгач, төп асыл. Мохит (среда[3]) һәм «мин – я[4]» – болар тик шул ук бертөрле «элементлар комплексының» дәвамлы-өзлексез бәйләнешләрендә барлыкка ия булалар (Ленин әсәрләре, XIII том, 73 нче бит). Идеалистик монизм турындагы бу аңлату көнчыгыш һәм көнбатыш символизмының һәр икесендә дә бер үк дәрәҗәдә татбикъ ителә[5] ала.

Көнчыгыштагы тасаувыф фәлсәфәсенең бөек теориячеләреннән саналган Газали[6], Мөхетдин ибн Гарәби[7] (бусы – символист шагыйрь дә), шулай ук Иран символист шагыйрьләренең классикларыннан Мәүләнә Җәлалетдин Руми[8] һәм Җамиләр[9], мәшһүр чыгтай шагыйре Нәваи, госманлы-азәрбайҗан шагыйре Фөзүли һәм башкаларның төп карашлары шуңа кайта. Яурупа символист әдип-

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[5] Татбикъ ителә – туры килә, яраша.

[6] Әбү Хәмид Мөхәммәд ибн Мөхәммәд әл-Газали әт-Туси (1058–1111) – мөселман дин һәм хокук белгече, фәлсәфәче. Газали эшчәнлеге суфичылыкның нәзари нигезләрен формалаштыруга, аны һәрьяклы һәм системалы өйрәнүгә юнәлтелгән.

[7] Ибн Гарәби (Мөхид әд-Дин Әбү Габдуллаһ Мөхәммәд ибн Али әл-Әндалуси; 1165–1240) – мөселман дин белгече, суфичылыкның иң күренекле вәкилләреннән берсе һәм аның теоретигы. Аллаһ белән дөнья арасындагы аермаларны кире кагучы яшәеш бердәмлеге (вәхдәте вөҗүд) турындагы тәгълиматны коручы.

[8] Җәлалетдин Руми (1207–1273) – шагыйрь, суфи шәех, философ. Фарсы һәм төрки телләрдә язган. Иң дәрәҗәле, иң абруйлы дин әһелләренә генә бирелә торган «Мәүләнә», «Мәүләви» («хуҗабыз», «остазыбыз») дигән исем йөртә. Шул исемдәге мәүләвия суфичылык тарикатен төзи. «Руми» тәхәллүсе Румга нисбәтле кабул ителгән. Иҗатында суфичылык тәгълиматындагыча кешене илаһилаштыру, галәмдәге һәрнәрсәне универсаль эчтәлекле Илаһият белән кушылу дип пантеистларча аңлатулар урын ала.

[9] Габд әр-Рахман Нур әд-Дин Җами (1414–1492) – атаклы шагыйрь һәм суфичылык әдәбиятының теоретигы. Иҗат эшенә шактый соң алына. 66 яшендә беренче әсәрен яза, барлыгы 100 әсәр иҗат итә, 78 яшенә кадәр кулыннан каләме төшми. Касыйдәләр, газәлләр язган, төрле җыентыклар иҗат иткән, илаһият белеме, суфичылык, шигырь төзелеше, риторика, музыка буенча хезмәтләр калдырган, биш йөздән артык суфиның биографиясен төзегән.

шагыйрьләреннән Стриндберг[1], Метерлинк[2] (символизм теориячесе, философ, шагыйрь), Ницше[3] һәм Ибсеннар[4]; рус символистларыннан Владимир Соловьев[5] (рус идеализм фәлсәфәсенең атасы һәм символизм теориячесе), Вячеслав Иванов, Валерий Брюсов[6] (шулай ук рус символизмының теориячеләре), А. Блок[7] һәм башкаларның дөньяга карашлары да шул сызыкта. Аеруча рус символистларының (бигрәк тә аларның төп аталары В. Соловьевның) карашлары түбәндә көнчыгышныкы белән бер ноктада, табан табанга баса.

Боларның һәммәсендә дә реаль барлык бер генә. Ул да «абсолют хакыйкать» (көнчыгышча – «хак» яки «хакыйкате мотлак»). Бу, аларча, «гомуми рух», «рухи көл», «төп илаһи нур» дип тә тәгъбир ителә. Боларның хыялынча, гүя шул «абсолют хакыйкать» яки «төп рух» үзен галәм рәвешендә күрсәткән була. Шулай итеп, галәм һәм андагы төрле хадисәләр, аларча, тик шуның төрле сурәтләрдә күренүеннән башка нәрсә түгел, ягъни дөньяда кеше күзенә гәүдәләнеп, матди булып күренгән һәммә нәрсә һәм шулардагы һәммә хәрәкәт, һәммә эшләр ялгыз шул «төп бер барлык»ның ачылу-ялтыравыннан гыйбарәт. Болар, аның тик символлары гына. (Көнчыгышча – рәмез[8], тәмасил[9], мәзаһир[10]). Кеше рухы үзе

[1] Август Стриндберг (1849–1912) – швед язучысы, публицист. Хәзерге швед әдәбияты һәм театрына нигез салучы.

[2] Морис Метерлинк (1862–1949) – язучы, шагыйрь, фәлсәфәче, драматург, тәрҗемәче. Әдәбият өлкәсендә Нобель премиясе иясе (1911).

[3] Фридрих Ницше (1844–1900) – күренекле алман фәлсәфәчесе, иррационалист һәм модернист, «яшәү фәлсәфәсе»нә нигез салучы. «Яңа әхлак», «гадәттән тыш шәхес» идеяләрен үстерүче.

[4] Генрик Ибсен (1828–1906) – норвегияле драматург, шагыйрь һәм публицист.

[5] Владимир Сергеевич Соловьёв (1853–1900) – рус шагыйре, публицист, тәнкыйтьче. XX йөз башындагы «рухи яңарыш»ны нигезләүче. Николай Бердяев, Сергей Булгаков, Сергей һәм Евгений Трубецкойлар һ. б. дини фәлсәфәсе аның йогынтысында формалаша, Андрей Белый, Александр Блок һ. б. символист шагыйрьләр иҗатына да тәэсире зур. Тикшерүчеләр Вл. Соловьевны рус идеализмының иң күренекле вәкиле дип саныйлар.

[6] Валерий Яковлевич Брюсов (1873–1924) – шагыйрь, прозаик, драматург, тәрҗемәче, әдәбият белгече, тәнкыйтьче һәм тарихчы. Рус символизмы теоретигы һәм аңа нигез салучыларның берсе.

[7] Александр Александрович Блок (1880–1921) – шагыйрь, драматург, тәнкыйтьче һәм тәрҗемәче.

[8] Рәмез – символ.

[9] Тәмасил – охшашлык.

[10] Мәзаһир – тышкы гәүдәләнеш, тышкы күренеш.

дә – шул ук «төп рух» яки Алланың бер өлеше. Ул аннан коелган яки аннан аккан (эманация[1]). Дөньяда ул шуның гыйшкы һәм шуңа барып кушылу кайгысы белән газаплана. Ул гүя аларча, җисемдә-табигатьтә әсир.

Бу урында шул уңай белән, мәсьәлә тагын да ачылсын өчен, кеше «рух»ына карата Көнчыгыш символистлары белән рус символистлары арасында аларның үз сүзләре аркылы бер чагыштыру ясап үтик. Газали: «Кеше рухының төп урыны – Аллада. Ул шул урыннан килде һәм шунда кайтып китәчәк. Яки кешеләрнең рухлары – һәммә нурларның башы һәм диңгезе булган аллалык нурыннан аккан раббани бер нур алар», – ди. (Газалиның «Мишкәт әл-әнвәр»е һәм «Ихйа»сы[2]). Ибн Гарәби аны рус символистларының карашлары белән тагын да охшашлы иттереп һәм кеше «рух»ын кояш дип атап, түбәндәгечә күрсәтә: ««Рух» дигәнебез «Хак» диелгән илаһи рухтан кояш кебек ялтырап чыккан иде. Ләкин соңра ул шушы беренче чыгуында җисемгә (тело[3]) килеп бәйләнде. Бу хәл «рух» өчен бату булды. Бу кояш (кеше «рух»ын әйтә) берзаман үзенең батышыннан туып чыгачак; бу караңгылыктан котылып, тагын чынлап ялтырарга башлаячак» (М. Гарәбинең «Фөтухат»ы[4]). (Түбәндә Валерий Брюсовтан китерелгән «караңгылану-яктыру» тәгъбире белән чагыштырылсын). Ибсенның «Бранд»ынча[5] да «рух» – «Алла»дан алынган, аның охшашы булган нәрсә.

Соловьев фәлсәфәсен һәм аның шигырендәге төп мотивын аңлатучылар аны дөрес рәвештә түбәндәгечә күрсәтәләр: «Соловьев шигырьләренең төп мотивы табигатьне «дөньяви рух» иттереп карап,

---

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] «Ихйа голүм әд-дин» («Дин гыйлемнәренең яңаруы») китабында Газали гыйбадәт гамәлләрен шәрехли, дин гыйлемен дөньяви максатларга ирешү чарасына әверелдергән дин әһелләрен тәнкыйть итә. Аның фикеренчә, мөселманнан, остазыннан белем алганнан соң, иман һәм иҗат берлегенең хаклыгын аңлау өчен, фәкать шәхси тырышлык кына таләп ителә.

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[4] Ибн Гарәбинең «әл-Фөтухат әл-мәккийә» («Мәккә ачышлары») хезмәте турында сүз бара.

[5] Сүз Г. Ибсенның «Бранд» (1865) әсәре турында бара. Әсәрнең төп герое – рухани Бранд – кеше рухын, гомумән дөньяны коткаруны үзенең яшәү максаты итеп куйган идеалист.

аны мистик рәвештә баштан кичереп үткәрүдән гыйбарәт»[1]. «Философ һәм шагыйрь булу ягыннан күк нурын («илаһи нур» дигәннәрен әйтә) аның мондагы чиксез чагылу-ялтырауларында эчке сизү аркылы күзәтте һәм, Әфләтун[2] шикелле, шул чагылу-ялтыраулардан аларның төп чишмәсенә күтәрелде»[3], – диләр. А. Блок символист шагыйрь булу сыйфаты белән шигырь телендә болай аңлата: «Җир эче бер генә: ул да – чиксез бушлык (фәза – хаос[4])ның кочагында гыйшык белән сагышланучы һәм «җиһани акыл»ның серлеге эчендә калучы әсир ханбикәне (царевна[5]) – «дөньяви рух»ны азат итү эше. Җирдәге бөтен романтизм, искиткеч могҗизачылык – бу ялгыз әнә шул картинадагы хуш исле чәчәк. Мескен рыцарь (Соловьевны әйтә) җирдәге ташкын гыйшкыннан шул чәчкәне әсир ханбикәнең аяк очына куя. Безнең һәммәбез көч җиткән кадәр чиксез фәза (эре хәреф белән хаос[6] дип яза) тарафыннан әсир ителгән ханбикәне – дөнья рухын, шулай ук үз рухыбызны азат итү эшенә катышырга тиешбез. Безнең рухларыбыз – җиһани рухның бер өлеше»[7], – ди. Күрәсез, тел, аңлату яки тасвир башка, әмма төп мәгънә бер.

Символистларча, дөнья, гомумән, «сер» белән тулган. Анда һәрнәрсә серле, һәрнәрсә – символ. Кешенең гади дөнья тормышы, көнкүреш эшләре тик бер хыялдан яки төштән генә гыйбарәт (иллюзианизм). Кеше өчен аннан уяну, яктыру бар. «Абсолют хакыйкать» яки дөнья рәвешендә ялтыраучы «бер бар»ның үзе дә, боларча, матурлык һәм мәхәббәттән гыйбарәт. Дөнья гүя аларча шуның мәхәббәте белән тулган, ул гүя һәр нәрсәнең шуңа булган гыйшкы белән әйләнә. Дөньяда нинди генә бер матурлык булмасын, ул – шул ук «бер бар»ның («рух»ның) матурлыгы, шуның матурлыгының символы. Шуның өчен, аларча, хатын-кызларның матурлыкларында, шуларның мәхәббәтләрендә дә әлеге «бер бар» яки «абсолют

---

[1] «Сборник первый о Владимире Соловьеве», стр. 28. Булгаков мәкаләсе. *(Авт. иск.)*

[2] Платон (б. э. к. 428/427 яки 424/423 – б. э. к. 348/347) – борынгы юнан фәлсәфәчесе.

[3] Шул ук җыентык – стр. 50, И. Трубецкой. *(Авт. иск.)*

[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[5] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[6] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[7] «Сборник первый о Владимире Соловьеве», стр. 95–103. А. Блок. *(Авт. иск.)*

хакыйкать»нең матурлыгы хыял кылына. Гүя алар (хатын-кызлар) – шуның мәхәббәтенең символы.

Көнбатыш һәм көнчыгыш, бигрәк тә рус символизмының икесенең дә (кайбер тәфсилләрендә һәм терминнарында аерымлыклар булу белән бергә) төп карашлары әнә шул нокталарга җыела. Монда шуннан артык озын-озак сөйләп утыруның кирәге юк. Алар турында киң танышасы килгәннәр китапның ахырында күрсәтелгән чыганак (мәнбәгъ)ларга карый алалар.

Шулай да иллюстрация өчен чыгтай, азәрбайҗан, госманлы һәм рус символизмыннан бу урында берничә мисраг китереп үтү файдасыз булмас.

XV йөздәге чыгтай символизмының мәшһүр классик шагыйре Нәваи символистларның дөнья турында югарыдагы карашларын болай дип тасвир итә:

Кылды мәзаһирдә хыял зоһур,
Тапкалый ул хөсне кәмале зоһур.
Җәлвәи хөснеңә юк ирди хәд,
Күзгү кирәк булды аңа бигадәд.
Ачты бу гөлшанны, ки: рәңин ирер,
Һәр гөл аңа айнәи чын ирер[1].

Татарчасы: «Шушы күренә торган нәрсәләрдә (дөньяда) хыял күренде. Ул матурлык үзенең төгәл-җитлекле күренүе өчен шулай эшләде. Матурлыгының ялтыравына чик юк иде. Шуның өчен аңа чиксез көзге кирәк булды. Кара, нинди матур, зиннәтле бакчаны ачты бит ул. Андагы һәр гөл – аның өчен бер көзге бит».

(Китапның икенче бүлемендә татар символистларыннан Дәрдмәндтән китерелгән шул ук мәгънәдәге мисалларга да кара.)

Нәваи тагын аны, ягъни югарыдагы юлларында күрсәтелгән «абсолют хакыйкать»ләрен аның шул «көзге»се аркылы болай дип сыйфатлый:

---

[1] «Хәмсәи Нәваи», гыйльми яктан караганда, төрк халыкларының иске әдәбиятларыннан китерелгән мисаллар үз имлалары белән китерелергә тиеш иде. Ләкин без бу турыда практик якны, ягъни хәзерге укучылар күпчелегенә укырлык булсын өчен, белә торып, яңа имла белән алдык, ләкин сарфи формалары үзгәртелмәде. *(Авт. иск.)*

Гаҗәп сурәт ки бер нәкъкашы маһир,
Булып йөз нәүгъ сурәт берлә заһир,
Үзе нәкышь вә үзе мәнкушы нәкъкаш,
Кеше бу сүзне миндик кыйлмады фаш.
Нитәй: әсраридин дивана булдым,
Дидем: чөн һушидин бигянә булдым.

Татарчасы: «Искиткеч бер сурәт бит бу (дөнья). Оста бер бизәүче (нәкышьче) анда йөз төрле сурәт белән күренә. Ул үзе бизәк (нәкышь) тә, бизәүче дә (нәккаш), бизәмеш тә (мәнкуш). Кеше бу сүзне минем шикелле фаш итмәгән итүен, нишлим соң: аның серләреннән дивана булдым да фаш иттем шул, чөнки аның һушыннан мин үземне үзем югалттым, онтылдым».

Нәваидән элек, аның ук шөһрәте Һират шәһәреннән чыккан мәшһүр Лотфи, бер матур хатынны Алланың матурлыгыннан символ итеп, аны болай мактаган иде:

Ул, ки хөсен итте бәһанә илне җәйда кыйлгалый,
Көзкүдик кыйлды сине, үзене пәйда кыйлгалый.
Әй хөсни! Җәмал әһле – хадимнәр вә солтан син.
Инсан сыйфаты берлә сурәте рахман син.
Хөсен ичрә шәригең юк, йөз хөҗҗәте рушан ирер:
Ул дәгьва-и вәхдәткә бу вәҗһе илә борһан син.
Кадд вә агызыңызга баксам, «аһ» дир мин,
Сине күргән саен «Аллаһ» дир мин.

Татарчасы: «Ул матурлык («илаһи матурлык» дигәннәрен әйтә), үзенең матурлыгы белән сагышландырып акылдан яздыру өчен, илне шуңа сылтау кылды. Үзен күрсәтү өчен, сине көзге итте: «Әй матуркай! Матурлык сөючеләр синең алдыңда хезмәтче, ә син аларның солтанысың. Матурлыгыңда тиңдәшең юк. Моның йөзләрчә дәлиле ачык. «Барлык бер генә» дигән дәгъваның («вәхдәте вөҗүд» – пантеистлык дәгъвасының) дөреслеген күрсәтү өчен, син үзең дәлилсең. Гәүдә һәм авызыңа карасам, «аһ» димен. Сине күргән саен «Алла» димен». (Бу шигырьне укыганнан соң, сөйгәнен «Алла» диюче мәшһүр татар шагыйре С. Рәми[1] һәм башкаларның шигырьләре искә төшәргә бик мөмкин.)

[1] Сәгыйть Лотфулла улы Рәмиев (1880–1926) – шагыйрь, драматург, прозаик, журналист, публицист, тәрҗемәче, театр белгече.

Инде азәрбайҗан-госманлы символизмының атасы – классик Фөзүлине тыңлыйк. Ул әүвәл галәм турындагы карашын: «Әй гафил, галәм – ул үзендә Алланың сыйфатлары күренә торган бер сурәт. Ул – үзендә чиксез тәмнәрнең нурлары ялтырый торган күренеш. Мондагы һәр күзгә гайб[1]-сер дөньясыннан аерым булмас. Серлелектән өлеше булмаган кеше сер дөньясының яшеренлекләренә дә ирешә алмас», – дип билгеләп куйганнан соң, болай дип җырлый:

Дәрк әйләде гонҗәи рәмзе вә имаэ,
Гөл адына ачды биң мөгаммә.
Бәндә әшкар улан сәнсән,
Бән худ йукым, ул, ки вар: сәнсән.
Даим сәңа бәндәдер тәҗәлла,
Бән гайредән улмышым тәсәлла.
Рухым, ки бәндәдер: сәнеңдер
Һәр нәсә, ки бәндер: сәнеңдер.
Чөн бән улубым сәнеңлә мәмлү,
Вәхдәт рәвешендә хуш дәгелдер бу.

Татарчасы: «Шул символ (рәмез) һәм ымлау гөнҗәләрен кара әле: ничек ул аны чиксез нечкәлек белән төшенеп эшләгән. Гөл исеме белән мең төен (мөгаммә) ачкан бит». «Миндә күренүче – синсең, мин юкмын, бар булган нәрсә – синсең. Син һәрвакыт миндә ялтырыйсың, мин – башкадан юанам. «Миндәге рух – синеке»[2]. Миндә нинди хәл, нинди кәеф булса, ул да синеке. Чөнки мин синең белән тулганмын. Берләшү рәвешендә бу яхшы түгел инде түгелен дә…»

Төрк халыкларының символист шагыйрьләреннән (бигрәк тә тагын азәрбайҗан символистларыннан Кауси[3] һәм башкалардан, шулай ук төрекмән шагыйре Мәхтүм Колыйдан) мондый мисалларны бик күп китерергә була. Ләкин безгә иллюстрация өчен бу урында алардан шул кадәресе дә бик җиткән (татар шагыйрьләреннән мисаллар түбәндә үз бабларында китереләчәкләр). Инде, тик бу урында шулар белән чагыштыру өчен, рус символистларыннан берәрсен

[1] Гайб – яшерен әйберләр, билгесезлек.

[2] Шундый ук сүзне казак шагыйре Мәгъҗан Җомабаевта да күрәбез. *(Авт. иск.)*

[3] Кауси Тәбризи – XVII йөз башында иҗат иткән азәрбайҗан шагыйре.

тыңлап үтәргә тиешбез. Моның өчен дә Владимир Соловьевның түбәндәге юлларын китерәбез:

Милый друг, иль ты не видишь,
Что все, видимое нами, –
Только отблеск, только тени
От незримого очами?
Милый друг, иль ты не чуешь,
Что одно на целом свете –
Только то, что сердце к сердцу
Говорит в немом привете?[1]

Бу юлларның бөтенесен дә хәрефкә-хәреф татарчага тәрҗемә итеп торуга хаҗәт юк. Төп мәгънә ачык: «Безгә күренгән нәрсәләр һәммәсе дә – күзгә күренмәгәннең ялтыравы, шуның күләгәсе. Бөтен дөньяда ялгыз бер нәрсә бар. Ул да – күңелнең күңелгә ымлап сөйләгән сәламе», – дигән сүз.

Без, югарыда көнчыгыш һәм көнбатыш символизмын берләштергән үзәк нокта – мистикачылык һәм шуның ук нәтиҗәсе булып пантеизм, идеалистик монизм, дигән идек. Моның шулай икәнен турыдан-туры символистларның үзләреннән алынган мисаллар аркылы да күрдек. Менә шуңа тагын болар арасында уртак хосусият итеп дүрт нәрсәне кушарга кирәк. Алар да шулар: 1) символизмның «яңа дин» рәвешендә күрсәтелүе, 2) шагыйрьләрнең, үзләренә пәйгамбәрлек сыйфатында карап, символлы аһәңле тезмәләр, гомумән, символлы шигырьләр тудыруны гадәттән тыш, ягъни «илаһи – серле» бер эш дип караулары, 3) символистлардагы индивидуалистлык, ахырда, 4) өслүбнең символлардан төзелгән булучылыгы.

Беренче мәсьәләне ачыйк. Яурупа, бигрәк тә рус символизмы, сәнгать булу белән бергә, дин дип тә танылды, ягъни рус әдәбиятындагы яңа символизм (икенче буын символизм) үзен сәнгать дип кенә түгел, бәлки дин дип тә игълан итте[2].

Символизм теориячеләреннән Вячеслав Иванов символизмның символларга нигезләнгәнен, символларның да мифтан гыйбарәт булуын әйтү белән бергә: «Шулай, дин һәрнәрсәдән элек бөтен бар-

[1] *Хезмәттә рус әдәбиятыннан китерелгән мисаллар барысы да кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] Г.Е. Горбачев «Капитализм и русская литература» 1925 г., стр. 131. *(Авт. иск.)*

лыкның, шулай ук һәртөрле хәятның мәгънәсен хис итү-сизүдән гыйбарәт булу ягыннан, чын символизм сәнгате дин өлкәсенә тоташа», – ди. Шуның өстенә ул, символизмны икегә бүлеп: «Идеалистик символизм (беренче буын символизмны әйтә) – нечкәрүчеләрнең интим сәнгате (интимное искусство[1]), реалистик символизм исә – дөньяның һәм дөньядан тыш дини әсәрләрнең яшеренлекләрен күрүнең серле сәнгате», – дигәнне куша. В. Ивановның бу игъланы, һичшиксез, В. Соловьевның дини-фәлсәфи тәгълиматына нигезләнгән, ягъни икенче буын рус символизмының «реалистик символизм» дип «яңа дин» рәвешендә болай ачык куелуы Соловьевның «рухлар дөньясы»н реаль һәм конкрет дөнья дип каравы, шулай ук аның «чиркәү тантанасы» турындагы тәгълиматы белән нык бәйләнешле. Чөнки чиркәү һәм теократик (дини-рухани) берләшү Соловьевның дини фәлсәфәсенең дә, аның шигырьләренең дә үзәгендә утыра. «Чиркәү хакыйкате»нең тантанасы аркылы кешенең сафлануы, илһамлануы белән ул бөтен барлыкның яңаруын, яңадан тууын хыял кыла[2].

Көнчыгышта да без тәсаувыфның һәм гомумән көнчыгыш символизмының гүя «яңа дин» рәвешендә тудырылганын, аны тудыручылар яки аларга каршы булучылар тарафыннан шулай дип аңланганын күрәбез. Ул төбендә Коръән, ягъни Мөхәммәт тәгълиматы белән ярашырлык түгел иде, яки ул шуны үзгәртүдән гыйбарәт иде. Чөнки Мөхәммәт тәгълиматы дуализм карашынча утырган булса, тәсаувыф монизм карашын алды. Кеше белән Алланы берләштерде, кешедә Алла күрде яки Алланы кешегә иңгән итеп таныды. Кыскасы, тәсаувыф аркылы Мөхәммәтнең «шәригать» диненә каршы гүя «хакыйкать» дине мәйданга чыгарылган булды. Берсендә (Мөхәммәт тәгълиматында) – акыл, икенчесендә (тәсаувыфта)

---

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] Ул романнарда болай сәнгатьне дә дин рәвешендә игълан итү мәртәбәсендә дингә нык бәйләнү рус иҗтимагый фикерендә, гомумән, күзгә нык ташланырлык бер төс алган иде. Шул ук заманнарда, хәтта, икенче яктан, социалист-большевиклар эченнән кайбер атаклы затларның да богостроительство һәм богоискательство юлына кереп китү шикелле аяк таюлары булды. Бу хәл рус символистларына идеологик яктан тагын да куәт бирә торган бер хәл иде. (Бу турыда Е.М. Ярославскийның «Краткие очерки по истории ВКП(б)» дигән әсәренең бүлегенә – 18–19 битләр, шулай ук «Большая Советская Энциклопедия»нең «Б» хәрефендә 593–595 битләренә карарга мөмкин. *(Авт. иск.)*

күңел (калеб) нигез ителде, хәтта турыдан-туры һәм төгәле белән Мөхәммәт тәгълиматын тотучылар, үзләрен тәсаувыф ияләреннән аеру өчен, «шәригатьче» («шәригать әһелләре») дип йөрттеләр. Тәсаувыф ияләре дә, үзләрен тегеләрдән аеру өчен, «хакыйкатьче» («хакыйкать әһелләре») дип аталдылар. (Шул ук тәсаувыф ияләре тегеләрне – «тышкы эшләрнең кешеләре» мәгънәсендә «әһле заһир» дип, үзләрен янә «эчке эшләрнең кешеләре» мәгънәсендә «әһле батыйн» дип тә йөрттеләр). Шуңа тагын намаз, руза, хаҗ һәм башкалар шикелле Мөхәммәт тәгълиматының нигезләреннән яки рәсми гыйбадәтләреннән тәсаувыф ияләренең үзләрен азат дип санауларын, андый гыйбадәтләргә тик гавам өчен генә кирәкле нәрсәләр дип карауларын кушарга кирәк. Шуның өчен дә ислам көнчыгышында «шәригатьчеләр» белән «хакыйкатьчеләр» арасында зур дошманлык, каршылык һәм көрәш барды. «Шәригатьчеләр», ягъни Мөхәммәт тәгълиматының юристлары («фөкаһа – фәкыйһләр») «хакыйкатьчеләр»не һәм шуларның юлындагы шагыйрьләрне юлдан язган – дәһри, зиндыйк (еретик[1]) дип гаепләделәр. Патшаларга баш орып, аларны утка яндыртты, суктыртты яки таш белән аттырып үтерттеләр[2]. Хәтта ислам тарихчылары эчендә хөр фикерле, мәсьәләгә киңрәк карашлы булган Ибн Хәлдун да суфиларның сул канаттагыларын («шәригатьче» булмаганнарын) күрә алмый. Ул: «Соңгы суфилар кәшеф[3] турында да, биш сизү әгъзасыннан тыш булган нәрсәләр турында да сөйли башладылар. Аларның күпләрендә Алланың кешегә иңүе һәм абсолют берлек турында да сүзләр таралды», – дигәннән соң, шуңа: «Болар шигыйларны (Галидә[4] һәм мөселманнарга башлык итә торган кешеләрдә, ягъни хәлифә – «имам»нарда аллалык күрүче иранлыларның) сүзләре белән сугарылдылар һәм диндә азгынлыкка чумдылар», – дигәнне куша. Шулай ук тәсаувыф ияләренең «пәйгамбәрлек» һәм «хакый-

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] Ибн Хәлдунның «Мөкаддимә»сендә пантеист һәм монист суфиларның үтерелүләре һәм шуны хаклы табып, шуңа шәригать юристларының, фәкыйһләренең фәтва бирүләре турында ачык мәгълүмат бар. 292 биткә кара. *(Авт. иск.)*

[3] Кәшеф – ачык беленмәгән бер нәрсәне табып мәйданга чыгару.

[4] Гали ибн Әбү Талиб (600–661) – гарәп хәрби һәм сәяси эшлеклесе, 656–661 елларда идарә иткән дүртенче хәлиф. Мөхәммәд пәйгамбәрнең икетуган энесе, аның кызы Фатыйманың ире һәм якын сәхабәсе. Шигыйлар Галине беренче имам һәм изге дип хөрмәтлиләр.

кать»не «вәлилек» (әүлиялык) исеме астында яңартырга кирәклек фикерендә булганлыкларын яза. Шундый караш ияләреннән һәм шагыйрьләр эченнән Мөхеддин ибн Гарәби һәм башкаларны саный («Мөкатдимә»се, 191–192 һәм 281 нче битләр). Дөрес, суфилар һәм суфи шагыйрьләр эчендә дә «шәригатьчеләр» юк түгел (Ясәви һәм башкалар кебек). Ләкин аларның булуы югарыдагы фикерләргә каршы килми. Без андый уң канат суфилар түгел, сул канат суфилар турында сөйлибез. Хәтта сул канат суфилардан: «Бар нәрсәләрнең барлыгы – бар итүченең нәкъ үз барлыгы – аннан башка да түгел, аерым да түгел»[1], – дип, Мөхәммәтнең нигез тәгълиматларына каршы юл тоткан М. Гарәби: «Нәсаралар (христианнар)ның мөэмин түгеллеге Гайсәне Алла дип белүләрендә түгел, бәлки кешеләр эченнән ялгыз аны гына Алла дип тануларындадыр[2]», – диюгә кадәр барып җитә; шуның белән Мөхәммәт (Коръән, хәдис) тәгълиматы белән ике арадагы каршылыкны тагын да ачыкландыра.

Кыскасы, көнчыгыш символизмы – Яурупа һәм рус символизмы шикелле үк, юнан фәлсәфәсен көнчыгыш диннәренең (зәрдәшт, будда һәм башкалар) фәлсәфәләре белән берләштереп, шуны мөселманлык буявы белән төсләндергән (Яурупа-рус символистлары аны христианлык белән төсләндерәләр), ягъни неоплатонизмлы үзенә башка бер дин рәвешендәге бер сәнгать иде.

Югарыда без Яурупа символизмы өчен мисалга Метерлинк белән Ибсенны күргәзешле кылып[3] алган идек. Менә боларның иҗатларында да чиркәүчелек – дин сыйфаты бар. Бу урында без, тәфсилгә кермичә, тик яурупа әдәбиятларын тикшерүче специалистларның шулар турындагы фикерләрен китерү белән генә канәгатьләнәбез. Шулар эченнән профессор Коган, Метерлинкның реаль дөньяны хурлап, аңа башка булган дөньяны хөрмәтләгәнлеген, аның чиркәүдән аерыла алмаганлыгын[4] һәм башка аның пантеистлыгын күрсәтә торган (безнеңчә) сыйфатларын әйткәннән соң, аңа шундый характеристика бирә: «Символизм драмасы, гомумән, символизм

[1] Ибн Гарәбинең «Фөтухате мәккийә»се. 4 нче том, 393 нче бит. *(Авт. иск.)*

[2] Петр Позднев – «Дервиши в мусульманском мире» 1886 г., Оренбург, стр. 103. Малькольмнан күчерә. *(Авт. иск.)*

[3] Күргәзешле кылып – күрсәтеп, мисал итеп китереп.

[4] П.С. Коган – «Очерки по истории западно-европейской литературы», т. II, стр. 388–397 и т. III, стр. 131–154. *(Авт. иск.)*

шигыре шикелле үк, фәлсәфи яки дини илһамлану өчен юл булырга тели. Бу драма позитив дөрес белемнәрнең ирешә алмаган хакыйкатьләрен ачарга омтыла», – ди.

Иҗаты Иранның Зәрдәш хәким фәлсәфәсенә тоташкан һәм Ницше тәгълиматыннан бирелгән дым белән үскән, кешедә кешедән өстен булганны (сверхчеловек) күрүче Ибсенның «Бранд» дигән әсәренең каһарманы (шул ук Бранд) түбәндәгечә сыйфатлана: «Тамыгсызлык[1] вәгазьчесе, христианлыкның традицион Алласын яклаучы; ул – чыннан да, Алла өчен сугышучы һәм эгоизм пәйгамбәре. Һәрнәрсәдән өстен торган шәхесне булдыру идеясе, аның карашында, Ницше тәгълиматындагы шикелле үк, кешелекнең зур бер алга барышы дип исәпләнә, шул фикергә тоташа»[2]. Бу характеристика белән шул ук Ибсенның үзенә характеристика бирергә теләнә.

Яурупа әдәбиятларын марксизм нигезендә яңадан тикшерүче профессор Фриче Ибсенны шәһәрнең вак буржуа укымышлылары идеологиясен тәгъбир итүче дин тотуы белән бергә, аның Брандын мещан җәмгыятенең (священник[3])ы (руханисы) дип сыйфатлый[4]. Шул рәвешчә, яурупа символизмында да дингә тоташу тамыры бар. Ул да үзендә дин булу сыйфатын күрсәтә.

Инде символистларның үзләрендә пәйгамбәрлек сыйфаты күрү мәсьәләсенә күчик. Башлыйк тагын Көнчыгыштан. Көнчыгышның «хакыйкатьчеләр»ендә (тәсаувыф ияләрендә) һәм символизм шагыйрьләрендә «пәйгамбәрлек» дәгъвасы юк-югын, ләкин шуңа якын булганы һәм аннан ашып киткәне бар. Алар, үзләренә «вәлилек»[5] яки «әүлиялык» сыйфатын тагып, пәйгамбәрләр шикелле үк «вәхи»гә[6] ия булучылыкны дәгъва итәләр. Ибн Гарәби карашынча, пәйгамбәрләргә килә торган «вәхи» – тик шәригать китерү турындагы «вәхи» генә, бу аларга хас. Әмма аннан башка төрле «вәхи»ләрнең пәйгамбәрләрдән башкаларга да булуы бик мөмкин. Мондый тип «вәхи» ияләре югарыда әйткәнебез «вәлилек» сыйфаты белән сыйфатланалар. Хәтта М. Гарәби үзенең «Фөтухат» исемле тәса-

[1] Тамыгсызлык – юмартлык.
[2] П.С. Коганның югарыда күрсәтелгән әсәре. *(Авт. иск.)*
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[4] Фриче – «Очерк развития западных литератур», стр. 206–208. *(Авт. иск.)*
[5] Вәлилек – изгелек.
[6] Вәхи – берәр фикерне Алла тарафыннан пәйгамбәрнең күңеленә салу.

увыф фәлсәфәсеннән гыйбарәт булган китабын һәм, гомумән, бөтен язганнарын: «Алланың имла итеп торуы белән язамын», – ди («Фөтухат»). Боларның бик ашырып җибәргәннәре пәйгамбәр генә түгел, бәлки үзләрен Алла дип тә саный башлыйлар. (Индивидуализм турында сүз барганда, бу яклары күрсәтелер.)

Рус символист шагыйрьләре исә үзләрен «шагыйрь-пәйгамбәр» итеп таныталар. Александр Блок ачыктан-ачык: «Без пәйгамбәрләр идек, шагыйрь булырга теләдек», – ди. Шул ук символист В. Соловьевны «рыцарь-монах» дип таныткannan соң, хәтта аны пәйгамбәрлектән дә өстен итеп сыйфатлый: «Ул, – ди, – саф рух, дөресе, терек кеше түгел, бәлки шуның сурәте, очерк, символ, сызгылама (чертеж[1])»[2], – ди. Шуңа тагын беренче буын символистларның (Мережковский[3], Гиппиус[4], Сологуб[5] һәм башкалар) үзләренә ничек карауларын, хәтта аларның да үзләрен Алла дип санау мәртәбәсенә күтәрелүләрен кушарга кирәк. Беренче буын рус символизмының беренче теориячесе Валерий Брюсов[ның]: «Аңла, аңла, бөтен яшеренлекләр бездә; бездә караңгылану һәм яктыру бар»[6], – дигән кебек сүзләре пәйгамбәрлек булмаса да, һәрхәлдә, көнчыгышның әүлиялык сыйфатына охшаш бер сыйфатны күрсәтә. Сологубның: «Мин яшерен дөньяның алласымын, бөтен дөнья минем хыял (мечта[7])ларымда»[8], – дию бу турыда аларның үзләренә карашларын тагын да

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] А. Блок – «О символизме», 1921 г. (Аерым брошюра). *(Авт. иск.)*

[3] Дмитрий Сергеевич Мережковский (1865–1941) – язучы, шагыйрь, тәнкыйтьче, тәрҗемәче, тарихчы, дини фәлсәфәче һәм җәмәгать эшлеклесе. Рус әдәбиятының Көмеш гасыры вәкиле, рус символизмына нигез салучылардан берсе.

[4] Зинаида Гиппиус (1869–1945) – шагыйрь, язучы, драматург һәм тәнкыйтьче. Рус әдәбиятының Көмеш гасыры вәкиле. Җәмәгате Дмитрий Сергеевич Мережковский белән символизм идеологларыннан саналалар.

[5] Федор Кузьмич Сологуб (Тетерников; 1863–1927) – шагыйрь, язучы, драматург, публицист һәм тәрҗемәче. Рус символизмының күренекле вәкиле.

[6] Шигырь юллары В. Брюсовның «Царю северного полюса» (1899–1900) әсәреннән тәрҗемәдә китерелә: «Пойми – весь мир, все тайны в нас, / В нас Сумрак и Рассвет».

[7] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[8] Шигырь юллары Ф. Сологубның « Я – бог таинственного мира» (1896) әсәреннән тәрҗемәдә китерелә: «Я – бог таинственного мира, / Весь мир в одних моих мечтах».

ашырып җибәрә. (Татар символистларыннан С. Рәми һәм Такташта, казаклардан М. Җомабаевта[1] да шул ук хәл.)

Үзләренә шул ук гадәттән тыш кеше итеп карауларының нәтиҗәсе булып, алар каршында символлы, аһәңле шигырьләр иҗат итү эше «серле-илаһи» бер эш яки «сихерле» бер нәрсә санала. Рус символистларында шулай булган шикелле, бу хәл көнчыгыш символистларында да шулай. Бу турыда башкалардан (яурупа һәм рустан) мисал китереп тормастан (чөнки алар мәгълүм), тәсаувыф теориячесе символист философ шагыйрь Ибн Гарәбидән һәм азәрбайҗан-госманлы әдәбиятыннан бер-ике мисал китерү мәсьәләне ачыкландыру өчен җитә. Ибн Гарәби: «Барлык дөньясындагы сүзләр, кирәк чәчмә, кирәк тезмә булсыннар – һәммәсе дә шул ук «бер бар» («абсолют хакыйкать»)нең сүзләре», – ди. Бу сүзе белән ул тәсаувыф ияләренең сүзләре серле-илаһи булганлыкларын, ягъни Алла сүзе икәнен аңлатырга тели.

Фөзүли әүвәл үзенең шагыйрьлегенең гадәттән тыш бер эш булуын, «кодрәт куллы» бер шагыйрь икәнен болай күрсәтә: «Кодрәт кулым (башкалар ярата алмаганнарны яратучы – тудыручы кул дигән сүз) шигъри иҗатлардан дөнья гөмбәзенә һәрвакыт йолдызлар асып куяр иде»[2], – ди.

Аннан соң болай дип көйли:
Әшгарә яман дип усанма.
Сәрмаяи назымы сәһел санма.
Сүз гәүһәре хизанәи дил,
Изһары сыйфаты кабил.
Җан – сүздер, әгәр билирсә инсан,
Сүздер, ки дирләр үзгәдер җан.
Лазем бәңа кәлде хифзы канун,
Забты носкы кәламе мәүзүн.
Бән шагыйрь Мусави кәлмем,
Сахирләрә могҗизе тәмамым.

Татарчасы: «Шигырьгә начар карама. Тезмә сүз тудыруның сәрмаясен[3] табуны җиңел дип исәпләмә. Сүз ул – күңел хәйләсенең

[1] Мәгъҗан Җомабай (1893–1938) – казак шагыйре, публицист. Яңа казак әдәбиятына нигез салучыларның берсе.
[2] «Фөзүли» мәҗмугасы, 1925, Баку. *(Авт. иск.)*
[3] Сәрмаясен – *биредә:* мөмкинлеген, шартларын.

җәүһәре, сүз белән аның («хак»ны әйтә) сыйфатын ачарга була. Кеше белергә тели икән – белсен: җан дигәнең үзе сүз ул; сүзне аны үзенә башка бер җан, диләр. Миңа канунны саклау тиеш булды. Миңа тезмә сүзнең матур тезелүен кулга алу, беркетү тиеш булды. Мин – Муса сүзле (Муса пәйгамбәрне әйтә) шагыйрьмен. Сихерчеләрне мин бу турыда бөтенләй аптыраштa калдырырлыкмын», – дигән сүз.

Госманлы символист Зыя Паша (XIX йөз шагыйре) остасәнгатьле тезелгән сүзен һәм үзен болай сыйфатлый:

> Һәр җөмләи вәсигадә мәбсут биң вөҗүд,
> Һәр кыйтгаи фәсыйхәдә мәшһүд биң җиһан.
> Каләме назым вә бәлягатьтә Сөләймандыр Зыя,
> Пармагында ханымы сихер вә бәяны дүндерер.

Татарчасы: «Һәрбер киңәйтелеп төзегән җөмләдә мең барлык җәелгән. Һәрбер оста төзелгән кисәктә мең җиһан күренә». «Тезмә сүз дөньясында һәм аны мәгънә ягыннан җиренә җиткереп кистереп әйтүдә Зыя – Сөләйман ул (Сөләйман – пәйгамбәр дигән сүз). Ул үзенең бармагында сихерле сөйләүнең матурлыкларын биетә».

Хәзер өченче мәсьәләгә – индивидуализм мәсьәләсенә күчик. Яурупа (Метерлинк, Ибсен, Ницше) һәм рус символизмының беренче буынында (Мережковский, Гиппиус[1], Сологуб һәм башкаларда) индивидуализм соң дәрәҗәдә көчле, хәтта, югарыда күрелгәнчә, профессор Коган тарафыннан Ибсен «эгоизм пәйгамбәре» дип сыйфатлана. Аның үзенә-үзе чиксез табынган каһарманы Бранд анасына: «Үзеңне-үзең эзләп тап, аннан соң ул ничек булып күренсә дә, шул үзеңнең табылган “мин”ең өчен чигенәчә көрәш», – ди. Кыскасы, кешедә кешедән өстен булганны (сверхчел.[2]) күрү яки кешене табигатьтән өстен бер бар итеп чыгару белән бергә, үзеңә бирелү, тик үзең аша «мәңгелек»кә бару – менә Ибсенның төп юнәлеш ноктасы шул. «Мин» – анда һәрнәрсә. Рус символисты Сологуб исә хәтта үзен, югарыда күргәнебезчә, Алла дип саный.

Көнчыгыш символизмында, ягъни тәсаувыфта һәм тәсаувыф шагыйрьләрендә менә шул сыйфат бармы? Бу урында мәсьәләнең әнә шул ягын карыйк. Тәсаувыфта һәм тәсаувыф шигырендә (ягъни

---

[1] Чыганакта «Гиппиусов».

[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

көнчыгыш символизмында) соңгы нәтиҗәдә кешенең «мин»леге үтерелүгә, Хак (Алла) гыйшыгында янып, бөтенләй аңа йотылуга («фәна» булуга) алып барыла дип караучы тикшерүчеләр аз түгел. Дөрес, тәсаувыфта ул бар, ләкин ул анда гомуми хәл түгел. Чөнки тәсаувыфның теория башлыклары (Газали кебекләрдән башкалар) һәм көнчыгыш символизмының зур шагыйрьләреннән байтаклары аның киресен күрсәтәләр, ягъни көнбатыш һәм рус символистлары дәрәҗәсендә үк чиксез индивидуализмга күтәреләләр, хәтта үзләрен үзләре Алла дип масая башлыйлар. Бу исә – шәхеснең үтерелүе, Аллада йотылуы түгел, бәлки чиксез кабартылуы, Алланы үзенең «мин»ендә йоттыру. Мәсәлән, үзенең шундый сыйфаттагы «мин»леге өчен утка яндырылган яки таш белән аттырылып үтерелгән (көнчыгышта мондыйлар аз түгел) Мансур Хәллаҗ[1] кебек «Мин Хакның – Алланың үземен» мәгънәсендә «әнә әл-Хак» диючеләрне аз очратмыйбыз. Шул ук тәсаувыф башлыгы Баязит Бәстами[2] (875 миладида вафат) «Сөбхани! Мә әгъзам сәни», ягъни «Үземне үзем олылыймын, мин һәммә нәрсәдән зурмын, өстенмен» дип, үзенең «мин»ен һәммә нәрсәдән өстен куя. Хәтта уң, ягъни «шәригатьче» суфиларның башлыкларыннан Ясәвидә дә без: «Атым – Рахман, затым – Сөбхан, бер нәзарда батыйннарын саф кылдым» («Исемем дә, затым да – Алла, бер карауда күңелләрен тазарттым да куйдым» дигән сүз) дию дәрәҗәсендә «мин»челекнең «Алла»лык дәрәҗәсендә үстерелгәнен күрәбез. Гомәр Хәйям[3] кебекләрдә бу хәл, ягъни «мин»челек, эгоизм бөтенләй соң чигендә. М. Гарәбидә дә моны

[1] Әбү әл-Могыйс әл-Хөсәен бине Мансур әл-Бәйзави (Мансур Хәллаҗ; 858–922) – суфи, шагыйрь. Ислам тарихында «Әнә әл-Хак» (Мин – Хак) дигән сүзләре белән билгеле. Вәгазьләре һәм фәлсәфи чыгышлары өчен үлем җәзасына тартылган.

[2] Әбү Йәзид (Баязит) Тайфур ибн Гайсә Бәстами (804–875) – күренекле суфи. Ул кешенең «мин»е Илаһияттә «эреп» югала дип саный, әлеге халәтне «фәна» дип атый. Аныңча, Илаһияткә кушылган шәхес аның сыйфатларына ия була башлый. Бәстами карашлары тәнкыйтькә очрый, аны Аллага әйләнү (холүл) идеясен таратуда гаеплиләр.

[3] Гомәр Хәйям (якынча 1048–1122) – фарсы-таҗик шагыйре, математик, фәлсәфәче. Поэтик әсәрләр, фәлсәфи һәм математик трактатлар, шулай ук робагыйлар авторы буларак мәгълүм. Әсәрләрендә яшәүнең мәгънәсе турында тирән уйланулар, хакыйкатькә омтылыш, икейөзле кешеләрне фаш итү һ. б. идеяләр хас. Робагыйлары Коръәннән алынган өземтәләргә бай, теле ачык, сурәтләүләр һәм символлар күп. Хәйямның шигырьләре дөньяның күп кенә телләренә тәрҗемә ителә.

югарыдагы бөтен сүзләреннән ачык күрә килдек. Җәлалетдин Руми, Җамиларда да бу бар. Гомумән, суфиларның үзләрен «вәли» дип исәпләүчеләрендә «мин»челек тагын да көчле.

Татар символистларыннан С. Рәми һәм Такташта янә «мин»челек «мин – Алла»чылыкта күтәрелә. Казактан М. Җомабаевта да шул ук хәл. Әмма икенче буын рус символистлары үзләрен индивидуализмга – «мин»челеккә каршы күрсәтәләр. «Без»че булуга тырышалар, ләкин боларның «без»челеген, югарыдагы сүзләреннән дә аңлашылып торганча, матди-иҗтимагый «без»челек түгел, бәлки рухлар «без»челеге (коллективчылык) дип аңларга кирәк. Бу яклары белән алар көнчыгыш тәсаувыфчыларының икенче бер өлеше белән бер сафта тезеләләр, хәтта В. Соловьев бөтен терек кешеләрнең һәм үлгәннәрнең «рухлар»ын берләштерү-оештыру аркылы (ул үлгәннәрнең рухы белән кушылу-аңлашуның реаль-вакыйгый булуына ышана) «үлемне үлем сугышына чакыра», ягъни бөтен «рух»ларның берләшүе аркылы хәтта бөтен кешелекне үлем куркынычыннан коткарырга хыяллана. Аның философлык һәм шагыйрьлек ягыннан дөньядагы бөтен эше шул.

Көнчыгыш суфиларында да үлемнән, үлем белән кешенең бөтенләй юкка чыгуыннан, бетүеннән курку бар. Алар да шуннан котылуның юлын эзлиләр, үлемсезләнергә тырышалар. Моның өчен дә аларның сайлаган юллары – «рухани» берләшү, мистик оешу, «илаһи-мөкатдәс мәхәббәт», «мәңгелек нур» тирәсенә туплану, дөньяда вакытта ук шуңа бергәләшеп тоташу; «рухани» яктан камил, җитлеккән кеше (гади кешедән өстен кеше (сверхчел.[1]) булып тәрбияләнү. В. Соловьев һәм аның «мөрит»ләре дә шулай, шундый ук юлны тоталар. В. Иванов аны бу яктан тәмамы белән көнчыгыш суфилары урындыгына утырта торган түбәндәге характеристиканы бирә: «Соловьев, – ди, – эш турында сөйли икән, монда ул, әлбәттә, һәр нәрсәдән элек үз ирегең белән үзеңне эчке сизү аркылы күзәтү (моракабә) илһамына бирү юлында риязәт чигүле (аскетик) һәм фаҗигалы сугышны уйлады»[2], – ди.

Билгеле философ символист шагыйрь Метерлинк та – «рухлар»ның бер-берсе белән якынлашу, аңлашу һәм бер-берсе белән

---

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] В. Соловьев турында югарыда күрсәткән җыентык, 42 б. *(Авт. иск.)*

кушылышуларына омтылучы. Ләкин ул мәңгелекне – сөкүт (молчание[1]) һәм эчке сизүле төшенү (моракабә) аркасында моңа ирешүне мөмкин дип белә, рухларның кушылулары өчен юл – ялгыз шул, ди. Димәк, ул – кешеләрнең сөкүттә берләшү юлы белән үлемнән котылу, мәңгелек тормышка ирешү хыялында. Матурлыкны да «рухлар»ның бердәнбер гомуми аңлашу, берләшү теле саный.

Менә боларның һәммәсендә көнчыгыш символистлары белән берләшү яки охшау сызыкларын күрәбез.

* * *

Көнчыгыш һәм көнбатыш символистларының өслүбтә, ягъни шигырь өслүбенең символларга нигезләнгән булуында берләшүләре яки бер-берсенә охшаулары ачык бернәрсә булганга һәм бу турыда югарыда да, шулай ук түбәндә дә аерым тукталынганга, бу урында аны калдырып, бу бүлемдә җыйнак бетермә ясыйк.

Профессор Фриче символизмны «нервылар шигыре»[2] дип дөрес әйтә. Көнчыгыш символизмына да, көнбатыш һәм рус символизмына да бу бик туры килә, ләкин монда боларның һәркайсына карата «авыру, табигыйлектән бөтенләй аерылган, тузган, өзгәләнгән нервылар» дигән өстәмәне арттырырга кирәк. Символист шагыйрь, кирәк көнчыгышныкы, кирәк көнбатышныкы һәм русныкы булсын, «серле», «илаһи», кайчагында «шайтани» яшерен сизенүләр белән нервыларның өзгәләнүен, йончу, ватылуларын җырлый. Бу өзгәләнүдә матди-иҗтимагый реаль тормыш белән килешә алмаудан яки дворян-буржуа тормышындагы мәгълүм бер иҗтимагый төркем белән реаль тормыш уртасында һичбер яктан килешү мөмкин булмаган татусызлык чыгудан килә. Кыскасы, символистлар авыру нервыларның шашкынлы бер сагыш белән «серле хакыйкать»кә омтылышларын һәм «сихерле мәхәббәт» белән шуңа гыйшык тойгыларын көйли. Монда да аларның уртак телләре – «сихерле» тел; өслүб – символ.

Көнчыгыш символизмында да, көнбатыш, бигрәк тә рус символизмында да бу шулай. Боларның һәр икесендә дә эротизм бар, икесе дә барлык дөньясын, бөтен тормышның «илаһи мәхәббәт» белән әйләнә дип карыйлар. Икесе дә «хак-хакыйкать» (истина[3])

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] «Очерк западных литератур», стр. 193. *(Авт. иск.)*
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

гыйшкы, «рухлар» мәхәббәте белән, ниндидер булмаган хыялый матурлыклар белән исерәләр, шуның белән җәзепләнү, ягъни шашыну-һушсызлану кәефләрен җырлыйлар. Бу соңгы сүз белән бу урында боларның икесендә дә экстаз – гаҗәпләнү барлыкны әйтергә тиешбез.

## III. Символизмда тематика һәм мотив

Без югарыда әдәби агым яки әдәби өслүб дөнья турындагы мәгълүм бер карашка (мировоззрение[1]), мәгълүм бер идеологиягә муафикъ рәвештә тудырыла, дигән идек. Символизмның кирәк көнчыгыш, кирәк көнбатыш вариантында булсын бу караш һәм идеологиянең ничек булганлыгы белән дә ачык танышып үттек. Инде безгә символизмның тематика һәм мотивын билгеләү кыен түгел. Бу исә символизм шигыренең мөндәриҗәсен[2] билгеләү дигән сүз була. Сәнгать һәм әдәбиятта фәнни мәгънәсе белән мөндәриҗә шул ук мәгълүм бер идеология һәм психологиядән башка нәрсә түгел. (Бер китапның яки бер хикәя һәм романның, бер драма һәм шигырьнең мөндәриҗәсе дигәндәге мәгънә белән бу мәгънә арасында аерма бар. Бер китап яки бер хикәянең мөндәриҗәсе дигәндә, гомумән, китапның эчендә сөйләнгән, тасвир ителгән нәрсәләрнең һәммәсе аңлана, бу – «мөндәриҗә» сүзенең гади мәгънәсе була.) Сәнгатьле иҗатның, шигырьнең төп һәм вак темалары, гомумән, тематика һәм мотивы – бу мәгънә белән булган мөндәриҗәнең органик бер өлеше. Алар шуңа карап билгеләнә. Тагын да ачыграк аңлатыйк. Әдип-шагыйрьләр, үзләренең эчке төзелешләренә, ягъни идеологик һәм психологик мөндәриҗәләренә карап, төп темаларны сайлыйлар һәм аларны шуңа муафикъ киңәйтә, тармакландыра, шуңа муафикъ тасвир яки тәгъбир итәләр. Шул темалар үзләренең сәнгатьле тасвирлану яки тәгъбир ителүләрендәге бөтен тәфсилләрендә, икенче төрле әйткәндә, әсәрнең бөтен композицион төзелешендә шул ук төп бер идеология һәм психология йомгагыннан сузылган җепләр белән бер үк үзәккә баглана баралар. Әдәби иҗатны бөтен бер организм иттереп карасак, фәнни мәгънәсе белән булган мөндәриҗәне әнә шул организмның нервылар системасы дип аңлый алабыз. Шул рәвешчә, мөндәриҗә әдәби иҗат тормышының баш ролен уйный,

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] Мөндәриҗәсен – эчтәлеген.

төп функциясен үти. Иҗатның формасы да шул ук мөндәриҗәгә карап билгеләнә. Мәгълүм бер мөндәриҗә үзенә муафикъ мәгълүм бер форма сорый, шулай итеп, форма белән мөндәриҗә, ахырда, бербөтеннең бер-берсеннән аерылмас ике ярымы булып чыга.

Шулай символизм шигыре дөнья турындагы төп карашына, идеологик һәм психологик төп «кәгъбә»сенә муафикъ рәвештә үзенең тематика һәм мотивын билгели.

Кирәк көнчыгыш, кирәк көнбатыш, бигрәк тә рус символизм шигыренең тематика һәм мотивы, төбендә, түбәндәге матдәләргә кайтып кала:

1. Ниндидер бер сер дөньясы, рухлар тормышы, илаһи мәхәббәт, серле мәгъшук; шуларның сихерле матурлыгы, шул табигый булмаган хыялый матурлык алдында шуның ләззәте белән исерү тойгылары (эротизм).

Бу тойгылар, болар турындагы моңнар да я сагыш, я газап моментларын эченә ала, яки ниндидер «серле мәгъшук»ка кавышу сәгатьләре якынлануны, хыялый-шәхси тормыш аркылы «аның» нурына, серенә чумуны һәм, ахырда, «мәңгелек таң ату»ны сизенеп, шуның белән шашкыну тойгыларыннан гыйбарәт була.

Бу маддәне түбәндәге мисаллар аркылы яктыртыйк. Безгә мәгълүм булган Нәваи болай дип хыяллана:

Гыйшык ирер дөрр, күңел дәрҗ аңа;
Бәлки кояш – гыйшык, күңел бруҗ аңа.
Кояш – мәгъшук, зәррат улдый гашыйк;
Димәй зәррәт, һәр зәррат улдый гашыйк.
Нидин гашыйкны үртәрсең, мәгъшук?
Чө гашыйк монда килде гайне мәгъшук.

Татарчасы: «Гыйшык – җәүһәр, күңел – шул җәүһәрнең савыты. Бәлки болай булыр: кояш гыйшык булса, күңел аның йолдызы булыр. Кояш – мәгъшук, ә зәррәләр, юк алай гына түгел, бәлки барлык зәррәләр аңа гашыйк булдылар». «Ничөн соң син, әй мәгъшук, болай гашыйкны үртисең? Чөнки монда гашыйк белән мәгъшук берләште шул».

Фөзүлинең хыялы аннан шул ук рухта болай дип җырлата:

Хөсен улмаса, гыйшыктан нә хасил?
Мәгъшук идәр әһле гыйшкы камил.

Нә ансыз улыр моның сөрүе,
Нә монсыз улыр аның зоһуры.

Гыйшык итте бинайе васылы мөхкәм,
Мәгънидә бәне сәнеңлә һәмдәм.

Татарчасы: «Матурлык булмаса, гыйшыктан нәрсә чыксын? Гыйшык ияләрен (гашыйкларны) җитлекләндерүче (камилләштерүче) мәгъшук булыр. Мәгъшуксыз гашыйкның шатлыгы булмаган кебек, гыйшыксыз мәгъшукның да күренүе юк». «Гыйшык кавышу бинасын ныгытты, мәгънәдә синең белән мине берләштереп сердәш итте».

В. Соловьевның «мәхәббәт кояшы» түбәндәгечә җырлана:

Везде огонь божественный горит,
Все, кружась, исчезает во мгле,
Неподвижно лишь солнце любви[1].

Ф. Сологубның Елизавета исеме белән эндәшелгән «серле мәгъшук»ына кавышу хыялы болай сурәтләнә:

Тебя я встречу в блестании света, любовь моя,
Мы будет вместе, Елизавета, и ты, и я[2].

К. Бальмонтның[3] «бөек кояш» символы астында болай дип җырлануны ишетәбез:

Я спросил у высокого солнца,
Как мне вспыхнуть светлее зари.
Ничего не ответило солнце,
Но душа услыхала: «гори».

Шул ук «илаһи-мөкатдәс мәхәббәт», «серле мәгъшука»ны В. Иванов менә болай җырлый:

Любовь, как атом огневой,
Его в пожар миров метнула;
В нем на себя она взглянула –
И в ней узнал он пламень свой.

---

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[3] Константин Дмитриевич Бальмонт (1867–1942) – символист шагыйрь, тәрҗемәче, рус әдәбияты Көмеш гасырының иң күренекле вәкилләреннән берсе.

2. Акылдан, акыл эшеннән качу, тик эчке сизүне генә алга кую, шуны гына тану (теософия[1]):

Кайда ки гыйшык уты булып шәгъләкәш,
Гакыл улып ут, өзә хашә күәш.
(Нәваи)

Татарчасы: «Гыйшык уты ялтыраган җирдә акыл янып көл булыр».

Бән гакылдән эстәрем дәляләт,
Гакылым бәңа күстәрер зәляләт.
Һәркем кәрәк үз эшендә камил,
Гашыйк нә дәва ки ула гакыл.
Диванаи гыйшык улырмы гакыл.
(Фөзүли)

Татарчасы: «Мин акылдан күндерү сорыйм, ә ул мине юлдан яздыра». «Һәр кеше үз эшендә җитлеккән булырга тиеш. Акыллы булу гашыйк булган кешегә яраша торган нәрсәме соң инде?». «Гыйшык диванасы акыллы буламы соң?»

Какое счастье – не мыслить,
Какая нега – не желать.
(Д. Мережковский)

О, я хочу безумно жить.
(А. Блок)

3. Дөнья тормышын хыял, төш күрү яки бер исереклектән гыйбарәт дип белү:

Бер хаб вә хыял, имеш, бу галәм,
Бу хабы хыялә улма хөррәм.
(Фөзүли)

Татарчасы: «Бер йокы-саташу һәм хыял икән бу дөнья. Ул саташуга, ул хыялга сөенмә».

Тәхкыйк улынса нәкыше тәмасиле кяинат,
Я хаб, я хыял вә яхуд әфсанәдер.
Бер мәйханәдер бу галәм.
(Зыя Паша)

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

Татарчасы: «Дөньяның символларындагы (сурәтләрендәге) бизәкләрне нечкәләп караганда, менә нәрсә беленә: я йокы-саташу, яки хыял, яки бер әкият кенә икән алар». «Бер исереклек йорты икән бу галәм».

Один лишь сон, – и в тяжком пробуждении
Ты будешь ждать с томительной тоской
Вновь отблеска нездешнего виденья,
Вновь отзвука гармонии святой.
(В. Соловьев)

И каждый вечер друг единственный
В моем стакане отражен.
И влагой терпкой и таинственной,
Как я, смирен и оглушен.
В моей душе лежит сокровище,
И ключ поручен только мне!
Ты право истинное, пьяное чудовище!
Я знаю: истина в вине.
(А. Блок)

4. «Мин»челек – индивидуализм. Тышкы матди, чын вакыйгыйлык белән килешә алмаганлыкларыннан, аның урынына символистлар үзләренең «мин»нәрен «чын вакыйгыйлык – реальность» дип саныйлар: «Бердәнбер вакыйгыйлык ул – безнең «мин»ебез», – ди буржуа идеологларыннан берсе булган Морис Баррес[1].

Бу яктан символистларны Плеханов яхшы характерландыра: «Кеше үзенең «мин»ен бердәнбер вакыйгыйлык дип исәпләүгә уңайлашкан икән, ул чагында инде ул, Гиппиус ханым кебек, «үзен Алланы сөйгән кебек сөя шул инде». Бу – бик ачык аңлашыла торган һәм бөтенләй зарури булган бер нәрсә. Кеше «үзен Алланы сөйгән кебек сөя» икән, ул үзенең сәнгать әсәрләрендә ялгыз үзе белән генә шөгыльләнүче булып китә. Тышкы дөнья я болай, я тегеләй һаман шул ук «бердәнбер вакыйгыйлык»ка, һаман шул ук кыйммәтле «мин»гә тигән чагында гына кызыктыра торган була[2].

[1] Плеханов Г.В., т. XIV, стр. 163. *(Авт. иск.)*

Морис Баррес (1862–1923) – француз язучысы, сәясәтче һәм журналист. Иҗатында шәхес азатлыгын буган барлык кануннарга каршы чыга.

[2] Плеханов Г.В., т. XIV. стр. 169. *(Авт. иск.)*

5. Җәмәгатьчелеккә, иҗтимагый-гамәли тормыш мәсьәләләренә дошманлык, җәмәгать һәм сәясәт эшләреннән качу. Шуның ук нәтиҗәсе булып, һичбер нәрсә һәм һичбер төрле гамәли максат белән чикләнмәгән ирекле сәнгатьчелек – «сәнгать – сәнгать өчен» дип, тик сәнгатькә һәм сәнгатьчелеккә генә табынучылык.

Безнең өчен монда көнчыгыш символизмыннан һәм азәрбайҗан-госманлы әдәбиятыннан иң характерлы мисал Фөзүлинең:

Шигырь – бер мәгъшуктыр, хөсне гыйбарәт зивәре,
Җан вә дилдән назнин мәхбүбләр – гашыйклары, –

дигән мисраглары булыр. «Шигырь ул – бер сөекле, өслүб матурлыгы аның зиннәте. Бөтен җан-күңелдән назлы сөелүчеләр – аның гашыйклары» дигән сүз. Менә бу көнчыгыш символизмында да, көнбатыш һәм рус символизмындагы кебек, «сәнгать – сәнгать өчен» ноктасына таба бер юнәлеш алганлыкны күрсәтә. Хәтта күрәсез: Фөзүли шигырьне турыдан-туры үзен мәгъшук иттереп куя. Аның да «хөсне гыйбарәт», ягъни өслүб матурлыгы, аһәңлеге, кыскасы, сәнгатьчә нечкә, матур төзелеше белән зиннәтләнгән булырга тиешлеген аңлата. Көнчыгыш символизмында, гомумән, тезмә сүзне килештереп төзүгә, вәзен[1], кафия[2] осталыкларына, тезмәләрнең бик нечкә һәм аһәңле эшләнүләренә артык әһәмият бирелү бар. Хәтта анда моның чиктән тыш бер рәвешкә әйләнеп, тик сүз (ләфыз) һәм кафия уеннарына кереп китү, формалистлыкка бирелү кебек хәлләрне дә күрәбез. Иран, чыгтай, госманлы әдәбиятлары таныш булучыларга бу – мәгълүм бер мәсьәлә. Шушы бишенче маддәне иллюстрацияләндерү өчен, рус символизмыннан да бер мисал китерик. Бу маддәне мәшһүр рус символист шагыйре һәм символизмның теориячесе (әүвәлге шагыйрьлек чорында) булган Валерий Брюсов үзенең «яшь шагыйрь»гә каратып язган түбәндәге өч маддәлек васыятендә бик ачык күрсәтә:

Юноша бледный со взором горящим,
Ныне даю я тебе три завета:
Первый прими: не живи настоящим,
Только грядущее – область поэта.

[1] Вәзен – ритм.
[2] Кафия – рифма.

Помни второй: никому не сочувствуй,
Сам же себя полюби беспредельно.
Третий храни: поклоняйся искусству,
Только ему безраздельно, бесцельно.

Бу васыять, шул рәвешчә, өч нәрсәгә кайта:

1. Хәзерге белән яшәмә, шагыйрьнең мәйданы ялгыз алдагыдан – киләчәктән гыйбарәт.

2. Һичкемгә хәерһаһлык күрсәтмә, үзеңне үзең чиксез сөй!

3. Сәнгатькә табын, һичбер башка максатсыз тик аңа гына буйсын.

Символизм югарыда да үз урынында әйтеп үткәнебезчә, гомумән, иҗтимагый мохит һәм вакыйгыйлык белән яраша алмау нәтиҗәсендә туган төшенкелек кәефен, бетү-егылу тойгыларын тәгъбир һәм тасвир итүче бер агым. Түбәндә күреләчәк булганынча, аның төп иҗтимагый-психологик тамыры да шунда. Шуның өчен аларның сәнгатькә табынуы, һичбер гамәли мәсьәләләр белән чикләнмәгән сәнгатьчелек юлын алулары – алар өчен бик табигый бер хәл. Чөнки бу аларның үзләренә ничек кенә булса да бер юаныч табарга тырышуларыннан башка нәрсә түгел. Плеханов бу турыда иң дөрес аңлатуны бирә: «Сәнгать – сәнгать өчен» фикеренә авышу, – ди, ул әйтә, – сәнгатьчеләр белән аларны чолгап алган иҗтимагый мохит арасында татусызлык булган җирдә туа»[1], – ди. Һәм икенче бер урында бу татусызлыкны да «ышанычсыз рәвештәге» бер татусызлык дип сыйфатлый[2].

Символистларның индивидуалистлык һәм «эгоистлык»ларын да аларның тормышта шуннан башка юаныч таба алмаулары ноктасыннан карарга кирәк. Югарыда исеме әйтелеп үткән Морис Барресның түбәндәге сүзләре символистлардагы бу хосусиятнең буржуазия мохитендәге нинди бер төшенкелек туфрагында туганлыгын ачык аңлату өчен яхшы күрсәткеч була ала: «Безнең әхлагыбыз, безнең милли хисебез – бары да җимерелде. Без алардан тормыш кагыйдәләре ала алмыйбыз һәм безнең мөгаллимнәребезнең безнең өчен дөрес хакыйкатьләрне утыртканнарын көткәнче, безгә бердәнбер вакыйгыйлыкка, үзебезнең «мин»гә генә таянырга кала»[3], – ди, ул әйтә.

[1] Плеханов Г.В., т. XIV, стр. 126. *(Авт. иск.)*
[2] Плеханов Г.В., т. XIV, стр. 131. *(Авт. иск.)*
[3] Плеханов Г.В., т. XIV, стр. 160. *(Авт. иск.)*

Менә бу, әлбәттә, пролетариат сыйныфы алдында, революция вакыйгалары куркынычы эчендә буржуазия сыйныфының егылуы якынлашуны алдан сизүче бер төркем буржуа укымышлыларының үзләрен үзләре юатып, эчке тынычсызлыкларының газапларын басарга маташулары иде.

## IV. Символизм шигыренең өслүбе

Форма белән мөндәриҗә – бер үк нәрсәнең бер-береннән аерылмас ике ягы. Моны югарыда әйттек. Болар арасында шундый органик бер бәйләнеш бар, ләкин элек – мөндәриҗә, аннан соң – форма, ягъни мөндәриҗә форма белән түгел, форма мөндәриҗә белән билгеләнә. Әдип-шагыйрь мәгълүм бер икътисади-иҗтимагый һәм сәяси шартлар астында мәгълүм бер сыйнфый идеологиягә, психологиягә ия була. Дөнья вакыйгаларын ул шуңа карап аңлый, аларны үз миендә, үз йөрәгендә шуларга яраштырып сындыра. Баштан кичерүләр дә һәммәсе шул чишмәдән сугарылалар. Шагыйрь шуларны сәясәтенә, максатына муафикъ[1] сәнгать тәгъбир яки тасвир итәргә тели. Шуларга муафикъ ук темалар сайлана, мотивлар билгеләнә. Әнә шуларның һәммәсенә ярашырлык шигъри форма – өслүб кирәк була. Шулай итеп, мәгълүм мөндәриҗә, мәгълүм тема һәм мотивлар үзләренең сәнгатьчә сурәтләнүләре өчен үзләренә муафикъ форма сорыйлар. Үзләрен тәгъбир яки тасвир итү васиталарының[2] берлеген нәкъ үзләренә ятышып тора торган рәвештә билгеләтәләр. Аларның башкача тәгъбир яки тасвир мөмкин булмый. Менә шуннан һәрбер сыйнфый идеологиянең, һәрбер психологик ясалышның үз формасы, ягъни өслүбе килеп чыга.

Башка агымнар яки әдәби өслүбләр шикелле, символизмның да үзенең идеология мөндәриҗәсенә муафикъ үз өслүбе туды. Бөтен дөнья, бөтен барлык, бөтен тормыш – ниндидер бер «серле бар»ның символлары, шулай булгач, инде шуларны тәгъбир яки тасвир итү васиталарының берлеге яки системасы да шуңа муафикъ булмыйча, ягъни символлардан төзелмичә хәле юк иде.

Шулай булды да. Символизм өслүбе дөнья һәм тормыш вакыйгаларын, шулардан туган фикер һәм тойгыларны, баштан кичерүләрне символлар (рәмезләр) аркылы тәгъбир яки тасвир итүче бер өслүб

[1] Муафикъ – ярашлы рәвештә.
[2] Васиталарының – чараларының.

булып эшләнде. Өслүбнең символлы булучылыгы иҗатның төп алымы итеп алынды. Бу агымга башкача бер өслүб булу мөмкин түгел иде, чөнки безгә хәзер мәгълүм: символистлар бөтен барлыкны ниндидер бер аңлашылмас сер дип төшенделәр. Аны аңлау, конкрет аңлату юлы (акыл юлы) белән белеп булмый, тик аның шул барлыктагы бөтен символлары аркылы ялгыз сизенеп калып кына була дип уйладылар. Алар карашында сүз, ягъни мәгънәле, аңлатулы сүз «хакыйкать»не, әлеге «сер дөньясын» аңлатуда яки аны күрсәтүдә көчсез, ярлы. Аны мәгънәле сүз белән әйтеп аңлатып булмый, тик символлар белән биргә, музыкалы булып кушылган сүзләрнең шыңгыраулары аркылы аны сиздереп кенә була. Шул юл белән ул тик йөрәккә генә коела ала. Хәтта аларча: «Әйтелгән сүз – ул ялган» (Тютчев[1]). Бу Көнчыгышта да шулай. Татар руханисе, татар буржуа тарихчысы үзенең «Вафийәт әл-әсляф» исемле хезмәтенең[2] мөкаддимәсендә[3] суфиларның ни өчен символларга бирелүен нәкъ суфиларның үзләре аңлаганча ук, түбәндәгечә күрсәтә: «Лөгатьләр, тәгъбирләр, сүзләр дә, – ди, ул әйтә, – аларның максутларын, төп әйтергә теләгәннәрен аңлатып җиткерерлек көчкә ия түгелләр, чөнки лөгать һәм тәгъбирләрнең, сүзләрнең күбесе тик билгеле булган нәрсәләр өчен генә эшкә ярыйлар. Аларның да әле күбесе тышкы биш сизүләр аркылы беленгән нәрсәләргә генә каратылганнар»[4], – ди. Көнбатыш һәм көнчыгыш шагыйрьләренең символлы өслүб сайлаулары да шундый ук мәгънәдә изах ителә[5]. Анлату формасы башкарак, яңарак булса да, монда да төп мәгънә бер.

Менә моннан символизм өслүбенең ике төп элементтан торганын күрәбез: 1) символлар, 2) шуларның музыкалы, шыңгыраулы булып кысылган төенле мәгънәле сүзләр белән берләшүләре. Бу да, аларча, югарыда күреп үткәнебез кебек «илаһи», «серле» бер

[1] Федор Иванович Тютчев (1803–1873) – рус язучысы, шагыйрь, дипломат. Текстта әдипнең «Silentium!» шигыреннән «Мысль изречённая есть ложь» дигән тезмәсе турында сүз бара.

[2] Сүз күренекле дин галиме, тарихчы, мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанинең мәшһүр мөселман эшлеклеләренең тормышын тасвирлаган «Вафийәт әл-әсляф вә тәхийәт әл-әхляф» («Элгәреләр һәм аларның киләчәк буынга сәламнәре») исемле алты томлы җыентыгы турында бара.

[3] Мөкаддимәсендә – керешендә.

[4] Мәрҗанинең бу аңлатуы «Ибн Халдун мөкаддимәсе»ндә бар. Мәрҗани аны шул чыганактан алып әйткән булырга охшый. *(Авт. иск.)*

[5] Изах ителә – аңлатыла.

осталык, «пәйгамбәрлек» дәрәҗәсендә гадәттән тыш бер эш, бер «могҗиза» яки «сихер» дип санала. Символистлар өчен бөтен ләззәт тә, юаныч та, исереклек тә әнә шунда: үзләренең эчке сизүләрен, баштан кичерүләрен шулай иттереп бирә белүдә.

Көнчыгыш символистларыннан болар өчен мисал китереп тормыйбыз. Югарыда алардан китерелгән мисаллар да шуны аңлату өчен җитәрлек. Шуның өчен без монда тик мисалларны рус символистларыннан китерү белән генә канәгатьләнәбез. В. Соловьев:

Мыслей без речи и чувств без названий
Радостно-мощный прибой, –

дисә, Ф. Сологуб:

Где ты делась, несказанная
Тайна жизни, красота –

дип җырлый. З. Гиппиус аларны түбәндәгечә тутыра:

Я – раб моих таинственных
Необычайных снов.
Но для речей единственных
Не знаю здешних слов...
Мне кажется, что истину я знаю –
И только для нее не знаю слов.

Мәшһүр дәвамлы символист А. Блоктан да бу урында безнең өчен берәр ачык мисал кирәк. Ул болай дип җырлый:

Одна лишь песня недопета,
Забылись вечные слова…[1]

Менә бу мисаллар символизм өслүбенең символлардан һәм шул символларны бирүче шыңгырау кылы, «сихер»ле тезмәләрдән торганын үзләре үк бик ачык күрсәтеп бирәләр.

Ләкин символизм өслүбе бу ике элементның кушылуы белән генә тәмамланмый әле. Аңа тагын аның төзелешендәге өченче элемент яки аерым бер хосусият булып аның композицион ягы кушыла. Бу – символизм өслүбендә әдәби организмның иң әһәмиятле бер ягы. Ул да шуннан гыйбарәт: символизм өслүбендә әдәби әсәрнең композициясе хыялый, уйдырма (хорафат) нәрсәләрдән тора. Тора гына

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

түгел, болар анда иң беренче урынны алалар. Әсәрнең канвасы шулардан тукыла. Төш, күләгә, шәүлә, рух, җен, пәри, албасты, әүлия, изге карт, фәрештә, юлаучы, дәрвиш, хыялый таң, «илаһи-мөкатдәс» нур, сихер, тылсым һәм башкалар символизм өслүбенең төп органик элементлары булып керәләр. Шуларга чүл, сахра, кабер, караңгылык, урман, сәрап[1], нур, ут, яшен, ай, кояш, йолдыз, җил, давыл, диңгез, өермә, шәраб (мәй), былбыл һәм төрле кыр кошлары, ерткыч хайваннар һәм башкалар кушылалар.

Шулай, әнә шундый композицион хосусиятне эченә алганы хәлдә, символизмда символ – һәр нәрсә. Көнчыгышның тәсаувыф шагыйрьләре яки «хакыйкать»че шагыйрьләр язны, бакча (бостан) ны, күңел ачу, сыйлануларны, бөтен дөньясын онытып, тәмам кәефләнеп мәй (шәраб – исерткеч) эчүне, исереклекне, мәй эчерүчене (сакыйны[2]), кадерле дусларны, утырдашларны, җазибәле[3] ярларны һәм шуңа охшаш башкаларны мактыйлар. Ләкин болар һәммәсе дә аларда реаль мәгънәгә ия түгелләр. Шагыйрь боларны икенче нәрсәгә символ итә. «Чынында бу – мистик юл белән эчке сизенүле күзәтүдә (созерцание[4]) булынучы, эчке сизүгә батучы «рух»ның (күңелнең) «хак»ка, әзәли[5] матурлыкка тоташуы өчен булган серле бер омтылышын тәгъбир һәм тасвирдан гыйбарәт була[6]. «Әзәли матурлык»тан символ булган «сөекле» дә, көнчыгыш символистларынча, үзен сөюче алдында илтифатсыз, сөючесен бер дә санга алмый торган иттереп тасвир ителә.

Көнчыгыш символистларында гашыйк ут (нур) тирәсендә шашып әйләнеп йөрүче күбәләккә охшатыла (бу охшатуның алда татар символист шагыйрьләреннән Дәрдмәндтә дә булганын күрербез). Бу – мәхәббәттә исерү һәм шуның ләззәтендә үзеңне үзең

[1] Сәрап – мираж.

[2] Суфиларның мәй (шәраб), касә (кадәх), сакый һәм исерү символлары турында «Җамигъ әл-ысул» иясе Зыяэтдин ибн Мостафа түбәндәгечә аңлатуны бирә: мәй – мәгъшукның матурлыгыннан ялтыраган нур, касә – шул нурны күңелләрнең авызына куючы, сакый исә – Алла, «Хак», исерү – мәгъшукның матурлыгы алдында һуштан, истән таю. Автор. *(Авт. иск.)*

[3] Җазибәле – сөйкемле.

[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[5] Әзәли – мәңгелек.

[6] Академик Коршның «Персидские лирики X–XV вв.» дигән әсәре, 1916 ел. Акад. Крымскийның шуңа язган мөкаддимәсе. *(Авт. иск.)*

югалтуның символы ителә[1]. Гөл белән сандугач (былбыл) һәм матур кыз – болар көнчыгыш символизмында «илаһи мәхәббәт» өчен иң сөелеп йөртелә торган символлар. Кояш, нур һәм караңгылык (золмәт), яшен, диңгез дулкыннары, таң, гонҗә (яңа гына ачылырга әзерләнеп торган нәфис чәчәк), аһу (газәл – кыр кәҗәсе) күзле чиксез матур хатын, сахирә[2], пәри, яңа туган айга яки җәягә охшаган кыйгач кашы өстенә чебен кунган матур, алсу яңак, матурның йөзен пәрдәләп торган яки аның биленә сузылып төшкән хуш исле (җофар исле) дөм кара чәч; кызарып пешеп торган уймак авыз яки мәхәббәт тойгыларын кузгатучы кечкенә кызыл иреннәр, нечкә бил, көләч яки ачулы йөз һәм башкалар – болар һәммәсе дә көнчыгыш символизмында «илаһи мәгъшук»ның төрле сыйфатларыннан, «соклангыч матурлык»ларыннан символ ителәләр. Гашыйк шулар аркылы «хак-хакыйкать»нең матурлыгын хыял кыла, шулар аркылы аның әзәли матурлыгын күрмәк була.

Мондый символларның күпләрен яки шул типтагы символларны яурупа-рус әдәбиятында да күрәбез. Мәй (вино), кояш, нуряктылык, таң, караңгылык, дулкын, ут шикелле символлар боларда да бар. Шулар өстенә аларның үзләренә махсус «экзотика», «әзәлият»ләре, «вәхши үрдәк»ләре, «диңгез өстендә утырган ханымнары» (бу соңгылар Ибсенда), «чибәр ханымнары» (прекрасная дама[3]), нечкәләнүче бакирәләре (снежная дева[4])лар, (незнакомка[5])лар, Елизавета[6]лар, «миләүшә бармаклар» (фиолетовые руки[7]), «ак аяклар» (царевна[8])лар, сихерле ялтыраулар, тылсымлы йөзләр, әллә нинди могҗизалы канатлар, шәүләләр, күләгәләр һәм башкалар бар. Болар һәммәсе дә шул ук «илаһи» яки «рухи» мәгъшукның – «абсолют хакыйкать»нең символлары.

Ләкин, аңлашылмау чыкмасын өчен, бу урында, бу бүлекчәнең ахыры итеп, шуны әйтеп үтәргә тиешбез. Бездә гомумән символизм белән, ягъни символизм өслүбендәге идеалистик символчылык

[1] Фалев П.А. (проф.) «Введение в изучение тюркской лит.», стр. 21. *(Авт. иск.)*
[2] Сахирә – сихерче.
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[6] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[7] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[8] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

белән аңа башка булган гади – матди символчылыкны саташтыру бар. Символизм өслүбендәге символчылык ул – китапның башыннан ук аңлатылып килгәнчә, дөньяга мәгълүм бер караш нигезендәге идеалистик монизм тойгыларын тәгъбир итүче символчылык. Кыскасы, ул – матди реаль дөньяны ниндидер «сер дөньясы»ның символы дип карау хыялына нигезләнгән символчылык.

Әмма гади символчылык, ягъни андый бер идеалистик идеологиягә багланмастан, матди тормышны реаль бер вакыйгыйлык дип аңлап та, андагы кайбер вакыйгаларны шул ук реаль тормышлы символлар аркылы тасвирлау да бар. Бу – әгәр шулай әйтергә мөмкин булса, тормышлы-реаль символчылык. Символизм символчылыгы ул – төенле, «серле», «сихерле» символчылык. Ул инде үзенең идеологиясе белән бергә үк әдәбият дөньясында гомерен бетерде, үлде. Әмма соңгы мәгънә белән булган гади – тормышлы, ягъни «сер»сез, реаль символлар әдәбиятта һәрзаман булгаларга мөмкин. Чөнки мондый символлар тормышның үзендә үк бар; мәсәлән, кызыл байрак һәм урак белән чүкечнең мәгълүм бер сыйнфый, реаль, конкрет мәгънәләргә символ итеп йөртелүләре кебек.

Шуның белән бергә, тагын тәкрар[1] шуны искә алып нык беркетеп куярга кирәк: символизмда символ – иҗатның, тасвирның төп алымы, ул анда шигырь өслүбенең үзәге. Әмма тормышлы-реаль өслүбле әдәбиятта, реаль шигырьдә символ алай үзәк була алмый. Ул тик кирәк бер урында реаль өслүбнең реаль бер элементы яки сәнгатьчә тасвир васиталарының бер кисәге итеп кенә кергезелергә мөмкин. Шуның өстенә тагын, югарыда әйткәнебезчә үк, символизм өслүбенең композицион төзелеше башка. Анда ул хыялый, уйдырма, ялган нәрсәләрдән тора.

Кыскасы, идеалистик бер идеологиянең калыбы булган символизм өслүбендәге символларны һәрхәлдә гади, тормышлы-реалистик символлар белән (мәсәлән, татар әдәбиятында Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр», «Тирән тамырлар»ындагы, М. Гафуриның «Урак белән Чүкеч»ендәге һәм башкалардагы, шулай ук хәрби коммунизм чорындагы кайбер яшь шагыйрьләрдә күренгән символлар шикелле) бутамаска кирәк.

[1] Тәкрар – кабат.

## V. Символизм шигыренең иҗтимагый тамыры

Символизм әдәбияты нинди иҗтимагый тамырдан чыкты? Аны тудыручы иҗтимагый төркемнәр кемнәрдән тора? Бу бүлекчәдә мәсьәләнең шул ягын карыйбыз. Бу «символизм нидән гыйбарәт» дигән мәүзугыбызның[1] аерым рәвештә иҗтимагый-сәяси яктан яктыртылуы булачак.

Әдәбиятның гомумән мәгълүм бер җәмгыять яки мәгълүм бер сыйныфның укымышлылар төркеме белән бәгланышы барлык мәгълүм. Яңадан-яңа әдәби агымнар яки әдәби өслүбләр шулар аркылы ачык күрсәтелә килде. Көнчыгышта да, Көнбатышта да моның шулай булганын ачык күрәбез.

Бу укымышлылар да заманнарында мәгълүм хаким сыйныфның яки җиңелгән, бетәргә йөз тоткан сыйныфның яисә вак буржуа кебек ике уртада (пролетариат белән буржуа уртасында) калган тирбәлүче-икеләнүче сыйныфның идеологиясен, шуларның настроениеләрен тасвирлыйлар яки җиңүче белән җиңелүче сыйныфларның уртасында аптырап шашып калган бер төркем укымышлыларның тойгы һәм баштан кичерүләрен җырладылар.

Дворян буржуа һәм вак буржуа – менә көнчыгышта да, көнбатышта да символизмның иҗтимагый тамыры шул сыйныфлар тормышының тетрәүле ноктасыннан башланды. Һәр ике вариант символизмны иҗтимагый яктан тикшерү шуны күрсәтә: бу агымның вәкилләре-шагыйрьләре я үзләренең төп чыгышлары белән үк дворян, буржуа яисә вак буржуадан яки кайберләре, төп чыгышлары ягыннан алай булмасалар да, шул сыйныфлар мохитендә һәм шуларның идеологик тәэсире астында җитешкән укымышлыларның мәгълүм бер өлеше булдылар.

«Мәгълүм бер өлеше» дибез. Чөнки дворян, буржуа укымышлыларының һәммәсе дә символист түгелләр. Алар эчендә романтик һәм реаль язучы укымышлылар да бар. Бу соңгылар дворян, буржуа төзелешенең, буржуа сыйныфының төп язучылары – актив көрәшчеләре иде. Дөрес, символистлар да – буржуа төзелешенең хезмәтчеләре, шул сыйныф идеологиясен яклаучылар, ләкин аларның бу хезмәтләре икътисади-иҗтимагый көрәш сафында турыдан-туры актив эшчәнлек күрсәтү юлы белән түгел, җәмәгатьчелектән,

[1] Мәүзугыбызның – соравыбызның.

гамәли-сәяси тормыш көрәшеннән качу, бер өлеш халыкны шул якка аудару, шулай итеп кискен революцион хәрәкәтләргә реакцион бер торыш күрсәтү юлы белән булды. Революцион хәрәкәт өчен зарар булган бу юнәлеш шул хәрәкәткә каршы көрәшүче дворянбуржуа өчен, әлбәттә, файдалы иде.

Шуның белән бергә, символизмны, кирәк көнбатышта, кирәк көнчыгышта булсын, бөтенләй, ягъни һичбер кайдсыз[1] реакцион бер агым иде, дисәк, бик үк туры сөйләгән булмаячакбыз. Чөнки Көнбатышта символизмның мещанлыкка, мещанлык сазына батып, буылып калучы фикерләргә каршы көрәше булган шикелле, көнчыгышта да аның фикер азатлыгы өчен омтылучылылыгы юк түгел (моны, югарыда күреп үткәнебез кебек, түбәндә дә күрә алабыз). XX йөздәге төрк-татар әдәбиятларындагы символизмда исә, көнбатыштагы кебек үк, мещанлыкка каршы көрәшне ачык күрәбез. Шуның өстенә символистлар телнең сәнгатьчә эшләнүендә яңалык күрсәттеләр. Әмма пролетариат революциясенә карата алганлыгыбызда, символизм баш-аягы белән реакциондыр.

Символизмның иҗтимагый мохит һәм чын вакыйгыйлык фикерләрен, егылу тойгыларын тәгъбир һәм тасвир итүче булганлыгы югарыдагы аңлатмаларыбызда беленде. Менә бу татусызлык та укымышлылар ягыннан күренде. Символизмда я тормыштан ризасызлык, елау-сыкрану, өметсезлек-пессимистлык бар яки, шуның ук нәтиҗәсе булып, иртәнгене оныту, ниндидер сихри-хыялый «матуркайлар» белән ләззәт чигеп, дөньяны, аның газабын онытырга, шундый юл белән үзеңә һәм башкаларга, ягъни сыйныфташларыңа юаныч табарга тырышучылык бар.

Көнчыгыш һәм көнбатыш символизмы икесе дә шул сыйфатта.

Мәгълүм икътисади-иҗтимагый шартлар астында мәгълүм бер сыйныф тарафыннан төзелеп дәвам итеп килгән иҗтимагый-сәяси тормышның тетрәве-кризисы башлану яки искенең какшавын күреп, яңаның ничек булачагына күз җитмәү, тормыш динамикасын, иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләрнең һәм, гомумән, төрле тарихи вакыйгаларның реаль сәбәпләрен аңлый алмау яки шуларга ия булудан гаҗизлек, ахырда иҗтимагый-мәдәни тормыштагы өстенлек ролен югалту-егылу куркынычы, шуның кайгысын басу өчен юаныч

[1] Кайдсыз – чикләнмәгән.

эзләү – менә символизмның югарыда сөйләнеп килгән һәр ике вариантында да (көнчыгыш һәм көнбатышта) иҗтимагый-психология уртак тамыр булып шулай ята.

Тәсаувыф фәлсәфәсенең һәм тәсаувыф шигыренең башлап туган мәмләкәтләреннән берсе – Иран[1]. Шулай булгач, аның беренче икътисади-сәяси һәм иҗтимагый төп тамыры да бигрәк шуннан эзләнергә тиеш.

Мәшһүр ислам тарихы галиме А. Мюллер[2] иранлылар турында болай дип яза: «Гарәпләр бер йөз елдан артык үзләренең кылычлары белән Иран халкын ялангач көенчә тураклаган булсалар, икенче йөз тәмам булмастан элек, бу ике милләт ислам хәлифәлеге эчендә, кайчагында тыныч торган шикелле булып, кайчагында кулларына корал алып, бер-берсенең өстенлеге өчен үзара һаман көрәш алып бардылар»[3], – ди. Ислам байрагы астындагы гарәплек империализмы тарихы, һичшиксез, шуның дөреслеген күрсәтә.

Ирандагы тәсаувыф фәлсәфәсе һәм тәсаувыф шигырьләре әнә шул империалистлык сугышлары, Иран аристократиясе белән гарәп аристократиясенең көрәшләре эчендә һәм шуларның нәтиҗәсе булып мәйданга чыкты. Гарәпләрнең империализм хәрәкәте белән туздырылган Иран дворян аристократиясендә, бигрәк тә аның укымышлыларында үзләренең бөтенләй бетү куркынычы туды. Тормышта иҗтимагый-сәяси урыннарын бөтенләй югалту факты алга басты. Тәсаувыф башта Иран укымышлыларының шундый төшенкелекле настроениеләрен тәгъбир итүче булып мәйданга чыкты.

Академик Бартольд[4] үзенең 1927 елда басылган «История культурной жизни Туркестана» дигән соңгы әсәрендә (59 нчы бит) исламда заһидлек – суфилык тууны сәяси оппозициячелек белән баглы булган бер хәрәкәт итеп чыгара. Актив рәвештә булмаса да,

---

[1] Соңгы мәнбәгъларның күрсәтүенчә, Ибраһим ибн Әдһәм тарафыннан буддачылык кояшы булган Бәлх шәһәрендә башлана (VIII йөзнең дүртенче чиреге башларында үлгән). Тәсаувыфның икенче урыны Евфрат елгасы буендагы христианлык шәһәре Хира булганы күрсәтелә. Академик Бартольдның «Ислам» дигән әсәренә кара. *(Авт. иск.)*

[2] Фридрих Август Мюллер (1848–1892) – алман шәрыкшинасы.

[3] Мюллер А. «История ислама», т. II, стр. 212. *(Авт. иск.)*

[4] Василий Владимирович Бартольд (1869–1930) – рус шәрыкшинасы, тарихчы һәм филолог.

пассив рәвештә аның шулай булганын яза. Моны да заманында властька бөтен мөнәсәбәтне өзү мәгънәсендә ала.

Тарихтан безгә мәгълүм: VII–IX йөзләр гарәп колонизациясенең Гарәбстанның төньягындагы, көнчыгыш һәм көнбатыштагы халыклар өстенә куркыныч дулкын булып җәелгән заманнары иде. Бу дулкынның һәлакәте, икътисади бөлгенлеге шул халыкның тормышын тәмам чыгырыннан чыгарды. Бигрәк тә гарәп милли аристократия күкрәгенә кадалды. Шуның өстенә Иранның дәүләте, мәдәнияте белән бергә аның дәүләт дине булган зәрдәшт дине дә юкка чыгарылды. Иран аристократиясе шул хәрәкәттән икътисади бөлгенлеккә төшкән бөтен хезмәт ияләре күпчелегенең гарәп-иран аристкоратиясе сугышларына каршы кузгалышыннан файдаланырга тырышты. Икенче яктан гарәпләргә каршы да төрле баш күтәрү (восст[ание][1]) ясалды. Әбү Мөслим Хорасани[2] юлбашлыгы белән булган күтәрелеш нәтиҗәсендә Өммәвиләр хәлифәлеге туздырылып, иранлыларга яхшырак караучы Габбасилар утыртылган булса да, моның белән янә күп эш чыкмады. Аннан соң шул ук иранлылар тарафыннан VIII һәм IX йөзләрдә Хорасанда[3], Табарстанда[4] һәм Иранның башка урыннарында, Җорҗанда[5], Азәрбайҗанда әллә ничә мәртәбә булган кузгалышлар да иранлыларны һәм башкаларны гарәп истилясыннан[6] коткарырлык нәтиҗә бирмәде. Шул ук иранлылар тарафыннан Иранда берсе – VIII, икенчесе IX йөздә мәздәкиләр хәрәкәте дә яңадан кузгалып карады. (Бу хәрәкәт башта VI йөзнең башларында Иранда Мәздәк дигән берәүнең юлбашчылыгы астында кузгалган һәм байтак таралган иде. Үзе дини юлдагы бер хәрәкәт булу белән бергә, буржуазиягә каршы булган бу хәрәкәт кешеләре мал һәм хатын-кызларда уртаклык һәм һәркемгә

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] Әбү Мөслим (Габд әр-Рахман ибн Мөслим; 718/719–755) – Хорасан һәм Мавәраэннәһердә Өммәвиләр династиясенә каршы хәрәкәт җитәкчесе. 747 елда, өммәвиләргә каршы әзерләнә торган хәрәкәткә җитәкчелек итү өчен, Мәрв оазисына җибәрелгән. Хәлифәлек Габбасиләр кулына күчкәч (750), Хорасан калгае *(титул)* итеп билгеләнгән. Абруе чиктән тыш артканлыгы, Хорасанны мөстәкыйль идарә итәргә омтылуы сәбәпле, хәлифә Мансур боерыгы белән үтерелгән.

[3] Көнчыгыш Ирандагы тарихи өлкә.

[4] IX–XII гасырда Каспий диңгезенең көньяк ярында урнашкан провинция (хәзер Иран биләмәсе санала).

[5] Ирандагы шәһәр.

[6] Истилясыннан – басып алуыннан.

тигез хокук дәгъва иттеләр[1].) Ләкин болар да ислам хәлифәләре тарафыннан бастырылдылар.

Ахырда Таһириләр, Саффариләр, Саманиләр, Исмәгыйль Сафавиләр кебек вак Иран кенәзлекләре тудырылып карады. Ләкин алар да озак яши алмадылар. Шулай да шушы кузгалышлар нәтиҗәсез калмады. Иран, үзе аякка баса алмаса да, гарәп самодержавие дәүләтенең егылуына сәбәп булды. Соңыннан Әфганстан һәм Иранда төрк хөкүмәтләре төзелеп (Газнәвиләр, Сәлҗукыйлар, Харәземшаһлар), Иран аристократиясе гарәп коллыгыннан соң төрк аристократиясе коллыгында калды.

Бу урында мондый тарихи экскурсия ясау белән без шуны әйтмәкче булабыз: менә бу хәлләр һәммәсе дә Иран укымышлыларына өметсезлек, җир тормышыннан качу, җәмәгать эшләреннән читкә тайпылу һәм шулай итеп мистикага бирелү психикасын хәзерләде.

Икенче яктан, Иран укымышлылары ислам динендә, Мөхәммәт тәгълиматында үзләре өчен фикер хөрлеген буучылыкны күрәләр. Шуннан котылу өчен, ничек булса да бер юл эзли башлыйлар.

Моның өчен ахырда шундый чара табалар: Иран укымышлылары Мөхәммәт тәгълиматына үзләренең максатларына муафикъ үзгәрешләр кертә башлыйлар. Иранлылар һәм алар яклылар тарафыннан гарәпнең сөннилегенә, ягъни Мөхәммәт тәгълиматы юлы белән шәригатьчелеккә каршы көрәшүче могтәзиләчелек, шигыйлык[2] кебек ул заман өчен сул канат «партия»ләр (мәзһәбләр) мәйданга китерелә. (Шигыйлар Әбүбәкер, Гомәр, Госманны һәм аларның хәлифәлекләрен танымыйлар. Мөхәммәтнең вәкиле һәм Алланың вәлисе дип Галине һәм аның нәселләрен саныйлар. Галигә Алланың иңүен әйтәләр.) Шулай итеп, Мөхәммәт тәгълиматына үзләренең Зәрдәшт хәким тәгълиматын, юнан фәлсәфәсен, шуларның пантеистик фикерләрен катыштырып, суфизм тәгълиматын яки фәлсәфәсен мәйданга китерәләр. Иран укымышлылары, гомумән, җәмәгать һәм сәясәт эшләреннән кул селтәп, фәлсәфәгә, шигырьгә биреләләр. Бер кыйсемендә[3] риязият[4] фәннәре белән шөгыльләнә

[1] Болар турында Бартольдның һәм Мюллерның югарыда күрсәтелгән китапларында буржуазия карашыннан бирелгән мәгълүмат бар. *(Авт. иск.)*

[2] Могтәзилә, шигый – ислам динендәге аерым бер юнәлешләр һәм төркемнәр.

[3] Кыйсемендә – төркемендә.

[4] Риязият – математика.

башлыйлар. Ахырда, форсатын табып, Багдадка, Габбасиларның патшалык сарайлары тирәсенә сырышалар да фән, сәнгатьне үз кулларына алалар. Шунда «сарай нигъмәтләре» белән ризыкланып, үз фикерләрен, үз карашларын тараталар, фикерләрдә хәрәкәт, көрәш, тартыш кузгаталар. Асыл Иран аристократиясенең милләтчелеге дә гарәп милләтчелегенә каршы үзен шунда ачык күрсәтә башлый. Кыскасы, «Мәэмүнне[1] әйләндереп алучы иранлыларның гарәпләр арасына кергезгән белем һәм фәннәре белән Иран милләтчелеге шул замандагы Багдадта нәкъ бергә очрашалар»[2].

Ләкин Мәэмүннән соң IX йөз (милади) ахырларында Иранның Мөхәммәт тәгълиматына каршы булган укымышлылары тагын да куркытыла, кысылалар. (Шуның бәрабәренә болар тарафыннан массаны хөкүмәткә каршы котыртулар бара.)

X йөзнең ахырларында Әфгастанда Газнәвиләр исемендә төрк дәүләте корыла. Шул дәүләтнең патшасы Мәхмүт Газнәвинең өстенлеге белән Иранның шигыйлыгы, могтәзиләчелеге тагын бастырыла. Шул сәбәпле Мөхәммәт тәгълиматына каршы булганнарны һәм, гомумән, дәүләт интереслары белән бәгланмастан, ирекле уйланып яшәргә омтылучыларны суфизм мистикасы үзенә тагын да нык тарта башлый. Чөнки «бу мистикачылыкта суфилык аскетизмы пәрдәсе астында шигыйлык һәм могтәзиләчелек (рационализм) яшерелә иде» (Мюллер, III том, 108 нче бит).

Тик XI йөздә төзелгән Сәлҗук төркләре дәүләтендә генә иранлылар, гомумән, хөррәк фикерлеләр өчен киңрәк сулыш алу мөмкин табыла. Монда да солтан Мәлик шаһның[3] вәзире (министры) Низам әл-Мөлекнең[4] иранлы булуының тәэсире күренә. Пантеист, скептик

[1] Әбү әл-Габбас Габдулла әл-Мәэмүн (786–833) – Һарун әр-Рәшиднең улы, 813 елдан алып вафатынача Габбасилар нәселеннән Багдад хәлифе. Дәүләт идарәсенә укымышлыларны җәлеп итә һәм Багдадта «Зирәклек йорты»н («Бәйт әл-хикмә») нигезли, шунда ук китапханә һәм сәйях галимнәр өчен мөсафирханә ачыла. Аның әмере һәм ярдәме белән Синҗар буенда меридиана дугасы үлчәнә, Птолемейның «Альмагест» хезмәте гарәп теленә тәрҗемә ителә, 829 елда Багдадта обсерваториягә нигез салына. Әл-Мәэмүн Коръәнне иҗат ителгән дип белдерә.

[2] Мюллер, т. II, стр. 2, 8. *(Авт. иск.)*

[3] Мәлик шаһ (Мәлик шаһ Әбү әл-Фәтх Җәлал әд-Дин Мәлик шаһ ибн Алп-Арслан; 1055–1092) – 1072 елдан сәлҗук солтаны. Аның идарәсе вакытында сәлҗуклар дәүләте куәте иң югары дәрәҗәсенә җитә.

[4] Сүз Әбү Хәмид Мөхәммәд ибн Мөхәммәд әл-Газали әт-Туси турында бара. Низам әл-Мөлек – аның титулы.

Гомәр Хәйям белән тәсаувыф теориячеләреннән философ Газали шул дәүләттә җитешә, шунда эшлиләр. Ләкин монда, бер яктан, заманына күрә гыйлем, фән үссә, икенче яктан, шул ук дәүләтнең һәм аның башында торучы буржуазиянең, сарай ияләренең ышанычсыз киләчәкләре тагын суфизмны тирәнәйтә. Бу дәвердә Шәех Гаттар[1] (1119–1230) кебек суфи-символист Иран шагыйрьләре мәйданга чыга.

Суфилык һәм Иран символизмының тирәнәю һәм үсүе аеруча моголлар хәрәкәтеннән, Чыңгыз вакыйгаларының һәлакәт һәм бөлгенлекләреннән соң була. Сәнаи[2] һәм Низами[3] кебек символистлар шул вакытта килеп чыгалар. Моголлар дәверендә, ягъни XIII–XV йөзләрдә Иран әдәбияты баш-аягы белән диярлек тәсаувыф, ягъни символизм әдәбияты була.

Сахра аристократиясеннән гыйбарәт булган могол-Чыңгыз хәрәкәтенең ул хәрәкәткә очраган халыкларны, мәмләкәт һәм дәүләтләрне нинди куркыныч, нинди икътисади бөлгенлек астында калдырганлыгы мәгълүм. Безгә бу урында ул хәрәкәтләр, ул вакыйгалар үзләре түгел, бәлки шуларның нәтиҗәләре, ягъни шул хәрәкәткә очраган урыннарда, бигрәк тә Иран һәм Төркестанда шул вакыйгаларның тудырган иҗтимагый психология ягы әһәмиятле.

Шөбһәсез, бу вакыйгалар үзләренең ачы һәлакәтле бер канатын Иранда бәрде. Аннан элекке вакыйгалардан да тетрәп, иҗтимагый-сәяси урыннарын югалтып килгән Иран буржуа укымышлылары бу вакыйгалардан тагын да нык тетрәп төштеләр. Шул сәбәпле аннан элекке шундый һәлакәтле, бөлгенлекле вакыйгалардан пессимизм һәм суфизм орлыгын үстереп килгән Иран шигыре үзенең тамырын тагын киңәйтте. Символизм мистикасы инде бөтенләй куәт алды.

Академик Крымскийның[4] бу турыда тарихи вакыйгаларның барышына, шуннан туган иҗтимагый психологиягә муафикъ бер

[1] Шәех Фәрид әд-дин Мөхәммәд бине Ибраһим Гаттар – XI гасырда яшәп иҗат иткән фарсы суфи шагыйре.

[2] Әбү әл-Мәҗит Мәҗдүд ибн Адәм Сәнаи (1080–1131) – күренекле фарсы суфи шагыйре.

[3] Низами Ганҗәви (якынча 1141–1209) – азәрбайҗан шагыйре, фикер иясе. Биш поэманы эченә алган һәм күләме утыз мең бәйт тәшкил иткән «Хәмсә» («Бишлек») әсәренең авторы.

[4] Агафангел (Агатангел) Ефимович (Юхимович) Крымский (1871–1942) – тарихчы, язучы, тәрҗемәче, шәрыкшинас һәм исламият белгече.

аңлатуы бар. Ул әйтә: «Моголларның дәһшәтле баскынлыклары, – ди, – иранлыларны «бернәрсәгә дә ия булмаган һәм бернәрсәгә дә кыйммәт бирмәгән кеше һичбер нәрсә югалтмый» дигән фикергә китергән»[1], – ди. «Ә андый һәлакәткә очрамыйча калган урыннарда нинди фикер булган?» дигән сорауга гүя алдан ук җавап урынында тагын бу аңлатуын ул түбәндәгечә киңәйтә: «Бу фикер, – ди, – моголларның җимерүче һөҗүмнәренә очраганнарның башларында туган шикелле, шул ук вакытта ул Алланың һәлакәтен[2] ерактан әле тик килүен генә көтеп торучыларның башларында да туды», – ди.

Бу аңлатуның безнеңчә дөреслеге шунда: тарихи вакыйгаларның сәбәпләрен аңлый алмаган яки заманында үзләренә башка халыкларның властьларына каршы оппозициядә булып баруны алга алган Иран укымышлылары, Иран шагыйрьләре өчен шулай дип уйлау һәм шуның нәтиҗәсендә бөтен иҗтимагый-сәяси тормышка кул селтәп, үз эчләренә төренүләре, мистикага, символизмга бирелүләре табигый иде. Алар өчен шуннан башка юл юк иде. Шуның белән бергә, яңа хакимнәрнең дәүләт килерләрен[3] какшату өчен, халыкны дөньядан ваз кичүгә өндәп, ярлы тоту рәвешендә оппозициянең бу яктан да эшләнгән булуы бик мөмкин.

Профессор Чубанзадә[4] дә үзенең Фөзүли турында язган мәкаләсендә («Фөзүли» мәҗмугасы, Баку) үзенә игътибарны карата торган фикерләр яза. Ул, ислам тарихындагы Гали-Могавия, Габбас-Өммәвия, ислам-могол, фарсы-гарәп, төрк-фарсы һәм гарәпләр арасындагы хезмәт массасын икътисади бөлгенлеккә төшергән һәм күп заманнарга сузылган һәлакәтле, канлы сугышларны искә алганнан соң, болай ди: «Югарыдан түбәнгә, бер читеннән икенче читенәчә бөтен Көнчыгыш сардыгына[5] бер галәмәт менә бу иде: ялгыз шагыйрьләр генә түгел, халык та мистик, суфи рухында булды», – ди.

---

[1] Крымский «История Персии и ее литературы», т. III, №№ 1–2, стр. 80. *(Авт. иск.)*

[2] Крымскийның мондагы «Алланың һәлакәтен» дигән[ен] суфи символистларының игътикадларына *(ышануларына, инануларына)* каратып әйтелгән дип аңларга кирәк. Автор. *(Авт. иск.)*

[3] Килерләрен – керемнәрен.

[4] Бәкер Ваһап улы Чобанзадә (1893–1937) – кырымтатар шагыйре, тюрколог, Баку дәүләт университеты профессоры, Азәрбайҗан Язучылар берлеге әгъзасы. Репрессия корбаны.

[5] Сардыгына – «сарып алынган» мәгънәсендә.

Чыннан да, бу вакыйгалардан, аеруча могол вакыйгаларыннан соң мистикачылык, суфилык, укымышлылар, шагыйрьләр күпчелеген генә түгел, хәтта укымышлыларны, ягъни «гавами» халыкны да үзенә тагын да нык тарта башлый. Крымский әйткәнчә, тәсаувыфның күпчелекне болай үзенә кызыктыруы да аның бер дин булу сыйфаты белән түгел, бәлки тормыш аскетизм булуы ягыннан иде, ягъни тормышы белән изелгән, фикере белән чарчалган[1] бер халык өчен суфилык шул заманда тагын да уңайлырак бер тормыш формасы булып күренде. Тормыш белән ике арада татулыклары югалган укымышлы шагыйрьләр өчен тәсаувыф идеологиясе шигырьнең йөрәк тамыры булып әйләнде. Мондый укымышлылар шуның белән символизм шигырен тагын да гомумиләштерделәр. Иранның XIII йөздәге классикларыннан Җәлалетдин Руми (1207–1273), Шәйхе Сәгъди[2] (1184–1291), Хөсрәү Дәһли[3] (1253–1325), Хафиз Ширази[4], Җами (1414–1492) һәм башкалар кебек моголлар дәверендәге суфи-символист шагыйрьләр Иран символизмын Иран эчендә генә шаулатып калмадылар, бәлки бөтен төрк халыклары арасында да шул шигырьнең таралуына, тәэсир ясавына сәбәп булдылар. Аеруча «Җами гасыры» дип аталган XV йөз Иран символизмы бик нык шаулаган йөз була. Госманлы әдәбияты Җәлалетдин Румидан сугарылса, чыгтай әдәбияты да Җамидан хәят суы ала.

* * *

Иран суфизмы һәм символизмының шул рәвешчә иҗтимагый тамыры белән танышканнан соң, шуңа ук баглы булып туган төрк әдәбиятларындагы тәсаувыф шигыренең яки чыгтай, госманлы-азәрбайҗан символизмының да иҗтимагый-психологик ягын карап үтик. Башлыйк чыгтай әдәбиятыннан. Монда да әүвәл үк чыг-

[1] Чарчалган – арыган.

[2] Сәгъди (Мөслах әд-Дин Әбү Мөхәммәд Габдулла Сәгъди Ширази; 1203–1210 еллар арасы – 1292) – фарсы шагыйре, фарсы һәм таҗик әдәбиятлары классигы.

[3] Әмир Хөсрәү Дәһләви (1253–1325) – Һиндстанда яшәп иҗат иткән фарсы шагыйре, галим, музыкант. Иҗат мирасы Низамига ияреп язылган «Хәмсә»не дә үз эченә ала.

[4] Хафиз Ширази (1325–1390) – фарсы суфи шагыйре, «Диван»га тупланган газәл, касыйдә, кыйтга, робагый, мәснәви жанрларында күпсанлы шигъри әсәрләр авторы.

тай символизмының да, госманлы-азәрбайҗан символизмының да классик шагыйрьләре я ханнарның үзләре (Бабур, Хөсәен Байкара һәм башкалар) яки аларның уң канатлары булган вәзирләре, сарай әһелләре (Нәваи) яки шулардан матди ярдәм күрүче, аларның нигъмәтләре белән азыкланучы һәм кай җирдә алар белән бик якынаеп, кайчагында алар белән татусызланучы, авыру нервылы укымышлылар (Фөзүли һәм башкалар) булдылар.

Чыгтай символизмының икътисади-иҗтимагый тамырын табу өчен, янә һәрнәрсәдән элек шул ук Чыгтай буыннарының, ягъни Аксак Тимернең канлы җиһангирлек сугышларын, соңыннан аның балаларының үзара булган сугыш-кырылышларын һәм шуның сәбәпле Иран, Төркестан хезмәт массасы тагын да авыр бер рәвештә икътисади бөлгенлеккә төшүләрен, илнең хуҗалыгы чыгырыннан чыгуы, ярлылык, мохтаҗлыкларны искә алып үтик. Шул ук Тимер балаларыннан булган Хөсәен Байкараның ханлык сарае, төзелер-төзелмәстән, һичөзлексез диярлек үзара сугыш дәһшәтләре, төрле бөлгенлекләр эчендә тетрәп яшәде. Бу сарайның уң канаты булган Нәваи шул куркынычларны, сарайның җимерелү, егылу хәвефен һаман үз күзе белән күреп, сизеп барды. Аның киләчәгеннән өмете өзелә торды.

Икенче яктан, үзәге Иранда – Һират шәһәрендә булган бу дәүләтнең, гомумән, Урта Азиянең икътисади кризисы башланды. Чөнки бу ханнарның яшәгән заманы XV йөзнең ахырлары булып, бу вакытта инде Һиндстан һәм Кытайга яурупалылар тарафыннан диңгез юлы ачылган, ул илләр белән сәүдә яурупалылар кулына күчә башлаган иде. Шул сәбәпле Һиндстан, Кытай һәм Уйгурстан белән Төркестан сәүдәсе үзенең әүвәлге әһәмиятен югалтты. Ул ике арада сәүдә кәрваннары әүвәлгечә йөрми башладылар. Шулай итеп, аңанча[1] Көнбатыш белән Көнчыгыш арасында сәүдә мөнәсәбәтләрендә күпер булып торган Төркестанның икътисади роле бетте. Тимердән элек һәм аның заманнарында сәүдә үзәге булган Һират, шулай ук Бохара, Харәзем (Хива), Сәмәрканд кебек шәһәрләр һәм алардагы җирле сәүдә капиталы сүнүгә юл алды. Шул рәвешчә Төркестан капиталистлары (сәрмаядарлары), зәгыйфьләнеп, төрле якта болгана башладылар. Ханлыкларның, шул җөмләдән Хөсәен

[1] Аңанча – аңарчы.

Байкара солтанлыгының таянычы нык какшый башлады. Төрле баш күтәрүләр кузгалды, хәтта бу ханга каршы аның үз уллары да баш күтәрделәр. (Шул ук сугышларда Нәваи дә хан ягыннан катышты.) Шуның өстенә тагын Алтын Урдадан Шәйбани[1] кул астында үзбәкләр күтәрелеп килеп чыктылар. Чыгтай ханлыкларының һәммәсен зир-зәбәр китерделәр[2].

Шуларның һәммәсенең нәтиҗәсендә Хөсәен Байкара һәм Бабур ханлыклары соңгы сулышларын үткәзделәр һәм, ахырда тәмам җимерелеп, алар урынына үзбәкләр урнашты. Бабур да, алардан качып, Әфганстан аркылы Һиндстанга йөз тотты, анда барып урнашты. Анда да шул ук яурупа капитализмы белән очрашып, ахырда ул якта да җимерелделәр.

Әнә шул хәлләрне күреп торган яки үз башыннан кичереп барган аристократия һәм сарай шагыйрьләре мистикага бирелмичә хәлләре юк иде. Вакыйгыйлык (реальность) аларны инкяр кылгач, алар үзләре дә вакыйгыйлыкны инкяр кылдылар. Үз эчләренә бирелү, илаһи гыйшык ләззәте белән юану юлын алдылар. Сәнгатьтән, тик мистик сәнгатьтән юаныч эзләделәр, сәнгатьчелеккә бирелделәр.

Чыгтай әдәбиятының мистикага бирелүендә, аның символизм әдәбияты булып үсүендә югарыда әйтелгән икътисади-иҗтимагый сәбәптән башка тагын икенче бер сәбәпне дә кушарга кирәк. Бу да чыгтай әдәбиятының турыдан-туры көчле фарсы әдәбияты тәэсире астында булуы иде. Иранлылар әүвәл гарәпләр, аннан соң төркләр тарафыннан сәяси яктан җиңелсәләр дә, мәдәни яктан җиңелмәделәр. Фәндә, бигрәк тә сәнгать һәм әдәбиятта аларга үз тәэсирләрен ачыктан-ачык күрсәтә килделәр. Аеруча Урта Азия һәм Анатулы төркләрен, гомумән, бөтен төрк халыкларын әдәбиятта, идеологиядә үз тәэсирләре астына алдылар. Хәтта төрк теленең фарсы теленнән артыклыгын, ягъни байлыгын каты дәгъва кылган («Мөхакәмәт әл-лөгатәйн»[3]) һәм фарсылар уртасында торганы хәлдә төрк телендә күп әсәрләр тудырган Нәваи әдәби тел, вәзен ягыннан заманындагы башка шагыйрьләрнең һәммәсеннән дә ар-

[1] Мөхәммәд Шәйбани (Шәйбани хан, тарихи чыганакларда Шәйбәк, Шаһибәк кебек тә телгә алына; 1451–1510) – Чыңгыз нәселеннән үзбәк ханы, Шәйбаниләр династиясенә нигез салучы, Бохара ханлыгы ханы.

[2] Зир-зәбәр китерделәр – тар-мар иттеләр.

[3] «Ике тел турында фикер йөртү».

тык фарсы теле тәэсиренә җиңелде. Аның шигырь теле, кирәк грамматик, кирәк лөгать[1], кирәк исә стилистика ягыннан булсын, үзенә, гомумән, 70–75% фарсы тәэсирен алудан котыла алмады.

Әсәрләре тематик, сюжет, мотивлары ягыннан каралганда, аларны бу яктан тәмамы белән диярлек XIV–XV йөздәге классик фарсы әдәбиятының, фарсы символизмының төрк телендә яңадан кабатлануы иде дияргә мөмкин, Иранның символист классик шагыйрьләреннән Хөсрәү, Низами, Фиретдин[2] Гаттар[3] һәм Җамиләрнең Нәваигә тәэсирләре зур булды. Ул алардан мәүзуг[4], өслүб алды, аларга тәкълид итте[5], аларга пародияләр (назыйрәләр) язды һәм аларның әсәрләрен тәрҗемә кылды.

Ләкин бу сүзләребездән Нәваинең үз иҗаты булмаган дигән фикер аңлашылмасын. Без тик моның белән аңа фарсы тәэсире зур булганын гына әйтергә телибез. Юкса аның үз иҗатлары, сәнгатьчелектә фарсы шигырьләре белән ярышырлык үз байлыклары да аз түгел иде. Фарсы тәэсирендә булса да, һәрхәлдә, ул – үз иҗади талантын күрсәтә алган бер шагыйрь.

Нәваинең тәрбияләнгән, үскән мохите фарсылар булган кебек, аның яшәгән сарае да фарсы шагыйрьләре белән әйләндереп алынган иде. Дәүләт эшләрен башкарган шәһәре янә фарсылар уртасындагы Һират шәһәре иде. Бигрәк тә аның остазы Иранның беренче дәрәҗә классик суфи символист шагыйре Җами булу Нәваине Иран символизмы тәэсире астына нык төшерде. Нәваи турыдан-туры мистикачылык, символистлык идеологиясен аннан алды, аның идеологиясе белән сугарылды. Шуңа тагын Нәваинең үзенең, төрк шагыйре булу белән бергә, фарсы шагыйре дә булуын кушарга кирәк (фарсы шигырьләрендә «Фани» псевдонимы белән язылды).

---

[1] Лөгать – сүзләр.

[2] Сүз фарсы телле суфи шагыйрь Фәрид әд-Дин Гаттар (1119–1223 еллар тирәсе) турында бара. Тумышы белән Нишапур шәһәреннән (Иран). Гаттар – зур гыйлем иясе, гамәли тыйб гыйлеме (медицина), фармакология белән шөгыльләнгән. Урта һәм Якын Көнчыгыш илләрендә (Мисыр, Гыйрак, Һиндстан һ. б.) булган. Күпләгән әдәби һәм гыйльми әсәрләр авторы.

[3] Гаттарның Нәваигә тәэсире турында Е.Э. Бертельсның «Неваи и Аттар» дигән әсәренә кара, 1928 ел. *(Авт. иск.)*

[4] Мәүзуг – тема.

[5] Тәкълид итте – иярде.

Чыгтай әдәбиятындагы символизм өчен мисал булуда Нәваи – күзгә иң ачык ташланып торган, иң типлы бер шагыйрь. Аның символсыз әсәре юк диярлек дәрәҗәдә аз булыр. Шуның өстенә аның кебек авыр, томанлы символлар белән язган шагыйрь дә бик сирәк булыр. Аның әсәрләре, шигырьләре чыннан да бикле, «мөгаммә»[1] шигырьләр. Баштанаяк пантеистлык һәм «илаһи гыйшык» белән тулган «Хәмсә»се – моңа тагын да ачык мисал. Шуның өчен дә Нәваинең шигъри әсәрләре – тәсаувыф фәлсәфәсеннән нык хәбәре булган, гарәпчә һәм фарсычаны яхшы белгән укымышлылар өчен генә (анда да байтак нәрсәләре авырлык белән) аңлашыла торган аристократик шигъри бер иҗатлар иде.

Чыгтай символизмының иҗтимагый тамырын һәм өслүб ягын күрсәтү өчен Нәваине мисал китерү белән канәгатьләнеп, хәзер госманлы-азәрбайҗан символизмына күчәбез. Монда да бер генә шагыйрьне – Фөзүлине (1503–1562) алу белән канәгатьләнәбез. Госманлы-азәрбайҗан символизмы өчен аннан да муафикъ, аннан да характерлы булган шагыйрь юк дисәк, хата булмас.

Бу символизм да Иран, чыгтай символизмы турында күрсәтелгән сәбәпләр белән бер үк характерда булган икътисади-иҗтимагый һәм мәдәни сәбәпләрдән туды. Фөзүли туган, яшәгән, эш күргән, шигырьләрен иҗат иткән иҗтимагый-сәяси мохит, шулай ук аңа Иран һәм чыгтай әдәбияты (аеруча Нәваи) тәэсире Фөзүлинең мистик символистлыгын, аның иҗтимагый-сәяси һәм психологик тамырын яхшы ачыкландыра ала.

Әүвәл, гарәп буржуазиясе, ислам хәлифәләре вакытында аның туган, яшәгән шәһәре булган Багдад бөтен көнчыгыш халыкларының сәяси-икътисади үзәге иде. Көнчыгыш сәүдәсенең төенләнә торган бер урыны булып килде, әмма Фөзүли яшәгән заманда Багдад һәм бөтен Иран, Гыйрак, Месопотамияләрнең бу әһәмиятләре югалган иде. XIII йөздән башланган моголлар хәрәкәте, Тимер вакыйгалары, Иран, Төркестандагы үзара сугышлар, шуның белән бергә бигрәк тә яурупа капитализмының, яңа сәүдә юллары (диңгез юлы) табып, Иран һәм Төркестанның икътисади ягын какшату шуның башлыча сәбәпләреннән булдылар. Шуның өстенә, шул ук сәбәпләр белән Төркия императорлыгындагы гаугалар, үзара

[1] Мөгаммә – табышмак.

сугышлар, гыйсъяннар, ахырда килеп, сафавиләр белән госманлылар арасындагы сугышлар, Багдадның, Гыйракның шулар арасында кулдан-кулга күчүе, шул вакыйгаларда мәмләкәтнең, халыкның хуҗалыгы асты-өскә килү – болар һәммәсе дә Фөзүлинең күз алдында булып үткән фаҗигалы вакыйгалардан иде.

Әнә шундый икътисади-сәяси вакыйгалар, көрәшләр азәрбайҗан-госманлы әдәбиятында да мистикачылык һәм символизмның тамырлануына сәбәп булды. Бер яктан, сарай әһелләренең тетрәвен, дәвамсызлыкларын, егылуларын, икенче яктан, халыкның, ягъни хезмәт массасының интегүен, мохтаҗлык, ярлылык белән газаплануын күреп торган һәм үзләре дә бу вакыйгаларның куркынычы эчендә калып, иҗтимагый-сәяси урыннарын югалткан яки ике уртада калган укымышлылар, шагыйрьләр бөтен нәрсәгә, дөньяга, тормышка, сәясәткә, җәмәгать эшләренә кул селтәүдән башка юл таба алмадылар. Мистикага, илаһи гыйшыкка, саф сәнгатькә бирелүдән, тик үз эчләренә, эчке сизүләренә чумудан башка чаралары калмады. Алар да шуннан үзләренә юаныч эзләделәр.

Фөзүли – заманындагы авыр икътисади-иҗтимагый шартлар астында үзләрендә әнә шундый шомлы психология туган укымышлы символист шагыйрьләренең башлыкларыннан иде.

Бу шагыйрь түбәндәге сүзләре белән үзен безгә бик яхшы ачып бирә:

«Шушы гыйсъян сәхифәләрен каралаучы, көчсез Фөзүли әнә шул рәвешчә үз хәлен, үз эчендәген ачып, шәрехләп бирә. Чөнки барлыгым көймәсе табигать җилкәне белән сабыйлык дәрьясыннан аңлау һәм эчке сизү ярларына килеп җитте. Һаваи[1] һәвәс[2] (ягъни тик үземнең тәртипсез теләкләремә-богемачылыкка бирелү дигән сүз) нең уты кабынды. Шуның кызулыгы җанга, йөрәккә сукты»[3].

Менә бу сүзләр безгә Фөзүлинең символистлыгын аның үз авызыннан да игътираф иттерәләр[4]. Аның башта бер дөнья матурына булган мәхәббәте (башта бер кызга гашыйк булган) ахырда мистик

[1] Һаваи – буш, мәгънәсез.

[2] Һәвәс – теләк, омтылу.

[3] Сөләйман Шиһабның «Тарихы әдәбияты Госмания»се һәм «Фөзүли» мәҗмугасы. Соңгысы 1925 елда басылган, Баку, Азәрбайҗан әдәбият җәмгыяте нәшере. *(Авт. иск.)*

[4] Игътираф иттерәләр – *биредә:* таныттыралар.

мәхәббәткә, хатын-кыз мәхәббәтен илаһи мәхәббәткә символ итүгә әйләнә. Иранлыларның шигыйлыкларына мәел итүче[1] булган Фөзүли пантеистлыкка шәригатьчеләр карашынча «зиндыйк»лыкка (еретизм[2]га) бирелә. Хыялый матурлыкка, хыялый мәгъшукасына («хак»ка) омтыла. Үзенең шул омтылышларын, шул тойгыларын да, кирәк лирик шигырьләрендә, кирәк дастаннарында булсын, төрле символлар белән тасвир һәм тәгъбир итә. Гамәли тормыш белән багланмаган газәлчелекне, ягъни саф лирикачылыкны үстерә.

Шуның өстенә Фөзүли үзе белән ике арада татусызлык, ышанычсыз татусызлык туган иҗтимагый мохитеннән аерылганын сөйләгәннән соң:

Бән аңа фетнә, ул бәңа афәт,
Мөтәнафир[3] бән андан, ул – бәндән.
Бән аңа госса[4], ул бәңа михнәт,
Мөтәфәккир[5] бән андан, ул – бәндән[6], –

дип, үзенең, югарыда әйткәнебезчә, иҗтимагый реаль тормыштан бизеп, мистик идеологиягә, символистлыкка бирелүен бик ачык тәгъбир итә.

Фөзүлинең классик әсәре булган «Ләйлә-Мәҗнүн»е үзе генә дә аның чын мәгънәсе белән символистлыгына бик ачык дәлил була ала. Фөзүлинең бу поэмасы – илаһи гыйшыкка символ булуы ягыннан һәм көнчыгыш символизмының идеологик тамырын, шулай ук символизмның өслүбен күрсәтү өчен һәммәсеннән дә артык алда торган классик бер мисал. Монда Ләйлә – илаһи матурлыктан, Мәҗнүн дә илаһи гашыйктан символ итеп алына.

Фөзүлидән соң Азәрбайҗан төркләренең атаклы шагыйрьләреннән Кауси (XVII йөздә) суфи-символистлыкта күзгә ачык ташлана.

[1] Мәел итүче – тартылган.
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] Мөтәнафир – бер-беренә нәфрәт белән караучы, яратышмаучы.
[4] Госса – кайгы, көенеч, борчу, сагыш.
[5] Мөтәфәккир – уйга чумган.
[6] «Мин аңа фетнә, ул миңа бәла. Мин аннан бизгәнмен, ул миннән бизгән. Мин аңа кайгы, ул миңа газап. Мин аның сәбәпле уйланам, ул минем сәбәпле уйлана» дигән мәгънәдә. *(Авт. иск.)*

Госманлы шагыйрь-әдипләреннән Гашыйк Паша[1], Шәйхе Чәләби яки Мөхәммәт Чәләби[2] (мәшһүр «Мөхәммәдия» иясе), Сөнан Паша, Нәфгый[3], Рагыйб Паша[4], Шәйхе Галиб[5], Бакый[6], Рухи Багдади[7], Нәби[8] һәм «Мөхәммәдия»гә шәрех әйтеп «Фәрхе рух» китабын язучы шагыйрь Исмәгыйль Хаккый[9], иң ахырда XIX йөзнең Зыя Пашалары – һәммәсе дә госманлы әдәбиятында символизм агымын үстерүче суфи-символист шагыйрьләр иде. Гомумән, XIX йөзнең ярымынача Анатулы һәм Азәрбайҗан төркләре әдәбиятында шул ук идеалистик монизм, шул ук тәсаувыф – символизм шигыре дәвам итте. Шуның өстенә, XX йөзнең башларында Анатулы төркләренең бөек әдипләреннән Халид Зыя тарафыннан «Мәзардән сәсләр»[10]

[1] Ашик Паша (1271–1332) – төрек телле суфи шагыйрь. «Гарибнамә» («Читят илдә яшәүче китабы»), «Мәгърифәтнамә» («Мәгърифәт китабы») поэмалары, «Диван-е Ашик Паша» («Ашик Пашаның шигырьләр мәҗмугасы») һ. б. әсәрләр авторы. Суфичылык тәгълиматы рухында язылып, ун баб-бүлектән торган һәм һәр бабы тагын унар дастанны эченә алган «Гарибнамә» поэмасы татар халкы арасында элек-электән кульязма нөсхәләрдә киң таралган. Кыпчак теле тәэсирендә оешкан борынгы гомум әдәби төрки телдә язылганлыктан, татар укучыларына поэма тәрҗемәсез дә җиңел аңлашылган.

[2] Мөхәммәд Чәләби (Язычы оглы Мөхәммәд Биҗан) – XV гасырда яшәп иҗат иткән госманлы төрек шагыйре. Мөхәммәд пәйгәмбәрнең тормышы һәм дини эшчәнлеге турында дини-дидактик «Мөхәммәдия» поэмасы авторы. XVIII йөздән поэма татар халкы арасында кульязма нөсхәләрдә, басылган китаплар рәвешендә киң таралыш ала, мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту әсбабы буларак файдаланыла.

[3] Нәфи (Нәфгый; 1572–1635) – госманлы төрек шагыйре. Госманлы солтаннары сараенда хезмәт итә, солтан һәм вәзирләр өчен шигырьләр яза. «Нәфи» – аның псевдонимы, «кире кагылган, читкә сөрелгән» дигәнне аңлата. Панегирик һәм үткен телле сатирик буларак таныла. 1635 елда аның һөҗү объекты – Бәйрәм паша – Нәфине җәзага тарттыруга ирешә: шагыйрь асарга хөкем ителә.

[4] Хуҗа Мәхмүт Рагыйб Паша (1698–1763) – Госманлы империясенең бөек вәзире (1757–1763). Шагыйрь буларак та дан ала.

[5] Шәех Галиб (1757–1799) – госманлы төрек шагыйре. Мәүләви тарикате шәехе. Шәех Галиб иҗаты аллегорияләргә һәм абстракцияләргә, үзе уйлап тапкан сүзләргә гаять бай.

[6] Бакый (Мәхмүд Габделбакый; 1526–1600) – госманлы төрек шагыйре, төрек әдәбиятын фарсы шигърияте йогынтысыннан азат итү тарафдары. Лирик жанрларда иҗат итә.

[7] Рухи Багдади (1605 елда вафат) – госманлы төрек шагыйре.

[8] Йосыф Нәби (1642–1712) – төрек шагыйре һәм дәүләт эшлеклесе.

[9] «Әл-Җүз әл-әүвәл мин шәрх әл-Мүхәммәдия әл-мусамма би-Фарх ар-рух».

[10] Бу әсәр, «Кабердән тавышлар» исеме белән шушы китапны язучы тарафыннан татарчага тәрҗемә ителеп, әүвәл – «Шура» журналында, аннан соң аерым китап булып басылган иде. *(Авт. иск.)*

исемендәге әсәре шикелле символизмның яңа формадагы, ягъни яурупа символизмы сызыгындагы (Көнчыгыш тәэсире аралаш) яңа үрнәкләре тудырылганын да күрдек.

Бу – Төркия буржуазиясенең икътисади-иҗтимагый һәм сәяси кризисы башлану, Төркия дворян-буржуа шагыйрьләренең шуннан аптыраушта калуларының бер нәтиҗәсе иде.

XX йөз башындагы төрек шагыйрьләренең «даһие» саналган Габделхак Хәмиднең[1] «Мәгъбәр» шикелле әсәрләре дә, мәшһүр француз шагыйре Гюго[2] әсәрләре шикелле үк, тәсаувыф-пантеизм идеологиясе белән сугарылган иде.

Бу турыда госманлы шагыйрьләре тарафыннан тәсаувыф-символизм шигыре үстерелүгә янә шул ук фарсы әдәбиятының тәэсире дә булганын искә алырга кирәк. Бигрәк тә Хорасаннан чыгып та, Төркиядә Коньяда яшәгән фарсы классик шагыйре Мәүләна Җәлалетдин Руминың госманлы шагыйрьләренә тәэсире зур булды.

Ләкин аның тәэсирен үзенә нык алучылар – Төркиянең иҗтимагый-сәяси тормышы яурупалашудан, төрек либераль буржуазиясе көч алудан әүвәлге шагыйрьләр иде. Соңгылар, ягъни XIX йөзнең ахырындагы һәм XX йөзнең башларындагы шагыйрьләр бу юлда тәэсирне француз романтизмы һәм символизмыннан алдылар.

Бөтен кешелек дөньясы әдәбиятларындагы символизмның иҗтимагый-психологик тамырлары бергә кайтканын, бу яктан да берләшкәнлекләрен төгәлрәк күрүебез өчен, инде яурупа һәм рус символизмына бу яктан бер экскурсия ясап үтик.

Яурупа һәм рус әдәбиятында символизм XIX йөзнең ахырларында башланды. Безгә тарихтан мәгълүм: бу йөз һәм аның ахырлары элекке иҗтимагый бер сыйныфның (буржуазиянең) иҗтимагый-сәяси барышы тетрәүгә очраган, аның алдында икенче бер яңа һәм аңа зур куркыныч тудыручы сыйныфның, ягъни пролетариатның кузгалган, тарих йөзенә чыгып, буржуазия алдында үзенең көчен күрсәтә башлаган бер заман иде. Буржуазия, бигрәк тә вак буржуа укымышлыларының бер төркеме әнә шундый кризис башлану

[1] Габделхак Хәмид Тархан (1852–1937) – төрек шагыйре һәм драматургы. Төрек дипломаты улы, берничә тел белгән, 1863 елга кадәр Парижда белем алган, озак еллар чит илләрдә (Франция, Иран, Греция, Англия һ. б.) гомер кичергән.

[2] Виктор Мари Гюго (1802–1885) – француз шагыйре, прозаигы һәм драматургы, француз романтизмының иң күренекле вәкилләреннән берсе.

вакыйгаларыннан курку, аптыраш эчендә калдылар, шуннан чуалчык һәм бизгәкле бер психика туды. Җимерелүне алдан сизү тойгылары йөрәкләргә сарылды. Иҗтимагый-сәяси тормыштагы урын какшады, тиздән иҗтимагый рольне югалту хәвефе туды. Гамәли тормыштан, акыл, дөнья эшләреннән тизрәк качып, мистикага, хыялга бирелү настроениесе башланды.

Бер өлеш буржуа һәм вак буржуа укымышлылары арасыннан чыккан символист шагыйрьләр, буржуазия җәмгыятендәге әнә шундый чуалчык, буталчык настроениене тәгъбир һәм тасвир итүче булып, мәйданга атылдылар.

Рус символизмы да шул ук сызыкта туды. Француз символизмы тәэсирендә, бәлки башта шуңа тәкълид[1] белән туган рус символизмы, бу агымның иҗтимагый-икътисади тамырын тикшерүчеләр фикеренчә дә, дворян-буржуа укымышлыларының бер өлешенең настроениеләрен, шуларның башларыннан кичергәннәрен чагылдырды. Бу агымның рус хәятындагы иҗтимагый-психик яктан төп тамыры әнә шуннан эзләнә.

Бу агымны тудыручы укымышлылар төркеменең андый настроениеләре – 1890–1900 еллар арасында Россиядә үсеп киткән сәнәгать капитализмыннан һәм шуның белән бергә ул замандагы революция хәрәкәтләреннән туган бик катлаулы бер иҗтимагый-икътисади һәм сәяси мөнәсәбәтләрнең, каршылыкларның нәтиҗәсе иде.

Рус символизмының, югарыда әйткәнчә, рус хәятының үз эчендәге иҗтимагый тамыры белән бергә аның икенче бер әдәбият тәэсирендә, ягъни француз символизмы һәм, гомумән, яурупа әдәбиятындагы романтизм, символизм тәэсирендә туган булуын да бу урында тәкрар[2] искә алып үтәргә тиешбез. Моның аркылы монда безгә экономикада, мәдәният һәм әдәбиятта алда торган бер сыйныфның идеологиясе һәм әдәби барышы үзенннән артта калган, ләкин сыйнфый интереслары берләшкән, мәдәни якын мөнәсәбәттә булган икенче халык әдәбиятына тәэсире мәсьәләсе тагын да яхшы ачылачак.

Е.И. Шамурин[3] «Русская поэзия XX века»[4] мәҗмугасында язган мәкаләсендә (19 нчы бит) рус символизмына карата бу турыда

---

[1] Тәкълид – иярү.
[2] Тәкрар – кабат.
[3] Евгений Иванович Шамурин (1889–1962) – әдәбият галиме, библиограф.
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

безнең өчен әһәмиятле булган түбәндәге фикерләрне яза: «Бер әдәби агым сыйфатында рус символизмы – бик катлаулы бер хадисә, хәзергәчә әле тәмам чигенә кадәр өйрәнелмәгән бер хадисә. Анда бик күп төрле тәэсирләр тукылган. Француз декадентларыннан Бодлер[1], Верлен[2], Метерлинк, Маллармеларның[3] һәм Оскар Уайльдның[4] инглиз эстетизмыннан, Ибсен һәм Ницшеның индивидуалистлык вәгазьләреннән алып, та Владимир Соловьевның мистик фәлсәфәләре, Достоевскийның романнары, Тютчевның һәм Фетның шигырьләре, Германия романтизмының «Sturm und Drang»ысынача[5] рус символизмына тәэсир ясады. Аның сәнгатьчә һәм гомуми фәлсәфи генеологиясе – бик низаглы мәсьәлә, хәтта терминологиядә дә берсүзлелек юк. Шулай, мәсәлән, хәзергәчә әле кайбер тәнкыйтьчеләр, бөтен символизмны бөтен хәленчә алып, «декадентлык» һәм «модернизм» дип атыйлар. Башкалар, мәсәлән, С.А. Венгеров[6], «символизм» мәфһүмен[7] «яңа романтизм» («неоромантизм») мәфһүме белән берләштерделәр», – ди.

Шулай ук хәлне без үткәндә, гомумән, көнчыгыш, бигрәк тә төрк әдәбиятларындагы символизмда да күрдек. Ягъни болардагы символизм да, бер яктан, шул заманнардагы икътисади-иҗтимагый шартларның җимеше булса, икенче яктан, төрк әдәбиятларына мәдәнияттә өстен булган башка халык әдәбиятларының тәэсире көчле булганлыгын һәм алардагы символизмның да бик катлаулы бер әдәби хадисә икәнен аңлый килдек.

---

[1] Шарль Бодлер (1821–1867) – француз символист шагыйре, тәрҗемәче, дөнья әдәбияты классигы.

[2] Поль Мари Верлен (1844–1896) – француз импрессионист шагыйре.

[3] Стефан Малларме (1842–1898) – француз символист шагыйре.

[4] Оскар Фингал О’Флаэрти Уиллс Уайльд (1854–1900) – мәшһүр ирланд әдибе. Европа модернизмында төп фигураларның берсе.

[5] Сүз немец әдәбиятында 1767–1785 елларда таралган әдәби хәрәкәт турында бара. Агым Фридрих Максимилиан фон Клингер пьесасы исеме белән аталган, татарчага «Җил-–-авыл һәм һөҗүм» дип тәрҗемә ителә. Идеологы – француз язучысы Жан-Жак Руссо карашларын уртаклашкан алман фәлсәфәчесе Иоганнн Георг Гаман. Бу агым вәкилләре, аң культыннан баш тартып, иҗатта һичбер кысалар белән чикләнмәгән индивидуальлекне ачуга йөз тоталар.

[6] Семён Афанасьевич Венгеров (1855–1920) – тәнкыйтьче, әдәбият тарихын өйрәнүче, библиограф һәм редактор.

[7] Мәфһүмен – төшенчәсен.

Элек Франциядә башланып, шуннан соң Англия, Америка, Скандинавия, Германия, Италия һәм башкаларда, соңыннан рус әдәбиятында шаулап киткән бу символизм агымы башта «декадентлык» агымы дип аталды. Декадент – «егылучы» мәгънәсендә. Болар егылу дәверенең вәкилләре саналалар һәм «авыру бер гасырның балалары» дип сыйфатланалар. Болар – бетүне алдан сизеп, шуның белән нервылары өзгәләнгән шагыйрьләр. Рус символистларыннан (декадентларыннан) К. Бальмонт декадент шагыйрьгә «нечкәләнгән һәм үзенең шул нечкәләнүе эчендә һәлак булган бер шагыйрь» дип яхшы характеристика биргәннән соң, моны түбәндәгечә изах кыла[1]: «Декадент» дигән сүзнең үзеннән дә аңлашылып торган шикелле, болар – егылу-инкыйраз дәверенең вәкилләре. Болар берсе тәмам булган, икенчесе әле тумаган ике дәвернең чигендә торып уйлыйлар һәм шул чиктә торып хис итәләр. Болар менә нәрсәне күрделәр: кичке шәфәкъ югалды, ләкин әле таң кайдадыр декадентларның офыклары артында йоклый. Әнә шунлыктан декадентларның җырлары караңгылы-яктылы бер вакытның һәм төн заманының җырлары булдылар. Алар искедән йөз дүндерделәр. Чөнки иске үзенең рухын югалткан һәм үлек бер схема рәвешенә әйләнгән иде. Ләкин яңаның алдында торып, искедә үскән бу шагыйрьләрнең үзләре шул яңаны күрә алырлык хәлдә түгел иделәр. Менә шуның өчен дә аларның настроениеләрендә иң шатлыклы, күтәренке бер бетү белән бергә шулкадәр дә күп авыр эч пошулар, сагышлар, кайгылар да бар иде».

Декадентларда өслүбнең төп алымы рәвешендә символ булмауга карап һәм башка кайбер сәбәпләрдән, аны символизм өслүбенә капма-каршы бер өслүб итеп куючылар да юк түгел[2]. Ләкин, ничек булганда да, декадентлык төбендә, үзенең идеологик тамыры, шулай ук төп өслүб хосусиятләре белән шул ук символизмнан, аның беренче кыягыннан башка нәрсә түгел.

Профессор Коган декадентлык белән символизм турында түбәндәгечә яза: «Декадентлыкны символизмнан аеручы чик булуга карамастан, бу ике агым – төбендә бер үк үзәкнең аерым тармаклары. Символизм дөньяда билгеле бер мистикалы караш булса,

[1] Изах кыла – аңлата.

[2] Берцкий и Сидоров – «От символизма до Октября», 32 нче бит, Л. Денисов хаты. Шул ук мәҗмугада декадентлыкның символизмда йотылуы, черүе дә әйтелә. *(Авт. иск.)*

декадентлык та үзендә нечкәлек өчен нечкәлек күрсәтә. Символизм билгеле бер мистикалы мөндәриҗәне һәм үзенең теге дөньядагы серле тормышка кушылуга, шул «чиксез тормышның стихиясе»н чумырып алуга омтылуын шигъри формага салса, декадент сүзләрнең кушылуларын, шул кушылуларның үзләре өчен сөя, саф шыңгырауны, үткенләү-остаруны һәм уйлап чыгаручыларны сөя. Аны музыкачыларның нәкъ үзе һәм авазларның ташучылыгы, сүзләрнең мәгънәләре белән дә, мөндәриҗәләре белән дә багланмаган хуш исләре (аромат[1]) сафландыра»[2], – ди.

Шуңа декадентларның да, символистлар шикелле үк, акылдан, конкрет аңлаучылыктан качуларын кушарга кирәк. Дөрес, декадентлар турында аларның акылдан качмаганлыкларын әйтүчеләр дә юк түгел. Ләкин бу фикер хата.

Көнбатыш декадентлыгы һәрнәрсәдән элек эстетикачылык – суык һәм үзенә-үзе төренгән бер эстетикачылык белән, шулай ук чиксез бер индивидуалистлык белән сыйфатланганын югарыда күреп үттек. Рус декадентлыгы да шулай.

Рус әдәбиятындагы символизм агымын икегә, ягъни ике чор яки буынга аералар. Берсе – XIX йөзнең ахырыннан 1905 ел революциясе алдынача булган чор. В. Соловьев, Н. Минский[3], Д. Мережковский, К. Бальмонт, Ф. Сологуб, З. Гиппиус, Валерий Брюсов һәм башкалар шул беренче буыннан саналалар. Декадентлык та нә шул беренче буынга нисбәт ителә. Икенче чор яки икенче буын исә – 1905 ел революциясе алдыннан Октябрьгәчә (бер агым булып дәвамы 1909 елгача) дәвам иткән буын. Вячеслав Иванов, Андрей Белый[4], Ю. Балтрушайтис[5], С. Соловьев[6], А. Блок һәм башкалар – шушы соңгы буын символистлар. Рус символизмының беренче буыны көнбатыш декадентлыгына охшаган бер декадент-

---

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] Коган. «Литература великого Х–летия», 1927 г., стр. 25. *(Авт. иск.)*

[3] Николай Максимович Минский (Виленкин; 1855–1937) – рус символист шагыйре.

[4] Андрей Белый (Борис Николаевич Бугаев; 1880–1934) – шагыйрь, язучы, тәнкыйтьче, рус символизмының һәм гомумән модернизмның иң күренекле вәкилләреннән берсе.

[5] Юргис Казимирович Балтрушайтис (1873–1944) – рус һәм литва шагыйре, тәрҗемәче һәм дипломат.

[6] Сергей Михайлович Соловьев (1885–1942) – рус шагыйре.

лык санала. Сологубның: «Тормышның тупас һәм буш бер кисәген алам да, шуннан тәмле легенда тудырам, чөнки мин – шагыйрь», – диюе; Брюсовның да: «Тормыштагы һәрнәрсә – шыңгырап-яңгырап торган тезмә өчен тик бер васита гына», – дип каравы бу турыда мәсьәләгә шактый ачыклык бирә. Шуңа Брюсовның югарыда күрсәтелеп үткән «Яшь шагыйрьгә»се белән «Иҗат» дигән шигырен кушарга кирәк.

Җылау-сыкрау, җан әрнү, тормышта гел аһ-зар күрү, тормыштан качу, үлемне чакыру, аны мактау – менә беренче буын символизмның (декадентлыкның) хосусиятләре шулар. Алар тормышны «тәмле легенда», «сер» белән алыштыралар, үз-үзендә онытылу һәм көчсезлекне тәлкыйн итәләр[1]. «Хыял музыкасы», «сүз музыкасы» – аларда һәрнәрсә. Аларның бөтен ләззәте, тормышы шуларда, шулай ук аларның бөтен тын алышлары эротикачылыкта. Бигрәк тә үз аңыңны һәм үзеңне генә бар дип белү, фәнни тәгъбир белән әйтсәк, солипсизм – аларның төп иҗат стимуллары.

Әмма икенче буын символистлар – «яшь символистлар» исә бу яктан алардан аерылалар. Болар (Андрей Белый, А. Блок һәм башкалар) солипсизмга каршы рухталар. Болар «көлли вәхдәт»че[2], ягъни күпле берлекчеләр. Шуның белән бергә, тегеләр кебек пассив түгел, активлар. Шагыйрьнең пәйгамбәрлек хезмәтен алга куючылар. Үзләренең дини-фәлсәфи идеяләрен тормышка кертергә омтылучылар.

Ләкин болар әнә шул рәвешчә бер-берсеннән никадәр генә аерым күрсәтелмәсен, һәрхәлдә, аларның иҗтимагый тамырлары бер. Боларның икесенең дә төп стихиясе – романтик мистикачылык, ягъни матди тормышта урын таба алмаучылык, матди тормыштан качу, аннан аерылудан гыйбарәт.

Көнчыгыш символизмы рус символизмының икенче чорындагысына якын, ягъни төбендә болар тәмам бер-берсенә охшыйлар.

Гомумән, кирәк көнчыгыш-төрк символизмында, кирәк көнбатыш-рус символизмында булсын, боларның сюжетлары мистик әкиятләр, йокы, саташу, адашу, акылсызлану, тилерү, төрле чуалулар һәм гадәттән тыш батырлыклардан гыйбарәт. Мотив – саф лирикачылык, ягъни тик үзеңнең шәхси кәефләреңне, үзеңнең башыңнан

---

[1] Тәлкыйн итәләр – сөйлиләр, аңлаталар.
[2] Көлли вәхдәт – универсаль ялгызлык.

кичерүләреңне бирү, бигрәк тә мистик һәм дини баштан кичерүләр. Боларда да мәңгелек, сер, кояш, шайтан, җен, пәри, төш күрү, албасты, ут, ялкын, Алла һәм башкалар турында сөйләнә. Боларның иҗат каләмнәрен гыйшык-эротика әйләндерә. Аларның матур хатыннарны һәм табигать манзараларын сөйләүләренең тамырында илаһи гыйшык ята, ягъни алар бу сөюне шул үзләренең төп идеологик максатлары өчен алалар, илаһи гыйшыкның символы итәләр. Болар – «мәңгелек тормыш» шатлыгы тудырып, шул шатлык эчендә ирешүчеләр. Валерий Брюсов символистлар өчен дүрт төрле шатлык күрсәтеп, түбәндәге маддәләргә кайтара:

1. Гыйрфан (эчке сизү белән белүчелек) эчендә – шөгурияттә яшәү.

2. Нурлы ут эчендә яшәү – «шигырь төргәкләре (строфа[1])лар – тормышның мәгънәсе».

3. Сөелгән булу шатлыгы – мәңгелек[тә] үзеңнең ялгыз булмавыңны күреп тору – «тирәнлек куркынычы эчендә без икәү очабыз».

4. Алдагын сизү шатлыгы – үлемнән соң тормыш дөньясы бар дип белеп тору: «йокы ул – җитлегү (камилләшү). Хыялда һәм шигырьдә сезне табынып котлыйм мин. Тормышта яшерен шатлыклар күп. Тормыш башыннан ахыргача ләззәтле. Бу шатлыклар – Алладан хәбәр бирүчеләр» («Отрады»[2] шигыренә кара. – «Русская поэзия XX века» мәҗмугасы, 53 нче бит. Бу шигыре 1900 елда язылган.)

Рус әдәбиятында символизм шигырен дәвамлы рәвештә бирүче шагыйрь Александр Блок булды. Рус символистлары эченнән башка берничәләре, бигрәк тә В. Брюсов үзенең символистлыгын шагыйрьлегендәге һәм идеологиясендәге үсү баскычларыннан берсе итеп калдырды. Хәтта Брюсов ул вакыттагы хәлләрен үзләренең балалыгыннан саный.

Чынлап та, революция рус символистлары арасына таралу, таркау кертте. Символистларның бер кыйсеме революция дошманлыгы юлына кереп китте һәм, шул элекке мистикачылыкка тагын да ныграк батып, шунда харап булдылар. Бер кыйсеме исә (мәсәлән, Брюсов һәм А. Блок кебекләр) революция юлына кереп, үзләрен төзәтәләр, хәтта Брюсов идеологиясе белән дә материалистлык юлына төште һәм партия сафына кереп эшләде, әдәбиятта да ре-

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

алистлыкка әйләнде. Тик А. Блок кына, революциягә кушылган хәлдә, һаман символистлыгыннан аерыла алмады. «12»се – шуның ачык мисалы (Кави Нәҗми тәрҗемәсенә кара).

Гомумән символизм белән шул рәвешчә аны уртак бер әдәби хадисә иттереп алып танышканнан соң, инде татар әдәбиятындагы символизмга күчәбез. Мондый гомуми танышу татар әдәбиятындагы символизмны яхшы аңлау өчен кирәк иде. Шуның өчен бу бүлем алдагы бүлемнең кыскалыгына да ярдәм итәчәкләр.

**Икенче бүлек**

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА СИМВОЛИЗМ

### I. Октябрьгә кадәр татар символизмында ике мәктәп һәм аларның классик вәкилләре

Китапның «Кереш» бүлемендә, шулай ук башка бабларында[1] символизмның бөтен көнчыгыш һәм көнбатыштагы дворян-буржуа әдәбиятларында уртак бер әдәби хадисә булганлыгын әйтеп үттек һәм шуны күп кенә дәлилләр белән күрсәтә килдек. Татар әдәбиятындагы символизм әнә шул уртак әдәби хадисәнең органик бер өлеше булып мәйданга чыкты.

Татар символизмының да үзенең эчке иҗтимагый тамыры, икътисади зәмине бар. Ләкин бу да шул көнбатышныкы белән (русныкы да шуның эчендә), гомумән, бер үк характерда.

XIX йөзнең соңгы ярымы – татар буржуазиясенең икътисади-иҗтимагый тормышында уяну, яурупалашу заманы. Шул заман эчендә татарның сәүдә капиталы яурупа һәм рус сәүдә капиталы белән тоташып, шуның методы белән яңа техника шартлары эчендә эш итә башлады. Шуның нәтиҗәсендә татар буржуазиясендә шул йөзнең ахырларында яурупа һәм рус буржуа мәдәниятенә таба әйләнеш ясалды. Татар буржуасы яурупа һәм рус буржуа мәдәниятен алып, шуның аркылы үзенең сыйнфый интересын саклап барырга, рус буржуазиясе белән икътисади-сәяси, мәдәни-иҗтимагый

[1] Бабларында – бүлекләрендә.

һәм хокукый яктан бер дәрәҗәгә җитәргә, һич булмаса, рус буржуазиясеннән калышмаска омтылды. Шулай итеп, ахырда, милләтчелек һәм мөселманчылык байрагы астында татар гына түгел, хәтта Россиядәге бөтен төрк-татар халкы өстеннән хаким сыйныф булып барырга теләде, шул юл белән татар буржуазиясе үзенең икътисад-иҗтимагый һәм мәдәни ролен Яурупа һәм рус буржуазиясе алдында танытырга, шуны көчәйтергә уйлады. Иң ахырда бөтен төрк-татар халкын берләштереп, аерым төрк-татар буржуазиясе патшалары тудыру ноктасын төп идеал итеп куйды. Чөнки татар буржуазиясенең сыйнфый интересы өчен шул идеал алдавыч матур бер соңгы нокта иде. Рус самодержавиесе шул теләкләргә ирешүгә мөмкинлек бирмәячәген күреп, татар буржуазиясенең алдынгы төркемнәрендә, укымышлыларында рус самодержавиесенә каршы хәрәкәт итү эшләре дә астыртын башкарыла торды. Рус буржуазиясенең революцион хәрәкәтләренә яхшы каралып, шулар белән бергә кушылып хәрәкәт итү сызыклары билгеләнә килде.

Менә 1905 ел революциясе кузгалды. Татар буржуазиясе, үзенең төрле иҗтимагый төркемнәре белән бергә, шул революция заманында үз интересы, үзенең югарыдагы бөтен теләкләренә, идеалларына ирешү чараларын күрү юлында үзенә нык кына бер хәрәкәт ясап карады. «Ислахчы шәкертләр»[1], приказчиклар һәм эсер «таңчылар»[2] шикелле вак буржуа иҗтимагый төркемнәрнең, гомумән, татар буржуа хәрәкәтенә каршы кайбер тышкы бәрелешүләре, үпкәле каршылыклары, тышкы кызылланулары булса да, болар татар буржуазиясен (либераль буржуа) куркытмый иде. Чөнки аларның төбендә тиздән шул ук бер юлга – либераль буржуа юлына кайтып төшәчәге һәм төшә башлаганлыгы ачык иде. Моны татар буржуазиясе төшенеп барды.

Ләкин татар буржуазиясе өчен шушы революциядә бөтен буржуазиягә каршы куркыныч тудыручы гомуми рус пролетариаты

[1] XX гасыр башында бер төркем татар шәкертләре милли мәгариф системасын үзгәртү таләбен куялар. Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре арасында оештырылган әлеге хәрәкәт ислахчылар булып тарихка кереп кала. Хәрәкәтнең идеологы Ф. Әмирхан була.

[2] 1906 елда Г. Исхакый, Ф. Туктаров һәм Ш. Мөхәммәдьяров тарафыннан таңчылар хәрәкәте оеша. Исеме «Таң йолдызы» газетасы белән бәйле бу хәрәкәт идеологик яктан рус социал-революционерлары (эсерлары) фикерләренә аваздаш була.

хәрәкәте белән бергә татар пролетариат хәрәкәте һәм «уралчылар»[1] аркылы татар арасына пролетариат идеологиясе таралу зур куркыныч тудырып куйды. Чөнки бу – татар буржуазиясенең идеалына каршы татарның үз эченнән килеп чыккан пролетариат гаскәрләре иде.

Реакция башланды. Бу – пролетариат хәрәкәтен шәфкатьсез кысуы, буып торуы (әлбәттә, вакытлы рәвештә) ягыннан гомум буржуа белән бергә татар буржуасы өчен дә шатлыклы хәл иде. Чөнки моның белән буржуа өчен, һәрхәлдә, азмы-күпме сулыш озаю тәэмин ителә иде. Ләкин шуның белән бергә, татар буржуазиясенең үз хәрәкәтен уйланганча тулы көченә дәвам иттерү өчен, реакция уңайлы шартлар тудырмады, ягъни бишенче ел революциясеннән либераль буржуазиянең көткәннәре дә реакция сәбәпле байтак ягыннан кысылды. «Төп идеал»га таба хәрәкәт авырлашты. Шул рәвешчә, бер яктан, гомум пролетариат хәрәкәтеннән өркеп калган, икенче яктан, реакциянең аның үз теләкләренә тиздән ирешүенә комачаулавын һәм татар буржуазиясенең гомумән рус буржуазиясе алдында көчсезлеген күргән кайбер татар либераль буржуа укымышлыларында (Дәрдмәнд[2] кебек) өметсезлек туды. Иҗтимагый-сәяси тормышта көтелгән яки уйланган урынны ала алмауга күз җитте. Шуның белән бергә, никадәр газапланса да, барыбер, татар буржуазиясе күтәрелгәнче, бөтен буржуазия сыйныфының җимерелүе сизелде.

Татарның вак буржуа төркемнәреннән күпләре реакциядән бөтенләй тетрәп калдылар. Кайберләре, көндәлек тормышны тәэмин итүгә бирелеп, мещанлыкка әйләнсәләр, кайберләре үзләрендә һәм милли татар буржуазиясендә, милли буржуа укымышлыларында, кирәк сәяси, кирәк иҗтимагый, мәдәни һәм гыйльми яктан тәмам көчсезлек күреп, татар тормышыннан өметсезлеккә төштеләр

[1] Сүз 1907 елның 4 гыйнварыннан алып 27 апреленә кадәр Оренбургта атнасына 2–3 тапкыр нәшер ителгән «Урал» газетасы тирәсендә тупланган татар революцион-демократлары төркеме турында бара. Газетаның фактик җитәкчеләре Х. Ямашев һәм Г. Сәйфетдинов була. Язмаларның күп өлешен Х. Ямашев бастыра; газета белән Г. Коләхмәтов хезмәттәшлек итә. Газетада дөнья күргән мәкаләләрдә халыкның тормышын яхшырту бары тик революцион көрәш аша гына мөмкин дигән фикер ята. Ул эшчеләрнең стачка хәрәкәте, крестьяннар һәм укучы яшьләр чыгышлары турында мәгълүмат бирә.

[2] Дәрдмәнд (Мөхәммәдзакир Мөхәммәдсадыйк улы Рәмиев; 1859–1921) – шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, нашир, берничә алтын приискасы хуҗасы.

(Тукай, Сәгыйть Рәми һәм башкалар). Пролетариат хәрәкәтенә бер хыял дип кенә карадылар, либераль буржуазия хәрәкәтеннән канәгатьләнмәделәр. Реакциянең бу соңгысын да кысуы күренгәч, татарның иҗтимагый-мәдәни тормышының киләчәгеннән бөтенләй өмет кистеләр, гүя татарның бөтенләй бетү, югалуын сизделәр. Реаль тормышта үзләренең урыннары, рольләре юклыкны яки югалуны күрделәр. Әнә шул аларда каршы сагыш тудырды.

Кирәк эре буржуа, кирәк вак буржуа укымышлыларында булсын әнә шундый хәлләр төшенкелек, реаль тормыштан бизүчелек, икенче бер ниндидер хыялый дөньялардан һәм «мин»челектән юаныч эзләүчелек юлына сөркеләде: мистикага батырды. «Саф сәнгать»кә табыну мәелен[1] тудырды, шуннан үзләре өчен юаныч эзләнде.

Әнә шуннан реакция елларында татар әдәбиятында романтизм көчәйде һәм символизм баш күтәрде.

Бик кыскача әйткәндә, татарда романтизм һәм символизмның иҗтимагый һәм психологик зәмине әнә шулай булды. Димәк, татарда символизм татар буржуазиясенең игътисади, иҗтимагый-мәдәни хәрәкәтендәге тетрәү һәм ышанычсызлык нәтиҗәсе иде.

Бу – бер. Икенче яктан, шул эчке иҗтимагый-икътисади зәмингә муафикъ рәвештә татар буржуа һәм вак буржуа шагыйрьләренә, гомумән, чит әдәбиятларның, ягъни көнчыгыш (бигрәк чыгтай һәм госманлы) һәм яурупа-рус символизмнарының да зур тәэсирләре булды.

Татар халкының ике төрле – икътисади-иҗтимагый һәм мәдәни тәэсир астында килгәнлеге беленде. Моның берсе – Урта Азия (көнчыгыш) мәдәнияте, икенчесе – рус мәдәнияте. XIX йөзнең соңгы чирегенә кадәр икътисади яктан да, мәдәни яктан да татар буржуазиясенең нык бәйләнеше Көнчыгыш белән иде. Шул вакыткача татарның сәүдә капиталы тамырын шул яктан үстерде, ә XIX йөзнең ахырларында бу турыларда рус буржуазиясенең икътисади-иҗтимагый хәрәкәте, рус мәдәнияте үзенең нык тәэсире астына алды[2]. Бу да татар өчен чарасыз, котылгысыз бер хәл иде.

1905 ел революциясенә килеп кергәндә, инде татар буржуазиясенә рус буржуазиясенең иҗтимагый-мәдәни тәэсире һәр яктан нык көчәйгән иде.

[1] Мәелен – омтылышын.

[2] Бу турыда тулырак мәгълүмат алырга теләүчеләр «Татар әдәбияты тарихы» исемле китабыбызга кайтып карарлар. *(Авт. иск.)*

Шул хәлләрнең нәтиҗәсе булып, бишенче ел революциясеннән соң һәм реакция елларында татар буржуазиясенең әдәби хәрәкәтендә һәм, гомумән, татар әдәбиятында ике төрле әдәби тәэсир үзен ачык сиздереп барды. Боларның да берсе чыгтай һәм госманлы әдәбияты тәэсире булса, икенчесе дә рус әдәбияты тәэсире иде. Эре буржуа шагыйрьләре төркчелек – бөтен төрк халыкларының берлеге лозунгысы белән хәрәкәт иткәнгә, алар чыгтай һәм госманлы тәэсирен үстерәләр (Дәрдмәнд, Н. Думави[1] һәм башкалар), вак буржуа шагыйрь-әдипләре дә, татарчылык юлын тотканлыкларыннан һәм турыдан-туры рус әдәбиятына нык бәйләнгәнлекләреннән, үзләре аркылы рус әдәбияты тәэсирен ачык күрсәттеләр (Сәгыйть Рәми, М. Хәнәфи[2] һәм башкалар).

Шул ике төрле мәдәни-әдәби тәэсир татар әдәбиятында символизм агымын да ике тамырлы, ике канатлы ясады.

Татар әдәбиятында символизм чаткылары Шәмсетдин Суфи[3] аркылы ук (XIX йөз) чәчри башласа да, бер әдәби агым рәвешендә ул башлап реакция елларында (1907–1908 елларда) туды. Берсе – эре буржуа, сәнәгать буржуасы шагыйре Дәрдмәнд шигырьләре аркылы, югарыда әйткәнебезчә, чыгтай һәм госманлы символизмы тәэсирендә, икенчесе – Сәгыйть Рәми шигырьләре аркылы рус символизмы тәэсирендә башлап мәйданга чыкты. Шуның артыннан соңгысын чәчмәдә[4] Февраль революциясенәчә М. Хәнәфи дәвам иттерде һәм аңа шул сызыкта ачык физиономия казандырды.

Дәрдмәнднең «Бүзләрем мана алмадым», «Без», «Кораб» һәм «Хәят» дигән шигырьләре (бигрәк тә соңгысы) югарыда сөйләгәннәргә бик ачык мисал була алалар.

Бу урында Дәрдмәнднең югарыдагы бөтен шигырьләреннән мисал алырга мөмкин түгел. Шуның өчен аның «Хәят» дигән һәм үзендә көнчыгыш символизмының тәэсирен иң ачык күрсәткән

[1] Нәҗип Думави (Нәҗип Сибгатулла улы Тахтамышев; 1883–1933) – язучы, әдәби тәнкыйтьче һәм публицист.

[2] М. Хәнәфи (Мөхәммәтхәнәфи Сәетгали улы Кайбышев; 1892–?) – язучы. Татар әдәбиятына хас булмаган үзенчәлекле күп әсәрләр яза. Татар дөньясындагы гомуми атмосфера хакында аналитик күзәтүләр авторы.

[3] Шәмсетдин Зәки (Шәмсетдин Ярмөхәммәт улы Гобәйдуллин, Шәмсетдин Суфи; 1821–1865) – суфи шагыйрь.

[4] Чәчмәдә – прозада.

шигыреннән берничә мисраг китерү белән генә канәгатьләнергә мәҗбүрбез.

Бу шигырендә без аның түбәндәге мисрагларын укыйбыз:

Сәер итеп, күр, канча сәнгать сарыф итеп дәсте әзәл,
Ни бәдаигъларны төзде, тезде хөсне багыны:
Илтимас итмеш әбәт кем (чөн будыр хөкме самад!)
Гыйшкы багыннан кичеп үтсен җиһан чардагына. <...>
Хикмәте хөкеме кадәрдән ба хәбәр булсаң әгәр,
Әй күңел, тап чара, өстә яра гыйшкы дагына.
Гыйшкы җәннәттер, морад итсәң хәяты җавидан.
Кер аңа вә кермә ул мәрдүт фәна япрагына.
Дәрде гыйшкы нирвәнәй шәмгы, «Дәрдмәнд» пәрваниясе
Ул канып күчте, янып кичте бәка тупрагына.

Шигырьнең, хәзерге татар теленә әйләндереп әйткәндә, мәгънәсе болай була: «Әнә кара әле дөньяга, тамаша ит әле шуны: искиткеч һәм һичкемнең кулыннан килми торган бер матурлык бит ул. Бу – ул матурның («төп барлык» – Илаһның) бакчасы бит. Шуны төзеп, анда ул үзенең матурлыгын (хөснен) тезде. Моны аның мәңгелеге теләгән. Җиһанны үзенең чардагына (гали урынына) үзе ясаган гыйшык бакчасыннан кичереп үткәрергә дип хөкем итеп куйган да әнә шул матур бакчаны эшләгән ул. Әй күңел! Әгәр тәкъдирнең хөкеменнән хәбәрең булса, чарасын тап та аның гыйшкының биргән каты ярасына тагын да яра өстә: тагын да каты ян, үртәл шуның гыйшкы белән. Мәңгелек – бетми торган «чын» тормыш эстәсәң, бел, аның гыйшкы – җәннәт. Бар, кер шул җәннәткә, кермә бу бетә торган, начар дөнья туфрагына, ягъни кач бу сөрелгән дөньядан. Аның гыйшкы (ягъни Алланың – «Хак»ның) – янып торган бер ут, ә мин – Дәрдмәнд – шул ут тирәсендә әйләнеп, очып йөрүче күбәләкмен. Аның гыйшык ләззәте белән янып, шуның утында янып, мин мәңгелек тормышның туфрагына үттем инде» (ягъни бу «фани, пычрак» дөньядан аерылдым, дигән сүз).

Дәрдмәнд бу шигырендә, «Хәят» (тормыш) дип алып, гүя үзенең мәгъшукасын, аңа мәхәббәтен, аның турындагы сагышын җырлый, ә бу мәгъшука, төбендә, матди дөнья матуры түгел, бәлки «хак» яки «чынбарлык» – «хакыйкый барлык» (Илаһ) булып чыга. Ул әнә, төбендә, шуңа гыйшкын тасвирлый, «Хәят»ны шул ук хыялындагы «төп хәят»ка символ итә. Фөзүли аны Ләйлә аркылы биргән булса,

Дәрдмәнд Хәят аркылы бирә. Ләйләнең гашыйгы Мәҗнүн булса, Хәятның шул ук Мәҗнүн урынындагы гашыйгы – Дәрдмәндтә күрсәтелә.

Татарда символизм өслүбе турында сүз барганда, Дәрдмәндтән соң Нәҗип Думавига тукталырга тиешбез. Бу шагыйрь шигырьләре белән Көнчыгыш тәэсирендәге символизмның алдынгы вәкилләреннән булган шикелле, ул шул ук вакытта символизмның теориясен тудырырга тырышучы да булды. Ул, менә шушы «хакыйкать» эзләүче шагыйрь, 1911 елгы «Шура»ның № 1 ндә «Хакыйкать артыннан» дигән хыялый-фәлсәфи хикәясендә символизм фәлсәфәсен болай тәкъдим иткән иде: «Һәр инсан үзенең рухани вә мәгънәви сәгадәте[1] өчен «Хакыйкатьне» эзләргә мәҗбүр». Шагыйрь үзенә зур симпатия белән караган бер каһарманнан сөйләтә: ***«Минемчә, "хакыйкать"-не хәүвас[2] илә дә түгел, акыл илә дә түгел, бәлки сәламәт калеб илә эзләргә тиешле».*** Менә шушы «хакыйкать» эзләүче шагыйрь 1914 елгы «Аң» журналының 13 нче санында язган «Хакыйкать эзләү» дигән хикәясендә символизмның теориясен утырту юлында түбәндәге фикерләрне язды:

«Мине нәрсә уйлатканын белмим. Әмма шуны яхшы беләм ки, һичбер вакытта да үземнең хисләремнән башка белгәнем юк; уйлый алганым юк. Шуның өчен әйтәм ки, ***җаным – хисләрем***».

«Мин мәңгелек бер кодрәткә сәҗдә итәм, әмма аны аңлау, аңа җитешү мөхал[3], димен». «Мин җанның, Алланың барлыгын сизәм, әмма ничек, ни белән сизгәнемне белмим һәм җан белән Алланы аерта башласам, аерырга да белмим. Алар икесе ике нәрсәме, берме – ләкин барлыкларын сизәм».

Шуңа тагын Н. Думавиның Җ. Вәлиди[4] тарафыннан «Шәрыктан гаребкә» исеме астында язылган мәкаләгә каршы 1916 елда «Аң»-ның 9 нчы санында язылган фикерләреннән түбәндәге өземтәләрне кушып укыйк:

«Гомерендә гыйшык татымаган кешедә хәят юк, дигән бер сүз бар. Бу сүз дуамалга гына әйтелгән сүз булмаска кирәк. Хәятны

[1] Сәгадәте – бәхете.

[2] Хәүвас – хисләр.

[3] Мөхал – мөмкин түгел.

[4] Җамал Вәлиди (Җамалетдин Җәләлетдин улы Вәлидов; 1887–1932) – тел галиме, тәнкыйтьче, әдәбият тарихчысы, педагог, җәмәгать эшлеклесе.

әллә ничәгә бүлеп йөртергә мөмкин булса да, сүз озаймасын өчен, мин адәм фән белән түгел, хыял белән яши, димен. Адәм машина да түгел, багаж да түгел, адәм – үлчәнүдән бик югары, бик гали нәрсә ул. Моның өчен кечкенә бер мисал – тимер юлда утырып хаҗга баручыда. Ул вагон эчендә багаж булып утырып баруын уйлап та тормый, аны яшәткән нәрсә – хыялындагы иманы. Бу кечкенә бер мисал булды. Әнә бер скульптура, әнә бер сүз, әнә бик шәп бер музыка. Менә шулар чынлап да аш, азык икән, аларны фән, акыл куйган үлчәүгә дә хаҗәт юк – үлчәүләр салкын нәрсәләр алар. Үлчәүләренә салып торырга бер дә хаҗәт юк аларны. Хәят – «хыялда шулардан бер карауда аңкып торган» мәгънәсендә; ул мәгънә үлчәнә торган нәрсә түгел».

«..Ләкин вакыйга иман, гыйшык, хыял – һичкайсы фәнгә сыймыйлар. Алар фәннән качалар. Бу сүзләрне, бу дәгъваларны ни белән изах итим: фәнни, аклый итеп[1] красота[2] аңлау хыялны, гыйшыкны, иманны үтергән дә, мөҗидләр символизм, романтизм юлларын ачканнар».

«Зур адәмне үз зурлыгында яшәткән нәрсә – адәмнең иркен, киң хыялы. Бу хыял, мондагы иман, мондагы гыйшык берсе дә фәнгә, акылга сыймыйлар. Ләкин акыл бик усал: эзәрләп, артларыннан үрмәләп, һаман аларны ихата итәргә маташа. Аның характеры шул».

«Дөрес, адәм ходайлыкны сөя, адәм үзен Илаһ хисап итәргә һич тартынмас. Ләкин мондый салкын мәгънәдә, мондый хайвани әсаслар[3] белән түгел (ягъни акыл әсасы белән дигән сүз), монда кодсият[4], пакьлек тә юк».

Бу өземтәләр артык изах сорамыйлар; болар – бик ачык аңлашылып торган нәрсәләр.

Бу урында тик шуларда Н. Думавиның түбәндәге шигырьләреннән мисаллар кушыйк та шуның белән бу шагыйрьнең нинди символистлыгын төгәл күреп үтик.

Ул 1912 елгы «Йолдыз» гәзитенең 5 майда чыккан санында «Үзгәрү» дигән шигырен бастырды. Бу шигырьне бөтене белән бу урында китерү мөмкин түгел, ялгыз аннан түбәндәге юлларны гына күчерәбез:

[1] Аклый итеп – акыл белән.
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] Әсаслар – нигезләр.
[4] Кодсият – изгелек, сафлык.

Кайгы, хәсрәт, ихтыяҗ, горбәт мине изгән иде.
Тормышымнан, дөньясыннан да күңел бизгән иде. <...>
Төн матур, саф тышта һава, ялтырый йолдызлы күк,
Әтрафым якты, ачык дөнья тәмам көндезге күк.
Мин шулай бер ялгызым кырда торам күккә карап;
Күк шары торган кебек һәм мин гаҗиз чүпкә карап.
Белмимен кайдан, ничек килде миңа шундый куәт:
Мин югалдым сәҗдәгә, күздән ага яшь мөлдерәп.
Җитми тел тәгъриф итәргә[1], миндә шундый бер халәт:
Мин оныттым кайгы, хәсрәт, горбәтемне шул сәгать.
Кыскасы, чын мәгънәсилә кайттым Аллага хәзер
Мин гаҗизгә күк назир, йолдыз назир, Алла назир.
Мин күтәргәндә башымны сәҗдәдән, күңелем тулы
Шат вә рәхәтлек белән, күкрәк тәмам иркен сулый. <...>
Дәр вакыйг[2] мин өр-яңа бу дөньяга төшкән кебек,
Яңа тән ләззәт илә шул дөньяда пешкән кебек.
Башладым ихлас илә тормыш итәргә талпынып,
Юк хәзер миндә азап чикмәк, галәмне тарсынып.

«Аң»да басылган «Син кеше!» дигән шигырендә янә:

«Син – бөек! Салган Ходай күктән
синә үз орлыгын!
Бул гали! Таптама, зинһар,
шул «ходайлык» зурлыгын!..» –

ди. Шул ук «Аң»ның 1916 елгы 15 нче санында «Тәңре» дигән шигыре дә символизм фәлсәфәсен бирә:

«Сез бөек! Бар ихтыяр берлән,
Тәңре, без – сезнеке,
Без бары куркак... уен, «тәкъдир»,
бөтен «эш» сезнеке!» –

ди.

Иллюстрация төгәлрәк булсын өчен, аның тагын шул ук «Аң»ның 1917 елгы 8–9 нчы саннарында басылган «***» сәрләүхәле шигыреннән түбәндәге мисалларны укыйк:

[1] Тәгъриф итәргә – сөйләп-аңлатып бирергә.
[2] Дәр вакыйг – чынлыкта.

Мал кирәкми, дан кирәкми,
Җан кирәк, җәнан[1] кирәк.
Шан кирәкми, сан кирәкми
Яр кирәк, висаль[2] кирәк.

Кол кирәкми, тол кирәкми,
Кыз кирәкми, наз кирәк.
Тән кирәкми, кан кирәкми,
Сүз кирәкми – саз кирәк... <...>
Әй хуры, кайда мәкянең[3],
Илһам ит, кайдан табыйм?
Ачмасаң гарзың никабың[4],
Мин сине кайдан таныйм.

Менә шул югарыдагы өземтәләр һәм шигырьләреннән китерелгән шул мисаллар безгә көнчыгыш төрк әдәбиятларындагы символизм нигезендәге бер символист, ләкин пассив түгел, актив бер символист икәнен, Дәрдмәнд белән бер тамырдан булганын ачык күрсәтәләр. Ялгыз Дәрдмәндтә символ моңа караганда күп катлаулы, оста һәм күп нәзек тукылганнар.

Көнчыгыш-төрк әдәбиятлары тәэсирендәге символизм мәктәбен һәм шул мәктәпкә мәнсуб[5] символистларны шул үз урынында тәмамлап үтик.

Монда без Мәҗит Гафурига[6] аз гына тукталып үтәргә телибез. Бу шагыйрьнең дә символизм мәктәбенә кайткан вакыты һәм шуның нәтиҗәсе булып туган шигырьләре бар. Ул 1911 елгы «Шураның № 2 ндә түбәндәге шигырен бастырды:

Кайвакытта әллә нишләп әйләнәм ямьсезләнә:
Бер югалган нәрсәсе бар төсле, күңелем эзләнә.
Бер урында тормый күңелем, тибрәнә, тапмый карар,
Җир йөзе нурсызлана, бал-майлары тәмсезләнә.
«Җир йөзендә чын сәгадәт юк» дип әйтеп куям:

[1] Җәнан – йөрәк, күңел.
[2] Висаль – кавышу.
[3] Мәкянең – торган урының.
[4] Гарзың никабың – йөз пәрдәңне.
[5] Мәнсуб – нисбәт ителгән.
[6] Мәҗит Гафури (Габделмәҗит Нургани улы Гафуров; 1880–1934) – язучы, публицист.

Әй күңел, җирнең йөзеннән чын сәгадәт эзләмә.
Әйләнәмдәге матурлыкларны тиң күрми күңел, –
***Иң ахырда мәгънәви куәткә күңелем тезләнә.***
Ошбу куәт каршысында баш бөгәм, хәйран калам:
Шул сәгатьтә шатланам, шуннан гына ләззәт табам.

Шуңа тагын бу шагыйрьнең «Тәэссорат» («Аң», № 17, 1913) дигән чәчмә лирик парчасы белән «Мәхәббәт» («Аң», № 8, 1914) һәм «Халәте тәәссердә» («Аң», № 24, 1914) дигән тезмәләре кебек шигырьләрен кушарга кирәк. «Тәэссорат»ы – тәмамән тәсаувыф һәм символизм җимеше. Монда ул, язның матурлыгын тасвир итеп, болай яза:

«Безне шатлык катыш бер моңлылык, әллә нинди бер шигърият изрәткән. Мәгънәви бер куәтнең тәэсире безне тик торырга мәҗбүр кылган сымак иде».

«Бөтен мәхлүкат мәгънәви бер куәтнең тәэсиреннән гайре ихтыяри сөкүнәтне илтизам кылганнар[1]. Боларның һәрберсе, фәүкыльгадә[2] бер эш көткән сымак, бер куәткә тәвазыглык итәләр[3]. Барча әшья[4] кайдандыр... бер илһам, сирри[5] бер тәблигънең[6] булуын көтә яки тиздән булачак бер нәрсәнең ләззәтеннән мәхрүм калмас өчен, бөтен калебләре, вөҗүдләре белән бер куәтнең алдында тез чүккәннәр».

«Бу минутта дөньяны бер мәгънәви газамәт[7] чолгаган...»

«Сандугачның күңелендә сакланып торган мәхәббәт, гыйшык, сер, моңлы тавыш белән тирә-якка тарала башлады».

«Ниһаять, үзенә илһам кылынган әсрарны[8], мәхәббәт вә гыйшыкны кәмале муаффәкыять[9] белән тәблигъ итеп беткән рәвешле үзенең сайравыннан туктады. Бу минутта җир өсте һичбер җинаять вә усаллык эшләнмәгән арзы мөкатдәс[10] сурәтен алды. Сөкүнәт[11] тагын бер-ике минутка сузылды».

---

[1] Сөкүнәтне илтизам кылганнар – тынып, оеп калганнар.
[2] Фәүкыльгадә – гадәттән тыш.
[3] Тәвазыглык итәләр – түбәнчелек күрсәтәләр.
[4] Барча әшья – бар нәрсә.
[5] Сирри – серле.
[6] Тәблигънең – хәбәрнең.
[7] Газамәт – мәһабәтлек.
[8] Әсрарны – серләрне.
[9] Кәмале муаффәкыять – бөтен тулылыгы.
[10] Арзы мөкатдәс – мөкатдәс җир.
[11] Сөкүнәт – тынлык.

«Газамәт, әлләә нинди бер мәгънәви куәт тарафыннан арта төште. ***Әшьялларның бер-берсе арасында галяка[1] сизелде. Болар бер-берсенә мәгънәви, фәкать ныклы бер көч белән бәйләнгән кебек булдылар.*** Һәммә нәрсә бер-берсен кочакларга, бер-берсенең муенына сарылырга омтыла башлады».

«Бу минутта һәммә нәрсә тәәссернең[2] иң ниһаятенә җиткән иде. ***Чөнки бу минутта җир өстендә чын мәхәббәт белән чын гыйшык хөкем сөрә иде.*** Аһ, чын мәхәббәт белән чын гыйшык...»

Әсәрдән гәрчә кисентеләп кенә алынган булсалар да, безгә шушы мисаллар Мәҗит Гафуриның да вакыты белән татар әдәбиятындагы символизм агымына кушылып киткәнен яхшы ачалар. Бу мисаллар да янә ачык, артык аңлатуга терәлеп тормыйлар. Шулай да монда тик шуны гына искәртеп үтәргә тиешбез: шагыйрьдән китерелгән шул мисаллар монда сандугачның илаһи мәхәббәткә символ итеп алынганын, шуның аркылы шагыйрь үзе дә шул мәхәббәтне – «Хак гыйшкы»н җырлаганын ачык күрсәтәләр. Шагыйрь монда шундый минутлардагы ләззәтләр аркылы гүя матди дөньяның газапларыннан юаныч эзли һәм таба... Бу юлда активлык күрсәтеп, башкаларны да шуның белән юатырга тели.

«Мәхәббәт» дигән шигырендә ул аны болай тасвирлый:

Кайда барма, кайда йөрмә, ул мәхәббәт чаткысы,  
Кап-караңгы төндә дә балкый аның шул яктысы.  
Кайда барма, кайда йөрмә, ул мәхәббәт анда бар;  
Тик аны кешеләр һаман да күрмәмешкә салыналар.  
***Ул мәхәббәт төрле җирдә, төрле төстә ялтырый,***  
***Ул тәҗәлла итдисә[3], таулар вә ташлар калтырый.***  
Юк җире, юк ул мәхәббәтнең, аны белми кеше  
Булмавы мөмкин түгел, ул – бу галәмнең Тәңресе.

Югарыдагы мисалларында да, бу тезмәсендә дә шагыйрь карашында көнчыгыш суфилары һәм символистлардагы шикелле үк дөньяның «Хак гыйшкы» белән әйләнә дип төшенүчелек бар икәнен ачык күрәбез.

[1] Галяка – бәйләнеш.  
[2] Тәәссернең – сиземләү-тоюның.  
[3] Тәҗәлла итдисә – нурланып күренсә.

Шагыйрь үзенең «Халәте тәэссердә» дигән шигырендә:

> Һәрвакыт иссә күңелдән чын мәхәббәтнең җиле,
> Мин буламын шулвакыт бу бабта Мәҗнүннән тиле, –

дигәне шикелле, аның бу моменты – чынлап та, шундый «мәҗнүнләшү» моменты. Ләкин ул кайвакытта бу турыда мәэюслеккә[1] дә төшә:

> Хәйләсез, чын саф мәхәббәтне күңел эзләп оча,
> Әйләнеп, мәэүс булып кайта, кунар җир тапмыйча. <...>
> Чолгап алган дөньяның вак тормышы башка кунып,
> Көч бетә, хәлдән таям, булмый һаман да ычкынып, –

дип җырларга керешә.

Татар әдәбиятындагы символизмның көнчыгыш-төрк әдәбиятлары тәэсирендәге яки шуңа охшаш канаты тагын байтак шагыйрьләрне үзенә беркетә: Вакыйф Җәлал[2], Искәндәр Киләүле[3], «М», Хөсәен Абушай[4], Ф. Ибраһимов[5], Хәбир Габдуллаев, Г. Сөнгати[6],

[1] Мәэюслеккә – өметсезлеккә.

[2] Вакыйф Җәлал (1886–1922) – шагыйрь. Дистәгә якын, шул исәптән «Сәда-и мәдәният» (1908 ел), «Күз нурларым» (1913 ел), «Яңа Гөлстан» (1917 ел), «Вакыйф Җәлал шигырьләре» (1918 ел) дигән шигъри җыентыклар, «Кара тормыш» (1913 ел) исемле хикәя авторы. Әсәрләрендә үз заманының социаль каршылыкларын чагылдыра, татар халкын гыйлемгә өнди. Тулаем алганда, В. Җәлал иҗатына күңел төшенкелеге хас. 1920 еллар башында Урта Азиягә китә, фаҗигалы төстә һәлак була.

[3] Искәндәр Киләүле – XX йөз башында иҗат иткән татар шагыйре. Шәхесе турында мәгълүмат сакланмаган.

[4] Хөсәен Абушаев-Атлаши (1892–1961) – шагыйрь. Шигырьләре 1909–1915 елларда «Идел», «Вакыт» газеталарында, «Шура», «Чүкеч» журналларында басыла. Аерым шигырьләре «Яңа әдәбият» хрестоматиясенә (1914, төзүчеләр: Г. Ибраһимов, Г. Баттал) кертелә. 1915 елда егерме ике шигыре кергән «Алтыннарым» җыентыгы дөнья күрә.

[5] Фәрит Таҗетдин улы Ибраһимов (1893–1943) – шагыйрь, мөгаллим. Шигырь һәм поэмалары 1912–1917 еллардагы татар вакытлы матбугаты («Аң», «Сөембикә», «Ак юл», «Балалар дөньясы», «Кояш», «Себер) битләрендә актив басылган. 1912 елда «Уйларым» һәм «Өмидемнең нурлары» дип аталган ике шигырь җыентыгы дөнья күрә.

[6] Габдерахман Сөнгатулла улы Сөнгати (Сөнгатуллин; 1894–?) – шагыйрь, «Ак юл» журналының җаваплы сәркатибе (1914–1915). 1915 елда Беренче бөтендөнья сугышына алына һәм хәбәрсез югала. Шигырьләре һәм поэмалары «Аң», «Ак юл», «Сөембикә» журналларында, «Кояш», «Халык» газеталарында басыла. «Таңгы җырларым» (1915) исемле шигырьләр һәм «Ил фәрештәсе» дип аталган хикәяләр җыентыгы авторы.

Б. Мирзанов[1], «Илһим», Ченәкәй[2] һәм башкалар. Болар төрлесе төрле сыйфаттарак: кайсысында – көчлерәк һәм ачыграк, кайсысында – йомшаграк. Ләкин, һәрхәлдә, төбендә бары да вакытында бер тамырдан сулышландылар.

Боларның һәрберсеннән тулы көенчә мисаллар китереп сүзне озайтуга хаҗәт юк. Татарда символизмның киң бер агым булып үсеп килгән һәм озын гына тарихка ия булган икәнен күрсәтү өчен, югарыда берничә әдип шагыйрьләрдән китерелгән мисаллар бик җиткән.

Шунда да бу соңгыларның да кайберләреннән бик кыска гына мисаллар алып үтсәк зыян булмас, бу тик мәсьәләне тагын да ачыкландыруга гына хезмәт итәр.

Ишеттем сүзләреңне, әйткәнеңне, дөньяга гаид,
Дидең: «Дөньяны фикереңдә вә җаныңда мөгаммә[3] ит!..»
Җиһан гомере фәна дәүләт, сизәм, дилбәрдә[4] бар ләззәт...
Җиһанда тор, фәкать мәстанә[5] бул – бер кәсеп ләйлә ит!
(«Шура», № 2, 1915)

Сер сиңа бу: син үзеңнән
Башканы һичбер сөймә;
Итмә бу бик күп сыналган
Серне инсаннарга фаш[6].
Вакыйф Җәлал («Шура», № 19, 1918).

---

[1] Бәхтияр Гомәр улы Мирзанов (1892–1941) – шагыйрь. Инкыйлабка кадәр «Сөембикә» журналында эшләгән, «Аң», «Шура», «Сөембикә», «Балалар дөньясы» журналларында, «Тормыш», «Вакыт», «Кояш» газеталарында шигырь-поэмалары басылган.

[2] Ченәкәй (Төхфәтулла Гыйззәтулла улы Ченәкәй; 1893–1959) – шагыйрь, фольклорчы, мөгаллим. Иҗаты 1914–1915 елларда башлана. Октябрьдән соң да иҗатын дәвам итә. «Өмет очкыннары» (1918), «Теләкләр төркеме» (1918), «Кан дулкыннары, яки Сугыш» (1919), «Бакчаларда» (1928), «Карагайлы каен урманында» (1928) һ. б. шигырь һәм җыр җыентыклары авторы.

[3] Мөгаммә – табышмак.

[4] Дилбәрдә – сөекледә.

[5] Мәстанә – исергән.

[6] Нәваи бу «сер»не фаш итәргә мәҗбүр булганын әйткән иде (югарыда аннан китерелгән мисалга кара). *(Авт. иск.)*

Бар минутлар: сафлана рух,
Җиңеләя һәм яктыра,
Шунда һәрнәрсә ачык
Күренә, үзен аңлаттыра... <...>

Аңлыйсың: барсы болар бик
Кыска эш, бер чүп кенә.
Аңлыйсың: дөнья – тиеш булган
Үтү, чүплек кенә. <...>

Аңлыйсың: бар башка бер бик
Зур җиһан, дарелхәят[1].
Башка бер нурлы хәят,
Изге хәят – дөньяга ят. <...>

Шунда чынлап аңлыйсың инде
Мәхәббәт мәгънәсен,
Мәңгелек нур, мәңгелек шәмгын[2]
Күңелнең, кальгасын.

Шунда дил[3] бу фәйзе Хак[4]
Берлән тулып, елынып, эреп,
Раббына коллык кыла,
Сәҗдә кыла ихлас биреп[5].
Искәндәр Киләүле («Шура», № 14, 1914)

Кабынган чалым – яңгыраган чагым,
Рахмани нурга табынган чагым.
Хөсәен Абушаев («Шура», № 22, 1914)

«Бу кара туфраклы Җир шарыннан күк патшалыгына, фәрештәләр сараена ашкына торган инсанның күңелен дөньяның золымы, җәбер вә җәфасы баса алмый; ул гали, ул хөр...

Рауза да шундый гали рухлы, изге күңелле бер кыз иде».

Гали Рәфикый («Аң», № 10, 1914)

[1] Дарелхәят – яшәеш йорты.
[2] Шәмгын – шәмен.
[3] Дил – күңел, йөрәк.
[4] Фәйзе Хак – Хак нигъмәте, юмартлыгы.
[5] Н. Думави һәм Дәрдмәндләрнеке белән бер үк мәгънә һәм бер үк өслүбтә. Бертөрле сыйнфый идеологиядәге шагыйрьләр арасындагы өслүб берлеге, мөндәриҗә белән тормышның органик багланган булуы әнә шул инде. *(Авт. иск.)*

Инде татар әдәбиятындагы символизмның рус символизмы тәэсирендәге канатына яки шул тәэсир астындагы татар символизм мәктәбенә күчик.

Бу мәктәпнең алдынгы вәкиле Сәгыйть Рәми иде. Ул:

«Мин» димен мин, «мин» дисәм,
Миңа зур бер көч кирәк:
Аллалар, шаһлар, кануннар
Булалар бер чүп кенә, –

дип, индивидуалистлык «гыйсъяны» ясап алса да, төбендә бу аның «чын Алла»сына каршы кузгалыш түгел иде. Бу – дин, кануннан соң кузгалган шау-шуга каршы аның тарафыннан утыртылган «җәгъли[1] аллалар» иде. (Бу турыда бу шигыре чыкканнан соң кузгалган шау-шуга каршы аның тарафыннан үзенең шул мәфһүмдә[2] аңлатуы да матбугатта булып үтте.) Шуның белән бергә, бу шигырь, дөрес, үз мәгънәсендә алганда да, шагыйрьнең үзе түбәндәге шигырендә әйткәне шикелле, аның бу настроениесе – аның үзе табынган «чын Алла»сына, Мәҗит Гафуриның «Юктырсың ла, Алла...» дигәне рәвешендә бер үпкәсе яки «тәмам иркә, очынган бер бала» сынлы читкә китүе генә иде. Мондый хәлне без көнчыгыш символист шагыйрьләрендә дә очратабыз. Мәсәлән, көнчыгышта «Әнә әл-Хак» («Мин – Алла» дигән сүз) диюче шагыйрьләр бар иде[3]. Романтик Ясәвинең дә:

Атым – Рахман, затым – сөбхан,
Бер нәзарда батыйннарын сафа кылдым, –

дип, Алланы үзе белән алыштырган моментлары булды.

Шулай, Сәгыйть Рәми «мин»ендә – Алланы («Хак»ны – «истина»[4]ны), Аллада янә үзен күрде:

Кем ул, белмим вә нәрсәдер,
Белмим дип, юл да эзләнмим;
Мәгәр аннан бүтән затка
Бөгелмим мин вә тезләнмим. <...>

---

[1] Җәгъли – ясалма.
[2] Мәфһүмдә – мәгънәдә, эчтәлектә.
[3] Сүз алдарак искә алынган Мансур Хәллаҗ турында бара.
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

***Була үпкәм аңа бәгъзән,***
Дүнәм, хәтта җитәм чиккә.
*Тәмам иркә, очынган бер*
***Бала санлы, китәм читкә. <...>***
Кем ул, андый Сәгыйть иткән
Мине һәм урнымы – белмим.
***Беләм тик бу җаным аннан***
***Яратылган, мин – ул; ул – мин.***

(«Алла» дигән шигыреннән).

Шулай итеп, бу шагыйрь «мин»ен «аның», ягъни Алланың символы итеп таный һәм аны шулай тасвир итә.

Шагыйрь өчен бу дөнья – матди тормыш – «бер кабер», ягъни «төн». Ул – газап оясы булган бер «ялган». Шагыйрь «гали, шатлыклы» тормышны икенче галәмдә күрә. Аның тәне монда булса да, ул үзе күктә:

Күрәм гали вә шатлыклы
Галәм анда, бар ул алда...
Минем тик бер тәнем монда,
Үзем күктә мәләк[1] анда.

(«Күрәм гали» дигән шигыреннән)

Ул шул галәмгә тизрәк күчә алмау, тәндә бикләнеп тору газабында, «теге»нең сагышы утында яна һәм җир тормышына бәйләнеп ваксынмый:

Пошам да әрнимен, әмма
Тәнәззел итмимен[2] җиргә,
Үләрмен... Шунда да утта
Үләрмен, үлмәмен җирдә.

(«Күрәм гали» шигыреннән)

Димәк, шагыйрь «теге»нең утында, нурында югалырга ашкына.

Шагыйрь үзендә бер-берсе белән алышынып тора торган «караңгылы»-«яктылы» ике халәт, ике төрле настроение күрсәтә. Берсе – аның «мин»ен күрми яки аның сүзен ишетә алмый торган чагы,

[1] Мәләк – фәрештә.
[2] Тәнәззел итмимен – төшмим.

«үлгән» вакыты. Икенчесе – «мин»ен күреп шатланган, актырган, күтәрелгән моменты:

Кайвакыт мин үләмен,
Сөймим үзем дә үземне,
Күрми торсам ул «мин»емне
Я ишетми сүземне.
Әмма соң кайчан күземә
Ул «мин»ем бер күренә –
Менәмен күкнең югары,
Иң югары түренә.

(«Мин» дигән шигыреннән)

Менә шунда, ягъни шул соңгы икенче моментында инде аның «мин»челеге, «мин» белән юанып шатлануы көчәя.

«Мин!» димен мин, яшәсен «мин!»,
«Мин» минөмчен Алла ул.
Рухым үлгәндә күренсә,
Рухыма җан салган ул («Мин»нән), –

ди башлый.

Көнчыгыш символистлары телендәге «хак» һәм рус символистлары телендәге «истина»[1] Сәгыйть Рәмидә «чын» дип йөртелә һәм аның алда көткән «бәйрәме» дә, бөтен «сәгадәт», «ләззәте» дә шунда, шуны «сизү»дә, шуңа катнашу һәм йотылуда:

Минем юк бәйрәмем монда:
Алалмыйм рәхәт тын да,
Сөймим дә бу рәхәтләрне:
Сәгадәт, ләззәтен чында.

(«Бәйрәм» дигән шигыреннән)

Әнә шул үзенең табынган хыялы – «хакыйкать, гыйффәт, мәхәббәт» эченә чума да, чын матди хакыйкатьне – матди, реаль вакыйгыйлыкны, реаль тормышны «ялган» дип, анда «бозыклык, ачу» тулган дип күрә башлый:

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

Бозыклык, ялган, ачу күрәм
Хакыйкать, гыйффәт, мәхәббәт эчендә, –

ди («Минем төн»еннән).

Шагыйрь кайчанда тәнен – бишек, җанын да шул бишектә кайгы да йотучы, шулай ук ямьле иттереп йоклаучы дип сизә:

Бак бишеккә, күр җанымны:
Нинди гамьне йотмый ул.
Дәүләт алган як-ягымны,
Нинди ямьле йоклый ул.

(«Ул йоклый» дигән шигыреннән)

Шулай да шагыйрьнең күңеле һаман тынычсыз:

Эзли-эзли, тынмый күңелем,
Тынмый, эзли Алласын.

(«Киң иман»)

Алласын эзләргә тотына да, ахырда тагын арып, аңа болай дип ялына башлый:

Илаһым, ал мине! – Талдым,
Юлыңда берүзем калдым.
Куям кылычым кире кынга...
Газаплый тик сиңа антым...

Менә шушы мисаллар һәм алар турында бирелгән шул югарыдагы аңлатулар Сәгыйть Рәмине безгә, һичшиксез, декадент-символист шагыйрь итеп таныталар. Бердән, декадентлардагы кебек үк, Сәгыйть Рәмидә соң дәрәҗәдә көчле һәм чиктән тыш кабартылган «мин»челек бар, ягъни ул һичнәрсә белән чикләнмәгән индивидуализм сыйфатына ия. Татар әдәбиятында аңа кадәр ул дәрәҗәгә җиткән «мин»челек юк иде. Бу шагыйрь иң башлап татар әдәбиятында әнә шуны үстерде. Соңыннан шундый ук индивидуализмны Искәндәр Киләүледә һәм Октябрьдән соң Такташта күрдек.

Икенчедән, Брюсовлардагы (әүвәлге дәверендә) шикелле үк, Сәгыйтьтә дә бер «караңгылану», бер «яктыру» бар. Бигрәк тә анда өметсезлек, күбрәк зарлану, елау, кайгы көчле.

Өченчедән, шагыйрьдә кайбер моментларда Аллага каршы гыйсъян-бунтарьлык бар, ләкин бу да аның шул Алласының

нурында янып, аның гыйшкы утында үзен үзе онытуыннан, көнчыгыш суфичыларынча әйтсәк, шуның белән аның «җәзеб»ләнеп[1], «мәҗнүн»ләнеп[2] китүеннән генә.

Сәгыйть Рәминең Дәрдмәндтән, гомумән, көнчыгышлык тармагындагы татар символизмыннан иң аерылган ноктасы – аның чиктән тыш индивидуалистлыгында һәм солипсизмында. Бу яктан Сәгыйть Рәми Мережковский, Гиппиус, Сологубларга якын, аларга юлдаш. Дәрдмәндтә андый дәрәҗәдә бер индивидуализм юк. Ул идеалистик монизм «без»леген җырлый.

Бу ике символист арасында янә зур бер аерма – Дәрдмәндтә тәгъбир һәм тасвирларның символларга байлыгы һәм аның иҗат композициясе бу яктан аерым бер дикъкать, аерым бер осталык белән ясалып чыккан булучылыгыдыр. Шуның өстенә, Дәрдмәндтә шул символлар сүзләрнең шыңгыраулы кушылулары белән берләшеп, артык бер нечкәлек күрсәтәләр. Фикер, тойгылар шул нечкә аһәңнәр, нәзек яңгыраулар аша бирелә.

Бу ягы белән Дәрдмәндтә декадентларга охшаш бер сыйфат юк түгел. Ләкин бу хосусият көнчыгыш символистларында да бар.

Сәгыйть Рәми белән Дәрдмәнд арасында тагын бер аерма шунда: Сәгыйтьтә – пассивлык, Дәрдмәндтә активлык бар, ягъни Дәрдмәнд үзенең фәлсәфи-дини фикерләрен тормышка үткәрергә, ул фикер һәм тойгыларын башкаларның күңелләренә дә урнаштырып, алар белән дөньяга карашын уртаклашырга, аларны да шул карашка тартырга һәм алар белән бергә нечкәләнеп кайгырырга, бергә юанырга тели. Бу турыда үзенчә җитәкчелек-юлбашчылык күрсәтергә омтыла.

Көнчыгыш тәэсирендәге татар символизмы тезмәдә генә калмыйча, лирик чәчмәдә дә үзен күрсәткән шикелле (Н. Думави, М. Гафури), рус әдәбияты тәэсирендәге символизм да шулай булды. Бу да тезмә шикелле үк чәчмә лирик әсәрләр дә бирде. Бу – М. Хәнәфи каләме аркылы 1913 елда «Аң» журналында башланды һәм Февраль революциясенә кадәр дәвам итте.

Ләкин Сәгыйть Рәми рус символистларының беренче буынына – декадент-символистларга якын булса, М. Хәнәфи икенче буын символистлар тәэсирендә иде.

[1] Җәзебләнеп – шашып.
[2] Мәҗнүнләнеп – диваналанып.

М. Хәнәфи чәчмәләре – татар әдәбиятындагы символизмның чәчмә өлешендә аеруча характерлы булган иҗатлардан. Алар – чәчмәдә һәр яктан символизмның күзгә ачык бәрелеп торган типлы үрнәкләре.

«Аң»ның 1913 елгы саннарында аның (3, 4, 7, 16, 18, 19, 23, 24 нче саннар) «Сәгадәт», «Дөньяга килдем», «Тегеннән», «Мәхәббәт», «Мин төш күрдем», «Мәгъшука», «Шулай ди яз көннәре», «***»; 1914 елгы саннарында (8, 19 нчы саннар) – «Сөю-җәллад», «Акылсызлыктан», 1915 елгы саннарында (6 нчы сан) – «Гөл бакчасында»; [19]16 елгы саннарында (19–20 нче саннар) «Кайдан, кайда?» кебек лирик чәчмәләре безнең югарыда сөйләгәннәребезгә иң ачык мисал була алалар.

Шулар эченнән бу урында безгә аның «Бер гөл бакчасында»сы белән «Мәгъшука»сыннан бер-ике мисал алу җитә. Болар татар әдәбиятының чәчмә өлешендә символизмның бөтен сыйфатларын үзләрендә тәмам ачык күрсәтәләр.

Беренчесенең сюжеты – символизм өчен түбәндәгечә бик характерлы бер нәрсә: чиксез матур «бер гөл бакчасы» (ягъни дөнья). Шуңа элек бер карт белән бер карчык килеп керәләр. Шунда алар дөньядагы бар нәрсәнең ялган булуыннан, «алдакчы дөнья»дан зарланалар, аны каргыйлар. Икенче вакыты шул ук бакчада бер җегет белән кыз. Болар бер-берсе белән кавыша алмаячакларын сөйләшеп елашалар. Икенче вакыт күрешергә булып аерылышалар. Икенче көнне җегет тагын килә. Сөйгәнен көтә, ләкин ул килми. Шуның өчен яна, үртәлә. Аның янына тагын башка бер җегет килеп чыга. Дөньяның – бакчаның матурлыгына аның игътибарын тарта, ләкин теге һаман «дөнья ачы, зәһәр», «ул караңгы зиндан», «сандугачлар үлем җырын җырлый, ул дөнья белән исәнләштерә» ди.

Шул ук «Бер гөл бакчасында» хыялда күренгән бер карт дәрвиш белән бер кыз. Кыз сөйгәненең үлгәненә, җир астына кергәненә кайгырып җылый. Дәрвиш кызга матди дөньяның үзенең юклыгын, шулай булгач, дөнья мәхәббәте булмауны сөйли. «Бар булган бер нәрсә булса, ул да – анда!..» – дип, «илаһи», «серле» мәхәббәтне, теге «рухы көл»не күрсәтә. Сандугач һаман «моңлы, серле җырларын» – «хәят җырларын» җырлый. Гүя ул – «сер дөньясы», «серле мәхәббәт»нең хәбәрчесе. Ахырда әдип үзе теге «хәят»ка ашкына,

тиздән шуңа ирешү өмете белән дәртләнә, зәукъләнә[1], илаһи мәхәббәт белән саташа.

Карт түбәндәгечә сыйфатлана:

«Зур ак сакаллы карт. Аның алдында озын кара чәчләре иңнәренә төшеп торган кыз тезләнеп тора. Картның күзләре җирдә түгел, күктә... Шулай да ул күзләр күкнең зәңгәрлеген күрмәгән кеби... күктән аша кеби карыйлар...»

Тагын түбәндәге тасвирларны укыйбыз:

«Ник бу дөнья аны үтерде? Ни өчен мин дә җәза күрәм?.. Аh, хәким! Җавап бир, син галәмнең бөтен серләрен беләсең!..

Кыз бу сүзләрне өзелеп сөйләгәндә, картның йөзе үзгәрмәде, аның күңеле дөньяда түгел кеби иде».

«Бала! Син мәхәббәт дип кайгырасың... Мәхәббәт юк ул...» Син дөньяны гаеплисең... Дөнья юк ул... Сөям дисең, сөям дисең, сөям дисең – сөйгәнең кайда? Аның булганы юк, ул – синең серең... Ул кара җир астына керде, дисең... Кайда ул җир? Ул җир юк ул. Ул синең күзеңә генә күренгәндер. Сөйгәнең дә синең җиргә кермәде, әгәр ул булган булса, нурга әверелеп, күккә очар иде... Куй ялган уйларыңны! Дөнья юк, дөньяда бернәрсә дә юк... Бар булган бер нәрсә булса, ул да – анда!»

«Картның югары караган күзләрендә чиксез еракта булган бер «намәгълүм»нең[2] шәүләсе күренгән кеби булды, ләкин, белмим, әллә күренгән кеби булмагандыр да…»

«Анда сандугач, гөлләрнең чибәрлекләреннән шагыйрь булып, моңлы серләр җырларын җырлый иде... Аның җырлаган җырлары «хәят җырлары» иде».

«Мин дә – бичара сандугачның кечкенә йөрәгендә типтергән гыйшык, кояш нурлары белән нурланган гөлләр гыйшкы... Ян, йөрәгем! Тыпырчын, әсир кошым, моңлы, утлы йөрәгем!..»

«Кояш нурларын чәчә... Язлар килә!.. Моңлы күңелләр уйганып, дәрт гөлләре аталар...

Дөнья яктыра! Дәртлеләр дөньясы... йөрәклеләр дөньясы. Илаһи мәхәббәттән саташканнар дөньясы...

Үлем юк монда – ул ул бар җирдә дөнья үзе юк... Хәят чишмәсе чылтырый, һәрбер тамчысы дөньяга җан бирә... Чәч, кояш, нурла-

[1] Зәукъләнә – ләззәтләнә.

[2] Намәгълүмнең – билгесез нәрсәнең.

рың! Яктырсын бу дөнья – дәртлеләр дөньясы... Илаһи мәхәббәттән саташканнар дөньясы!..»

Менә бу мисаллар артык изах сорамыйлар. Без монда символизмның нинди хосусиятләре барлыгында да шикләнеп тормыйбыз. Болар безгә монда бик ачык. Бу ачыклыкны тагын аның «Мәгъшука»сы белән «Кайдан, кайда?»сыннан алынган түбәндәге мисаллар белән ныгытыйк:

«Яз көннәрендә мин синең кем икәнеңне беләмен!..»

«Хәзер минем синең барлыгыңда шигем юк! Чөнки син – мин, мин бар һәм син мин булганда барсың!..»

«Тормышымның кешенең чыдамы җитмәслек авыр минутларында мин сиңа кулларны сузам, синең кулларыңны караңгыда эзлим; чөнки син – сәгадәт кояшы, син минем куәтем, гайрәтем чишмәсе икәнлекне күңлем миңа ачы тавыш белән тәкрар кыла... ***Җир йөзендә гомер кичерүеннән максат – синең белән кавышу.*** Бу – минем ялгыз иманым, бу – минем татлы, гүзәл хыялларымның чибәрлеге, ләззәте, бөтен дөньяны күреп туймаслык иткән бизәкләре!..»

«Яктылы-караңгылы уйларымны синең өчен уйлыйм... Бер кайгылы, бер шатлыклы җырларымны синең мәхәббәтең хөрмәтенә җырлыйм! Иңсез хыялларымдагы сәгадәт бакчаларын сиңа бүләк ясар өчен яратам!.. Син – мин... Син – бөтен чиксез галәмсең... Шулай, ди, яз көннәре...»

«Дөнья серләре күп. Ләкин кешенең күңеле, кешенең дөньяга килеп китүе иң бөек серләреннәндер...»

«Кеше үлде, ул юк булдымы? Ничек мин моңа ышаныйм? Юк! Ул юк булмады, ул бар, ул үлмәде, бетмәде, ул тик минем күзләремә күренми башлады...»

«Мин хәбестәмен. Минем үземнеке булган һичнәрсәм юк. Мин исемсезмен, бу – минем шөһрәтем, һичберегез мине якын күрәчәк түгел...»

«Сезнең телегез белән әйтсәм, мин мәсгудмен[1], минем күңел шулкадәр тыныч ки, дөнья җимерелсә, мин тынычлыгымны югалтачак түгелмен...»

«Бу юл – бу сезнең оныткан юлыгыз, бу – сезнең ташлаган юлыгыз. Бу – сез пычраткан юл, шуның өчен дә хәзер бу – сездән

[1] Мәсгудмен – бәхетлемен.

яшерен юл. Ләкин шулай да бу – чын сәгадәт юлы, чын хакыйкать юлы, бу – нурлы юл!..

Бөек Тәңре күңлегезгә тынычлык бирсен!..»

Чәчмәдәге бу символизм М. Хәнәфи каләмендә генә тукталып калмады, аны үстерүгә башка каләмнәр дә булыштылар.

Нәҗип Гасрый[1] белән Гали Рәхим[2] һәм Нәкыя[3] бу турыда ачык күзгә ташланалар. Нәҗип Гасрыйның «Мазарстанда» («Аң», № 5, 1916) дигән һәм көчле каләм белән язылган лирик хикәясе – шуның ачык мисалы. Ул – бу юлда иң характерлы бер хикәя. Аның бу лирик хикәясендә без түбәндәгеләрне укыйбыз:

«Җәнүб[4] күзенең битене үбә торган, әфсанәви[5] кулы белән сыйпый торган елдымлы кояшлы бер көнендә үлекләр мәмләкәтен, рухлар өлкәсен зиярат кылу нияте белән өйдән чыктым...»

«Диңгез алиһәсенең, диңгез кызларының күп нәгъмәләрен[6], гыйшыкларын тасвир иткән күп әфсанәви моңнарын тыңлаган сезләр, әй сез, тау-ташлар, диңгезнең, әлбәттә, бик күп серләрен беләсез!»

«Диңгез буеннан барганда, аяк астымдагы комнарның уалып китүләре, мәүҗүдиятнең[7], табигать тулкыннарына тотырык бирә алмыйча, ахыр бервакыт зәвал[8] табачагына шәһадәт бирә иде!..

[1] Нәҗип Гасрый (Мөхәммәтнәҗип Аллабирде улы Мәүләмбирдиев; 1886–1937) – әдәбият тәнкыйтьчесе. «Ил», «Идел», «Йолдыз» журналларында басылган, XX йөз башы татар әдәбияты һәм татар әдәби теле мәсьәләләренә багышланган, Г. Тукай, М. Акъегетзадә, Г. Ибраһимов, Гыйффәт Туташ иҗатларына караган күпсанлы мәкаләләр авторы.

[2] Гали Рәхим (Гали Мөхәммәтшакир улы Габдрәхимов; 1892–1943) – язучы, әдәбият галиме. Хәрби-сәяси курсларда (1920–1921) татар әдәбиятын, Шәрык академиясендә (1921–1922), Шәрык педагогия институтында (1922–1930) татар әдәбияты һәм фольклоры тарихын укыта. «Татар әдәбияты тарихы» (1–2 т., 1923–1927) китабы авторларының берсе.

1923–1930 елларда Татар халкын өйрәнү фәнни җәмгыяте эшендә, фольклор экспедицияләрендә катнаша; татар теле һәм әдәбияты белеменә, фольклорына, тарихына, археографиясенә багышланган мәкаләләр авторы.

[3] Нәкыя (Нәкыя Сәлах кызы Сәйфуллина; 1889–1960) – педагог, журналист, тәрҗемәче. 1912 елдан газета-журналларда языша, «Аң» журналында үзенчәлекле нәсерләре басыла. Татар укучысына «Абруй Сәйфи» тәхәллүсе белән билгеле.

[4] Җәнүб – көньяк.

[5] Әфсанәви – әкияти.

[6] Нәгъмәләрен – көйләрен, моңнарын.

[7] Мәүҗүдиятнең – яшәешнең.

[8] Зәвал – үлем.

Аһ, сиһерле, серле хәят! Син “яшим!” дип комга басасың – ул аяк астыңнан тая, кача бара!»

«Минем йөрәгем курку катыш рәббани[1] бер хис белән тибә; тамырларымдагы шәфкать тойгысы белән кайный иде!

Үзем яхшы ук тирли дә башлаганмын...

Аякларыма бераз хәл җыелгач, бөтен барлыгымны сарган шигъри тойгыны вә мәзарлар[2] арасындагы тынлыкны бозмаска тырышып, әкрен генә тагын алга атлый башладым».

«Ниһаять, вакытсыз үлгән сөекле Ләмганның кабер ташы күренә башлады!..»

«Мин: “Рухларыбыз әбәдияткә[3] кадәр аерылачак түгелләр, Ләмган!” – дигәннең соңында, Ләмган күз яшьләренә буылган хәлдә, тагын да үбешә идек...»

«– Аһ, Ләмган!

Син бер Ходайга иң якынлашкан санияләреңдә[4], күңелеңнең иң сынган аннарында[5] олуг Тәңредән, сине хәлык итү[6] сәнгатен күрсәткән бөек Раббыбыздан озын бер хәят, хәяты гашиканә[7] тели идек!..»

«Ләмганның теге куе зәңгәр елгага ингыйкяс итеп[8] тора торган мәзар ташына якынлаша башладым. Бик күп ләтыйф[9] рухларның очып йөргәндәге җилләре минем битемә йомшаклык белән бәрелә иде!»

«Ләмганның мәзар сакчысы итеп утыртылган яшь, матур чинар агачының яфраклары тәсбих әйтә башладылар. Ләмганның мәзары өстеннән нурани ак бер шәүләнең күтәрелгәнлеге тоеладыр иде... Бу ак шәүлә мине үзенең мөһим ләтафәте[10] белән сарып алды.

Мәәүс[11] бер хәлдә Ләмганның каберенә актык күз яшьләремне түгеп, бу үлекләр дөньясыннан үземнең өемә – мәзарыма (дикъкать итегез!) кайтырга карар бирдем».

---

[1] Рәббани – илаһи.
[2] Мәзарлар – каберләр.
[3] Әбәдияткә – мәңгелеккә.
[4] Санияләреңдә – *биредә:* мизгелләреңдә.
[5] Аннарында – вакытларында.
[6] Хәлык итү – юктан бар итү.
[7] Хәяте гашиканә – мәхәббәтле тормыш.
[8] Ингыйкяс итеп – чагылып.
[9] Ләтыйф – *биредә:* җисемсез.
[10] Ләтафәте – йомшаклыгы, назы.
[11] Мәәүс – өметсез.

«Менә бервакыт еракларда, бик еракларда йәде кодрәт[1] нурани бер-ике сызык сызып алды: бу – диңгезләр алиһәсенең боерык камчысы иде...»

Ләкин Н. Гасрыйның мондый хикәяләре бигрәк француз декадентлыгы тәэсире астындагы госманлы символизмы (Халит Зыяның «Кабердән тавышлар»ы кебек әсәрләр) тәэсирендә язылган булуга охшый.

Гали Рәхимнең символизмның бу канатына ялгана торган чәчмәләреннән аның «Җәйге нәсер»е характерлы булыр. Аның «Тынлык», «Миләүшәләр арасында» кебекләре дә («Аң»да басылдылар) түбендә шул сызыкталар.

Аның «Җәйге нәсер»ендә без түбәндәге юлларны укыйбыз:

«Бу һаваи бинаны (язгы күренешне һәм фәзаны[2] әйтә) сарай дип атаудан кайтмыйм. Чөнки анда торучы минем гали рухым, бөек хыялым, канатлы ирегем, корыч ихтыярым! Соң мин патша түгелмени? Шул гали рухыма, бөек хыялыма, канатлы ирегемә, кырыч ихтыярыма хаким түгелмени мин?»

«***Минем рухым акылның теге ягында булган дәрьяларда гизә.*** Хыялым – шул канатлары бер офыктан икенче офыкка җитә торган хыялым – матурлык, гүзәллек белән тукланып, икенче матурлыклар хәлык кыла, яңадан-яңа гүзәллекләр кәшеф итә[3]».

«Илаһи! Кичке, җилсез тын төннәрдә никадәр сиррият[4], никадәр гыйшык тулган...»

«Әнә шул чәчәк тулкыннары арасында акрын гына, башын аскарак салып йөргән зат турында мин ни әйтим – ***әллә ул минем рухымдамы, тәнемнән аерылып, хуш исләр дәрьясында йөзә?***»

«Аһ, ник бу хыял гына, ник соң болар барысы да коры хыял гына! Тормыш, син ник бу кадәр әшәке дә, ник синдә мин теләгән матурлык юк? Тормыш! Ник син буш?» («Аң», № 11–12, 1916).

Чәчмәдәге символизм хәтта элекке реалист-классигы Фатих Әмирханны да үз ягына тартты. 1916 ел аның әнә шул якка башлап борылу юлы булды. Аның шул ук елның «Аң»нарында (№ 11–12

[1] Йәде кодрәт – кодрәтле кул.
[2] Фәзаны – күк йөзен.
[3] Кәшеф итә – барлыкка китерә.
[4] Сиррият – серлелек.

һәм 13) басылган. «Яз исереклегендә» дигән лирик хикәясе – шуның ачык үрнәге.

Монда ул җанының «кодси[1] олуглык вә кодси яшеренлек»не сизүен, «күз алдында вә бөтен идракта[2] шушы бераз белемсезрәк, бераз серлерәк кодси олуглык кына калу»ын тасвирлый. Күк йөзендә ниндидер – Коръән укып утырган «чалмалы карт»лар күрә. Ул карт та бөтен шул зәңгәр вә аллыгы эчендә һәм матур, һәм шигъриятле, әдипчә, «бәлки ул дөньядан йөз чөергән бер мөтәсаувифның[3] күк йөзендәге хәятыдыр».

Әдип бу хикәясендә күк йөзендә чапкан атлар күрә... Шулай ук әдип күзенә ниндидер коймалар арасына ал мәрмәрдән салынган сарай күренә. Әдип аңа кызыгуын болай тасвирлый:

«Аның гарәп тарызы мигъмарисында[4] эшләнгән тәрәзәләре дә миңа аерымачык күренәләр. Күккә менеп, шул тәрәзәләрдән карасаң, җир йөзе кызык булып, кечкенә һәм түбән булып күренер иде. Ул тәрәзәләрдән алга, алга, еракка карасаң, офыкларның серләре аңланыр иде», – ди. (Бу рус символистларының тәрәзәләрен искә төшерә.)

Әдипнең сөйкемле кызының күзләре дә бу хикәясендә түбәндәгечә тасвирлана:

«Бу күзләр миндә әүвәл караштa ук зур тәэсир калдырдылар. Алар, үзләренә махсус бер хәят белән тереклек итеп, ияләре торган мохиттән башка мохитне (яшерен «серле дөнья»ны була) карыйлар вә күрәләр һәм ниндидер серле вә шигъриятле бер нәрсәләр хакында уйланып, шул нәрсәләрнең шәүләләрен үз өсләренә чыгаралар шикелле иде».

«Шулай да я мин аларны, я алар мине сөяргә тиешләр. Өстәл яны минем өчен яңа бер хәят кәсеп итте».

Ф. Әмирханның 1922 елда басылган «Тәгъзия»се исә әнә шул символизмга борылышның тәмамланган ноктасы булды. Үз сыйныфының, ягъни буржуазиянең егылтылуы белән буржуа язучысы әнә шул хәлгә төште, егылды.

---

[1] Кодси – пакь, изге.

[2] Идракта – *биредә:* аң-зиһендә.

[3] Мөтәсаувифның – суфиның.

[4] Тарызы мигъмарисында – архитектур стилендә.

Бу урында Газиз Гобәйдуллинны[1] да искәреп үтмичә булмый. Монда бигрәк тә характерлысы шул: заманында кыска-кыска юмор һәм сатирик хикәяләр бирүче бу язучы да 1916 елгы «Аң»ның 18 нче санында басылган «Юлдаш эзләгәндә» дигән фәлсәфи хикәясендә символизм фәлсәфәсен тәкъдим итте.

Монда без аның Ильясы аркылы шуларны укыйбыз:

«Кая син, кая син? Кая киттең син, ул заманнарда йокламаганда йокы биргән, үлемнән курыкканда тынычлык биргән йомшак аһәң».

«Ильяс үзенең рухының төбендә әллә нинди бернәрсә сизде. Аның рухына әнә шул яр буенда тауга терәлеп үскән каенда, үзенең шушы матур төндә аңа карап торуында бер хикмәт бар төсле тоелды: аның акрын гына шыгырдавы да Ильяснең рухына бер сер әйтергә теләгән күк булды...»

«Хатыны Зөһрә ифрат рәхәттә, ифрат бер тынлыкта, мәңгегә килгән күк йоклый иде. Каты куллар белән кәфенгә төрелгән килеш үлем аның күз алдына килде...

Ильяс үзенең бик ялгыз икәнен сизде. Аңарга әллә ниткән бер маһият[2], әллә нинди бер юлдаш, мәгънәви бер ярдәм кирәк булды...»

«– Үлгәч нәрсә булачак? Мин шулай югалырмын да бетәрменмени? Әллә нинди бер караңгылыкта батармынмыни? Юлны белмим... – дип уйлады ул. Бу мәҗһүлият[3] аның күңленә бер күңелсезлек, хәтәр, хәвефле бер аһәң салды. ***Рух җылый, рух теге юл күрсәтүчене, теге караңгылыктагы юлбашчыны эзли башлады...***»

«...Шундый озын язылган фикерләр, шундый нәрсәләр, Ильяснең фикеренчә, мәсьәләдән бик ерак торалар иде. Чөнки мондый мәсьәләләрне (Алланы табуны әйтә) ***тикшерүдән бигрәк хис итәргә кирәк иде.***

[1] Газиз Салих улы Гобәйдуллин (Г. Газиз; 1887–1937) – тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, публицист. Казанда Шәрык академиясен нигезләүчеләрнең берсе. Хезмәтләре татар халкы тарихына, татар әдәбиятына («Татар әдәбияты тарихы», т. 1–3, 1922–1925, Г. Рәхим белән берлектә), Идел буенда һәм Азәрбайҗанда барган крестьян сугышлары тарихына карый. Г. Гобәйдуллин – сатирик һәм юмористик хикәяләр остасы. «Җомга көн», «Исерек» (икесе дә 1913 елда), «Чалбар» (1915) сатирик новеллалары, Г. Исхакый, С. Рәмиев иҗатлары, XX йөз башы татар әдәбиятында романтизм турындагы (1911–1913 елларда басыла) әдәби тәнкыйть мәкаләләре авторы.

[2] Маһият – нәрсәнең дә булса (эшнең) үзлеге, асылы.

[3] Мәҗһүлият – билгесезлек.

Мондый мәсьәләне кимия гонсырларын[1] тикшергән ысул белән түгел, бәлки адәмнең эченә авыру кергәч, шул авыруны ничек тоя, ничек турыдан-туры хис итә – шулай гына хис итәргә мөмкин иде. Сөйгәнен югалткан кеше нинди бер караңгылыкта кала, шул кешенең рухы белән генә бу мәсьәләгә килергә мөмкин иде. Дикъкать итегез, анда да мәсьәләгә килергә генә – хәл итәргә түгел. Чөнки аны хәл итү өчен, тагын үзенә махсус хис кирәк...

Бу мәсьәләгә философларның «вак мәсьәләгә»гә караган күк карaулары Ильяска бик зур бер хәкарәт[2] күк тоелды. Ул бу мәсьәләне, әгәр хәл итә алса да, бары үзе генә, һәрбер аерым кеше үзе өчен генә хәл итәчәген аңлады. Гомеренә бу мәсьәләдә хис итмәгән, итсә дә, үзенә махсус бер хис белән бу мәсьәләгә килмәгән бер кешенең акыллыбашлыгыннан бернәрсә дә чыкмаслыгын Ильяс сизде, тойды...

«Мин зәгыйфь йөрәккә тегендә мәҗһүл[3] җиргә алып барырга бу китаплардан укыган нәрсәләрем берсе дә иптәш табып бирмәделәр, хәтта булган юлдаштан мине аердылар... – дип уйлады».

Нәкыянең бөтен чәчмә һәм тезмәләре диярлек – символизм әсәрләре. Аның «Мәхәббәт» («Аң», № 9–10, 1915), «Мәхәббәт тәңресе алдында»лары («Аң», № 20, 1915) бу турыда аерым характерлар, нәкъ М. Хәнәфи чәчмәләре рухындалар.

Бу язучы мәхәббәтне болай тасвирлый:

«Ул – минем күккә оча торган Илаһи серле канатым... Ул – минем рухымны гарше әгъляларга[4] ашыра торган хикмәтле җилкәнем!..»

Менә бу юллар һәммәсе дә ачыктан-ачык тәсаувыф-символизм карашын бирәләр һәм символизм өслүбе белән язылалар.

«Минем җаным, аның җаны белән бергә кушылып, күккә, Тәңремнең пакь, саф, иркен күгенә оча. Минем җаным аның җаны берлә бу мәрхәмәтсез салкын җирдә – кан елгалары, яшь елгалары ага торган куркыныч, йөрәк яргыч җирдә, былчырак, өстен золмәт, тәгассыб[5] каплаган җирдә берләшә алмый... Алар Тәңремнең кодрәт нуры берлә корылган серле тәхете өстендә генә кавыша алалар...» – ди.

[1] Кимия гонсырларын – химик элементларны.
[2] Хәкарәт – хурлык.
[3] Мәҗһүл – билгесез.
[4] Гарше әгъляларга – күкнең иң югары катына.
[5] Тәгассыб – фанатизм.

Шуңар тагын түбәндәге тасвирларны кушып укыйк: «Рух патшасы булган мәхәббәт нуры, аның дулкынланып, диңгезләнеп торган илаһи шәгъләсе[1] бөтен рух галәмен яктырта, тетрәтә... Кояш яктысын үзенә сәҗдә кылдыра ич ул. Аһ... Мин... Мин... хәлсез җариян...»

Нәкыянең бу юллары да аерым изах итеп утыруны сорамыйлар, үз-үзеңнән ачык аңлашылып торалар. Болар да дөнья турында ачыктан-ачык символизм карашын тәлкыйн итәләр[2].

Шул ук татар шагыйрьләреннән Гыйффәттән[3] дә символизмга мисаллар табарга мөмкин.

Шушы мисаллардан инде татар әдәбиятындагы берсе – көнчыгыш тамырыннан, икенчесе көнбатыш-рус әдәбиятындагы тамырдан, ягъни шулар тәэсирендә үсеп чыккан ике канатлы символизмның идеологик һәм өслүб хосусиятләре, шулай ук аларның үсү тарихлары һәм аларның характерлы вәкилләре ачык аңлашылды булырга тиеш.

Шуларга тик бу урында Гали Рәфикый[4], Г. Сөнгати, Ф. Ибраһимов, Ченәкәй, Бабич[5], Исәнбәт[6] кебек язучыларның, шагыйрьләрнең дә кайбер шигырьләре, романтиклыктан узып, символизм тезмәсенә тезелгәнен әйтеп үтәргә кирәк.

Бу өслүбнең «сәнгать – сәнгать өчен» дигән теориясе дә ачык мәйданга куелды. Бу теорияне шул ук «Аң» журналының 1914 елгы

---

[1] Шәгъләсе – ялкыны.

[2] Тәлкыйн итәләр – җиткерәләр.

[3] Гыйффәт Туташ (Заһидә Хөсәен кызы Бурнашева; 1895–1977) – шагыйрә. Әдәби тәнкыйтьтә һәм укучыларда зур кызыксыну уяткан, уртак исем белән чыккан «Гыйффәт Туташ шигырьләре» исемле өч җыентык авторы. Шигырьләренең төп мотивы – татар хатын–кызының катлаулы язмышы. «Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан» (1971) исемле автобиографик китап авторы.

[4] Гали Лотферахман улы Рәфикый (1890–1944) – журналист, язучы, тәрҗемәче. «Шура», «Аң», «Ак юл», «Белем», «Культура революциясе» журналларында, «Вакыт», «Башкортстан», «Яңа авыл» газеталарында мәкаләләре басыла. «Алатау буйларында» (1913), «Вакытлы никах» (1913), «Артык кеше» (1914) һ. б. очерк һәм хикәяләр җыентыклары авторы. И.С. Тургенев, А.И. Куприн әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Урта мәктәпләр өчен рус теле дәреслеге авторы.

[5] Шәехзадә Бабич (Шәехзадә Мөхәммәтзакир улы Бабичев; 1895–1919) – шагыйрь, публицист, җәмәгать эшлеклесе.

[6] Нәкый Исәнбәт (Нәкый Сираҗетдин улы Закиров; 1899–1992) – язучы, фольклорчы, тел белгече, педагог. ТАССР, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1957, 1959), ТАССРның халык язучысы (1986).

1 нче санында Н. Хәлфин[1] күтәреп чыккан булса, аннан соң, югарыда да күреп үткәнебезчә, аны Н. Думави яклады һәм нигезләндерергә тырышты.

Н. Хәлфин үзенең «1913 елда татар шагыйрьләре» дигән мәкаләсендә («Аң», югарыда күрсәтелгән сан), шагыйрьләрне «дөнья гаразы»ннан[2] аерылырга, «күк галәменә» очарга өндәп, болай язды:

«Шагыйрьләребезнең һәркайсы диярлек берәм-берәм нәфис әдәбияттан – гади әдәбиятка, шигырь вә сәнгать почмагыннан дөнья, вәгазь чатына таба күчкәнен күрәсең. Ихтыярлымы, ихтыярсызмы, шагыйрьләребез шигырьгә вә нәфасәткә[3] хезмәтне ташлап, бер мәсләккә, бер фикергә хезмәт итүне артык күрә башладылар».

«Шагыйрьләребез һәркайсы диярлек акрынлап шигырь, ибдаг[4], хыял вә күк галәменнән матбугат, фикер, мәсләк, үгет галәменә күчеп беттеләр».

«Менә безнең шагыйрьләрне һәлак иткән нәрсә шул дөнья гаразына хезмәт итү булды инде».

«Аларның (шагыйрьләрне әйтә) шигырьләре гараздан гали тора алмый; шуның белән бергә, шигырьлек кыйммәтләре дә, табигый, кими. Шагыйрьләр, вак эшләр белән чуалып, үзләре вакланып китәләр».

«Шаяд[5], 1914 ел чын шагыйрьләребезне үз эчләренә вә табигый вазифаларына кайтарыр».

Менә бу – татар әдәбиятындагы символизм һәм аның теориясе тарихында беркетелеп куела торган тарихи төп документ. Моның

[1] Нәҗип Хәлфин (Мөхәммәтнәҗип Латыйф улы Хәлфин; 1886–1938) – сәясәт эшлеклесе, әдәбият тәнкыйтьчесе, тәрҗемәче, географ. «Аң» журналы белән хезмәттәшлек итә. 1917 елгы Февраль революциясеннән соң Мөселманнар комитетын оештыруда, 1 нче һәм 2 нче Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары (1917) эшендә катнаша. 1917 елда Казан губернасы Милли Шурасы башкарма комитеты әгъзасы. Милләт Мәҗлесе депутаты (1917–1918), Идел-Урал штатын гамәлгә кертү һәйәте әгъзасы. 1921 елдан Азәрбайҗан университетында (Баку) фәнни һәм педагогик эштә. Г. Исхакый, Й. Акчура һәм XX йөз башындагы татар әдипләре иҗатына, икътисади географиягә караган хезмәтләр авторы. К.Ф. Фуксның хезмәтләрен татар теленә тәрҗемә итә.

[2] Гаразыннан – теләк-омтылышларыннан.

[3] Нәфәсаткә – гүзәллеккә.

[4] Ибдаг – хыял.

[5] Шаяд – ихтимал.

һәм аннан соң Н. Думавиның бу турыдагы шундый теоретик мәкаләләре тәэсирсез калмадылар. Татар әдәбиятында, 1914 елга керү белән, символизм җәелеп, көч алып китте һәм Февраль революциясенә кадәр шул көчендә дәвам итте. Гомумән, «Аң» журналы шул агымның төп органы булып барды һәм шул агымны көчәйтүгә зур хезмәт күрсәтте.

Билгеле, «Шура» журналы да бу турыда калышмады. Ул да андый рухтагы шигырь һәм хикәяләрне үзенә бик яратып урнаштырды. Дәрдмәнд шул журнал аша күтәрелеп чыкты. Аның артыннан башкаларның шул ук рухтагы шигырьләре һаман басылып торды.

## II. Октябрьдән соң яңа тип символлар

Октябрьдән соң татар әдәбиятында символизм яңадан баш күтәрде һәм кыска бер мөддәт[1] эчендә булса да шаулап алды.

Югарыда да әйткәнебезчә, бу өслүбнең аерым бер өслүб рәвешендә танылуы һәм «символизм» дигән әдәби атаманың татар әдәбият дөньясында мәшһүр булып китүе дә Октябрь революциясеннән соң булды.

Революциядән соң аның беренче вәкиле булып Һади Такташ чыкты. Ләкин, яшь шагыйрьләр арасында байтак кына тәэсир ясый алса да, үзенә күп иярченнәр тудыра алмады. Тиздән сүрелде, сүнде. Социализм җәмгыятендә буржуа һәм вак буржуа өслүбе булган бу өслүбнең яшәве мөмкин түгел иде. Яңа төзелеш һәм пролетариат идеологиясе аның яңадан үсүенә юл бирмәде; идеалистик[2] монизм үзенә үзе кабер хәзерләргә кереште. Бу өслүбнең Октябрьдән соңгы беренче вәкиле булган шагыйрьнең «Такташ үлде» («Безнең юл», № 2 (14), 1923) дигән шигыре ул өслүбнең, яңадан башын күтәрер-күтәрмәстән, үлемгә аяк сузуының бик табигый һәм мәҗбүри бер авазы иде. Дөрес, «үлгән Такташ» урынына «яңадан туу» – иҗат мәйданында «яңа Такташ» булып яңа юнәлеш алу омтылышын башлаган бу шагыйрьдә һаман әүвәлгенең тәэсире,

[1] Мөддәт – вакыт.

[2] Чыганакта «материалистик» дип бирелгән. Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас бүлегендә авторның шәхси архивында саклаган нөсхәдә кулдан «идеалистик» дип төзәтелгән.

психологик шаукымы дәвам итте итүен, ләкин, ничек булганда да, әүвәлге сыйфатта һәм әүвәлге куәтендә үк түгел иде[1].

Хәрби коммунизм чорындагы совет әдәбиятында, бигрәк тә яшь каләмнәрнең шигырьләрендә, гомумән, символчылык көчле генә роль уйнап алды. Ләкин моны дөньяда мәгълүм бер караш нигезендә булган символизм агымы белән бутамаска кирәк. Символизмны тик тәгъбир һәм тасвирда символчылыктан гыйбарәт дип аңлаучылар да булды. Хәтта Такташны да шундый тик символчы шагыйрь генә дип төшенделәр. Андагы символлар, символлы өслүб идеологиядәге идеалистик нигезнең органик төп бер элементы икәнлек искә алынмады.

Моның бер ачык мисалы шагыйрь Кави Нәҗминең[2] Такташ катарыннан[3] үзен үзе символист («символист-имажинист») дип чыгуы булыр («Безнең юл», № 12, 1923). Хәлбуки Кави үзенең символлы шигырьләрендә чагылган идеологик тамыры, дөньяга карашы ягыннан Такташка капма-каршы бер ноктада торды. Кавидә символистлык юк (дөньяга мәгълүм бер караш нигезендәге әдәби бер өслүб мәгънәсе, ягъни «символизм» терминының әдәбияттагы, әдәбият тарихындагы мәгънәсе белән), тик ул символчылыкка гына нык бирелеп алды. Такташта символлар идеалистик идеологияне, шул идеология тәэсирендәге баштан кичерүләрне тасвирда өслүбнең төп алымы, аның органик төп элементы итеп алындылар. Әмма Кавида алар булмады. Анда символлар материалистик идеологияне, реаль вакыйгаларны тәгъбир һәм тасвир өчен васита ителделәр. Аның шигырьләрендә символлар, һәрхәлдә, реаль табигатьтә иделәр, ләкин авыр аңлаешлы символлар булдылар. Кыскасы, Такташның символлары «рух сарае»нда торып сайланды, композиция элементлары шул «сарай» нәрсәләреннән алынды, ә Кави символлары турыннан-туры матди-вакыйгый тормыштан, революция, сугыш хәрәкәте күренешләреннән сайланды, ул шуларны реаль символлар

[1] Бу турыда, гомумән, бу шагыйрьнең идеологик борылышы һәм иҗади революциясе турында тәфсилле анализ белән кызыксынучылар авторның «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты» дигән әсәренә карый алырлар. *(Авт. иск.)*

[2] Кави Нәҗми (Габделкави Һибәтулла улы Нәҗметдинов; 1901–1957) – язучы, җәмәгать эшлеклесе. К. Нәҗминең 1920 еллар шигърияте стиль, образларның үзенчәлеге, яңа шигъри формалар эзләү белән аерылып тора.

[3] Катарыннан – сафыннан.

аркылы тасвир итте. Бу мәгънә белән символчылык исә, гомумән, хәрби коммунизм әдәби өслүбенең төп һәм табигый хосусияте булды. Шагыйрьләр ул вакытта эшче һәм крестьяндагы гомуми хәрби энтузиазмны тулылыгы, киңлеге белән тәгъбир һәм тасвир өчен шундый символлы язуны алга алганнар иде.

Символ, ягъни урыны белән символлы тәгъбир һәм тасвир нәфис әдәбиятта һәрвакыт булгаларга мөмкин. Моны китапның беренче бүлемендә сөйләп үттек.

Мондый символларның да әдәби кыйммәте, әлбәттә, томанлы, төенле булмавында, ачык аңлаешлы символлар була алуындадыр. Хәрби коммунизм чорындагы күп әдәби символлар әнә шул ачык аңлаешлы була алмау, артык томанлы тукылулары белән интектеләр. Хезмәт катлавының әдәбияты булган пролетариат әдәбияты, әлбәттә, андый әдәби символлар белән дус була алмаячак иде.

Һәрхәлдә, Октябрьдән соңгы яшь әдәбияттагы символчылык белән әдәби агым булып алынган символистлык бер-берсе белән чуалтылмаска тиеш. Әдәби символчылыкны һичбер символист булмаган, реаль лирик һәм «акыл-уй» шагыйре булган Туфанда[1], шулай ук аннан башка бик күпләрдә дә күрәбез. Мондый символчылык символизмга капма-каршы һәм аның дошманы, аны җимерүче булып туган футуризмда да бар.

Октябрьдән соң татар әдәбиятында символизмның бердәнбер типлы вәкиле Такташ булганын югарыда әйттек. Ул революциядән соң бу өслүбнең һәм беренче, һәм иң соңгы шагыйре булып калды. Бу өслүбне шаулатып, күтәреп чыгуында аңа, әлбәттә, рус символизм агымының, рус символист шагыйрьләренең тәэсире зур булуда шик юк.

Бу шагыйрь белән башланган «яңа» символизмда символистлыкның декадентлык өлеше дә, төп символистлык та бар. Аны декадент-символист дисәк, дөресрәк булыр. Ул декадентлыктан сүзләрнең үзара шыңгыраулы кушылуларын, артык нечкә тукылуларын алды. Аларның андый кушылуларын да нәкъ шул рәвешчә кушылулары өчен сөйде, һәрнәрсәдән элек ул шуларның шагыйре булды. Асыл символистлыктан янә ул символчылыкны «идея» дөньясын тасвир һәм шагыйрь үзенең «рухи сер»ләрен тәгъбир өчен төп шигъри алым, төп әдәби өслүб итеп кабул кылды. Шуның өстенә

[1] Хәсән Туфан (1900–1981) – татар шагыйре.

икенче буын рус символистлары шикелле үк анда активлык, үзенең фәлсәфи-мистик карашларын, фикерләрен укучыларына җитәкче фикерләр, хисләрен дә алар арасында уртак хисләр итәргә теләвен, аларга ниндидер бер «хыял-җәннәт», реаль булмаган «бәхетле тормыш» төзешергә тырышты, ниндидер бер «сәмави»[1] юаныч эзләде.

«Җир уллары»нда «Иҗадиятем турында» дип язган декларациясе өстенә аның:

Табигать! Кит минем юлларымнан,
Ташла сәнгать коралларың кулларыңнан!
Менә санигъ[2] сиңа! Юл бир миңа!
Төзим җәннәт ташландык ил-кырларыңнан!

рәвешендә «санигъ» булып, үзен «пәйгамбәр» дип («Үтерелгән пәйгамбәр» шигыре) чыгуы шуны күрсәтте.

Такташ («үлгән» Такташ) шаулатырга теләгән агым, шиксез, символизм агымы иде. Бу – Октябрьгәчә рус әдәбияты тәэсирендә дәвам иткән символизмның революция ялкыны астында тагын да нечкә һәм яңарак бер төстә «гыйсъян»чылык рухында кузгалышыннан башка нәрсә түгел. Бу хөкемнең дөреслеген без иң әүвәл Такташ шигырьләренең төп идеологик тамырларын капшап карау аркылы ачык күрәбез. Ул үзенең «Җир уллары» трагедиясе һәм шуңа кушып бастырган башка шигырьләре аркылы тәмамы белән идеалист һәм «рух сарае» шагыйре, «сәмави» җырчы булып мәйданга чыкты:

Мин, җыеп бар зар-фәганны,
Моңлы кылларга салып,
Рух сараеннан сәмави
Сихри бер сорнай алып
Җырларым, –

дип, кулына чынлап та «сихри сорнай» алып моңнарга кереште.

Икенчедән, символистлардагы кебек үк, «ят өннәр», ниндидер «серле сахра» шагыйрьнең илһам чишмәсе булды:

Ниндидер ят өннәр күкрәгемдә
Ишетелә дә тагын тын кала;
Эзлим ул өннәрне, тапмыйм… Кинәт
Тагын бер бәгърем таша, ут ала… <…>

[1] Сәмави – күкнеке.
[2] Санигъ – эшләүче.

Тирән сахра минем барыр юллар
Күчә алмаслык ерак, караңгы… <…>
Җефәк үргән чәчләремне туздырдым да
Шашып төннәр буе йөрим мин урамда.
Очраганнар, әйтегезче, сөйләгезче,
Кайда ул җир, гөл түгелгән серле сахра?...

Өченчедән, шагыйрь – ниндидер «кем»ле, «төнге дус»лы бер шагыйрь:

Кайгы шәлеп ябынып, әй, кем,
Нигә һәркөн киләсең?
Киләсең дә
Төпсез күзләреңне
Еракларга табан тегәсең.
Ни көтәсең аннан?
Син җавапсыз?
Сары гөлләр синең кулыңда,
Үлем йоклап ята юлыңда.
Мин гыйсъянчы менә уңында
Карап торам.
Тынлык…

«Әбәд»[1] үзенең тирән серен саклый:

Кемнәр килер аннан – билгесез;
Әйе, аннан кемнәр килер – белмим.
Әмма монда шундый авыр,
Шундый күңелсез… <…>
Сүнгән күзле минем төнге дустым
Әйт син миңа, җырлый беләмсең?!
Җырлыйсы иде, шашып җырлыйсы иде,
Юкса нинди хәсрәт, күрәмсең. <…>
Бик күп инде, бик күп юлаучылар
Бу җирләргә килеп киттеләр;
Алар:
«Аннан, безнең арттан
Бакчачылар килә!» –
Дип хәбәр иттеләр.
(«Бакчачылар» шигыреннән)

[1] Әбәд – күк.

Дүртенчедән, шагыйрь ниндидер төн, су, урман, таң, җен-пәри кызлары, тәмуг уе, албасты-шайтан туйлары, күләгәләр белән саташа:

Табалмыйм, нидер эзлим кара төндә.
Гүя күңелем кәгъбәсендә мәгъбүдемне[1],
Йоклаганда, пәриләрдән алдырганмын,
Гүя бәхет кошын артта, томаннарда
Бер ялгызын онытып калдырганмын. <…>
Кем ул?.. Аһ! Мин шашам...
Ул... Ул – бер төн кызы;
Исме аның – Галия, ул – бер җен кызы. <...>
Таң сызылгач, җилләр белән бер күләгә,
Төренеп ал гөлләргә, ул килә дә,
Күргәзеп ак мәрмәрдәй кулы белән
Тыныч кына йоклап яткан Галиягә:
– Оныттың! – ди. <...>
Хәтерлимсең, бәхтең эзләп барган чакта
Мәхәббәт сахрасыннан үткән идең.
Сахраның сакчысы мин – Фәйрүзәне,
Антлар биреп, уң битеннән үпкән идең.

Менә монда без шагыйрьнең илаһи мәхәббәт тойгыларының «мәхәббәт сахрасы» тәгъбире астында ифадә ителүен[2] дә күрәбез. Шуны искә төшергәннән соң, мисалларга экскурсия ясауны дәвам иттерик:

Мин уйлаучан, шулай бик күп төннәр буе
Газаплый мине буй кызы, тәмуг уе;
Ә шунда, үч иткәндәй, чүмеч кагып,
Өй алдыннан җырлап үтә шайтан туе.

Менә бу – тәмамы белән символистлар хыялының җимеше, шуларның әдәби композициясе. Шагыйрь тагын ниндидер «таң кызы» – «пәри кызы»на болай дип җырлый:

Пәри кызы, ник чыктың да юлларыма,
Утлы кызыл гөлләр тотып кулларыңа?
Гөлләреңне ыргытып бер елмайдың да,
Ник яшерендең, төренеп таң нурларына? <…>

[1] Мәгъбүдемне – табынган затымны.
[2] Ифадә ителүен – аңлатылуын.

Пәри кызы, ник чыктың да юлларыма,
Тәмуг гөлен тотып нечкә кулларыңа?
Күз аттың да күзләремә, ник ыргыттың
Уйнап-уйнап, мине тәмуг утларына!
Шәүкәт белән таң нурлары арасыннан
Бәхет эзләп, илдән-илгә барган чакта,
Таң кызы, Гөл, ник чыктың юлларыма,
Бәхет гөлен тотып нечкә кулларыңа,
Маңлаемнан үбеп мине ник йокладың,
Тагын кире төренеп таң нурларына? <…>
Таң да атты, ай да батты. Мин кузгалмыйм:
Таң сахирәсен ат өстендә туктап көтәм,
Тагын килер, сөяр, дип, алыр, дип
Хәнҗәрен ул канга баткан күкрәгемнән...

Бу юллар да символизм идеологиясе һәм символизм өслүбе өчен иң характерлы мисаллардан.

Беренчедән, Такташ, М. Хәнәфинең «Кайдан, кайда?»сын һәм башка символист шагыйрьләрнең шундый рухтагы шигырьләрен искә төшерә торган рәвештә «Мәңгелек әкият»ен җырлый:

Шул урманда яшерен бер урында
Ялгыз кабер тора. <…>
Ул – бер җегет кабере. <…>
Ул күп, бик күп уйлап йөргән:
«Адәм кайдан килгән? Тагын да
Кайда китәр?» Ләкин моңар җавап
Табалмаган үзенең аңында.
Шуннан соң ул яшерен урын сайлап,
Кабер казып җиргә күмелгән.
Мескен җегет, кайтам дип киткән,
Кайтмас җирдән – упкын төбеннән… <…>
Син эзләгән яшерен шул серләрне
Мин дә эзлим, җегет,
Тыныч бул!
Син күзләгән төпсез упкыннарны
Мин дә күзлим, җегет,
Тыныч бул!

Шуның белән бергә, үзен «яшь бер пәйгамбәр» дип танучы бу шагыйрь «күккә ашарга», «Гайсә» янына китәргә җилкенүче һәм:

Кил, асраган анам! Үп углыңны!
Гайсә киткән җиргә китәм мин, –

дип юанучы.

Алтынчыдан, рус символистларындагы шикелле үк, анда да ниндидер күктән җиргә – «тар зинданга» төшкән «күк кызлары», «шәфкать нуры», фәрештәләр бар («Күктән сөрелгәннәр» һәм «Газраилләр»енә кара).

Ләкин шунысы бар: Такташта символизм үзенең бик яшерен һәм артык нечкә формасында. Ул турыдан-туры «хак гыйшкы», «илаһи мәхәббәт» белән ялганып әйтми. Ул үзе, Сәгыйть Рәмиләр шикелле үк Аллага дошман, аңа каршы гыйсъян күтәрүче. Ләкин шуның бәрабәренә ул, «рух»чы, «идея» – «сер дөньясы»н тасвирлаучы, фәрештәләргә зур симпатия белән карауче, Тәңренең «мәхәббәт утлары»н игътираф итүче[1]. Ул:

Ник яраттың җиргә, Тәңре,
Син мәхәббәт утларын?!
Ник яраттың канлы күз яшьләр,
Газапларның барын?..
Ник мәхәббәтне яраттың?
Ник яраттың да аны –
Ут итеп, шул ялкын утка
Ташладың ник бәндәне?.. –

дип, фәрештәләр авызыннан «мәхәббәт»нең Алланыкы, аның яраткан илаһи бер нәрсәсе булуын әйттерә.

«Җир уллары» трагедиясе – үзенең тематикасы, сюжеты һәм сайланган каһарманнары ягыннан символизм өчен иң характерлы әсәрләреннән берсе. Монда Аллага каршы гыйсъянчылык бу фикернең дөреслеген бозмый. Моны һәм шагыйрьнең башка шул Аллага каршы булган яки үзен Алла дип тану хисе белән язылган шигырьләре дә – Сәгыйть Рәмиләрнең шул рухтагы шигырьләре шикелле генә бер нәрсәләр.

«Җир уллары»нда Кабил белән Әкълимә һәм Идея – символист бер шагыйрь өчен иң характерлы персонажлар. Монда бигрәк тә

[1] Игътираф итүче – танучы.

ачык рәвештә Кабилдә шагыйрь үзе шәүләләнә. Монда объект белән субьектның тәмам берләшү ноктасы бар. Мәҗнүндә – Фөзүлине, «Хәят»та Дәрдмәндне күрсәк, Кабилдә дә «Җир уллары» иясен ачык күрә алабыз. Шагыйрьнең иң көчле симпатия белән сурәтләндергән тибы – шул Кабил. Кабил монда, Әкълимәгә каратып:

Куркыныч, һәр як караңгы,
Ниндидер өннәр килә? –
Дә улап төннәр буенча
Як-ягыннан ишетелә... –

дигәннән соң, болай җырлый:

Әйдә, бу каргалган илдән
Без сәгадәткә таба
Юл салыйк, очыйк икәү
Иркен хәятлы дөньяга!..
Кайда юк Алла, канун
Һәм эч пошу, хәсрәт, көек.
Кайда без иркен яшәрбез,
Хөр, азат җилләр кебек...
Шуларга тагын Кабилнең Һабилне үтергәч:
Алда упкын... Артта ут...
Уңда Һабилнең гәүдәсе...
Кайда юл?... Кайда сәмави яктылык
Берлә янган идеалымның
Сихерле шәүләсе?!. –

дип моңаеп, фәрештәләрнең Әкълимәне күккә күккә алып китүләрен, монда Әкълимә һәм фәрештәләрнең җырларын, Кабилнең аларга җавапларын нык искә алырга тиешбез.

Шагыйрь – бу трагедиясендә «революция»че, «гыйсьян»чы. Ләкин матди тормыш өчен түгел, «мәгънә» дөньясы, «мәгънә дөнья»сындагы азатлык өчен булган бер гыйсьянчылык. Бу исә символистлыкка чит бер сыйфат түгел.

Кыскасы, Такташ, бигрәк тә «үлгән Такташ» шигырьләре һәм шулар аркылы күренгән әдәби өслүб күп ягы белән символизм өслүбенең нәкъ үзе булды. Гомумән, символизм агымындагы хосусиятләрнең бу шагыйрьнең әүвәлге елларында язган һәм бастырган күп шигырьләре үзләрендә ачык күрсәтәләр.

Шагыйрьнең беренче һәм сәнгатьчә иң көчле әсәрләре булган «Бакчачылар», «Урман кызы», «Нәләт», «Онытылган ант», «Таң кызы», «Күләгәләр», «Эшлиләр», «Күктән сөрелгәннәр», «Газраиллар», «Мәңгелек әкият», «Янар таулар» һәм башкалар әнә шундый шигырьләреннән иде.

Бу шигырьләрнең исемнәре үк символизм шигырьләре икәнен күрсәтеп торалар. Боларда шагыйрьнең караңгы, чуалчык булган «халәте рухиясе», ләкин «гыйсъян»чылык-»бунтарь»лык куәте белән ташкан өермәле-давыллы хисләре, томанлы кәефләре төенле, бикле «сәмави» символларга төренәләр. Күләгәләнү, фикер, хисләрне тәгъбир һәм тасвир өчен төрле нечкә символлар эзләү, үз эченә чуму, «сер»гә бату, «рух сарае»на омтылу, «сихри»лек, «ят өннәр»не тыңлау, «тирән серле сахра»ларда гизенү, җен-пәриләр, җен кызлары, «шайтан туе», караңгы юлларда адашу, фәрештә, идея һәм күләгәләр-шәүләләр, тагын шуңа охшаш башкалар – аның өслүбендә төп композиция элементлары. Шуларга соңгы әсәрләрендәге җил, давыл, төш, ут һәм башкаларны кушарга кирәк. Ахырда шуларның һәммәсенә килеп чиктән тыш бер моң-аһәң, музыкачылык, иҗтимагый тормыш теләкләре, гамәли максатлар белән һич чикләнмәгән тәмам ирекле сәнгатьче булу, сәнгатькә, тик сәнгатькә генә табынучылык һәм индивидуализм кебек хосусиятләр кушыла. Такташ гүя ул Октябрьдән соң татар дөньясында Брюсовның югарыда әйтелгән өч маддәлек васыятен үтәүче «яшь шагыйрь» булып мәйданга атылган иде.

Рус әдәбиятындагы шикелле, татар әдәбиятында да символизм өслүбе (аеруча Дәрдмәнд белән Такташ шигырьләре) шигъри теленең аһәңен, музыкавильлеген арттыруда зур тәэсир күрсәтте. Бу – символизм өслүбе[нең] иҗаби[1] ягы булып, шигырь теленә карата күзгә ачык ташланган хезмәтләреннән санала.

Татар әдәбиятында символизмның туу һәм үсү тарихы әнә шул югарыда язылганча булды. 1925 елгача шул өслүб үзен яшәтергә тырышып килде. Аннан соң ул әдәби бер өслүб булу сыйфаты белән мәйданнан тәмам югалды, бетте.

Фәкать кайбер шагыйрьләрдә (шуларда эченнән Такташның үзендә дә) революциядән соң яңа һәм нечкәргән рәвешендә вак буржуа интеллигенциясе тарафыннан кайтадан баш күтәрергә

[1] Иҗаби – уңай, уңышлы.

итеп караган бу реакцион әдәби өслүбнең тәэсирләре дәвам кылды. Совет әдәбиятындагы мондый буржуа тәэсиренә каршы көрәшне тагын да кискенләштерергә тиешбез. Моның өчен дә, билгеле, иң әүвәл диалектик материализм иҗат методын, пролетариат әдәбиятының тудырып үсеп яткан үз әдәби өслүбен (диалектик материализм өслүбен), аның бөтен сыйнфый практикасы һәм теориясе белән өйрәнүне тирәнәйтүебез кирәк. Шуның белән бергә, икенче яктан, совет әдәбиятында буржуа әдәби өслүбләренең тәэсирләренә каршы уңышлы көрәшү өчен, буржуа өслүбләрен, аларның төп хосусиятләрен яхшы белеп алган булуыбыз да күп ярдәм итәчәк.

Октябрьдән соң рус әдәбияты тәэсирендәге символизм СССР-дагы башка төрк халыклары әдәбиятларында да баш күтәреп алган иде. Казакта бу өслүбнең беренче вәкиле милләтче Мәгъҗан Җомабаев булды. Үзбәктә исә шул өслүб аркылы әдәбиятта советка, пролетариат диктатурасына каршы көрәшеп азапланучыларның башлыкларыннан шул ук милләтче-символист Чулпан (Габделхәмид Сөләйман)[1] булып килде. Болар икесе дә соң дәрәҗәдә милләтче шагыйрьләр иде. Боларда символизм идеологиясе һәм аның символлары «милли тойгылар» белән аралашты.

Такташ исә бу ноктада алардан аерыла: анда без милли тойгыларны, бер дә булмаса, тегеләрдәге дәрәҗәсендә милли тәгассыб, милли шовинизмны сизмибез.

Ләкин символистлыкта бу өч шагыйрь өчесе дә бертуганнар иде. Бигрәк тә Такташ белән Мәгъҗан арасында күп яктан бер-берсенә якынлык, охшашлык бар. Икесе дә – чиктән тыш индивидуалистлар һәм «пәйгамбәр»лек дәгъва итүчеләр. Икесендә дә рус символистларының тәэсире бик зур.

Такташ «мин киләм» дип чыккан булса, Мәгъҗан Җомабаев та:

Мин киләмен, мин киләмен, мин киләм.
Көннән туган, говеннән туган пәйгамбәр, –

дип чыкты.

Мәгъҗан Җумаваевның бөтен шигыре диярлек символизмга мисал була ала. Шулар эченнән дә иң характерлы булганнары түбәндәгеләр: «Төш», «Җиләнде кара урман», «Кышкы җулда», «Җазгы

[1] Чулпан (Габделхәмид Сөләйман углы Юнысов; 1897–1938) – үзбәк шагыйре, язучы, драматург һәм публицист. Яңа үзбәк әдәбиятына нигез салучыларның берсе.

җулда», «Саулә», «Гөлсемгә», «Болбол», «Җан җарымды бер сөяем төшемдә», «Тилердем», «Җан суры», «Караңгылык куеланып киләде», «Александр Блок», «Алдамчы үмер», «Аял», «Төн иде», «Баткан көн, аткан таңның йыры», «Җазды көне калада» һәм «Айда атынды Сарсәмбай», «Чын айт», «Урал», «Ут», «Мин кем?», «Җумбак», «Бустандык», «Бөгенге көн – үмер, үлем – минеке», «Серем», «Үмер», «Караңгы давылды төн», «Үләң» һәм башкалар.

Мәгъҗан Җомабаев шигырьләрендә дә, башка символистлардагы шикелле үк, төш, шәүлә (күләгә – символ), йокы, Алла, пәйгамбәр, пәри, җен, фәрештә, тылсым, сер, хыял, әфсен, җил, ут, көн, нур, ай, төн, таң, чүл, былбыл һәм башка шуңа охшаш нәрсәләр – иң сөелеп йөртелә торган төп композиция элементлары. Бу шагыйрьчә, кыш та, яз да – табигатьтәге бөтен нәрсә төш күрә.

Җомабаев та – Такташ шикелле үк декадент-символист. Ләкин бу шагыйрьгә Александр Блок күбрәк һәм ныграк тәэсир ясаган күренә.

* * *

Рус символистлары шикелле үк, татар символистларының да берничәсе революция тәэсирендә һәм шуның тәэсирендә әүвәлге юлларын – символистлыкларын ташлап, революция таләпләренә кушылды һәм пролитариат өчен яза башладылар. М. Гафури, Такташ һәм башкалар шундый юлны алдылар. Әмма Дәрдмәнд, Думави, шулай ук С. Рәми кебекләр әүвәлге юнәлешләрендә катып калдылар. Дәрдмәнд исә пролитариат революциясендә үз сыйныфының, ягъни буржуазиянең җиңелүләрен күрү белән үк:

Җиһан тормыш туен иткән чагында,
Синең урының үлекләр аймагында, –

дип, терек булганы хәлдә, тизрәк үлекләр «аймагына» ташланды.

Думави бөтенләй тавыш-тын чыгармас булды. Сәгыйть Рәми дә үзенең символистлык юлында җиргә керде.

Татар әдәбиятында да символизмның хезмәте, иҗаби[1] ягы әдәби телнең матурлану, шомару, аһәңләнү юлында күрсәткән тәэсире булды. Кирәк тезмә, кирәк чәчмәдә булсын байтак яңалыклар тудырды, искене ватышты, яңа, ирекле вәзеннәргә юл салышты. Бу ике мирасның файдалы ягы хәзерге көндә дә әнә шул ягы булыр.

*1932*

[1] Иҗаби – уңышлы, уңай.

## ТЕКСТЛАРНЫ ГАМӘЛДӘГЕ ЯЗУГА КҮЧЕРҮЧЕЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘҮЧЕЛӘР

*Гарипова Л.Ш.* – филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

*Гыйлемшин Ф.Ф.* – филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре.

*Заһидуллина Д.Ф.* – филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

*Надыршина Л.Р.* – филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Ханнанова Г.М.* – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге фәнни хезмәткәре.

*Хәсәнова А.Н.* – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фәнни хезмәткәре.

# ЭЧТӘЛЕК

Габдрахман Сәгъди һәм аның хезмәтләре . . . . . . . . . . . . . 5

Тел вә әдәбият мәсьәләсендә файдалы агым . . . . . . . . . . . . 15

Татар театр әдәбияты һәм аның үсү тарихы . . . . . . . . . . . 34

Фатих Әмирхан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 89

Бездә әдәби тәнкыйть (Октябрьнең ун еллыгына) . . . . . . . . 106

Символизм турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126

Текстларны гамәлдәге язуга күчерүчеләр
һәм шәрехләүчеләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 254

**Габдрахман Сагди**

**ИЗБРАННЫЕ СОЧИНЕНИЯ**

**Том 1**

**Духовное наследие: поиски и открытия**

Выпуск 22

(На татарском языке)

Редактор А. А. Давлетова
Компьютерная верстка Н. Т. Абдуллиной
Дизайн обложки К.В. Кормушина

Подписано в печать: 07.11.2024.
Бумага офсетная. Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс».
Усл.-печ. л. 14,9. Уч-изд. л. 13. Тираж 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20